# казан утлары

12

ДЕКАБРЬ-1975

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**12**

ДЕКАБРЬ
1975


## Бу санда


**Х. ТУФАН.** Ә яшибез әле. Шигырьләр . . . . . 3
**Ә. ГАФФАР.** Теге гозер... Повесть . . . . . . 9
**Ф. САФИН.** Кичегү. Шигырьләр . . . . . . . 38
**Н. ӘМИНОВА.** Илдә давыллар басылган. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 42
**В. НУРУЛЛИН.** Яшьнәп үткән яшьлек. Повесть . . 44

ДУСЛАР ИҖАТЫ

**Т. ӘЙДИ.** Моң һәм нәфрәт парчалары . . . . 98
**И. МӨХЛИСЕВ.** Кашгар дәфтәре хатирәләреннән новеллалар . . . . . . . . . . . . . . 99

ПАРТИЯНЕҢ XXV СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 107
**М. МАЛИКОВА.** Мең дә бер сынау . . . . . 110

ГАЗИЗ ИДЕЛЛЕГӘ 70 ЯШЬ

Хезмәт шатлыгы . . . . . . . . . . . . . 118
**Г. ИДЕЛЛЕ.** Беренче остазым . . . . . . . . 119

СӘНГАТЬ

**Ч. БӘХТИЯРОВА.** Казан консерваториясенә 30 ел. 123
**И. ИЛЯЛОВА.** Актер осталыгы . . . . . . . . 128

Г. ТУКАЙНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

**Ә. ФӘЙЗИ.** Тукай һәм рус әдәбияты . . . . . 136

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

**Ф. ӘГЪЗӘМОВ.** Социалистик реализм әдәбиятының нигез ташы . . . . . . . . . . . . . 140
**Ф. МУСИН.** Әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтьтә стиль мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . 147

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. ГАЛИМУЛЛИН.** Әдәбият хәзинәсе . . . . . 156
**Ф. ГАНИЕВА.** Заман темасын заманча чишик . . 158



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ИСТӘЛЕКЛӘР

**Г. КАЙБИЦКАЯ.** Якты йолдыз белән якәшә . . . 164

ТӨРЛЕСЕННӘН

**С. ЛАТЫЙПОВА.** Идел буе халыклары һәм декабристлар хәрәкәте . . . . . . . . . 168
**С. МӘҮЛЕНОВ.** Җырлы Казан . . . . . . . . . 172

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**Ф. ХӨСНИ.** Икесе дә гаепле. Хикәя . . . . . 179

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 182

1975 елда журнал битләрендә басылган әсәрләр. 184

**БАТУ МУЛЮКОВ** музыкасы, **З. НУРИ** шигыре. КамАЗ-батыр . . . . . . . . . . . . . . 191

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/IX-1975 ел. Басарга кул куелды 4/XI-1975 ел. ПФ 07432. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90.000 экз. Заказ Я-358. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1975 ел.

## Хәсән Туфан

### Ә яшибез әле

Иң эчкәре ниятләрен Илнең
Укыйлар да күңел күзләрең,
Канатлы җыр булып очып, Хәким,
Ил түренә куна сүзләрең.

Кол Галидән бирле шулай инде,
Шагыйрь җаны — ачык, әшкарә:
Боерганны гына түгел шигырь,
Боермаганны да башкара!..

«Эшләр инде кими төшәр...» димә,
Тынармындыр...» димә, туганым:
Безнең юлның — данлы, данлы юлның
Тына торган чагы юк аның...

Ә яшибез әле, ә яшибез,
Син әле — нәкъ Такташ — нинди яшь! —
Оныкларың — бабай... дисәләр дә,
Син бит миңа — һаман энекәш!

Кол Галидән бирле — юл бер генә,
«Дин» бер генә — ачык, әшкарә:
Боерганны гына түгел шигырь,
Боермаганны да башкара...

### Язып куй тарихка

Сөямләп үлчәтте элгәре
Бәхетне, уңышны бу дөнья.
Кайда син,
Элекке — бизмәнле,
Мыскаллы, кадаклы губерна!?.

Яз, Заман,
Язып куй тарихка.
Бер миллиард тонналы табышны! —
Безнең бу — титаник ярышта
Иң алгы сызыкта барышны.

Остардың, нефтяник туганым,
Жиңәргә, үсәргә остардың:
Хәерле сәгатьтә башлансын
Икенче миллиардка стартың!

О, ничек күңелле Союзда
Беренче урында барулар.
— Әссәлам! Сезгә яшь Әлмәттән,
Нефтьнең классигы Бакулар!

## Ахыргача

Чишендереп җанны барлады да,
«Языгымны» язмыш... яндырды.
Тик инану мине, ленинчылар,
Сезгә иман исән калдырды.

Әйт син, йөрәк, үтә интим серне,
Әйтеп куй син исән көнеңдә —
Синең әле үзең үлгәч тә бит
Яшисең бар бераз шигырьдә:

Ахыргача, коммунистик дөнья,
Синеке мин, фәкать синеке! —
Җаным белән мәңге большевик мин,
Булмаса да миндә билеты.

Фикерем-хисем, шигъри эшем минем
Синең юлың белән бертуган.
Беркайчан да, беркайчан да сине
Көендермәм, Илем, борчымам.

## Юл авыр булган саен

*Сәфәрдәге юлдашларга*

Татарча әйтсәң генәдер
Чамалап була аны:
— Сездә дә бардыр гомернең
Җиде төн урталары.

Болытсыз төннәр түрендә
Сез — Тимерказык сыман! —
Мин сезгә багып-чамалап
Азимут язып куям.

Уятып, уйландырып сез
Кәрванны, туганнарым,
Яктырак яна барасыз
Юл авыр булган саен!..

Син тауларга,
Уйланырга киттең...
Сизде күңел, сизде шул чакта:
Нинди тирән бушлык туар иде
Син булмасаң әгәр хәятта.

Синең гамьнәр — шәхси, вак гамь түгел,
Алар өлкән, олы киң гамьнәр:
Ил күңеленнән илче булып килгән
Пәйгамбәр син, гүя пәйгамбәр.

Сөен генә — рухи тәрәзәңә
Имансызлар кырын караса,
Көен, кайгыр — әгәр илсезләр дә,
Денсезләр дә мактый башласа.

Син тауларга,
Уйланырга киткәч,
Сискәндем мин карап һәр якка:
Коточарлык вакуум туар иде,
Син булмасаң әгәр безнең шигъри,
Безнең фикри, рухи хәятта.

## Үзе гүзәл, үзе усал

*(Рифә Райханова)*

Салкын карга басып Алсу килә...

*Такташ.*

Аклар аскан Миңлегөлләр,
Байлар сүйгән Бибиләр,
Давылларда туган кызлар
Нәкъ шушындый иделәр.

Әле дә лә бу Казанда
Бар икән бит асыллар,
Үзе гүзәл, үзе усал,
Үзе изге Алсулар.

Бу ничек соң болай инде,
Нишләвең бу, кыз бала? —
Бу заманда мондый гадәт
Юк бугай бит дөньяда.

Нәкъ җәядәй тартыла да,
Киерелә дә кашларың,
Һәр нахалны телсез итә
Бер сүз әйтеп ташлавың.

Өсләреңдә ситсы күлмәк,
Аягыңда күн итек.
Башына бас юхаларның
Нәкъ апаңнар күк итеп.

Син микәнни илкәеңнең
Алсу сыман чибәре,
И гүзәлем, и усалым,
И лә изгем дигәне.

Таҗлар киеп килгән кебек
Бәхетләрең каршына,
Үр дә шушы чәчләреңне
Урап җибәр башыңа.

Ки дә, Рифә, тәңкәлесен,
Чәмчәлесен киемнең,
Ямьләндереп җибәр әйдә
Бәйрәмнәрен илеңнең!

Нигә сиңа ни кисәң дә,
Ни дисәң дә килешә —
Син яңадан тергезелгән
Миңлегөлме, югыйсә?!.

## Ямалган яра эзләре

Бу аның соңгы көнедер,
Ахыргы сәгатедер,
Сүзенең сәер булуы —
Саташу халәтедер.

Авырулар яткан баракның,
Сарайның түрендәрәк,
Татарча җырлап куя ул,
Немецча сүгенгәләп.

Мөгаен, ярсып сугышкан:
Таныррлык түгел йөзе.
Битенең һәрбер сырында
Ямалган яра эзе...

Кемгәдер әйтә саташып,
Үз күреп, туган итеп,
Икесе бер үк сагышны
Кичергән сыман итеп:

«И... тагын безнең арага
Хәл белеп килдеңмени?..
Иңеңдә, майор, синең дә
Штатный киеммени?..»

«И, ничек ваттык тегенең
Чуенлы коймаларын! —
Зигфридның тимер-бетонлы,
Сихерле зоналарын...»

«Ә... безнең поход, генерал,
Эльбада туктамаса,
Ярсыган корпусларыңны
Уздырып Боннар аша,

Атнада җитәчәк идек
Пиреней тауларына,
Азатлык илтәчәк идек
Атлантик ярларына,
Асачак идек Тегене
Лиссабон тауларына...»

Ишектән — җилдән арырак,
Сарайның түрендәрәк,
Җырлый да елап куя ул,
Немецча сүгенгәләп.

Бу инде соңгы төненең
Ахыргы сәгатедер:
Сүзенең сәер булуы —
Җан бирү халәтедер.

«Өстеңдә инде синең дә
Ямаулы киеммени?..
Сырхаулар сараена син
Хәл белә килдеңмени?..»

Солдатың башын тагын бер
Сыйпа син, сыйпа, сыйпа...
Күзеңдә — яшьләр, генерал —
Ни булды бүген сиңа?..»

Кычкырып куйды санитар,
Йөрәген тыңлап аның:
«Бирмә син, йөрәк, үлемгә,
Бирмә лә солдат җанын!»

Әйтерсең соңгы сулышта
Нигәдер үкенгәләп,
Җырлый да елап куя ул,
Немецча сүгенгәләп.

●

...Сөйләдең... бу синең
Ышану идедер.
Кайгыңнан яртылаш
Бушану идедер.

Салланды — авырайды
Йөрәгем ничектер. —
Синдәге сагышлар
Миңа да күчептер...

Бу авыр йөрәкне
Үзеңә алып тор! —
Өф-өф ит:
— Авыртты,
Авырта,
Авыртыр...

## Туган ил—алтын

*Жыр*

Юл ташларына
Яфрак коела.
Кыр казы күлдән
Юлга җыена.
Киткән кошларга
Адреслар бирсәм,
Казан өстеннән
Очарлар микән?!.

И нурлы Казан,
Син — илем түсе,
Синең ташларда
Тарихлар эзе.
Синең утларың —
Күңел нурларың
Яктырта безнең
Гомер юлларын.

Алсу Алтайда,
Зәңгәр Байкалда,
Истә син, Казан,
Истә һәркайда.
Еракта да син
Йөрәккә якын:
Торган җир — көмеш,
Туган ил — алтын!

## Дөнья бу

«Ни генә күрми хатын-кыз!..»
Дигәли идек элек.
Бу гәпнең инде, кызыйлар,
Кызыгы бетте кебек.

Без теге — иске караштан
Инде бит шактый ерак:
«Баш» түгел, «муен» булырга
Өйрәнә инде ир-ат!

Әнә бит — Дөнья дигәнең
Нишләтте безне, җаным:
Ни генә кылмый да инде,
Ни генә нитми хатын.

Мактый да сезне, кызыйлар,
Яклый да инде китап.
Бездә бит сиңа «брат» дип,
Яраша инде ир-ат.

## Әхәт Гаффар

# ТЕГЕ ГОЗЕР...

ПОВЕСТЬ



Әкрен генә уянган бер таңны Җиһангир картның сыеры үлеп китте.

Декабрь урталары иде.

Сыер чирләп-нитеп тормады. Әле кичә генә карчыгы Сөмбел ярты чиләк күпереп, чыжлап торган сөтен савып керде. Оныгы Солтан, идәндәге чиләк алдына тезләнеп, борын очын күбеккә буйый-буйый, туйганчы шул сөтне эчте.

Җиһангир картның бүген-иртәгә бәрәнләргә торган сарыгы бар иде. Шуңа күз-колак салырга дип, абзарга чыгып кермәкче булды. Иңбашына тунын элә-элә, болдыр баскычыннан төште. Күз иялəшер-иялəшмәс кенә булып җиргә иңә башлаган яктылыктан ул таң атуын тойды.

Карт бу арада начар йоклый иде. Әүвәл моның сәбәбен аныклап маташмады. Һәр елны диярлек кыш кергәндә бер авырып ала торган гадәте булганга, шуның зәхмәте уяна торгандыр дип уйлады, илтифат итмәде. Аннары гына ул күкрәгенең хаста сызлануы белән түгел, бик тә таныш бер борчылу белән тулуын сизенде. Инде ноябрь узган, декабрьның икенче атнасы түгәрәкләнеп килә, ә туфрак исе, озак сырхаулаган кешедән авыру исе тиз чыкмаган кебек, җир өстеннән җилләр булып очасы итмәде — кыш кыстатып килде. Бер-ике мәртәбә җилләп-җилләп кар тузгыса да, ятып калганы кояшта эремичә, җиргә сеңмичә генә юк булды. Ужымнар, уңган чәч шикелле, тузан төсенә керде. Салкын аларның тамырларын өшетмәсә дә, кыякларын куырды, ужым тере нурын җуйды.

Күз күреме иңләрлек җирнең өметсез бушлык белән тулу галәмәтеннән Җиһангир картның кыска гомерле сырхавы быел эч пошу булып кына аваз салды.

Җиргә кыш кирәк иде.

Сарыгын карарга чыккан карт җирнең яңа бер ис белән сулый башлаганын тойды. Таң атып килә. Ә ул таң белән бергә җиргә кыш якынлаша иде. Җилсез-тынсыз июнь көнендә биек-биекләргә күтәрелеп очкан, аннан җиргә кунган тупыл мамыклары шикелле, тыныч кына, әкрен генә кар ява иде.

— Кар ява! — дип пышылдады карт.

«Бәрәнләр болай булгач. Кемнеңдер, нәрсәнеңдер беренче кышы булырга кирәктер ич?» — дип уйлады ул.

— Бәрәкәте белән булсын!..

Авыз эченнән генә әйтмәкче иде — тавышы гөлдерәп чыкты. Дөньясын тутырып килгән куанычын тыя алмады. Ул иңбашларын калтыратып, муенын җыерып куйды. Салам белән ябылган әвеслеккә үтте. Капшанып электр утын кабызып җибәрде.

Күз чагылдырып лампочка балкыды. Җиһангир картның озын гәүдәсеннән күләгә сузылды. Күләгә әвеслек бушлыгын караңгы почмакларга, түбә кыегы астына, сыер утлыгы артына, такта ярыкларына куып кертте, әвеслеккә җан өрде.

«Күләгәсе булмаса, кеше нишләр иде икән? — дип уйлады карт.— Ялгыз кеше кояш белән яктылык барында күләгәсен иптәш итә. Коры куаныч. Алай да куанычның булуы шәп».

Ул, башына килгән уен кемгә дә булса әйтәсе килеп: «Әйеме, малкай!» дип, сыерына эндәшмәкче иде дә абзар ишегенә таба атлаган җиреннән туктап калды. Әвеслек эче гадәттәгечә түгел, ничектер үзгәргән кебек тоелды. Сулышын тыеп, уе белән артка, күләгәсе ягына текәлде. Әле борылмас борын сыерының суламаганын ишетеп алды. Утлык артына карады. Сыерының сулаганы күренмәде. Аның борынынан бөркелеп чыгарга тиешле аксыл сулыш буы утлык рәшәткәләре арасыннан күтәрелми иде.

«Күршедә җан иясе булмаса, кеше күләгә белән генә нишләсен?»

Әллә җиргә басып тора, әллә, суда йөзгәндәгедәй, тәне бушлыкта калган кебек иде — ул ничек басып торырга, нигә таянырга белми катып калды, теленә сүз, башына уй кермәде. Күзе утлыктагы суы каткан яньчек чиләккә текәлде. Нишләрен белмичә, суны өйгә кертеп эретү уе белән чиләккә иелде, йон төшкән дип, болганчык бозга кулын сузган иде — кире тартып алды: сулы чиләккә тычкан төшеп, бозга катып калган иде.

«Каткан эре-ер, җан иясенең үлгәне терелми шул»,— дип уйлады карт.

Җиһангир картның тәрбияле кыз кебек сабыр холыклы көрән сыеры әнә шулай көтмәгәндә-уйламаганда үлде дә китте. Сарыгы бәрәнләр дип көткән иде, югыйсә.

Аныcы бәрәнләмәгән булып чыкты.

Иренен дерелдәтеп кенә йоклап яткан Сөмбелен уятырга ниятләгән иде дә борчырга базмады. Ятты, күзен йоммады. Шөпшә кебек тигез генә зыңлап, йөрәк астына борчу инде.

— Бәла-каза алдан хәбәр салып килми шул,— дип көрсенде.

Сөмбеле уянганга хәтле, җыйган акчасын уенда кат-кат санады, сыер сатасы кеше белән сатулашып, быелгы елны мал бәясен төшерердәй сәбәпләрне барлап чыкты.

Мал врачы Мөҗип килеп, күршесе Зәкәрия җыеп кергән ир-ат белән ындырга сөйрәп чыгарылган сыерның суынган йөрәгеннән күгәрек әнә табып алганчы, күңел кесәсендә андый сәбәпләр байтак җыйналды. Ул арада эңгер-меңгер төште. Шул хәтле дә тере булып ялтыраган күз агын тимгел-тимгел кызыл тап баскан коңгырт күзле сыерны үләксә киртәсендәге тирән базга илтеп ташладылар.

Өйалдындагы озын такта өстәлдә туң сөтле яшел чиләк кенә, гаҗәпсенгәндәй итеп, түшәмгә текәлеп калды. Җиһангир карт сатлык сыер эзләп алты көн йөргән арада ул чиләккә кул тидермәделәр. Карт алты авылга барып кайтса да, күзе һәм күңеле төшәрдәй сыер очрата алмады. Колхоз председателе Шаехне тыңлыйсы булган икән дип, йөрүенең бушка китүенә үкенә башлады. Сыер сатып алу ниятен карт кичектереп тормакчы булган иде, мартларны көтмичә бүтән әмәле барлыгына өмет итми дә башлаган иде инде. Юкса бит, председательнең әйткәннәре, учка-уч тәңгәл килгәндәй, раска чыга: ничә ай ашат-

кач сыерны сатып җибәрү — ач булып та пешкән тавыкның яртысын ашау, яртысын ташлау белән бер ич.

Сыеры үлгәннең өченче көнендә иртүк ул колхоз идарәсенә кергән иде.

— Сыер үлде, Шәех олан.

— Ишеттек,— диде Шәех, чем-кара мыегын аска таба сыпырды.

— Страхавае бик аз тиде: взносын җәллэп керткән идем лә, каһәр! Алтындай сыерга тулар-тулмас өч йөз тәңкә...

— Ишеттек,— диде Шәех. Урыныннан торып, ялтыраулы шкафыннан тире эчле пальтосын алып киде, кесәсеннән борыңгы тишек акча тагылган ачкыч чыгарды.

— Өй сиплэтергә җыйган акчам бар,— диде карт, председательнең ашыгуын ошатмыйча.— Колхоз җүнле генә бирәр сыер сата алмас микән? Бәясеннән тормас идем. Аннары соң ат-арбаларыгыз юклыгын да беләм, авырыксынмам, җәйгә таба биш-алтыны ясап бирермен. Юк бит алар, таба алмый интегәсез.

Шәех мыек очын теле белән элэктереп иренена капты да кигән бүреген салып өстәлгә куйды.

— Утыр әле, Җиһангир абзый. Ялгыш сүз әйтермен дә, гаеп итәрсең я.

— Сүзнең ялгышы түгел, явызы гаеп. Әйт.

— Синең арбага калганмы! Сыер, сыер... Андый-мондый гына ярамый, җүнлесе...— диде председатель. Аның пальто төймәләрен әле ычкындырып, әле төймәләп торуын карт зур өмет белән күзәтте.

— Булмас, кәҗә генәмени, сыер ич!

— Бәлки мартларга хәтле түзәрсең? Ел ахыры, сөт кими, һәр тамчысы — зәмзәм суы, санаулы. Мартларга җае чыгар. Сүзем ир сүзе,— диде Шәех.

Ул, бүтән әйтер сүзе юклыгын белдерәсе килеп, бүреген киде.

— Сүзеңә рәхмәт,— диде Җиһангир карт.— Тик бигайбә, яме, көтә алмыйм аңынчы. Аю түгел ич мин, кышны ничек йоклап уздырмак кирәк. Печәне нинди быел, печәне! Үзең ашарлык. Бигайбә, энем, сыер бит ул йорт җаны. Көтә алмыйм мартыңны.

— Күрше-күләннән бер-ике чынаяк сөт тапмас идегезме?

— Картлыкта көтеп яшәү — бетеп яшәү. Безнең көткән бер генә — гүр.

— Хуш иттек соң,— диде председатель, аңа кулын бирде. Кулының картның җылы, йомшак учында кеп-кечкенә булып калуына уеннан гаҗәпләнде.— Сабырсыз сез, агалар, балалар шикелле.

— Шулай шул. Ул сыер безнең өчен уенчык кына ла кана. Эшсез торып, кулларга үрмәкүч пәрәвез үрсенмени?

Идарәдән өенә кайтышлый ике җирдә сыер мөгрәгәнен ишетте. «Кысыр калдыргannар. Җаның кысыр булса, мал да кысыр шул»,— дип уйлады. Баганаларга әллә ничә сатлык сыер бәйләгән Зюзино базары күз алдына килде. Уе белән шул сыерларны карап йөрде, читкәрәк китеп сынады, яшьләрен чамалап мөгезләрендәге сырларын санады. Кызылын да, аклы-каралысын да, карасын да ошатмады, көл төсендәгесен, буазлыгы торыш-кыяфәтеннән үк тәгаен билгелесен сайлады, кыйммәтсенеп сатулашмады, күпме сорасалар шуны бирде. Үзләренең капка төбенә җитеп исенә килгәндә ул бәягә өендәге акчасы җитмәвен хәтеренә алды, сыер очрап акчасы җитми калуына чынлап аяна язды. Күз алдына килгән күренеш председатель Шәех вәгъдәсен тузан урынына өреп тузгытты.

— Сыер кирәк,— диде карт үз-үзенә.— Оныкка сөт кирәк.

Һәм бүген жиденче көн инде, шушы сүзен юлдаш итеп, жиденче авылга, бу юлы Җәмәлҗәнгә чыгып китте.

Беренче өч көнне күрше авылларга үзе белән оныгын алып йөрде. Сыер кауларга кулына киндерәдән ишкән чыбыркы тоттырды. Укуы озак кала дип бүтән иярмәде. Калган ике көндә Сөмбелен алды. Икенче көн инде сәфәренә карт ялгызы гына чыгып китте.

Сыер сатарга ниятләгән кешеләр ул барган авылларның һәммәсендә бар иде. Тик күңеле теләгән малны очратмады. Бер тана тәкъдим иттеләр — иялəштерергә көче җитмәс кебек тоелды. Бүтән берәү сыерын кысыр калганга сата иде. Карт, кысыр мал алу — көмәнле кәләш төшерү кебегрәк мәгънәсез булыр дип, арзан булса да кызыкмады. Тагын берсенеке чәйнәп биргәнне дә йота алмас дип куркырлык карт булып чыкты. Аннан тагын кайсысының сөте аз иде, кайсына артык күп сорадылар.

Җиһангир карт һәр көнне буш кул белән кайтканы өчен Сөмбеленнән уңайсызланды. Сыер урыны да, кортлары ташлап чыккан умарта оясы шикелле, салкын бушлыгы белән җанын көйдереп торды. Оныгы да бабасын җәлли. Ул кайтып керүгә, биленә бугай баугa күз ташлый, бауның эзәр итеп буылганын күргәч, шым гына дәресен хәстәрләргә китеп бара иде.

Ул карашларга алты көн түзде. Инде менә — җиденче сәфәре. Җиде саны туры килүне ул эше пешәсенә юрады. Тик күңелен ышаныч белән омсындырып куярга ашыкмады. Юлы унганга хәтле байтак мәшәкать чигәр күк сизенде. «Үтәсе юлны алдан ук авыр итеп күрсәң, җиңелгә килә»,— дип күңелен күтәрде ул.

Җәмәлҗән — рус авылы. Җәен анда баруы — үзенә бер сихәтле сәяхәт. Төбәк елгасы үзәне буйлап чирәм тасмалы ат юлы сузылып китә, урманыннан утын ташый торган такыр юлы да бар. Авылга урман чыгып барасы. Аралары унбиш чакрымнар тирәсе булганга кешеләре болай да әллә нигә бер аралашкан Җәмәлҗән белән Әҗмәхне кайчандыр калын булып та сугыш вакытында шактый киселгән урман аера. Кышка кергәч, ике авыл арасында хәл-әхвәл белешү бетә, берберсенең дөнья күрмешен район газетасы гына искәрткәләп тора. Җиһангир карт аның битләрендә берәр таныш-белеше исеме күренмәсме дип укыштыргалаган да итә. Тик тормыш язгы урман булган хәзер — яшәргән, үзгәргән: карыйсың-карыйсың — агачлар шавы элеккечә, аланлыклар әүвәлге, чишмәләр таныш, юл-сукмаклар шул көе, җиләкләр тәме гел бер, кошлар гел искечә сайрый. Яшәү җыры бүтән — дәртле, яңа. Әнә урман да: җәен узасың — шаккатасың. Икенче борылманы узганда читтәрәк карама торырга тиеш дип барасың — анда инде имән икән. Түллинкә чокырлыгын төшү юлындагы сулга каерылган сукмак башында тын чишмә булыр күк — анда кырмыска оясы. Юл буйлап бөрлегән булыр дип көтәсең — анда җете ал сандугач чәчәкләре. Шуның кебек, газетада да гел яңа исемнәр...

Менә хәзер Җәмәлҗәнгә килеп керер — кайсы капкага шакыр? Кибет тыкрыгыннан өченче өйнекенәме? Бәлки анда хәзер Наталья... («Кем-кем?» — дип сорады карт.) Әйе, Наталья өе кыйшаеп утырмый, берәр китапханә яктырып, әллә тагын берәр кантур кукраеп торадыр?

Җәмәлҗән юлына аның байтактан, әйләнечтән асфальт юл салганнан бирле, аяк басканы юк иде. Газета сина Архиплар капка төбендәге кое күмелеп, хәзер аның урынына телевизор антеннасы утыртылган дип әйтәмени? Асфальт юллар Җәмәлҗәнне генә әйләнечтән урап салынмый. «Андый юллар кеше хәтерен урап та салына кайчак»,— дип, тиз генә уйлап алды карт. Төбәк уйсулыгын кыйгачлый кисеп узган трактор юлы белән Җәмәлҗәнгә чыгып китте. Кичә кичкырын анда барып килергә уй корганда әле кышкы юл салып өлгермәгәннәрдер, дигән фикер килгән иде. «Күрәсең, шәйләнми калынган»,— дип сөенде ул.

Җәмәлҗәнгә асфальт юл белән дә барып була. Ул чагында боры-

лыштан соң җәяү биш чакрымлап кына үтәсе кала. Карт иртәнге тугызда киләсе автобусны көтәсе итмәде. Урманга барып ботагы-ние белән агач сөйрәп кайткан чылбырлы тракторның туң җиргә хәтле төшкән эзеннән алга атлады.

Җиһангир карт көннең җылы булуына шөкер иде. Җәмәлҗән, Зәңгәрле, Рус Әҗмәхе урманнары артындагы болытларның җәйге яңгыр килгәндәге кебек зәңгәрләнеп торуы гына аның кәефен кыра алмады. Кырның иң читләренә хәтле җәелгән кар җәймәсе, якындарак ак, еракларда зәңгәрсу төскә кереп, болытлар белән тоташа. Офык беленми.

«Һава бозылуга», — дип бәяләде карт.

Җил юк. Алай да ул болытларның куе чәйгә салынган сөт шикелле бөтерелеп торуын күрде. Кояшның кургашка охшаганрак, менә-менә эрер дә тамчы булып тамар сыман шәүләсе генә яктырта җирне.

«Иртәгәләргә тузгый да тузгый, — дип тәгаенләде карт. — Бәлкем әле бүген үк буранларга керешер».

Күңеленә шик төшсә дә, кире борылмады. Кояш аклыгы төшкән болытларны күзәтә-күзәтә атлаган карт үз аңының да уянуын тойды. Әйтерсең ялан кыр белән ул — икесе бер җан иясе. Кыр өстендә катып калган кар дулкыннары шикелле, тыныч кына чәчелеп яткан уйлары бергә укмаша, төерләнә, калка башлады. Гүя йокысыннан торды да, тәрәзәне ачып, саф һавалы якты дөньяга күз ташлады. Аның зиһен дөньясы да ачык, киң: уй белән кайсы өлгесенә орынмасын, үткәннең теләсә нинди хәтер сәхрәсе ачылырга тора.

Алда — Җәмәлҗән. Картның уйлары аның хакында иде. Ул элек олы юл өстендә утыра, арган юлчылар, сусаганда чишмәгә юлыккандай, аңа тез чүгә, аның куенына иелә иде. Район үзәгеннән калага асфальт юл салынгач, Әҗмәх халкы Җәмәлҗәнне андагы урманга барганда гына искә ала башлады. Аның төннәр караңгылыгыннан дәшеп торган утларын, туңган, әлсерәгән юлчыларны бишеккә салгандай, изрәтеп йоклаткан салам түбәле өйләрен, чабаталы, биштәрле, ә сулышларын чана ләмкеләре кыскан юлчыларга юатучан ана булып каршы чыккан иске бүрекле хатыннарын, тәмәкеле ирләрен, кара шәлле әбиләрен Җиһангир карт бик әйбәт хәтерли.

«Утлары күптән яктыргандыр, саламнары түбәләрдән күптән төшкәндер, без тел сындырып сөйләшкән кордашлар картайгандыр, — дип уйлады ул. — Ишәйгәндер, әллә кимеде микән?»

— Наталья да картайдымы икән? — диде ул искәрмәстән.

Бу сүзләрне бүтән берәү әйтәме әллә дигән сыман, артка борылып карады. Сары чәчле, кечкенә генә борынлы, боек карашлы Наталья басып торыр күк иде, түбән яктан Әҗмәх кына күренде. Авыл өйләре элек печән җыйгандагы чүмәләләрне хәтерләтә иде. Кайсыдыр бер чүмәлә — аның өе бит. Ә ул өйгә сыер кирәк. Быел, яңгырлы ел булып, үлән уңды, карт күп итеп печән җыйды. Насыйп итмәде, сыерының ашар ризыгы беткән булып чыкты.

«Ә теге вакытны Наталья үз сыерына сарай түбәсе саламын ашата иде, — диде ул. — Дөньяның кабатлануы диген. Әле печән булып, сыеры юк, әле сыер булып, печәненә интеккәнбез».

Кайбер чакны карт бер төшенә кергәнне икенче төшендә кабат күрә иде. Аның төшенә хәзер үткән сугыш каны да, елгаларда су коену да, урман кисүләр дә, сабан туе мәйданнары да, хатын-кызның яулык төзәткән булып, бармак араларыннан үзенә карап торуы да керми. Ул яңа гына очып килгән торналарның томанлы иртәдә биюләрен күрә. Муеннарын соң чиккәчә «г» хәрефе итеп бөгеп, алар бер-берсеннән әле ерагая, әле якынаялар. Карт канатлар шапылдавын, томшыклар текелдәвен ишетә, кибеп җитмәгән җирдә уелып калган аяк эзләрен дә күрә. Томан пәрдәсенә зәңгәрсу дары төтене бәреп керә. Кошлар-

ның һәммәсе югала. Күке авазы гына ишетелеп кала. Карт санамакчы итә, ләкин шул урынга җиткәч уяна да китә иде.

Күрәсең, дөньяның төшләре генә түгел, көннәре дә кабатлана икән.

«Тукта, ни булган иде әле? — дип хәтерләде карт. — Әһә!»

Бервакытны, сугыштан соң, Кама аръягыннан печән сатып алган иде. Март ае. Гафиятулла кордашы да бар. Буран чыгу сәбәпле соңгардылар. Юлга көртләр салды. Җәмәлҗәнгә җитәрәк, атлары тәмам эштән чыкты. Караңгы төште. Хәвеф-хәтәрдән сакланганын яхшы дип, Җәмәлҗәндә төн кунарга булдылар. Атларга тыгызга, хуҗаларга авырга килмәсен дип, аерым өйләргә төштеләр. Гафиятулла танышы Архипка тукталды. Ә Җиһангир күршедәге түбәсез капканы какты.

«Төнгә каршы кем анда?» — дип, капканы яшь бер хатын ачты. Аның йомышын тыңлап бетермәде, төбен көрәштергәләп, олы капканы ачты:

— Уз! — диде. Печәнен иснәп тә, капшап та карады, сүз әйтмәде. Бары тик:

— Бөтнек исе, — диде.

«Мин ул чакны хуҗа кайда?» дип сорадым, — дип исенә китерде карт. — «Үзем хуҗа!» сүзен ишеткәч, уңмаганга гел уңмас дип үкенгән идем. Аннан нишләде әле ул? Әһә, өйгә кергәч, плитәдән сулы чиләк алып, ишеккә таба китте. Мин аңа: «Юк, юк, өшәнмә, атка су бирергә иртә әле, тирләгән, ашасын бераз», — дидем. «Синең атка түгел, үз сыерыма әле. Башак болгатырга, черек түбә саламы», — дип дорфа гына җавап кайтарган иде. Аннары мин: «Онын бармы соң?» — дип сорадым. Ул: «Үзебезгә умачка җәйгә кадәр җитәр кук»,— дип сукранасукрана чыгып киткән иде. Мин берүзем калдым. Өй галәмәт ярлы. Коры стена. Бер көзге бар иде, радио тәлинкәсе, карточкалар рамы. Аннан почмак кашагасын ачып бер малай чыкты. Бер малай... Әһә, хәзер менә кичә булган шикелле ачык күренә...»

Карт юлны һәм хәтерендәге уйларын гына күреп атлады да атлады. Юлдашына сөйләгән шикелле итеп, әллә кайчан булганны үзүзенә сөйләп барды. Сыер турындагы борчуы сизелмәстән онытылды да ак яланга таралды китте.

«Аннан мин инде чөйгә элеп куйган тунымны кидем дә яшь хатын артыннан ияридем».

Тәмам караңгы иңгән, тын иде. Тик җил генә сызгыра да, биткә уч-уч кар китереп бәрә. Ул атының кыштыр-кыштыр печән ашавына колак салды. Печән исе, байталдан бөркелгән тир исе борынын ярып керде. Сукыр кеше сыман кулын алга сузып абзар эчендәге ишеккә таба китте. Хатынның, сыерына дәшкәләп, башак болгатканы ишетелә иде. Искәрмәстән дәшү куркытмасын дип, Җиһангир тамагын кыргалап алды. Шул мәлне үк фонарен тотып хуҗа хатын үзе килеп чыкты, ә ул читкә тайпылды.

«Бүлдердем... ахры» — диде хатын, читкә карап узды, авыз эченнән генә көлеп куйды.

Ат, әле генә мәшәкатен бетереп, тагын печән кыштырдата башлады. Ул да башта авыз эченнән, аннары тыела алмый кычкырып көлеп җибәрде:

«Ходай тәгаләнең рәхмәте... Ат ул»,— диде.

Аннан кинәт уңайсызланып китте, хатынның «үзем хуҗа» дигәнен искә алды. «Тол хатын белән шулай тәмсезләнеп буламы? Әллә уенчак, әллә җәрәхәтле ул тагын»,— дип уйлады, җәлләп куйды.

«Карале, исемеңне белмим»,— дип эндәште.

«Наталья», — диде хуҗа хатын өйалды ишегеннән кереп барган җиреннән.

«Карале, Наталья, сыерыңа печән салмыйсыңмы?»

«Болгаттым ич инде».

«Онсыз-нисез... Тамагына ялганырмы соң?»

«Күнеккәндер инде. Үзебез соң? Бәрәнге дә арыш умачы. Ашардай бүтән әйбер юк. Анысы, иттән өзсә өзсен, өметтән өзмәсен»,— диде. Фонарен җилдән ышыклап кереп китте. Фонарь тоткан кулы, потлы гер күтәргән кебек, арудан хәлсезләнепме, ялгыз инәнә төшкән мәшәкать йөгеннәнме, түбән салынган. Калын шәлен сырмасы эченнән япканга, бераз бөкрерәк күренә. Кигәне биленә ипле ятып, билдән түбәнрәк исә тыгыз тартылып тора.

«Күзне кызыктырырлык, ләкин йөрәкне сызлатырлык җәл хатын иде шул».

— Туктале, бүлдермә әле,— дип ачуланды ул үзен.— Син ни кирәген хәтерлә. Сиңа аның сырмасының кай төштән буш, кай төштән кысан булуы хәзер нигә кирәк?

«Ләкин бу миңа ул чакта да кирәк түгел иде,— дип каршы төште карт.— Мин уйламадым да аны. Мин бары тик: «Тукта әле, Наталья, иртәгә өчен алып куй, печәнне әйтәм. Чык әле, чык»,— дип эндәштем. Ә ул миңа: «Рәхмәт, ялап кына туелмас», — диде.

Әллә нишләп тә киткән иде шул. Тыела алмады, кызганыйнманмы, Наталья кебек ялгыз хатыннарның иза чигүенә дөньядагы бөтен ирләр өчен сугышны каһәрләвеннәнме, сөйләнә-сөйләнә, йөгенең як-ягыннан печән йолкырга керешге. Кулына курпылар чәнчелде, битенә тир бәреп чыкты. Бастырыклап бәйләнгән һәм кайта-кайта басылган печән учлап-учлап кына суырыла иде. Аның басынкы тавышлы шушы кырыс хатынны юатасы, ялгызлыгына сукранмый төн кунарга керткәненә рәхмәт әйтеп, берәр игелек кыласы килде.

«Кирәкми,— диде кай ара аның янына килеп баскан Наталья.— Кеше өлеше кирәкми. Ялап кына туелмас дим ич».

«Анысы да дөрес, Наталья. Ялап кем туйган? Болай итик».

Нишләсен әйтмәде. Артка чыгып бастырык бавын ычкындырып җибәрде. Карлы печән йолкудан туңган бармакларының сызлавын да, арганлыгын да онытты. Бастырыкны алга шудырды, йөккә кадалган сәнәгеен алды да хатын ягына өч-дүрт потлап печән ишеп төшерде. Көтмәгәндә юмартланып ташлавына бәя биреп өлгермәде.

«Ир кеше идем ич, — дип хәзер бәя бирде карт. — Хатын-кыз нужаның бугазыннан алып көрәшкәндә мин биленнән генә алып җиңмәс идемме? Дүрт пот кына аз булган әле ул,— дип үкенде ул.— Ярты йөген аударып калдырасы булган да бит... Хәер, алай дисәң, иртәгесен Гафиятулла ни уйламас иде! Әле бит болай да күз ачырмады. Саттым дип алдадым. Сөмбел күңеленә шик юшкыны булып утырмас идеме?.. Шуннан соң ни булганын мин үзем генә беләм, — дип пышылдады ул. — Әй!.. Кирәкмәс иде дә соң. Әй...»

Печәнне ишеп тә төшерде, чана астыннан ишетелгән кебек тоныкына итеп, Наталья аваз салды: әллә елый, әллә көлә иде.

Шуны ишетеп кенә исенә килде: кызып китеп, хатынны искәртергә оныткан лабаса!

Уч төпләрен, кул артларын, беләкләрен чәнчеп бетергән курпыларга карамастан, кабалана-кабалана печәнне актарып ташлады.

«Наталья!» — дип эндәште ул. Кулы хатынның салкын битенә тиеп китте. «Бер-бер җирең алай-болай булмагандыр ич?»

Печән эченнән хатынның тыелып кына көлүе ишетелде. Җиһангирның йөрәге иркенәеп китте. Печәннән башын чыгарып Наталья тирән итеп сулый башлады. Ул Җиһангирга кулын сузды. Аның шәле шуып төшкән, чәче тузгыган, чәч араларына печән вагы, кар тулган. Сулуы капкан, үзе нихәл һтәргә белми көлә иде. Печән арасыннан чыкты да, аста калган итеген эзләп табып, аягына киде. Сырмасының өске төймәсен ычкындырып, хәлсезләнгән тәненә сулу бирергә исәп итепме, ба-

шын күтәрде, бер кулы белән артка таянды, бераздан икенчесен аңа сузды.

«Йөге белән аудардың мәллә? Ник? Хәл китте, торгыз», — диде.

Ул хатынның кулын учына алды. Ялан кул эшләп йөрсә дә, аның кулы җылы, йомшак, уч төбе исә кытыршы иде. Аяк астындагы печән карда шуып таеп китте, Җиһангир, сөрлеккән кеше шикелле, бөтен авырлыгы белән Натальяга таба авышты. «Ах!» — дип куйды хатын. Бүтәнчә аваз салырга өлгермәде. Авызы белән битенә, борынына, иягенә ягыла-ягыла, Җиһангир аның иренен сарылды. Миенә кайнарлык йөгерде. Карлыгачлар көтүе уйнаклап узган кебек, бөтен тәне талпынып, калтырап куйды.

Наталья күрер күзгә генә авыр сөякле, басынкы гәүдәле икән — Җиһангирның кул астыннан кинәт талпынып шуып чыкты да тезләренә таянды. Җиһангир ирексездән терсәге белән йөзен каплады, хатын менә-менә сугып җибәрер дип көтте. Буранлы күк биеклегеннәнме, әллә печән астыннанмы пышылдаулы сыкрау ишетелде:

«Бүтән берәү булса... Өзгәләр, сөякләреңне ватар, маңгаеңа җиргә тигәнче тибәр идем! Авыртудан түгел, тол хатыннар хәтерен калдырудан, оятыңнан сызланыр идең..»

«Я, ялгыш, онытылып... кем белән булмый», — диде Җиһангир, тезенә чүкте.

«Теләсә кем белән шаяр, минем белән кирәкмәс иде, — диде Наталья. — Бөтен авыл белә минем аны ничек көткәнне. Синең ише байтак исәрләрнең телен аркылы тешләттем».

«Уйламаган да идем, икмәктер».

«Икмәкне вак-төяккә өләшмә, — диде Наталья коры гына. Шәлен рәтләп, аягына басарга талпынган иде дә аның иңбашына таянды. — Җаның яхшы күренә, юлчы».

Еламады, бәлки, ыңгырап-иңрәп, Җиһангирның күкрәгенә капланды:

«Әллә кемнәрне эт итеп кудым. Әллә кемнәрне төшләрдә күрдем. Синдәй бөтенләй читне кем көткән!»

Ул эндәшмәс булды. Эссе сулышы белән Җиһангирны баусыз буды. Хатынның өзгәләнүе, усак яфрагы кебек дерелдәве, иреннәре белән сулкылдавы аның бугазына кайнар төер булып утырды...

Шул чактагы ояты кире кайттымыни: Җиһангир картның эче-тышына кайнарлык йөгерде. Аны тетрәндереп Наталья ни диде әле? Әйе, суырып бер үпте дә:

«Костя булсаң икән әгәр! — дип сулкылдады. — Бөтен авыл белән җыелып карап торсалар да... буран диме, өшеме... оялмас идем, Костя булсаң әгәр! Ә син Костя түгел. Бер төн кунагы да гомерлек вөҗдан табы булырга гына ярыйсыңдыр... Тор, ашка умач салырга вакыт. Суы кайнап бетмәсен тагын».

Натальяның өе сары тәрәзәләре белән, каш астыннан, Җиһангирга карап тора иде.

«Гомерлек вөҗдан табы... — дип кабатлады Җиһангир карт. Гомер гөнаһсызлыгын вөҗданнардагы ялгыз тапка карап та белерлек тормышлар бар микәнни шулай?»

— Нәрсә хак — шул хакыйкать, — диде карт җайлы гына барган уңайга.

Ул урманга житте. Кар урман читенә кырдагыдан калынрак яткан. Трактор эзе, бер клинне кыйгачлый кисеп, электр баганалары үткән киң аралыкка турылай чыккан. Әҗмәх инде күптән күренми иде. Аралыктагы юлны әйбәт кенә таптарга да өлгергәннәр. «Делянкаларыннан бүрәнә-такталык агач ташыганнар, — дип төшенде карт. — Эһә, этләр дә ияркәннәр, ә? Зур булган болар, эзләре уч хәтле».

— Тукта әле, юлны гына кисеп чыкканнар түгелме соң? Бакчы, бүре эзләре ләбаса! Берәүме, икәүме шунда... Икегә генә дә охшамаган әле бу, күбрәк, өч. Ә-ә-ә! Җанварлар җибәргәннәр дигәнне ишеткән иде ич! Кабан дуңгызлары, ике кыр кәҗәсе... Кара, йөриләр икән, ә? Беттеләр дигәндә... Зур булган болар. Эзләре уч хәтле.

— Син бүлендең,— диде ул, бүре эзләре турысын узгач.

«Ул чакны да бүлендек ич. Безне теге малай тавышы бүлде. Ул: «Әни, син кайда? — дип кычкырган иде. Сискәндергән иде әле».

«Монда, Сашенька, сыерны карап йөрүем», — бусын Наталья дәшкән иде.

Өйгә керделәр. Туның салып, уңган гимнастерка, сырган чалбардан гына калгач, ун яшьләрдәге сипкелле малай аңа текәлде:

«Бу кем, әни? Әти мәллә? Әти кайттымы әллә?»

«Атаң чәчен китәрми, улым. Ә бу абыйның башы кабак шикелле тап-такыр».

Көлештеләр. Аннан Наталья самаварга иелгән булып аңа:

«Атасы киткәч тапкан идем мин аны», — дип пышылдады.

Шушы пышылдау Натальяны Җиһангирга якынайтып җибәргән төсле итте. Тартынуда тоткан киеренкелек бушана калды.

Плитәдәге чиләктән чүмеч белән су алып, Наталья аны юынырга чакырды. Суның кадерен белеп кенә сала башлаган иде. Битен юганда бармаклары арасыннан ул Натальяга күз атты. Хуҗа хатынның кулы җиңелчә генә калтырана. Калтыравы су агымына да күчте, су әле учлардан ташырлык булып, әле бөтенләй читкә акты. Җиһангирны үз кулларының чамадан тыш зурлыгы, беләкләренең юанлыгы уңайсызлады. Хатын, болай итеп күптән су салып карамагангадыр инде, дулкынлана иде. Җиһангирның яшертен карашы аның йөзеннән йөгереп үтте дә муенына вакытсыз төшкән ике сыр арасындагы миңгә җиткәч тукталып калды.

«Ул миңне мин шомыртка ошаттым бугай әле, — дип хәтеренә китерергә тырышты карт.— Миң уртасыннан, җимешнең кыска сабагы шикелле, бер кара төк тә тырпаеп тора иде әле. Шуннан тотып шомыртын кап та йот иде инде менәтерә».

Аның баш очыннан сызгырып, Җәмәлҗан ягыннан козгын очып узды.

— Люцерна кырына тычкан эзләргә китте, карт төлке...— диде ул.

«Ә кача-поса Натальяның миңен күзәткәндә мин төлке түгел идемме? Үземне хәйләләп булса да ауладым шул Натальяны, ауладым. Ул да, козгынны сизеп кар астына чумган тычкан кебек, минем карашны тоеп, чаршау артына ашыкты. Суын да салып бетермәде. Чаршаудан кулын гына чыгарып, суккан сөлге ташлады. Җиңен сызганган, кулы кара, беләге кар төсле ак, кан тамырлары белән челтәрләнеп беткән».

Карт андый кулның көчле, эшкә чыдам, аруга бирешми торган икәнен белә инде хәзер. Чөнки тамырлар күп булган саен, кулга кан килә. Саф кан, бар аруын йөрәк сөзеп калган яңа кан килә.

Картның үз кулы шундый.

Наталья өендә, Сөмбеле каршындагыча, җиңнәрен терсәгенә хәтле сызганып, ул өстәл янына килеп утырган иде. Гадәткә әйләнгән бу эшнең ялгыз хатын янында ярамаган бер золымлык икәнен күңеленә төшереп, кулларын өстәлдән тиз генә аска табан шудырды. Наталья калын ирене һәм күз читләре белән генә көлемсерәп алды. Моны күреп, ул тагын да уңайсызлана төште.

Җиһангирның тун кесәсендә май ягып бер-берсенә каплаган ике телем ипи, киртләч-киртләч таш кисәге шикелле бер шакмак шикәре бар иде — чыгарып өстәлгә куйды. Наталья аның алдына арыш умачы

салынган тирән тәлинкә китереп утыртты. Умачлары учка алсаң чуер таш сыман чыкылдап, кыштырдап торыр шикелле кара иде.

Ашаганда да, ашап сөтле чәй эчкәч тә эндәшмәделәр.

Җиһангирның икегә аерып куйган ипи телемнәре белән шикәре орынусыз калды.

Кечкенә Саша шул шикәрдән күзен алмыйча утырды-утырды да, «кабак» башлы абый чалгы пычак белән бер китемен кыеп биргәч, мич артына, тал чыбыгыннан үргән караватына менеп ятты.

«Рәхмәт, Наталья, — диде Җиһангир. — Син инде баягы... нине чынга алма. Җәберләдем бугай».

Ул, өстенә киенеп тормастан гына, болдырга чыкты. Буран кызуланган иде. Ишегалдындагы йөк печән булып түгел, көрт булып төсмерләнде. Аты өстеннән толыбын кайтарып алды.

Озаграк торылган, күрәсең, кергәндә ут кысылган иде. Наталья түрдәге ян караватка яткан. Алып кергән толыбын Җиһангир ишек катына җәйде. Чөйдән туныи алды. Тагын ни алыйм икән дигән кыяфәттә, дәү гәүдәсе белән өйне тутырып, уртада басып калды. Урындыктагы мендәрне алырга кул сузган гына иде — Натальяның теш арасыннан сулкылдап җибәрүенә аптырап гәүдәсен сагайтты.

«Җә инде, булган-булган, юк-бар өчен ул хәтле изаланмасаң... Бар икән соң дөньяда изге җаннар!» — диде ул. Мендәрне алып толыбы өстенә атты.

«Көн дә чыккан кояшның унөч елга бер җылысы булмады бит миңа! — диде хатын һәм борылып мендәренә капланды. — Унөч ел җәйгән пар мендәр тышыннан гел күз яше тозы гына юарга язды», — дип үкседе.

«Кунарга кермисе калган ла, рас сиңа шул хәтле хәсрәт салганмын икән! Кермисе калган ла, ялгыш булса да орынасы түгел икән, — диде ул. Пыяла өстенә учын куеп, лампаны өреп сүндерде. Печән ишкәндә кылган гамәле өчен үкенде. Җәйгән урынына таба атламакчы иде, хатын туктатты:

«Юк инде... Бер кузгалган инеш бозы кире кайтамы?»

Хатынның пышылдавы, миләшкә сарышкан колмакның уч-уч эре яфрагына шыбырдап яуган яңгыр шавы кебек, җанны изрәтеп ишетелде...

Җиһангир карт туктальш калды, әйтерсең лә аның уенда терелгән Наталья, теге чактагы вәсвәсәсенә үкенеп, бүген: «Кирәкмәс!» диде. Карт алдындагы аклыктан күзе чагылып керфекләрен кысты, йөзен җыерды. Уендагы Натальяның шул сүзләре яшен булып балкыдымыни — Җиһангир карт, урманны үтеп, Җәмәлҗән кырына аяк атлады. Натальяның караңгы өеннән килеп чыккан шикелле итте. Күзе, яшь бәреп чыкканчы, кар аклыгыннан чагылган икән. Сиздерми кузгалган җил кояш турысындагы болытларны куып тараткан. Кояш тирәли алка күренә. Урманда гына беленмәгән икән — җил көчәйгән, юл аркылы кар еланнары шуыша башлаган.

«Натальяның да чәче шулай кар булып кыштырдады түгелме әле? — дип сагайды карт. — Чәче кылган эше сары, кылган эше коры иде. Боларның һәммәсе, былтыргы яңгыр, орлык бирер өчен чәчәген койган көнбагыш, син ясаган ояда бала чыгарып киткән сыерчык кебек, ерак инде хәзер. Чү, ни диде әле ул? Хәзер, хәзер... — Карт, үзе белән туктаган хәтерен хәрәкәткә китерергә теләгән шикелле, кузгалып китте. — Хәзер, хәзер... Әһә! «Кайтмый калганнар кояшны күрми...»

Ә тышта буран иде.

Аның Наталья сүзләрен тыңлап ятканда да күзе яшьләнгән иде. Хәтерендә ишетеп тә күңеле тулды. Картның хәзер моның белән килешәсе килмәде.

— Бу юлы минем күз кояш яктысыннан, кар аклыгыннан яшьләнде, — дип акланасы килде. Теле белән әйткәненә акылы белән каршы төште. Хәтерендәге ничек ятса шулай йоклап киткән хатыннан яхшысынмады.

Ә ул иртүк уянды. Атына бер култык печән салып керде, су эчертте. Бераздан Натальяның самавары кайнап чыкты. Караңгылык эреде, өйгә әкрен-әкрен яктылык иңүгә күз иләшә башлады.

«Атың ничек синең, юлчы?» — дип сорады хуҗа хатын, уңайсызланып беренче сүзен катты.

«Җиһангир».

«Безнеңчә Җиган икән».

«Алай да ярый».

Наталья читкә борылды. Тар алюмин балдак кигән бармагының бите белән күз төбенә кагылып-кагылып алды.

«Ә хәтергә Костя булып кына килерсең... Исемеңне болай гына соравым».

«Аңламыйм».

«Теләсә кем аңласа — ул ярату булыр идемени?»

«Теләсә кем аңласа — ул ярату булыр идемени?» — дип, күңеленә беркеткән иде ул чагында Җиһангир.

— Әйе, теләсә кем аңласа — ул ярату буламыни? — дип кабатлады Җиһангир карт.

«Кем соң ул, Костя да Костя!.. Кайтмадымыни?» — дип сорады карт үз хәтереннән нәкъ теге вакыттагы кебек итеп.

«Кайткан кеше хәтердә генә булыр микән?» — дип, һич карышмый җавап кайтарды Наталья.

Җиһангир карашын караңгы өйдә яңаклары тагын да ач, ябык булып күренгән һәм үзен кинәт үкенечле бер кызгану белән яраттырган хатынның күзе текәлгән ноктага күчерде.

Стена. Ике ян тәрәзә уртасы. Кадакка энәләр кадалган түгәрәк мендәр элеп куелган. Аннан өстәрәк — эреле-ваклы фоторәсемнәр белән тулы рам. Күзен зур ачып, хатын шуның уртасына караган да аскы иренен тешләгән.

Ул, рәсемне ачыграк күрер өчен, торып өстәл аша үрелде дә, күзен кыса төшеп, әкрен генә сынын катырды. «Костя. Леушин, якташ... Икенче орденың кайда?.. Анысын алырга кайтмадың ла шул... Әй!» — дип уйлады.

«Костя, Леушин», — ди рәсем, гүя нәкъ теге чакта фронтта очрашкандагыча кулын суза.

«Гриша, — ди Җиһангир, — Татарстаннан». Әйе шул, Җиһангирны барысы да Гриша дип атый иде бит.

«Якташ, димәк», — ди Костя. Тагын нидер әйтмәкче иде дә, блиндаж брезентын ачып полковник чыкты, танышмый калдылар: төрле батальоннан җыелган иң көчле унтугыз разведчик сугышчан бурыч тыңлады.

«Леушин... Костяң шушымыни инде?» — диде ул.

«Әйе, Костя, — дип, Наталья Җиһангирны таң шәүләсе төшкән җылы өйгә кайтарды. — Леушин... Леу-шин! Син каян беләсең?»..

Наталья, чытырдап, Җиһангирның иңбашына ябышты:

«Син каян беләсең, Җиган, кадерлем!» — дип, чыраен сызланулы сытып ялварды ул.

Җиһангир берни әйтмәде. Яктырган иде инде, ә аның күзалды караңгыланып китте. Шул караңгылыкта, снаряд шартлавы булып, Леушин сүзләре ялкынланып кабынды:

«Кайткач, минекеләрне күр, якташ! Натальяның миннән башка кеме дә юк. Онытма, якташ, Натальяны күр! Ярдәмеңнән калдырасы түгел, бел аны!»

«Кайсы авыл, Леушин, кайсы авыл дим?..»

Леушинның соңгы сүзе булып куенындагы соңгы гранатасы шартлады...

«Натальяга берни әйтмәдем шул мин, — дип уйлады карт. — Әллә нишләп киттем. Леушин кайтып кергән күк булды. Оятмы, нәрсә басты. Ничек котылды әле ул? Ә-ә-ә! Өстәл почмагындагы бер дәфтәрне күреп кулыма алдым да: «Александр Леушин» дип укыдым. Шуннан беләм, янәсе. Теге кечкенә малай дәфтәре булгандыр инде».

— Тукта, ә Наталья ышандымы соң әле аңа? — дип сорады үз-үзеннән карт. — Ни диде әле? Дәфтәрне алды, «Леушин, — дип пышылдады. — Костя». Ышангандыр, ышанган.

«Алай булгач, ник мин укыганча, Александр дип укымады соң ул, «Костя» диде? — дип җавабына карышты карт.

Аннары да миңа борылып: «Син кайсы авылдан, Жиган?» — дип сорады. Ышанмаган ич, ышанмаган, авылга килеп, яхшылап тагын бер сораштырырга уйлаган! Ә мин әйтмәдем. Ян тәрәзәгә чыбыркы сабы белән Гафиятулла шакый башлаган иде. Толыпны беләккә салып чыгып киттем», — дип үкенде карт.

«Төш кебек, тормыш хәлләре кабат кайта. Менә ич, тагын Җәмәлҗәнгә барам. Үзем барам, үзем үткәннәргә кайтам».

Теге буранлы төн — кабат кайткан төшме, әллә инде яңадан кичерелгән вакыйгамы соң, нәрсә?

Адымнарының акрынаюын тоеп, карт уйларыннан декабрьның яңа карындагы яңа эзгә кайтты. Аның сыеры үлгән, аңа сыер кирәк иде — кызурак атлап китте.

«Кайдадыр миңа дигән сыер булмый калмас. Юкса, бу дөньядан бүтән ни ала алыйм инде мин тагын? Бар нәрсәм бар, сыер гына юк, — дип юатты ул үзен. Яшертен генә: «Әгәр бик теләсәң, теләк уңарга тиеш», — дип уйлады.

Җәмәлҗәнгә ул төш җитәрәк арып, тамагы кибеп килеп керде. Ничәме мәртәбәләр калага, Кама аръягына печәнгә йөргән авылны танымады. Ул аның ярлы, караңгы вакытын белә иде. Хәзер исә авыл челтәр-мелтәрләр астыннан бөтен тәрәзәләре белән нурланып, көязләнеп утыра. Елга яры буйлап бер яңа урам өстәлгән, зиратлары да киңәйгән икән: куе агачлык белән рәттән нәзек-нәзек каен, тупыл, өрәңгеләр утыртылган җир өстәлгән.

Карт, авылга аяк атлауга, беренче очраган кешегә сатлык сыер хакында сүз катты. Бишмәте өсли кара халат кигән берәү башлары корыган өч тупылга сыенып утырган йортка таба төртеп күрсәтте.

Карт, үз гомерендә аяклы мал белән күп сату-алу иткәнгә, хәйләле сорау бирде:

— Бу вакытта ник сата? — диде. Кем белә кешене: малы әллә чирле, әллә кире булганга саталар. Бәлки ашыгыч саталардыр, бәлки ашыкмыйча. Бәянең күпмегә төшәр әмәлен шулардан аныклый карт.

— Кем белә кешенекен. Кичәле-бүгенле генә ишетә беләм. Ашыгыч сатарга телиләр бугай.

«Йөз, йөз иллегә төшү җае бар».

— Әнә, хуҗа хатыны, — диде кара халатлы.

Капкадан сары шәл бөркәнгән бер хатын-кыз чыгып, каршыдагы колонка авызына чиләген элде.

— Исән-саулармы? — дип эндәште карт. — Сыер сатасыз икән.

— Сатам шул, — диде хатын. Әйтте дә, Җиһангир картның артыннан килү-килмәвенә игътибар итмәстән, капка келәсенә барып орынды.

«Коры нәмәрсәгә охшый, — дип уйлады карт. — Моны сындыруы җиңелдән булмас. Бәһасеннән төшәр микән?»

— Уз, кара, — диде хатын аңа таба борылып. — Инде сатмам да дип уйлаган идем.

«Бәяне күпертә», — дип уйлады карт.

— Дан булмаса да, сыерым сөткә юмарт. Аны түгел, үземнең ярты санны сатам, — дип дәвам итте хатын.

— Савып күрсәтерсең ич? — дип ишарәләде карт. — Ә без хуҗа белән бәя килешә торыйк.

«Һе, ярты сан сата! Артык сатулашмаска булыр, — дип карар кылды карт. — Я сатмаслар тагын. Сыеры да шәп булса».

— Бәясе килешенгән инде аның.

— Кем белән?

«Әх, тагын корыга гына йөрү булды!» — дип курка калды карт.

— Үзем. Артыгын да, кимен дә сорамыйм.

— Ә хуҗа... бирәр яртын киттеме әллә?

— Китте шул. Китте дә кайтмады. Үзем калдым аның урынына.

Төз, озын гәүдәле, юанчарак рус хатыны сулы чиләге ягына кыйшаебрак кереп киткән ачык капка төбенә җиткәч, ник икәнен дә белмичә, Җиһангир карт кинәт туктап калды. Монда аңа нидер таныш кебек иде. Ул урамга таба борылды. Кайдадыр бер күргән кешене таный алмый торган кебек, бер күзен кыса төшеп, капка төбеннән ачылган күренешкә бакты. Каршысында колхоз амбарлары торырга тиеш булып тоелды. Ләкин анда такта түбәле амбар түгел, ике морҗалы, дәү-дәү тәрәзәле озын йорт сузылган иде.

Ул кече капканың нәкышлап бөгелгән келәсенә тотынды. Нәкъ шунда: «Наталья нинди икән хәзер?» — дип уйлады. Бу уеннан тимер келә аның кулын утлы күмер шикелле көйдереп алган кебек итте. Уч төбен келәгә бәйләгән корыч чыбык очы чәнечте. Ул картның уч төбен түгел, зиһенен чәнчеп үтте: яңа булмаса да, әле бөтенләй үк каралырга өлгермәгән өе бүтән, капкасы бу юлы калай түбәле итеп эшләнгән, ләкин шушы келә әүвәлге иде.

«Наталья! Соң ул үзе ләбаса инде!»

Җиһангир карт, теге чактагыча, Архип дәдәйнең салкын тиюдән гыжылдый башлаган тавыш белән:

«Теге як күршеләр суны да үлчәп эчәр, сараннар, менә Наталья сеңелгә кер — изге җан», — дип сөйләнүе ишетелер сыман булды. Ишетелмәде. Теге чакта үзе калдырган дүрт пот печән өемен күрер шикелле тоелды. Күрмәде.

Сыерын җитәкләп, лапас астыннан баягы хатын чыкты:

— Менә, шушы.

«Шушы, — дип инанды ул, — үзе!»

— Сатуым шуңа: колхозда сыер савам. Пенсиягә ике ел калды. Фермадан өйгә кайтасың — тагын шул сыер көтеп тора. Сатуым шуңа.

Җиһангир карт сыерга түгел, аңа карады:

«Үзгәргән, ләкин үзе — Наталья. Ә минем танырлык йөз калмаган микәнни инде?»

Сары шәл япкан хатын сыерын болдыр баганасына бәйләп куйды: йөзе куркынган, бармаклары калтырый, бәйләгән төененә түгел, сыеры күзенә карый — сыерын гынамы, сыеры белән бергә, чыннан да, үзенең ярты санын сатамы? Күрәсең, әйткәненчә, малкае аның өчен ялгызлыкта иптәш булган да ул үзе, кояштан йөзен алмас көнбагыш кебек, шуңа багып торган.

— Бүген саумаган идем әле,— диде хатын.— Фермада аппарат юабыз, бер юл кулдан саудык. Ардырды. Элек сыер имчәкләре бала ирене генә булган шул. Хәзер каты.

«Аның каравы, хәзер без бала ирене — йомшардык» — дип уйлап алды карт.

Ул сыерга күз ташлады. Гомерен кичерде, иллә моның ише сыерны хуҗалыгына аяк атлатмады атлатуын: кечкенә үзе, мөгезе баш бар-

мак хәтле генә, «тимәгез миңа» дигән кыяфәте белән алар авылындагы кечкенәлегеннән кияүгә чыкмаган Кәҗә Сафурасын хәтерләтеп басып тора иде.

«Йөрүем әрәмгә китә икән инде, — дип кайгырды ул. — Председатель әйткән мартларны көтеп, аның мәрхәмәтенә баш ими чара юк».

Наталья, чит караштан ятсынып кына, сыер саварга кереште. Сыер астында кечерәеп, кызгандырырлык булып калды. Бүтән эш эшләсә, карт ярдәмгә килер иде. Сыер койрыгы тотып торып буламыни? Булса да ник тотасың аны, болгый-болгый кигәвен куар чагы түгел ич.

«Ярдәмеңнән калдырма!» — дип ишетте карт. Әллә нишләп китте. Шушы сүзләрнең аңында пәйда булуына гаҗәпсенеп: «Нәрсә, нәрсә?» — дип сорады.

...Немецлар эзәрлекләвеннән икәү ычкындылар. Өченчесе — күн комбинезонлы немец очучысы. Дошманның ерак тылындагы аэродром турында сөйлисе «тел». Арттан куа чыккан гитлерчыларны тоткарлау группасына командир Җиһангирны да билгеләгән иде. «Икебезнең беребез кайтсын, иптәш лейтенант!» — диде Леушин командирга. «Ник?» «Без — якташлар. Беребезгә ике гаилә калсын, бер ир кулы... Җиһангир кайтсын». «Аның урынына кем кала?» — диде лейтенант. «Мин,— диде әрмән егете.— Балалар йортыннан, өйләнмәгән».

Исән калган алты сугышчы аңа тормыш бүләк итте. Шул тормышка гозерләп Леушин васыять әйтеп җибәрде.

Җиһангир карт гомере буе вөҗданында шул гозерне йөртте.

Теге юлы васыять йөге Натальяга ишеп төшерелгән печән булып дүрт потка кимегән. Тик хатынның теге буранлы төндә яратуга сусавы Җиһангирның уйларын буталчыклыкта калдырган иде.

«Минем җан нишләрен белмәде шул»,— дип уйлады карт, карлы букәнгә утырган килеш. Үзе шулай дип уйланды, үзе колхоз эшен эшләп үз сыерын саварга вакыты калмаган ялгыз хатынның ирле хуҗалыкка биргесез хәйран таза абзар-курасын күзләп, тикшереп чыкты.

«Ә-ә, малае... Ничек әле?.. Малае, Сашасы бар иде ич! Аның кулы кергәндер. Ару гына тормыш итә икән болар!»

«Ләкин аңа карап гомерем өчен алган гозер минем өстән төшмидер ич!» — дип, үз-үзеннән ашыга-ашыга сорады ул. «Бу йорт-җир синең дүрт пот печәнеңне сатып тергезелмәгән лә!» — диде карт, әлеге уена ачуы килеп. Хәзер исә Леушинның гозерен хатынга кирәге беткән сыерны сатып алу белән булса да үтисе, шуның белән җанын тынычландырасы килде. Натальяга Леушин һәм үзе турында сөйләп ни гомер эчен яндырган утны сүндерергә карар итте. Хәтта күршегә әйтеп җибәргән сәламнең дә җиткерелер, гозерләрнең үтәлер вакыты була.

Аның вөҗданы сатулашып яшәмәде. Ул эре сөякле, мендәр кадәр җиленле, һичшиксез, буаз булырга тиеш сыер алырга дигән акчасы салынган куен кесәсен капшап карады.

«Йөз, йөз иллеләр өстисе булыр»,— дип карар кылды.

Наталья Җиһангир күз алдында сыерның йодрык кадәр генә җилененнән дүрт литрлап сөт савып алды.

— Малның җилененә түгел, җелегенә кара шул,— диде карт.

— Хурлыйсы урында ник мактап торасың әле? — диде хатын.— Миңа сатасы, сиңа аласы бит.

— Ни күрәм, шуны алам. Сатулашып тормыйм, бәяне үзем куям,— диде карт.

— Ә минем нием бар, шуны сатам. Киләчәкне яшереп булмый.

Сыер кысыр. Бу вакытта шушы кадәр сөте булу уңмау сәбәбе инде, уңмау сәбәбе. Алдап ни мәгънә.

Җиһангир карт малкайның мөгез сырларын санап чыкты. Биш бозаулау аның мөгезенә биш сыр уйган. Дөньяга ул китергән биш бозау тамгасы. Картның мал танырга күнеккән үткер күзе, көзен киткән каргаларга карап язның нинди буласын чамалаган күңеле кебек, мөгездә чак сизелерлек яшь бөҗра эзен күрде. Сыерның сырты да бөгелебрәк төшкән — эчендәге тере орлык тибәр сәгатен көтә.

«Буаз» — дип уйлады ул. Аннары хуҗа хатынга:

— Ялгыша күрмә, хуҗа, малың бушка ашарга җыенмаган — буаз. Майлар бетүгә җиңеләясен көт тә тор,— диде.

— Каян килеп? Көтүгә үгез җибәргәннәр иде дә, көтүче ул-бу шәйләмәгән. Фермага алып барырга күңел үсмәде, вакыты да тимәде.

— Сиңа инде ышанасы гына. Сатучы түгел, алучы әйтә.

— Алай булгач, син нинди малчы?

— Мал кадере алдаудамыни?

Өйгә керделәр. Җиһангир карт кәгазьгә төргән унлыклардан җитмеш бишен санап, өстәл почмагына куйды. Тартынмады, кычкырып санап барды. Наталья, башын кага-кага, аның кул йөрешен барлап торды.

Карт, озак ягылмаган кышкы мунча ишегенә сарган бәс төсле кыска ак чәчле башын күтәреп, әүвәлгечә ян стенадагы рамнан Леушин рәсемен эзләп тапты. Аннары, эшне беткәнгә ишарәләп, аягына басты.

— Утыр,— диде хатын, почмакта газ кабызып, чәйнек куйды. Өстәлгә май, бал утыртты, почмактан башланган шешә алып чыгып, аның алдына бастырды, идән астыннан тозлы кыяр иелеп алды.

Явымсыз көзләргә, кыстатып кына килгән кышларга зарланышып чәй эчтеләр. Җиһангир карт, көзен көтүгә җыела алмыйча озак тулганган кара каргаларның ике тәүлектән соң әйләнеп кайтуларын, бер көннән соң тагын күздән югалуларын искә алды. Шуның белән язның иртә киләсен, ләкин озакка сузыласын юрады. Аннан, түземсезләнә башлап, сәгатьтән күзен алмас булды. Кайтасы ара эчен пошырды. Балга иренен тидермәде. Тешеннән сөзеп кенә ике-өч йотым аракы авыз итте. Чәйне шикәрсез, куе ясатып, сөт белән эчте. Маңгае тирләп чыкты. Күңеле ашыктырса да, кузгала алмады, утырды да утырды. Аракы җиңелчә генә башын әйләндерде. Күз алдында күгелҗем томан хасил булды. Бөтенләй оеп китеп, күз кабаклары йомылып-йомылып алды.

«Хәзер кинәнеп бер йокла иде»,— дип уйлады. Ни арада үзен печән чаба итеп күрде. Бер аягын сузып, икенчесен бөкләп утырган Сөмбеле тирән эчле тәлинкәгә яңа гына чишмә авызыннан алынган бидоннан сөт салган да шуңа тешли-тешли ипи турый, бер-ике уч җир җиләге салып җибәрә икән. Ә ул Сөмбелен печән белән күмә дә ашыга-ашыга казый, ә аннан хатынының кара чәч толымы түгел, талкыган җитен төсле булып, Натальяның аксыл-сары чәче тузгып чыга икән...

Җиһангир карт исенә килде. Түбәтәен җайлады да урындыктан алып бүреген киде:

— Рәхмәт, хозяюшка! — диде.— Күрәмсең, чыпчыклар казына — буранга,— дип, тәрәзәгә ымлады.

— Буранга,— дип кабатлады Наталья. Әле генә күргәндәй, өстәл почмагында орынусыз калган акча өемен бер кулы белән генә уртага бөкләп кулына алды да, теле белән бармак очын юешләп, санарга кереште.

— Ышанмыйсыңмәллә — саныйсың? — дип сорады карт.— Ә-ә, сакланганны алла саклаган, сана, сана... Әллә әзсенәсеңме? Соң мә, өстим. Шулай инде, нәфеснең төбе була димени...

Хатын күз кырые белән генә аның олтанлы итегеннән күзенә кадәр сөзеп минде дә тар алюмин балдаклы сул кулы белән аңа таба ун уңлыкны этәреп куйды.

— Дөрес әйтәсең, нәфес чиксез. Тик артык акча түләү юмартлык түгел,— диде.— Телең белән әйтергә кыймаганны акча белән яшереп буламы? Буламы, Җиган?

Әйтерсең лә юлдашы белән тыныч кына гәпләшеп барган җиреннән аяк чалып сугып ектылар. Сизми дә калды. Аягына баскач, җәберләүчесенә әйләнеп карагандай, гаҗәпсенеп Натальяга текәлде. Сугып егулары чын булса, гарьләнүеннән нишләргә белмәс иде. Хатынның инде күптәннән танып та, аерылышыр мәлдә генә, башка суккандай, Җиган дип эндәшүеннән кая качарга белмичә оялып китте. Күзен кыса төшеп, карашын читкә, өйдәге бердәнбер караватка юнәлдерде. Югалып калуы читтән ашты: «Саша кайда йоклый соң әле? Наталья ялгызы тора икән ич!» — дип уйлап алды. Пышылдап:

— Исәнме, Наталья,— диде.

«Ә мин тагы танырлыгым калмаган дип пошынам,— дип уйлады ул.— Әй, шулай булсачы!»

— Кеше дөнья тулы анысы. Ә һәрберсе тамгалы. Танымас дип уйладыңмы? — диде Наталья.

Җиһангир карт күңеленең тыелгысыз бер куркуга буйсынуына колак салды.

— Мин синең янга белеп кермәдем,— диде карт.— Йортың яңа, капкаң бүтән. Белгән булсам... Сыерым үлгәнгә мин гаепле түгел. Шулай ук якын авылларда рәтле бер сыер очрамаганга да.

— Ә сыерым кечкенә булганга гаепләме? Кыяфәткә ул да рәтле түгел.

— Ник алай дисең? — Җиһангир Наталья әйткәннәрнең асылына төшенми башлавын тойды. Хатынның сүз сөреше, таш кантарын уртада калдырып аккан су шикелле, аның аңын читләтеп үтә кебек иде.

— Ник алай дисең?.. Минем сыерга куйган үз бәям бар. Син биргәне күпкә артык.

— Бәяне кысыр дип куйгансың ич. Мин буаз дим. Артырга тиеш.

— Анысын да исәпләдем,— диде хатын.— Телеңне нидер тота синең. Акча белән шуны каплыйсың.

Үз-үзен ирексезләп көлгән итте дә Җиһангир карт зур башын чайкады:

— Юк, Наталья,— диде.— Әйтергә теләгәннәремнең барлы-юклысы шул: мин болай гына... Син ялгызың. Ә мин, чүтеки, ир кеше — хәлеңне җиңеләйтергә теләү генә. Теге чакны печән ишеп төшергән кебек.

— Юк. Кул астыңа улымның дәфтәре туры килгәне кебек!

Җиһангир карт Натальяга карады. Аның күзендә ялвару күрер кебек иде. Ләкин хатынның күз алмасындагы зәңгәрсу бер тапны гына шәйләп алды.

«Теге тапмы әллә, кояш табы?» — дип уйлады һәм Леушинның һәр искә килгәндә йөрәгендә кайнар учак булып уяна торган, «икебезнең беребез кайтсын, лейтенант» дигән сүзләрен яңадан ишеткәндәй булды. «Бурычны таш яуса да үтәргә кирәк. Гомер буе куенда граната йөртеп булмый. Бер шартлый ул. Тиеш»,— дип уйлады.

— Туры килеп начар иткәнмени? Мине синең белән табыштырган язмыш үз ялгышын шулай төзәтер чара тапкан икән — начар иткәнме?

— Тәки күргәнсең, белгәнсең икән,— диде Наталья.

Тирән итеп алган сулышын бер кавым чыгармый торды да, бөтен тәне белән сулап, урынына утырды. Кулындагы акчалары, көзге яфраклар кебек, аяк астына сибелде. Карт тезләнде, сизенмәстән шул акчаларны җыярга кулын сузды. Башын күтәрде. Натальяга карады. Әйтерсең лә үтәмәгән васыять өчен хатын алдына тезләнеп гафу сорый иде.

Нәрсә югалтты соң ул? Төн узып, кар күмгән юлдан печәнгә йөзтүбән яткан килеш авылына кайтканда, ул Наталья белән шулай очрашуын, язмыш шаяруы дип, уенга гына исәпләгән иде. Кире килер, Леушинның соңгы сүзен җиткерер, җаен табып, гомеренә кушып алган бурычны үтәр шикелле иде. Әмма: «Алай итсәм, амәнәт амәнәт булып каламы соң? Бурыч үтәвемне Наталья, Җәмәлҗан белән Әҗмәх халкы, Сөмбел ничек кабул итәр?» — дип, ни дә кыла алмады шул. Наталья моңа вак хаҗәт эстәү дип кенә карамас, хурланмас, хәтта җирәнмәс идемени?

Шушы уе, шушы шиге, шушы газабы Җиһангир күңеле белән Җәмәлҗан юлы өстенә сират күпере булып яткан иде. Чәчелгән акчаны җыярга дип, Наталья алдына тезләнгәч, шул күперне чыгуның никадәр гади булганлыгына исе китеп, хәрәкәтеннән язды. Кодрәтеннән килсә, җанындагы Леушин гозерен үти алмый йөргән елларын хәзер йодрыгына җыеп таш иткәнче кысар иде дә үкенеч белән тулы башын шуңа орыр иде кебек.

Әйе, бактың исә, тормыш гап-гади бер нәрсә икән. Кеше дигәнең аны үзе бутый икән дә, шуны урман ясап, адашып йөри икән.

«Шулай шул,— дип килеште ул. Уйларын бер-берсенә ябыштырган-дай, акчаларын бик пөхтәләп, йөзен йөзгә җыя барды. Бер карасаң, Наталья белән шулай очраштырып язмыш ялгышкан, иллә ялгышын төзәткән. Ә мин салам белән печәнне бутаган, аңсыз. Гөнаһымны юларга кыюлык җитмәгән — әйләнеч юлдан киттем шул. Сәлам булса да җиткезәсе калган!»

— Күргән идем, белгән идем,— диде ул. Аягына басты, җыйган акчаларын Наталья аерган унлыкларга кушты.— Синең сизенүең хак. Улыңның дәфтәре кул астына туры килде бит. Тыңла, сөйлим. Сөйләрлеге бер минут. Әйтер өчен күпме еллар кирәк булды. Бер минутта сөйләрлеккә бер гомер җитмәде. Әле дә ярый, сыерым үлде. Шулай инде, тереләргә үлгәннәр гел ярдәмгә килә. Ярдәмнәрен үлгәнче үк күрсәтеп калганнар. Сыер булып сыер, кеше булып кеше. Безнең тормыш — алар үлеме...

Сөйләнүеннән аңа җиңел булып калды. Наталья сыерын җитәкләп Җәмәлҗаннан чыгып киткәндә өйлә узган, эңгер-меңгер төшәргә берике сәгать кенә калган иде инде.

«Ярарсана калса,— дип юанды карт.— Әгәр сәгатенә өч чакрым тыйтакласам, биш сәгатьтән кайтып җитәм дә җитәм!»

— Себертә генә башлады менәтерә. Минуты белән буранларга тора. Әле дә ярый, җил каршы түгел, яннан...

Сыер, аркасын бөкрәйтеп, койрыгын күтәрде дә туктап калды.

«Ерак юлга чыгар алдыннан кеше дә йортында бер эшен эшләүчән,— дип уйлады карт.— Малныкы да кешечә. Сизә, күрәмсең».

Ул үзе дә бияләйләрен салып, эзәр итеп буган шарфка кыстырды, тун итәген ян-якка кайтарып салды... Аны салкын җилле һава туңдырып җибәрде. Натальядан чыгып китешли: «Юл астына»,— дип эчкән ике йотым аракы йокыны китерә. Ул моның узасын, бераздан тирли дә башласын белә иде. Ләкин ул тирләмәскә кирәклеген искәртеп куйды.

Атлап киттеләр. Картка ул сыер түгел, Натальяның үзен җитәкләгәндер шикелле иде. Хәзергесен түгел, ефәк кебек кылган чәчлесен. Бәлки зур сыер очрап, зур сыер сатып алу насыйп итсә дә, бу кадәрле үк тыныч канәгатьләнүле булмас иде ул.

«Юл авыр авырын. Аның каравы, кулга гына түгел, җанга да бәйле сыерга тиештем»,— дип куанды ул.

— Бирнәң зур булып чыкты синең, сыер,— дип эндәште ул барган уңайга. Сыерны бәйләгән нечкә капрон бауны иңбашыннан чалулап алып, култык астына элмәкле төенгә төйнәде.

— Бусы син кисәк тартылып ычкынмас өчен.

Ул яшьлегендә күрше авылдан алган бер танасының кулыннан ычкынуын һәм, койрыгын чәнчеп, байтак вакыт кыр буйлап чабулаганын хәтерләде.

«Бүген оныкны ияртәсе калган,— дип уйлады ул.— Арттан каулаучы булса, тизрәк кайтылыр иде».

— Әле дә ярый, Сөмбел чыгасы итмәгән. Натальяга сөйләнелми кала иде тагын. Белгәннән белмәгән хуш.

Сыер тыныч кына бара. Җәмәлҗаннан урманга күп йөрелгәнгә, юл тапталган, җил буйлый искәнгә, көрт салмый, һаваны кискәләгән кар бөртекләре куерган саен, кырдагы күз төртердәй таплар югала барды: кырның офыгы-күге бетте. Карт үзен дәфтәр бите буйлап бөҗәк сөйрәп барган кырмыска шикелле кечкенә итеп тойды.

Быел ул печән чапкан җиреннән тамак ялгарга утырган иде. Сумкасыннан суган кыяклары, май ягылган ипи телеме, ике йомырка чыгарып җиргә җәйгән гәзиткә куймакчы иде — аяк терәп яшел бер корт сөйрәгән кырмыска аларны шәйләп алды. Берсе, алданрак барганы, гәзиттән чыгып китте, арттагысы өлгерми калды. Кырмыска кырыйга җитәрәк, карт, уен ясап, кәгазьне борып куйды. Кырмысканың яңа гына килгән юлына каршы китүен көткән иде.

«Галәмәт тә булды шул,— дип искә төшерде карт. Ни дә булса уйласа, аңа рәхәт иде.— Капма-каршы борылып китте дә барды бит, тамаша! Кортын да ташламады».

Шул рәвешчә гәзитне өч кат әйләндерде, кырмыска адашмады. Әллә үз сукмагы исен ул гәзит аркылы да сизә иде шунда, әллә ул, кояшка карап барган юлчы кебек, үз күләгәсе торышын хәтерендә тота иде, әллә инде бу дөньяның соң бөҗәге дә, кешедән һич калышусыз, җирнең бар үзгәрешенә шулай җайлаша беләме?

«Гәзитне бер-ике адым читкәрәк күчергән булсам, нишләр иде икән ул?»

Карт җәй көне җавабын тапмаган шушы табышмакның башына килүенә шатланып куйды. Озын юлларны, ялгыз сәгатьләрне күңеле белән өнәмәсә дә, очы күренмәгән уйларны ярата иде. «Ахыры булган уй — узган көн кебек. Узган көн — үткән гомер». Шулай уйлап, уйларның чиксезлеге белән генә булса да, гомере ахырыннан ераклашырга тели иде. Әз йоклады. Йокысына төш керүне яратты. Моның һәммәсе, аныңча, гомерне озайта иде.

«Бу кыр да — гәзит кәгазе, ә минем сыер җитәклəп баруым — кырмысканың табыш сөйрәве түгелмени?» — дип уйлады карт.

Җәйге табышмагына кинәт җавап табуын бөтен ачыклыгы белән күреп өлгерде. Эченә курку йөгерде. Җавабын зиһененә теркәп куярга теләгән сыман, ул сыер белән үзен тоташтырган җепне учына кысты.

Хәзер буйлаган кырын гәзит кәгазе итеп нихәтле бормасыннар, карт үз авылы юнәлешеннән тайпылмасына шикләнмәде. «Кеше салган сукмакта сукыр да адашмый. Кармаланыр таягы гына булсын. Күзлегә ни кала?»

«Мин үз гәзитемне үзем борган. Борган, тик әүвәлге юнәлешне җуйганмын. Кырмыскага хәтле үз сукмагыннан язмады. Ә мин Леушин әйткән үтенеч юлында да миңгерәгән, аңгыра сарык».

Картның:

— Син бит кырмыскалы гәзитне бер урында гына әйләндереп тордың,— дип акланасы килде.— Ә синекен Наталья бер-ике адым читкәрәк күчереп куйган. Бөҗәкләр ис тә тояр, күләгәсен дә чамалар, җайлаша да белер. Ә син, кеше вөҗданы, ни ис, ни күләгә сизмисең, ни җайлашыр, ни посар урын белмисең шул. Адашуың хикмәте шунда.

Ул уйланып бару белән әллә җилнең үзгәрүен, әллә юлның борылышын сизми калды. Җил каршыдан исә башлады. Авыл ягына таба аның баш очыннан ялгыз козгын очып үтте.

«Баягы козгын. Кошларга рәхәт,— дип уйлады ул.— Ирекләләр — җил кая иссә, шунда очалар. Кирәк Җәмәлҗангә, кирәк Әҗмәхка».

— Алай дисәң, козгынның да үз авылы бар бит, әйеме, сыер? Бу юлы җил аңа аркан икән, аннан ник көнләшергә? Очсын, җилгә аркан очсын. Алай дисәң, җилгә каршы очу аларга җиңелрәк тә бугай әле. Шуңысына көнләшерлек, ичмасам. Без бит җилгә арка кую ягын чамалыйбыз.

Аягы үзеннән-үзе ашыга, ашыкканга күрә тая, җил каршылыгын җиңә алмыйча, ян-якка, хәтта артка да баса башлады. Сыерны бәйләгән бау әле бушады, әле картны артка каерып тартылды. Аның сулышы тигезсезләнде. Һава җитмәүдән авызы ачыла, сулыш юлына җил кереп тула, тончыктыра иде.

Дүрт-биш чакрымны ул шулай үтте. Буранга эләгүдән каушау галәмәте. Өнгә килеп, адымын акрынайтты, салмаклатты, тизлегенең әкренәймәвен белде. Тагын бер-ике чакрым атлагач, тизлеген дә киметте — аркасының тирли, күкрәгенең туңа башлаганын сизде. Буранга эләккәндә тирләүнең мөшкел хәл икәнен татып белә иде. Башта тән кыза да аннан кисәк арый, суына, ял сорый, йокы баса.

Зәңгәрләнеп күренгән урман инде стена булып каршыда торса да, әүвәлгедән дә ераграк төсмерләнеп, тоныкланып калган иде. Кар юллары баганаларга сузылган тимер чыбыклар сыман турайды, тартылды. Кояшка караган шикелле, күз кабакларын кыса, ачтырмый. Инде җил түгел, кар сызыклары сызгыра иде.

Сыер, картның көчен чамалаган сыман, туктый, моңарчы язмышына үпкәләгәндәй түбән иеп килгән башын күтәреп, каерылып-каерылып, килгән юлына таба борыла башлады. Аны урман шавы тынычсызлый иде. Ул җил, кар керми торган абзарын искә төшерде, йөгереп китсә, яңадан шунда булам, нечкә бауны өзә алам дип белә иде, күрәсең.

Тик ул үзенең бәйләнгәнен, көчлерәк тартылса, башына йөгән итеп кидерелгән бауның, кысылып, борынын каты авырттырасын белми иде.

Урманны ярып Зәй ягыннан Казанга таба сузылган тимер чыбыклар астындагы юлга кергәндә, эңгер-меңгер караңгылык белән алышынды.

«Инде сыерлы булдым. Ничә еллар уйлап йөргән әманәтеннән Наталья азат итте. Урманны гына чыгасы калды,— дип уйланды карт.— Кайтып житкәч, мич алдына тезләнеп җылыныр идем. Әле дә ярый, оныкны иярткәнмен, нишләр идең, ә?» — дип куанды. Ләкин бу уйны кычкырып әйтергә кыймады — урман шавы шомландыра иде. Ул аның һәр авазына колак сала-сала атлады. Берәр нәрсәдән өркеп, тартылып китмәсен дип, бавын сыер мөгезе төбеннәнрәк тотты, аның сулышын тойды. Аягы белән ниндидер йомшак нәрсәгә басты. «Нәрсә булыр икән?» дип уйлаганчы ук, аның саламмы, печәнме икәненә төшенде. Иелеп кулына алды, борынына люцерна исе бәрелде. Башта үзе иснәде, аннан сыерның борынына төртте:

— Аша, сыер. Хәл керер, юлыңны кыскартыр, шөгелең булыр. Йотмый күшәп бар.

Сыерының русчага күнеккән булуын исенә төшерде, сөйләгәнен чак кына русчага күчерә башламый калды. Бу омсынуына елмаеп куйды.

Урманда җил күкрәккә бәрми, читлектәге кош сыман бәреләсугыла исә, вакыт-вакыт хәтта арка яктан да этәреп җибәрә иде. Кар агымы тоташ басым белән каршыдан ябырылмый, әле яннан, әле өстән камчылый. Бер җепкә тагылган кеше белән сыерга кар агымы җилләп-җилләп кенә кагыла иде. Әмма һәр адым саен юл кыенлаша барды. Урман юлы Җәмәлҗән кырындагы кебек утырырга өлгермәгән, һәр баскан да, комнан барган сыман, артка чигә, итеге бата, кар ишелә, өч-дүрт адымга бер адымы югала иде. Шуңа күрә ул, кырыйгарак

чыгып, бер агач сындырып алды, ботакларыннан арындырып, таяныр-дай таяк ясады. Әрәмгә булмады, баруы ару гына уңайланды.

«Бүре эзләре турысын уздым бугай инде», дип уйлады ул. Күңеленә: «Әгәр килеп чыксалар? — дигән шик төште.— Аларга тагын... Берәр зоопаркта дөньяга килгән бүреләрдер әле. Хәзер чыны каян килсен?»

Урман авызына җитәрәк, күз алдында Әҗмәх кырыяктылыгы шәйләнә башлады дигәндә, карт, әйләнеп китеп, аркасы белән кинәт тартылган сиернең корсагына бәрелде. Сиерга арттан камчы белән сыдырып алдылар диярсең. Ул, арт санын җиргә ия төшеп, кырын-кырын чабулап китте. Карт, моны көтмәгәнгә, сөрлегеп китте. Егылмас өчен, уң кулы белән сиернең мөгез төбеннән тоткан бауны бушатырга мәҗбүр булды. Бау уч төбеннән шуган арада, ул аның үзенәрәк бәйләгән җирен сул кулы белән урап каптырды. Аягы таеп, аркасы белән янадан сиернең корсагына терәлеп калды.

— Шайтаныма дип ашкынасыңмы? — дип кычкырды карт. Ике куллап бауга ябышты да аягын терәде. Бияләй кигән килеш нечкә капрон бау белән сиер куәтен буйсындыруы әнәне уч белән тотып тегү тегүгә тиң иде. Карт кулларын алмаш-тилмәш ычкындырып, бияләйләрен берәм-берәм эзәренә кыстырды. Юешләнгән бау ялан кулны әчеттереп шуа иде. Карт аны азрак бушатып, урап тотты. Капронның кул сыртлары итенә батып керүен тойды, шул авыртуга түзүе белән сиернең карышуын сизде. Күрәсең, хәйләләп, көч белән тартканда борынын кысарлык итеп бәйләнгән бау сиернең каршылыгын җиңде. Ул, борыны белән карны сөзәр дәрәҗәдә аска игән башын бушатмаса да, чабулавыннан туктады, картны сөйрәп атлавында дәвам итте. Шуннан файдаланып, карт артка борылып карады. Күзенә ике ут ноктасы төсмерләнгәндәй булды. Башта ул моны күзенең әлҗе-мөлҗе килүе, арганлык галәмәте генә дип уйлаган иде. Игътибар белән карагач, алданганлыгын аңлады. Анда сүнә-кабына ике ут ноктасы шәйләнә иде. Картның ул утны көтеп торасы килде. Вакытын әрәм итмәде, тынычлыгын җуйган сиеры артыннан сөйрәлә бирде.

«Бакчы, трактор! — дип уйлады карт.— Ни әйтсәң дә, хайван сизгер шул. Күзе белән түгел, тәне белән күрә».

— Ә ник тавышы юк? — диде ул.

«Тавышын җил апкитә, урман шавы баса. Ерак, ахры, әле, нуры кар пәрдәсен ерта алмый».

Карт, яңадан каерылып, артка күз салды. Ут юкка чыккан иде. Аның караве, кар аклыгында ни икәне танылмас бер, аннан тагын бер шәүлә төсмерләнде. Шәүләләр, кояшка карагач күз алдында торган тонык ноктарлар сыман, туктаусыз кыймылдый, иллә кечерәеп ерагаймый, бәлки зураеп якыная бара иде. Карт кырын-кырын атлый бирде, юлдан күзен алмады.

Ул курка башлады. Урман шавы тантанасына әле генә сагаеп колак сала иде. Инде хәзер ул шауга күкрәгеннән күтәрелгән шом да кушылды. Кулы белән сиер тәненең, су өстен җил шадралап үткәндәге сыман, калтырануын тойды. Хайванның табигатьтәге теләсә нинди халәттән курыкмавын белә иде, буран көчле булса да, һава сиер туңып калтырар дәрәҗәдә салкын түгел иде. Нәкъ шушы чакны, аның зиһенендә ялкынланып кабынган утны дөресләгән шикелле, баягы ике ут төймәсе ялтырап алды, аның яшькелт елтыравы картның шигенә килеп кушылды.

— Бүреләр! — диде. Сиер ишетмәсен дигәндәй, пышылдап кына әйтте.— Теге бүреләр...

Аларның Җәмәлҗән урманына җибәрелгәнен ишеткәч:

— Балалар бүре улавының ни икәнен белми башлаганда — ни

хаҗәте бар икән? Бүресез дөнья, усаллыксыз тормыш булмый, күрәмсең. Бүредән курыкмаса, җәнлек аза шул,— дигән иде.

«Каян килеп җыен җыентык минем юлны кисә соң әле?» — дип уйлады карт пошынып.

Урманны чыкканчы бүреләр якынаймады. Егерме биш, утыз адымнардан һич калмый эзгә басып килделәр.

«Караңгыда кыймыйсызмы? — дип хурлады аларны карт.— Шулай шул, шүрләгәнгә кыр иркен».

Урманга кергәнче гел карулашып барган сыер, артыннан чыбык белән каулап баргандагы шикелле, кызу атлый иде.

«Әйтәм ич, әле дә ярый, оныкны, я Сөмбелне ияртмәгәнмен. Барыбер киректәре чыкмады. Алар урынына бүтән ярдәмчеләр — бүреләр бар»,— диде, тешен кысты.

Карт, сыерның сул ягына чыгып, таягын уң кулына алды. Ул әле таякның, таянып барудан бигрәк, нигә ярыйсын аныклап җиткермәгән иде, сырган чалбар кесәсендәге чәнти бармак озынлыгындагы, ләкин һәрчак тырнакка кабарлык кайраулы йөрткән тимер саплы пәкесен дә, файдасызга санап, учына алмаган иде.

Ул таягын пәкесе белән очлый алыр иде. Ләкин бүтәнчә эшләде: барган шәпкә таяк очын чәрдәкләндереп сындырып атты. Пәкесен чыгарып ачты да бүрек кайтармасы артына тыгып куйды. Хәзер аның иң кимендә беренче ташланган бүренең генә булса да тамагын теткәләрлек коралы, бүреләр үҗәтләнеп табыш даулаган мәлдә, иңбашыннан култык астына үткәреп бәйләгән бауны кисеп, сыерын ычкындырырлык пәкесе бар иде.

Һәм картның тагын: «Бүреләр бәлки урман чыкканчы гына эзәрлекләр, кыр ачыклыгына аяк баскач, үз юллары белән китәрләр», дип, күңелен юатып килгән зур өмете дә бар иде. Әнә шул өмет бүреләр белән алышуның котылгысызлыгын сизеп киерелгән тәнен йомшарта, зиһенен курку пошаманыннан арындырып аек тота, уйларына җитезлек бирә иде.

Урман авызын узып, ачык кырга килеп чыктылар. Карт бүрек колакчынын тарттырып бәйләде, күтәреп куелган якасын төшерде, муенына ураган шарфын бушата төште. Атлавы җиңеләйде, ләкин күлмәге манма тир булган иде, тәнен салкын өретте. Адым саен кемдер аның якасына тыгыла, күшеккән кулын аркасына тидереп ала кебек иде. Шуңа чиркануы белән бер мәлгә бүреләрне онытып торды.

Ышык урман артта калды. Аркылы-торкылы көртләр каплап бетерә язган трактор юлыннан бөгелә-сыгыла бару читен иде. Курыкмады, сөенде генә. «Юлсыз җиргә көрт ятмый,— дип уйлады ул.— Көрт еруы авыр авырын, бу көртләр — адаштырмас юл ич».

Аннары ул артка әйләнеп карады. Карлы эңгер-меңгернең аңа йодрык күтәргән карачкылары булып өч шәүлә кыймылдый иде. Урманны чыкканда алар, үләксә киртәсенә юл аласымы, әллә илле адым алдан борыннарын үртәп барган тере иткә теш батырасымы дип, әллә икеләнеп калганнар — хәзер инде борыннарын карга төртеп түгел, туры басып киләләр иде, ахрысы,— ара тиз кимеде. Карт аларның ниятләре катгый икәнен шуннан белде. «Җанвар туры килсә, күзен кан баса, дошман туры килсә, аңы томалана»,— дип уйлады.

— Ә миңа күз үткерлеге, аң җитезлеге өчен салкын канлы булу кирәк,— диде ул.— Ул чагында тагын бер-ике чакрым атлыйм әле мин,— дип ышанды.— Авылга якынрак чүтеки. Тизрәк табарлар.

«Ә син, картлач, алдан үзеңне күммә әле, яме? Дошман алдында ачык ишек түгел, кыя бул, үлмәс борын җан бирмә!» — дип сүкте ул үзен.

Ул сыерына күз салды. «Үз җаныңны гына саклау җиңелрәк җиңелгә. Сыерны ташладың киттең. Юк, кайткач эчәсе чәйнең тәмен боз-

мыйм әле. Тән сакларга калкан, җан сакларга хыянәт була, нәрсәнедер корбан итеп вөҗдан саклый алмыйм инде»,— дип уйлады ул.

— Син Наталья сыеры шул,— дип уена куәт бирде.— Бәһаң акча белән генә бәяләнми. Синң алмашка рус хатыны ире хәбәрен ишетте. Әсир дошман җанын саклап та унсигез егет корбан булды. Дошманнан дошманны яклап. Сине генә саклармын әле...

Карт инде артка борылып карамас булды. Уе белән генә бүреләр куып җитәр минутны секундларга бүлеп барды. Алтмыш адым атлагач, ирексездән иңбашын җыерып куйды, таягын югары күтәреп, кырт борылыйм, шуның белән бүреләрне сискәндереп төрле якка таратыйм дип барганда гына күзе яннан үтеп барган карачкыны шәйләде. Бүреләрнең берсе, аның юлына каршы төшәр өчен, әйләнгечтән уза иде.

«Кулда я балта, я камчы булса иде,— дип уйлады ул. Туңармын димәс, алмашка туны сорасалар да салып бирер иде хәзер.— Таяктан бүре түгел, үгез дә котыра гына». Ләкин ул уйдагы балтадан мәгънә тапмады: «Син таягыңны ничек мылтык итәргә икәнен уйла»,— диде. Җил кереп сулышын бумас өчен авызын ачмый гына әйткәнгә, тавышы ыңгырашу кебек кенә булып чыкты. Аның сүзен җөпләгәндәй, сыер да мөгрәп куйды. Атлаган саен аның эчендә нидер әле чапылдый, әле шапылдый иде.

— Синең дә карын ачкан, эчең буш,— диде карт, кыюлык өстәгәндәй, кулы белән аның муенына суккалап алды. Бияләен инде күптән салган булса да, кулы күшекмәгән, бармаклары иркен языла иде. Бармак битләре генә, кызышып, суга салган борчак кебек бүртенгән иде. «Зарарсыз, таяк түгел, лезвие тотып тырнак та кисеп була әле бу бармаклар белән».

Картның бүреләр үз юллары белән китәр дигән өмете, суга ыргыткан таш шикелле, аңында ризасызлык эзләре калдырып сүнде, югалды. Ерткычлар белән сугышуга үзен инде бөтенләе белән көйләп куйса да, ул моны теләми иде. Аның үзен җылы ятакта итеп тоясы килде, торналар турындагы төшен сагынды. Ә хәтере белән хәзер ул көрт баскан трактор юлыннан кырык беренче елда район үзәгенә илткән тузанлы юлга килеп чыкты. Ул чакны да аның һәр кичне Сөмбел белән тулган җылы урынынннан читкә китәсе, михнәткә, газаплы аянычка каршы атлыйсы, печән чабасы көчен нинди дер афәткә сарыф итәсе килмәгән иде. Ләкин ул, башка ирләр белән бергә, үзенең колхозда завхозлык йөген бергә тарткан Күгәрченкәй исемле аты җигелгән арбага утырып, Лашман күперен узды. Кулын бер мәлгә дә аның кулыннан алмыйча, янәшәсеннән Сөмбел атлаган иде. Шул чактагы йөрәген тырнап карышкан хисе картның эчендә яңадан уянды. Аның бүреләр белән дә сугышасы, тәнен аларга тешләтәсе килмәде, калган көчен юл көртләрен ера-ера авылга таба атлауга гына түгәргә теләде. Иртәгесен оныгы белән икәүләп Сөмбелнең яңа сыерны савып бетерүен көтеп торырлар, күз тимәсен дип, сыер ягына карамаслар иде. «Күрәсең, кешегә көрәшүсез ярамыйдыр,— дип уйлады ул.— Дөньяга килдеңме — син сугышчы. Бу юлы явызлыктан сыерны яклыйсы бар инде».

— «Күгәрченкәй» дигән теге байталга әйләнсәң икән дә мине атландырып очсаң икән син,— дип эндәште ул сыерына. Хәзер инде ул аңа кайсы телдә дәшүе белән кызыксынмады.

Сыерының кырт туктап калуына сискәнеп, алга текәлде. Биш адым алда, коеп куйган сын шикелле булып, бүре утырып тора иде. Карт арттагыларының да үзенә таба соңгы адымнарын атлавын яхшы аңлады. Алдагы ерткычның беренче хәрәкәте үк арттагы икесенә ыргыларга ишарә булачак иде.

«Телләре булса, алар: «Рус, бирел, син камаулы!» дип кычкырырлар иде микән?»

«Хәзер монда Леушиннарның берәрсе килеп чыксын иде дә, безнең дошман белән сугышканны читтән генә онытым карап торсын иде».

Теге чакны, күн пальто кигән немец офицерын Харитонов белән икәү уртага алып урманны чыкканда, бер кибән төбенә сулу алырга туктаганнар иде. Ертык балактан чыгып торган тез башы шикелле болыт сәләмәләреннән ай кырые күренгәли. Алар, салкын тиргә батып, печән кибәне төбенә чүгәләделәр, һәркайсы гыжлый-гыжлый сулу ала иде. Боты яралы Харитонов тыела алмыйча авыз эченнән генә ыңгыраша. Җиһангирның кибәнгә ышыкланыр хәле дә калмаган иде инде. Ул егерме чакрымлап инде алмаш-тилмәшләп әле әсир немецны, әле Харитоновны култык асларыннан күтәргәләп алып килде.

Арудан косар дәрәҗәдә сару кайнаган шушы мәлне, тавышларына буыла-буыла, урман эченнән өч эт чәчрәп чыкты. Күрәсең, эзәрлекләп килгән гитлерчылар, Леушиннар засадасын үткәннәр, янадан эзгә төшкәннәр иде. Этләрне байтактан ычкындырган булганнар, ахрысы, авызлары тулы күбеккә тончыга-тончыга, Җиһангирларга ташландылар. Җәһәт кенә автоматын эләктереп, Җиһангир берсен терәп диярлек атып екты. Анысы артыннан ук томырылып килгән икенчесенә пычагын куеп өлгерде.

Немец әсире чапаланып акырып җибәрде — этләрнең берсе, аны бәреп егып, тирән карда аунатa-аунатa талап ята иде. Харитонов, автоматын ташлап, пычагы белән эткә ябырылды. Җиһангир өлгерми калды — эсэсчы эт астыннан шуып чыкты да, карлыккан тамагы белән сулык-сулык һава йотып, суга батучы кеше таякка ябышкандай, Харитоновның автоматын эләктереп алды һәм бер йомгак булып бөтерелгән эт белән Харитоновка чатырдатып атып җибәрде. Җиһангир аны автомат түтәсе белән сугып артка элеп атканда, эш узган иде инде. Харитонов белән эт кочаклашып тынып калганнар иде.

Җиһангир, көчсез ярсу белән ыңгырашудан битәр, берни дә эшли алмады. Фашистның кулын бәйләде, авызына чүпрәк тутырды һәм якасыннан сөйрәп торгызды да кире урман ягына алып китте: яхшы аучы ерткычның эзенә арттан төшә...

Ә бүреләр нидер көтә иде. Алар этләр кебек котырына-буыла ташланмады. Явызлыкның сабыры дәһшәтлерәк шул.

«Юкка көтәсез», — дип уйлады карт. Ул әүвәлгечә үк ярсулык белән шашып искән җилдән һәм кар көрпәсеннән башын бора төшеп алга атлады. Сыер, каккан казыктай, кузгалмады, аягын терәп тора бирде. Бүре борылмый гына ике-өч адымга артка чигенде. Карт арттагыларына әйләнеп карады. Алары, алдагысы шикелле тик кенә утырмыйча, түземсезләнеп йөренә, иснәнәләр иде.

«Куркынычы сез түгел, — диде карт, аңлап алып. — Куркынычыгыз — алдагысы икән, йөртүчегез — шунысы».

— Таяк чыралары синең танауга насыйп икән! — дип кычкырды ул йөртүчегә.

Баш бүре, аның сүзен аңлап гарьләнгән шикелле, азау тешләрен шакылдатты, арт санына утырган җиреннән сыртын кабартып аягына басты.

«Сыерны калдырсам, син миңа юл бирер идең бирүен дә бит...»

Карт аның, нидәндер өркеп, кисәк читкә тайпылуын гына шәйләп алды. Җир кинәт каядыр оча, әйләнә башлады, аска-өскә сикеренде. Әйтерсең лә картны күренмәс канатларына элеп каядыр читкә алып атты, каршы торып булмастай бер көч аны кыр өстеннән сөйрәп китте. Шул көчкә мамык карышуы да күрсәтмичә буйсынды. Миеннән: «Арттан пычак тыкты, кабахәтләр!» — дигән ачынулы сүгенү йөгереп узды. Ләкин шул ук көч аны көрт салынган юлдан читкә шудырып чыгарды, кар өсләтеп сөйрәп китте. Шушында гына ул коты чыгып дулаган сыерның кыр буйлап үзен өстерәп киткәнен күрде. Көтелмәгән бу

хәрәкәт бүреләрне дә куркыткан иде: алар эре-эре сикерешеп бер күчкә өерелешеп калдылар.

«Сыер дуласа — бүредән яман», дип уйлады ул.

Бау картның күкрәгән кыса, сулышын буа иде. Бауның төене, култык астыннан иңбашына күчеп, муен төбеннән кысып алды. Гүя шул урынга кызган күмер китереп бастылар. Картның ютәле кузгалды. «Сыер ничек түзә икән, тиресен бау ярып, борын кимерчәге яньчелмәсә ярар иде».

Карт таягын төшереп калдырмады. Башта яны белән шуып барды, аннары йөзтүбән әйләнде. Күкрәгенә кар тулды. Ул эреп, суы күлмәген чылатты, корсагына акты. Сукаланган җир түмгәкләрен кар күмеп бетермәгән иде әле. Сул аягының тез башы кантарга бәрелде, аягы әрни башлады. Ул буш кулын алга сузды, бауга ябышты, күкрәген бушандырасы килде. Карлы, юеш бау шуа, нечкә булганга, аны бармаклар тота алмый иде. Ул кулын ычкындырды, астан алдырып бауны беләгенә урады. Болай тотар өчен терсәкне бөгәргә кирәк булды. Ләкин каткаклыкка терсәге дә бәрелде. Кулының җегәре бетте, бармаклары бушап язылды. Ул бауга таяк тоткан учы белән дә ябышты. Күкрәк белән ятып баруы кыенлашты. Бер мәл тигезлеген югалтты, янга авышты, аркан ук әйләнә язды, иңбашы белән талпынып кире корсагына борылам дигәндә, бите җиргә тиеп сыдырылып алды. Авырту сизелмәде, битен юеш кар белән уган шикелле генә тоелды.

«Бүреләргә иң җайлы мәл, — дип уйлады ул. — Куып җитәсе дә сикерәсе. Бу хәлне көтмәделәр шул».

Карт, муены буылмасын өчен, башын янга салып өстерәлә иде. Кулында тартылып, бауны бер-ике карыш бушата алды. Ләкин җеп уч тиресен сыдырттырды, шуганнан-шуа барды. Бушаган кадәресе яңадан тартылмасын өчен, бауны учына урады. Күшексә дә, ачылмас булып йомылган йодрык чыдамады — пычак тыгып каерылган бака кашыгы кебек ачыла башлады. Бау кул сыртын ярып керде.

Түзәр әмәле калмый, җегәре бетә дигәндә генә, сыер сөрлегеп китте. «Вакыт!» — диде карт. Бау йомшап калды. Ул артка каерылды, бауга тартылып тезенә калыкты, аягына басты. Сыер сөрлеккән җиреннән тезләнгән иде, тураерга өлгермәде. Карт җилпенеп килеп аның борыныннан кысты.

Сыерның селәгәе ага, ул авырлык белән пошкыра-пошкыра сулый: бау кыскан борыныннан канлы күбек чәчри иде.

«Әҗәлдән аяк качырса, иң элек мин чабар идем, җүләр!» — дип сүкте ул сыерын.

Сыер артыннан озак сөйрәлгән кебек иде. Әйләнгәли-әйләнгәли тыпырчынып, ычкынырга ярсынган сыерын тыя-тыя: «Җитмеш адымнар»,— дип уйлады. Сөйрәлеп килгән эзен тапты, буран пәрдәсенә караш ташлады: арт саннарын сикертә-сикертә, аңа бүреләр якынлаша иде.

— Ә, иске дуслар, түрдән узыгыз,— диде ул. Күшеккән, кан катыш карлы бармаклары белән кармаланып бүрек кайтармасыннан пәкесен алды. Бауны кисеп җибәрде. — Берәрегез әҗәл тансыклаган, ахры. Соң, кунакка — теләгән ризыгы!..

Тез буынының җиңелчә калтырый башлавын әнә шулай көр тавыш белән басарга теләде. Бүреләр якынайганнан-якынайды, зурайганнан-зурайды. Сыер, тынгысызланып, читкә сөйрәде, ләкин карт аның казналыгы астыннан ураган баудан кулын ычкындырмады: «Әх, сыер, кечкенә булсаң да, сөтең күп иде лә».

Ул сыеры белән дә, Сөмбеле белән дә хушлашуын аңлады.

«Бу сыерга кем дошманрак икән: минме, әллә бүреме?» — дигән сорау килде кинәт.

Карт соравына җавап эзләп мәшәкатьләнмәде. Сатып алып, җылы абзарыннан ялан кыр аша чит-ят җиргә җитәкләп киткән, эштән чыкканда аны я симертеп суя, я иткә озата торган адәм белән җылы канга сусаган ач бүре арасында ни аерма бар соң сыер күзеннән карaганда?

«Кеше кешелеклерәк, — дип уйлады карт. — Бүре үзенең җанын асрамакка кан эчә. Ә мин онытыма сөт булсынга җиде көн эзләдем бит. Тапкач менә сатып алдым. Натальяга сыерын сату кирәк булганга сатып алдым...»

Түземсезләнеп йөренгән бүреләр, үзләрен моңарчы читтә тоткан куркуларын җиңеп, янәшә үк килеп бастылар. Аларны хәзер кеше исе генә җибәрми тотып тора иде. Бүреләр менә-менә карт белән сыерга ташланыр дәрәҗәгә җиткәнче кызганнар иде инде.

Аларның якынлашуын күзәтеп, Җиһангир карт баш бүренең уртада, ләкин бер кадәр арттанрак атлавын күреп алды.

«Явызлык дөньясында шулай инде, көчле көчсез артына поса. Алай иткәндә калҗаның майлырагы тия аларга, — дип уйлады карт. — Безнең командирлар гына алдан йөгерде шул, аларны без атлап үттек. Немецларныкы үлек аша атлап йөрде».

Ул бер мәлгә үзенең кайда икәнлегән зиһененнән җуеп торды. Разведкадан кайтышымы? Ләкин ул, хәйләкәр җәнлек кебек, үзен аулап килгән ярты дистә немец чаңгычысыннан качып калганда, тавыш чыгармасын дип, әсир немецның изүеннән каптырмаган, ә бәлки вакытыннан элек кыр буйлап дулап чапмасын өчен сыерны тыеп тора. Төш күрәме? Ләкин аның күз алдында торналар биегән томан рәшәләнми, бәлки битне буран энәләре чәнчи дә, учы суелган һәм сырты ярылган куллар сызлый.

Баш бүре карт ягында кыймыйчарак атлаган бүрегә тамак төбе белән ырылдап, аның арт санын тешләп алды. Тегесе үзен кыерсытканга ырылдады да, борылып та тормыйча диярлек, картка сикерде.

— Син түз инде, сыер, бигайбә, — дип сызланды карт. Сыерны тоткан бауны ычкындырды да ике куллап таягын бүрегә төбәде. Бу юлы кадамады, читкә тайпылып калды. Бүре, сөрлегеп, карга барып төште. Үрсәләнеп тыпырчынды да кабалана-кабалана картка таба борылды. Карт бу юлы таякны әрнеп әчеткән уң кулына алды, бүрене көтте. Бүредән бүтән берни күрмәсә дә, койрыгын чәнчеп кыр буйлап җилеп киткән сыерын уе белән озатып калды. Ау дәрте бугазларына чыелдык улау булып тулган ике бүре аның артыннан томырылды. Кайдадыр читтәрәк аларның ярсып-ярсып ырылдаулары ишетелде.

Карт бу вакытта, гәүдәсен як-якка айкап, каршысындагы ерткычны алдап торды. Һәм пәке тоткан сул кулын, бүрене котыртып, капылт өскә күтәрде дә алданып бушлыкка сикергән ерткычның авызына очы чәрдәкле таягын тыкты. Болай ук туры китерермен дип көтмәгән иде. Кисәк талпынып алга атлады, таяк чәйнәп ярсыган бүрене җиргә кысты. Сулыш юлына ерткыч авызыннан аңкыган сасы ис бәреп керде.

«Бүресенең дә рәтлесе туры килмәде,— дип әллә үкенде, әллә шатланды ул. — Ичмасам, кешечә сугышып та булмады, әрвах!»

Бүре чәбәләнә, тик башын җиргә кыскан таяк аның тешеннән үткенрәк булып чыкты. Авыртуга түзә алмыйча хырылдады, аяклары белән кар тузгытты, туң җир тырнады. Хырылдавы башта улауга, аннан сулкылдаулы чыелдауга күчте.

«Әгәр ул көчле бүре булган булса, сыртына әйләнеп ычкына алыр иде», — дип уйлады карт.

Бүре, нәкъ ул уйлаганны ишеткән шикелле, кисәк кенә аркасына әйләнде, башын таяк астыннан суырып алды. Әмма карт таягын ташлап, күкрәге белән бүренең башына капланды, сасы искә чыдый алмыйча, сулышын тыйды. Шушында гына ул баш бүренең үзен алдаганын белеп

алды. Ул сугышкан бүре чыннан да авыру булган, күрәсең, аның кабыргалары, юеш кер белән капланган сырлы бәләк шикелле, тире астыннан бүлтәеп, сизелеп тора иде.

«Ичмасам, бер кешечә сугышырга да насыйп итмәде,— дип үкенде карт.— Бәлкем бу соңгысы булгандыр».

Бүре боргалана-сыргалана иде. Карт сул аягы һәм уң тезе белән аның муенына басты да, үрелеп, арт сыйракларыннан каптырып алды. Бүренең гәүдәсен сындырырга теләгәндәй бөкте һәм арт санын югары күтәреп кисәк аягына басты. Бүре зәһәр ырылдый, ал санын җиргә бәрәбәрә тапырчына, ләкин ул арык, хәлсез, җитмәсә, шүре җибәрүдән аяклары буялып, кар белән укмашып юешләнгән иде. Карт, җирәнүдән нишләргә белмичә, аның корсак астына типте дә үзеннән этәреп җибәрде. Ялгышмады: бүре ычкыну белән читкә ташланды һәм буран пәрдәсенә уралып күренмәс булды.

— Әле дә ярый, оныкны ияртмәгәнмен, — дип куанды карт. — Хурлыгымны күрмәде.

«Әй син дөресен әйт, картлач: синең бит бу бүрене үтерәсең, авылга алып кайтып кешеләргә күрсәтәсең килгән иде, — дип битәрләде ул үзүзен. — Янәсе, ул сыерын зергә корбан итмәгән».

— Ләкин сиңа бу юлы, немец очучысын тапшыргандагы кебек, һәлак булганнар өчен җиңү шатлыгыннан елау насыйп булмады, — диде ул. — Буялып кына калдың.

Ул, иелеп, кулларын кар белән ышкып юды, әмма сасы истән котыла алмады. Моңа гарьләнде, горурлыгыннан оялды.

Ул хәзер генә аңкавы, теле белән тамак төбенә йон ябышып беткәнен тойды. Бүре йоны икәнен аңлагач, авызында да кулына сеңеп калган ис тәмен тойды. Печән салып сасыткан зәңгәрсу-яшел су күз алдына килде. Ул теле белән айкап бар төкереген җыйды да, аңа гарьлеген дә кушып, җил уңаена, алдакчы бүреләр аның сыерын куып киткән якка төкерде.

— Җиндем дип улыйсызмы? — дип кычкырды карт. — Сезгә тагын, адәм кызгануы аркасында гына яланга, азатлыкка эләккән мәхлукләр! Сез мине алдадыгыз гына, менә шул,— дип өстәде.— Җиңелгәннең күңеле сызлый, җаны сыкрый аның. Ә минем, — дип пышылдады ул, — яңак сызлый, җеп сыдырып суйган кул сызлый. Бавы асыл иде, җинел, нык иде. Әрәм булды. Пәке дә төшеп калды, ярар, хәерле булсын.

Караңгы иде. Тирә-юнь кар аклыгыннан яктырып тора, ләкин дүртбиш сажин ары, текә яр кебек, караңгылык башлана иде. Картның уенча, авылга җитәргә дүрт чакрым бар иде әле. Ул юлга чыгып торуны кирәкмәс санады, җил һәм буранга каршы атлап китте. Кар тирән түгел, әмма көзеннән сукаланып калган җир уентыклы-чокырлы, баруы авыр иде. Бияләйләре эзәргә кыстырылган җиреннән сыер сөйрәгәндә төшеп калган. Кулларын җиң очларына тыккан һәм башын игән көйгә атлады да атлады. Кыр чиксез, ә аның кыл уртасында, җансыз бушлыкның яралы йөрәге булып, Җиһангир карт бара иде.

«Син артык тиз ярлыкадың үзеңне, — дип уйлады карт. — Тиз канәгатьләндең. Сыер белән бергә җан тынычлыгы да таптың дип зрә уйладың».

— Бүгенге михнәтең шуның хикмәте, — диде ул.

Ул тамак төбенә утырган төенгә буылып, бернинди оялусыз елый башлады.

Шуннан соң бераз тынычланса да, аның кәефе күрәймәде. Бүреләрдән җиңелүе бер хәл, Наталья алдында ачылып сөйләгәннән генә, яз җылысы белән калай түбәдән кар шуып төшкән кебек, иңнән бурыч йөге шуып төшми икән шул. Карт өеннән ни белән чыгып китсә, шуның белән кайтып керәсенә ризалашты.

Берни үзгәрмәде. Ул, йөрәгендәге җәрәхәтенең, әйләндереп киюдән керле икәне күренгән күлмәк кебек, бөтен кешегә күренерлек яралар кыяфәтендә битенә һәм кулына төшкәнен генә белде. Ул тагын итен бүреләр умыра-умыра ашаган сыерын күз алдына китерде. Сыеры урынына үзе ятып калган кебек тоелды. Аның тәне дә, сыерның канлы гәүдәсе кебек, берни тоймый, авыртмый иде инде.

«Тормыш — кыр икән шул, — дип уйлады ул. — Аның каршы искән җиле кечкенә булса да, син иң зуры дип исәпләгән табышыңны йолкып алыр бүреләре бар, — дип күз алдына китерде һәм: — Ләкин адәм баласының ул кырны чыгып җылы өйгә кайтып егылыр әмәле бар, — дип өстәде. — Иң кирәге — кайтып егылыр йортың, сөйләшеп юатыр һәм юмаланыр кешең, түшәк-ястыгың булу».

Карт карга тезләнде, өенә җитеп ятагына ятам дип саташа башлады. Кар әлпәсе аша колхоз фермалары янындагы тоныкутларны шәйләп алды да, бөтен зиһене белән ыңгырашып, аягына басты.

«Каршы булса да, җил мине алдамады, — диде ул. Уен эчтән уйлыймы, кычкырып әйтәме — аермый иде инде. — Җил мине алдамады».

Җил көчәйде, кар диңгезендәге җилкән итеп, картка ябырылды. Ферма каралтыларын узган чакта да, караңгылык бөркәнеп йоклаган авыл урамына килеп кергәч тә, җил аны берничә мәртәбә аяктан екты. Соңгы тапкыр исә җил аны инеш бозына кергәч сузып салды. Карт, канаты каерылган кош кебек, кулларын артка җәеп йөзтүбән килеп төште. Борыныннан шарлап кан китте. Ул аны туктатырга омтылмады. Аягына басарга талпынды. Тагын таеп егылудан куркып, басасы итмәде, яр кырыена мүкәләп чыкты, бераз хәл алгач, ат юлыннан югары үрмәләде. Өенең капкасына килеп җиткәнче, бер яклы урам каршындагы озын зират рәшәткәсенә аркасы белән таянып, әллә ничә тапкыр ял итте.

Капканы озак кагарга туры килмәде. Уты сүндерелмәгән өендә, бөтен тәрәзәне күз-колак итеп, аны күптән көткәннәр икән.

— Кем анда? — дип кычкырдылар.

— Мин лә, кем булсын, — дип җавап кайтарды Җиһангир карт.

Ишегалдын болдырдан төшкән ут яктыртты. Карт, капкага сөялгән жиреннән такта ярыгына иелеп, Сөмбеленең кабалана-кабалана капкага ашыгуын күзәтте.

— Сәгать ун бит инде, кунарсың дип торам, — диде Сөмбел. Бикләгеч кендекне шудырып, кече капканы ачты. — Алай да самавар куюлы, яңа кайнады.

— Су гына бирерсең, — диде карт. — Миңа су гына кирәк.

— Кем белгән буранлыйсын... Көнең тагын заяга узган. Кыш уртасы ич, кай җүләр сыер сатсын.

— Заяга шул, — диде карт. — Адаштым. Бер юлдан яздыңмы — гомер буе адашыла икән.

— Кендеге бер килмәсә килми инде.

Сөйләнә-сөйләнә, түм-түгәрәк гәүдәле Сөмбел карчык, картының култык астына кереп, аны өйгә таба җитәкләде. Ләкин читтән караганда, култык астына кыстырып, Сөмбелен Җиһангир карт үзе күтәреп бара кебек иде.

— Малай нишли? — дип сорады ул өйалдында.

— Уйный, — диде Сөмбел.

— Ник йокламыйсың? — дип сорады ул өйгә кергәч оныгыннан.

Малай бөтен җиренә умач-умач кар укмашкан бабасына көндәгечә кызганып карады.

Карт чиләнеп төенләнгән бүрек бавын чишә алмады, бармаклары тотмый иде. Аның бүреген чишәм дип кармаланган Сөмбел карчык кабаланып картының кулына ябышты:

— Аба-ау! Битең өшегән ич! Тиресен суеп төшерден ләбаса!

— Өшеде шул, — диде карт. — Бөтен җан өшеде.

Чишенеп бетергәч, аны бизгәк алды: калтырана, бөтен тән итләре белән дерелди башлады.

— Син нишләдең? — диде малай. — Канап беткәнсең.

— Бер нишләмәдем, — дип җавап бирде ул. — Адаштым гына. Җәмәлҗән юлы адаштыра ул. Син юк чакта бер адаштырган иде инде... Ник ятмыйсың? — дип сорады.

— Сарык бәрәнләде ич! — диде малай. Йөгереп барып почмак чаршавын ачты. — Өчне! Берсе тәкә, икесе бикәч!

— Каян беләсең?

— Әби әйтте.

Сөмбел тыштан каз мае алып керде:

— Битеңә сөртик.

— Кирәкми. Исен сөймим. Су китер.

— Әби, тәкәне печәбез, ди, — диде малай.

Карт сырган чалбарын, тән җылыткычын салып утыргычка куйды да диванга барып ятты. Өстенә, баштанаяк бөркәнеп, юрган япты. Юрган кырыен күтәрә төшеп, малайга эндәште:

— Печмибез, улым. Малай икән, малай булсын! Аның бәхете шунда.

Сулы стакан тотып кече өйдән Сөмбел кергәндә, ул йокыга киткән иде инде. Стаканын куймыйча юрганны ачып, аның йөзенә карады. Картның маңгаена, салкыннан кергән балта йөзлегенә пар тамчылары кунган шикелле, борчак-борчак тир бәреп чыккан, яралы яңагында шундый ук кан энҗеләре җемелдәп тора иде.

Бер кавым икеләнеп торгач, Сөмбел картының иңбашыннан селекте:

— Су эч әле, су. Тәнең яна, — диде. Карты уянгач: — Яңагың өшемәгән ич синең, тиресе сыдырылган, — дип өстәде.

Карт, башын калкытып, күзен ачмый гына су эчте, күзен ачмый гына:

— Бу юлы шәп сыер тапкан идем, — диде. — Сиңа охшаган: кечкенә, нык бәдәнле. Бүреләр талады.

— Син нишләдең?

— Бер нишләмәдем. Өйгә кайттым.

— Бүре бармыни әле? — дип сорады малай.

— Бар, улым, — диде карт, малайның башыннан сыйпады. — Бүреләр бар әле.

— Миңа да очрар микән берәрсе?

Ул малайның соравын ишетмәдеме: яңы белән мендәргә аумас борын йоклап китте.

— Бәлки очрар, — диде Сөмбел.

Иртә белән алар өенә ферма мөдире Зыятдин керде. Җил кичәгедән дә көчлерәк исә. Карт торган, икесен култык астына үзе кыстырып, берсен малайга тоттырып бәрәннәрне имезергә сарайга чыгарган, ашапэчкән иде. Зыятдин кергәндә, ул яңабаштан Сөмбеленең шәлен бөркәнеп, диванга сузылып яткан иде инде.

— Әх, бураны! — дип, кулларын угалады Зыятдин.

— Күз тидермә, — диде карт. — Басуларның җәрәхәтен күмә ул.

— Җәрәхәтен?

— Җәрәхәтен.

— Әй-ә! Көзлекләр өшегәнне әйтәсеңдер.

— Ы-ы. Шуны әйтәм.

— Җан җылады шул беркавым, — диде Зыятдин.

— Язын тагын яшьләнер әле. Яшьләнер дә яшәрер.

— А-а! Күпме җирне яңадан чәчәсе!

— Җир кабат та чәчелә, — диде карт. — Кабат яшәп булсае!

— Нишләр идең, Җиһангир абзый?

— Шул җирләрне чәчәр идем, Зыятдин олан.

— Туелмадымыни әле?

— Әйтәсең дә инде, әй! Рәнжетермен димисең. Ипи белән эштән туяр исәп кемдә булсын?

Җиһангир карт Зыятдинга таба борылмады: сыдырылган яңагын күрсәтәсе килмәде.

— Ни, Җиһангир абзый, аңысы да моңысы, хәбәр китердем әле.

— Синең хәбәр бер инде, эшкә үгетләү.

— Бүген ниткән эш, буран ич. Председатель дәшә. Идарәдә хәл иттек кичә. Сыер бирәбез.

— Сыер? Язга хәтле булмый дигән иде ич әле.

— Ничек икәнен сорама — юнәттек. Бер колхозга бер каза малмыни? Сыер фәрештә түгел.

— Ертыкка ямау ише генә булмаса инде, — диде карт. Ул торып утырды. Аның куллары чүпрәк тасма белән уралган, битенә әллә ничә төштән шырпы кабының күкертле кәгазе ябыштырылган иде. — Сыер булса, синең күзлекләрең шикелле кадерләп сөйләрлеге булсын.

— Андые ук артмый шул, Җиһангир абзый. Иллә буаз.

— Кайчан төшәсе ди соң?

— Бүген кычытканны иртәгә кашыйсы итмә инде.

— Аңысына, гомер үтеп, Сөмбел апаң зарланмады, — диде Җиһангир карт һәм малайга эндәште: — Ишетәмсең, Солтан, берәр киндерә тап әле. Сыер алырга барабыз. Кара әле, малай, — диде ул Зыятдинга, — бер энәдән күпме мәшәкать. Каян эләккән диген.

— Яткан җирендә булгандыр инде.

— Энә булып та саламда югалып калмаган, каһәр, җан иясе йөрәгенә барып чәнчелгән, ә?

— Мәшәкатьләр — бер энәдән, бер дөядән инде, Җиһангир абзый.

— Энәсен дә татып карасын дигәндер инде. Дөя ише тау-тау мәшәкатьләрне әзме күтәрде безнең башкайлар... Үзми дә, куймый да.

— Бер башлана, бер ташлана... Яшәү дигән нәмәстә шул буладыр инде...

— Әйдә соң, кузгалыйк, — диде Җиһангир карт Зыятдин белән оныгына һәм киенә башлады. Тәне һаман сызлый иде әле аның.

Бөтен җирен кар сырган Сөмбел чишмәдән кайтып төште.

— Кая кузгалдың тагын? — дип сорады ул.

— Сыер алырга, — диде Җиһангир карт.

Январь-март, 1975 ел.

## Фәннур Сафин

### Кичегү

Кичегәбез кайчак бер мизгелгә,
ә кайвакыт гомер буена.
Кичегәбез әткәй үлеменә
яки сөйгән ярның туена.

Кичегәбез...
Йолдыз нуры кебек,
соңга калып килә шигырьләр.
Таңга калып, нурга үрелгәндә,
ут эчендә була гомерләр...

Кемнәр килер, нинди куллар белән
бәйли алыр күңел ярасын?
Ә хәзергә Җирем йоклый кочып
хакыйкатьне — күкрәк баласын...

### Буран

Буран!
Күм дә бу иске йортны
табылмаслык итеп,
уят якын дусларны
тәрәзәләрен чиртеп!

Йоклый торган төнмени,
ярсый, кайный буран,
күңелләрне актарып,
куырып ала торган!..

Бураннан ярсу язның
хуш исләре аңкый,
әйтерсең ерак йортта
өмет уты балкый...

...Ак ялкын уртасында
тетрәнә йорт-курам...
Яшьлек җыена юлга,
күңелендә — буран.

●

Нинди озын юл бу — гомер!..
Әкрен генә барам бу юлдан.
Йөрәгемә маңгай сырларыдай
буразналар гүя уелган...

Нинди кыска юл бу — гомер!..
Очып үтәм еллар арасын!
Синең кулдай йомшак җитез җилләр
сыйпап ала йөрәк ярасын...

●

Үзәннәрдә йөрдек ялан аяк,
үләннәрне сыйпап, җил кебек...
Ярларыңнан төштек, и туган як,
үрләреңә мендек җилкенеп...

Кайгыларын җирнең йотып бардык,
нәкъ йөрәккә төште утлары...
Чын дусларын илнең югалтмадык,
нинди генә дулкын сукмады!

Сизелми дә узган чирек гасыр,
сизелми дә узган гәпләшеп.
...Кемнәр өчен шулай ялкынланып
чәчәк аткан идең син, яшьлек?!

## Чын йөрәктән

Чык йөрәктән, зинһар, чык йөрәктән,
канатларым чөеп давылларга,
мин ялварып әйтәм чын йөрәктән:
— Чык йөрәктән...

Ялган мәхәббәтне кичермиләр.
Зур дауларны кичә алган ирләр
ялган хисләр белән исермиләр...
Кичермиләр...

Чык йөрәктән, зинһар, чык йөрәктән,
үз-үземә кинәт гаҗәпләнеп,
мин пышылдыйм сиңа чын йөрәктән:
— Чык йөрәктән...

●

Биек-биек тупыллардан
төште өйгә күләгә...
Төне буе яуды яфрак,
сибәләде түбәгә...

Кызгылт-сары яфрак яуды,
кар да түгел, югыйсә.
Чигәләрен ак бәс сарды,
яшь икәнен белмичә!

Ябь-яшь егет ап-ак килеш
керде нәфрәт иленә.
Ә күңеле әверелде
дулкын тынмас Иделгә!

## Хушлашырга ашыкма

Хушлаштың да китеп бардың.
Аерылу авыр бит!..
Күзләреңнең моңын
Йөрәгемә салыйм,
Тукта, дустым, сабыр ит!

Гомер буе ярсу йөрәк
Сине сагынып сулкылдар...
Иделләрдә дулкын, —
Чү, ашыкма, дустым! —
Күңелдә ул дулкыннар!..

Сайрар кошлар синсез нишләр,
Ничек агар бу сулар?
Урман ничек шаулар,
Ишелмәсме таулар? —
Икебез дә моңсулар!..

●

Әле якты көннәргә,
әле кара төннәргә,
әле ал-гөл язларга,
әле сары көзләргә
теплоходта, арбада,
татлы хыял-сүзләрдә
без барабыз, барабыз!
Оча гомер-паровоз!..

Алга сузып кулларны,
үттек озын юлларны.
Капма-каршы йөгердек,
күрешергә үрелдек.
Ә син бераз ялгыштың,
күрмәмешкә салыштың...

Без барабыз, барабыз!
Һаман ерак арабыз...

## Төнге болын

Шундый якты мөлаем төн!
Нинди төндер...
Йолдызларга чөеп җанын
җырлый кемдер.

Кибәннәре кабатланмас
матурлыктыр.
Печәннәрен иснәп туймый
ятарлык бер!

Чалгычылар җыры килә
офыклардан —
кызлар яулык болгап калган
кызыл ярдан...

Кырык бердә киткән алар,
чалгы кадап.
Яшь йөрәкләр тулы яра —
балдак-балдак...

Җыр шикелле ягымлы төн,
үзе моңлы.
Бүгенге төннең нигәдер
күзе дымлы...

## Нәҗибә Әминова

●

Илдә давыллар басылган,
Сугышлар инде тынган.
Дус кылычы күптән кында,
Дошман кылычы сынган.

Икмәк исе генә аңкый,
Дары исе юк инде,
Саубуллашу зәңгәр төстә,
Сары төсе юк инде.

Кайтасын белә ирләрнең
Солдатка киткәне дә.
Һәм әйләнеп кайта җиргә
Йолдызга җиткәне дә!..

Давыллар басылган илдә,
Сугышлар инде тынган.
Ә бит...
Кылычлар саклана
Суырылмаса да кыннан.

Туган өеннән солдатка
Малайлар һаман китә,
Тыныч тормышлы урамнан
Һаман солдатлар үтә.

Илдә бар да, җирдә юк шул
Тынычлык дигән Чынлык.
Кындагы кылычлар белән
Саклана әле Тынлык...

●

Вак сагышлар,
Вак бәхетләр белән
Күпме гомер җирдә үтәдер...
И бөеклек,
Кер дә күңелләргә,
Матур бер хис булып күтәрел.

Кеше жаны
Ваклыклардан өстен,
Вак хисләрдән булсын югары.
...Данны түгел,
Кеше
Күңелендә бер
Балкыр таңны көтә нибары...

●

Унсигездә үпкәләшкәнбез дә
Яшьлек үтәр дип белмәгәнбез,
Бәхет гөлен бөгелеп алыр өчен
Беребез дә иелмәгәнбез.

Вак хисләрдән өстен булыр идем,
Кайтаралсам кабат шул чакны.
Кабызырга үзем иелер идем
Моңсуланып калган учакны.

Безнең язмыш язылыр дәфтәр битен
Бер сыначы тагын очраштырып
Бер сыначы тагын очраштырып
Шул унсигез яшьлек чак итеп...

**Вакыйф Нуруллин**

# ЯШЬНӘП ҮТКӘН ЯШЬЛЕК

ПОВЕСТЬ

5



Әш майтара алырдай һәм совет властена турылыклы кешеләрне табып, Карый волкомын яңабаштан оештырганчы атнадан артык вакыт үтеп китте. Ярый әле, Сәгыйдулла абзыйның малае Фәйзулла булды. Миңнулла шикелле яшьтән революцион түгәрәкләрдә катнашып йөргән кеше булмаса да, сәяси яктан бик әйбәт мәгълүматлы һәм акыллы егет иде ул. Кулына эләккән газеталарны, китап һәм брошюраларны берсен дә калдырмыйча укып бара икән. Унынчы сентябрьдә Казанның, уникенче сентябрьдә Сембернең аклардан азат ителүен дә белә. Ленинга һөҗүм булганын да ишеткән иде. Тик, Ленин тикле Ленинга атарга кемнең кулы барсын икән дип, ул хәбәрнең чыннан да дөрес булуына гына ышанмаган. Хәтта Миңнулла Ленинның Каплан тарафыннан яралануы турында газетада басылган мәкаләне күрсәткәч тә, юк, барыбер ышанмыйм, минем өчен барыбер исән ул һәм гомерем буена шулай исән булып калачак, дип үз фикереннән кайтмады.

Волкомга председатель сайлау мәсьәләсе килеп баскач, Миңнулла, һич икеләнмичә, ул урынга әнә шул Сабитов Фәйзулланы тәкъдим иткән иде. Әмма, булдыра алмас, яшьрәк әле ул дип, аның фикерен хупламадылар. Фәйзулла үзе дә риза булмады:

— Бүтән теләсә нинди эшкә куйсагыз да риза, ләкин андый зур җаваплылыкны үз өстемә ала алмыйм, — диде ул. — Тәҗрибәм дә, андый эшкә маһирлыгым да юк минем.

— Алайса, кемне тәкъдим итәсез соң? — диде Миңнулла. — Ягез, кемнәрдә нинди фикерләр бар?

Сәгыйдулла агай урыныннан торды да, бүреген йомарлый-йомарлый:

---

Ахыры. Башы 11 санда.

— Кемне дип, менә... мин... моңарчы эшләп килдем ләбаса. Нүжәли артабан да эшли алмам икән, — диде.

Җыелыштагылар мыек астыннан гына елмаешып куйдылар. Хуплап сүз әйтүче булмады.

Председатель булырга бүтән кулай кеше дә, теләүче дә юк иде. Ахырдан Миңнулланың үзенә килеп туктадылар.

— Минем хәлем әйбәт түгел, иптәшләр. Авырып йөрим. Дәваланып, азрак ял итеп китәргә дип кайткан кеше генә бит мин. Ярдәм итүен итәрмен, ләкин председатель итеп үзегезнең арадан берәрегезне куегыз! — дип караса да, тегеләр:

— Син бит аяклы авыру. Курыкма, артык борчымабыз. Безгә синең киңәшең кирәк, эшнең рәтен белеп-әйтеп торуың кирәк. Калган ягын үзебез чамаларбыз без аның. Волком эшләрен бер кат тәртипкә салганчы гына эшләп тор инде, энекәш! — дип чат ябыштылар. Аннары әлеге укымышлы егет Фәйзулла да: — Әгәр син председатель булсаң, урынбасарың булып эшләргә мин каршы түгел, — дигәч, Миңнуллага ризалык бирүдән башка чара калмады...

## 6

Хәле шәптән булмаса да, җаваплылыкны өстенә алгач, Миңнуллага шул көнне үк эшкә керешергә туры килде. Ә эш муеннан иде. Аннары килеп, аны һәр нәрсәне дөрес хәл итә ала торган җитәкче дип санасалар да, ул үзе дә мондый эштә башлап йөргән кеше түгел иде бит әле. Шуңа аңа беренче көннәрдә бик кыен булды. Волком председателенә дип килгән кешеләр, Миңнулла бүлмәсенә кергәч, аның председатель икәнлегенә ышанмыйча интектерделәр. Зур көрәк сакаллы, дәү таза гәүдәле бер рус карты белән булган әнә шундый аңлашылмау күңеленә аеруча нык сеңеп калды Миңнулланың. Башта ишек шакып, тыйнак кына булып килеп кергән иде ул карт. Ә менә өстәл артында әле яңа гына мыек чыга башлаган Миңнулланы күргәч, сәлам дә биреп тормастан:

— Тьфу, черт, тагын урынында түгел икән! — дип кире борылып чыга башлады.

— Ә кемне эзли идегез соң сез? — диде Миңнулла.

— Волком председателе Гайсин кирәк иде лә!

— Рәхим итегез, алайса. Мин — Гайсин.

— Лыгырдап тормасана, молокосос!

Шулай диде дә, ишекне шартлатып ябып, чыгып та китте. Күрәсең, волком ишеге төбендә постта торучыга ник мине алдап керттең дип бәйләнгәндер, болдырда кычкырышкан тавышлар ишетелә башлады. Аннары сакчы, аркасына мылтык терәп, картны Миңнулла бүлмәсенә алып керде дә:

— Уф, нишләтим икән, иптәш Гайсин, бу томананы? Синең волком председателе икәнлегеңә һич кенә дә ышанмый бит! — диде.

— Ни йомыш иде сезнең, агай? — диде Миңнулла, каны кыза башласа да, тыштан тыныч булырга тырышып.

— Йомышымны мин бары тик волком председателенә генә әйтергә телим. Кая ул? — диде карт, гел үз туксанын туксанлап.

Инде Миңнулла да кызды:

— Мин председатель дип әйтеп торам бит инде сиңа!

Карт барыбер ышанмады.

— Давай, алайса, мине персидәтелнең урынбасарына алып кер! — диде ул сакчыга. — Бу молокососка сөйләп сүз әрәм иткәнче, ичмаса, персидәтел урынбасарына сөйләрмен.

— Атып кына үтеримче, иптәш Гайсин, шушы төнтәкне? — диде сакчы, картка ачуыннан тәмам калтырана башлап. — Бер ахмакны үтергәннән генә дөнья харап булмас әле.
Ләкин картның исе дә китмәде:
— Кемне атып үтермәкче буласың әле син, анаңнан ялангач туган нәрсә?! — диде ул, бер дә ашыкмыйча гына сакчыга борылып. — Кулыңа мылтык тоттырганнар икән, кемне атсам да ярый дип уйлыйсыңмы әллә син? Әй, афәт! Атарсың менә, аттырырмын мин сиңа! Әйдәле, персидәтел урынбасары янына алып кер әле мине. Күрсәтим әле мин сиңа кемне атарга исәп иткәнеңне!
Бу картны Сабитов янына кертеп торудан мәгънә юк — аңа да ышанмаячагы көн кебек ачык иде. Шул ук вакытта йомышын йомышламыйча чыгарып җибәрү дә ярамый, чөнки аның ниндидер мөһим эш белән килгәнлеге кыяфәтеннән үк күренеп тора иде. Шуңа Миңнулла кискенрәк чара кулланырга булды:
— Әгәр үзегезнең кем икәнлегегезне һәм нинди эш белән килүегезне хәзер үк әйтмисез икән, мин сезне кулга алырга мәҗбүр булам, бабакай! — диде ул. — Я, кайсына риза буласыз?
Бары шуннан ары гына йомшарып китте карт.
— Ярар, сөйлим инде, алайса. Тик башта сакчыңны чыгарып җибәр әле.
Сакчы чыгып киткәч, карт өстәл янына ук килеп утырды да:
— Матвеевка авылыннан Степанов Григорий булам. Григорий Петрович. Пожалысты, менә туу турындагы таныклыгымны да алып килдем, — диде. Миңнулла ышанмаудан бигрәк картның күңеле булсын өчен генә таныклыгын карап кире биргәч, Григорий Петрович пышылдап кына:
— Мин синең Гайсин икәнеңә ышанам, ну, шулай да син дә берәр документыңны күрсәт әле, энекәш? — диде.
Миңнулла мандатын сейфтан алып күрсәткәч, картның йөзе кояштай яктырып китте һәм ул ни гомер көттереп йөдәткән серен чишәргә керешге...
Григорий Петрович җентекләп, озаклап сөйләгән ул сернең асылы бик гади һәм менә нәрсәдән гыйбарәт иде: Матвеевка авылында урта хәллеләр чутында йөри торган җиде кулак бар һәм алар артык икмәкләрен дәүләткә тапшырырга теләмичә, яшереп саклыйлар икән. Григорий Петрович аларның ул икмәкләре кая яшерелгәнен белә, әгәр Миңнулла волостьтан продотряд җибәрсә, ул отрядка ярдәм итәргә дә әзер икән.
Картның бу тәкъдиме бик мөһим: кулакларның яшергән икмәген табып, фронтка озатырга кирәк иде. Ләкин отрядсыз кая барасың? Ә отряд ул көнне өйдә юк, азык-төлек бүлеге начальнигы белән икенче бер авылга киткән иде.
— Әйдә бүген үк барыгыз минем белән! — дип, карт бик ашыкса да, Миңнулла аны:
— Шушы араларда барып чыгарбыз, тыныч бул, Григорий Петрович, — дип ышандырып калырга гына мәҗбүр булды.

## 7

Аклар кулында тоткын булып яткан чагында Миңнулла, әгәр исәнимин кайта алсам, иң элек әти-әнине, аннары Зәйнәп-сылуны күреп сөйләшер идем, дип күңеленә беркетеп куйган иде. Нинди генә ашыгыч эшләре булса да, берсе белән дә исәпләшеп тормастан, Барсайга барып кайтырга иде исәбе. Карыйга кайтып эшли башлаганына инде

менә икенче атна китте, әмма кичектергесез көндәлек эшләр артыннан йөреп, тәки шул Барсайга бара алганы юк иде әле.

Ул кайчан шул максатына ирешер иде икәнен әйтүе кыен, әмма Григорий Петрович чыгып китү белән Зәйнәп үзе волкомга килеп керде.

Узган җәйдә ул тагын да чибәрләнебрәк киткән. Йөреш-хәрәкәтләре сылу-салмакланган. Кыяфәтендәге балалык чалымнарының эзе дә калмаган. Күз карашлары җитдиләнгән, хәтта кирәгеннән артыграк та җитдиләнеп киткән шикелле. Буйга да сизелерлек үскән. Ә күзләре нишләптер бик моңсу. Аннары тәнгә дә бик ябыккан. «Замананың авырлыгы безнең ир-ат халкына гына түгел, кыз балаларга да кагылмыйча үтми икән шул», — дип уйлап алды Миңнулла. Әгәр менә шушы кызны күрсә, сөйләшеп сүзе бетмәс шикелле тоела иде Миңнуллага. Ә менә хәзер, кыз аның янына килеп кергәч, ул нигәдер югалды да калды. Әйтәсе сүзләре кинәт онытылды һәм теле тотлыкты.

— Нихәл, Зәйнәп? — диде ул, ниһаять, телгә килеп. — Үт әйдә, тарсынып торма!

— Син булгач тарсынмыйм инде, — дип, кыз өстәл янына килеп утырды.

— Кайчан килдең, Зәйнәп? Шушындый мәхшәрдә, ничек курыкмыйча юлга чыктың?

— Авыл кешеләренә ияреп килдем. Куркып кына ятып булмый гел. Курка-курка туеп та беттем инде.

— Барсайда ниләр бар соң? Сафиулла агай белән Әминә апа ару гына торып торалармы?

Кызның ике күзеннән дә мөлдерәп яшь чыкты:

— Син әле ишетмәдең дәмени, иптәш Гайсин, бездә ниләр булганын?

— Нәрсә, әллә берәр күңелсез хәл булдымы, Зәйнәп?

— Әти белән әни юк инде минем, — диде кыз, тыелгысыз аккан күз яшен сөртә-сөртә. — Сәйфи бай малае Шакир атып үтерде икесен дә. Миңнулланың башы әйләнеп китте.

— Ни өчен, Зәйнәп?

— Шул ми... минем өчен инде. Кызыңны бир дип бик аптырата башлагач, әти мине башка авылга илтеп куйган иде. Шуннан теге, табып бирегез кызыгызны, дип, башта әнине дә, әтине дә кыйнаган, аннары аларның күз алдында безнең өйне яндырган. Әти белән әни минем кайда икәнне һаман әйтмәгәч, икесен дә атып үтергән. Ә мине күрше авылдагы туганнарыбыз яшереп асрады. Сине волком председателе итеп куйганнар дигәч, монда килдем әле менә. Миңа берәр эш таба алмассыңмы икән дигән идем.

— Эше булыр ла аның. Тик менә нинди эшкә кирәк соң сиңа?

— Мин барысына да риза. Волкомыгызга җыештыручы итеп алсагыз да ярый. Шушында кунып йөрергә рөхсәт итсәгез, миңа берни кирәк түгел. Ә авылга кайтмыйм мин. Теге хәшәрәт Шакир килеп чыгып үземнең дә башыма җитәр дип куркам.

— Азрак укый-яза белмисеңме соң, Зәйнәп?

— Укый да, яза да беләм.

— Кит аннан! Кадимчәме, җәдитчәме?

— Җәдитчә.

— Соң нигә күптән шулай дип әйтми утырасың аны! Молодец та кеше булып чыгасың бит әле син, болай булгач! Алайса, әгәр риза булсаң, мин сине волкомга секретарь итеп алам, ямә! Шунда минем янда азрак русчасын да өйрәнерсең дә аннары үзеңне халык мәгарифе

бүлегенә алырбыз. Әле өченче көн генә мәгариф бүлеге ачарга дип өяздән күрсәтмә килгән иде.

— Ә мин русчасын да ипилек-тозлык кына сөйләшә алам. Аз гына укый да, яза беләм шикелле, — диде кыз, кыю гына итеп.

Аның бу сүзләре Миңнулланы тәмам хәйран итте.

— Син минем сорауны яхшылап ишетеп җавап бирдеңме, Зәйнәп? — диде ул, кызга ышанып бетмичә. — Русча сөйләшү һәм русча укый-яза алу турында сораган идем мин синнән.

— Мин дә шул турыда әйтәм. Бала чагымда бездә фатирда рус тимерчесе торды. Аларның минем шикелле кызлары бар иде. Шул чакта мин аннан русча сөйләшергә һәм азрак кына укырга-язарга өйрәнеп калдым. Ә ул кыз миннән безнең татар телен өйрәнде.

Миңнулла, өстәлендә яткан газетаны алып, Зәйнәпкә сузды:

— Менә шушы газетаны укып кара әле!

«Правда» газетасының 11 сентябрьдә чыккан саны иде ул.

Алай бик үк йөгерек итеп булмаса да, Зәйнәп шул газетаның баш мәкаләсен хәйран ипле генә укып китте: «Казань взята. Белые бегут по шоссе к Симбирску. Важнейший передовой пост белогвардейского движения пал...»

— Молодец,— диде Миңнулла, көченнән килсә айга сикерердәй куанып. — Булды бу! Менә шушы минуттан үзеңне волкомның халык мәгарифе бүлеге мөдире дип сана!

— Ой, андый зур эшне булдыра алырмынмы икән?

— Ничек кенә булдырырсың әле, дустым! Курыкма, бергә эшлисе бит. Ярдәм итәрмен.

— Алайса, тырышып карармын.

## 8

Азрак ял итеп, какшаган сәламәтлеген «ремонтлап» килү нияте белән кайткан Миңнулланың ял итәргә түгел, ял турында уйларга да вакыты юк иде хәзер. Дөрес, әнисе Гайниҗамал апа тырыша инде тырышуын. Үзләренең сыеры иртә буаз булганлыктан инде күптән ташланса да, каяндыр табып, сөтен-каймагын да, мәтрүшкәсен дә, тагын әллә нинди шифалы үләннәр дә кайнатып эчертә. Бурсык мае да таптан. Миңнулла яратмаса да, аны да көчләп-көчләп эчертә.

Әллә әнисенең әнә шул тырышлыгы нәтиҗәсе булды, әллә бу егет көн-төн эш белән мәтәвекләнеп йөри, моның миңа игътибар итәр чамасы бөтенләй күренми, барыбер җиңеп булмас, ахрысы, бу ташбашны, дип авыру үзе курыктымы — Миңнулланың хәле Карыйга кайткач сизелерлек яхшырды: аңа тән куна башлады, эченнән кан килүе туктады.

Ә өяздән тагын яңа күрсәтмәләр килә торды. Элек Кызыл Армиягә нигездә үзе теләгән кешеләрне генә алган булсалар, хәзер сәламәтлекләре ярардай булган унсигез яшьтән алып кырык яшькә кадәрге барлык ир-атларны фронтка озату мәҗбүри итеп куелды. Сугышка барырга яраксыз дип табылган ир-атлардан авылларда хәрби дружиналар төзү, июль-август айларында кулаклар коткысы белән күп кенә авылларда оештырылган бунтлар нәтиҗәсендә таркатылган ярлылар комитетларын яңадан оештыру, сугышчы кызылармеец семьяларына ярдәм итү, тагын шуныңише мең төрле мәшәкатьләр — барысы Миңнулла өстендә. Кыскасы, кая анда ял да, кая анда авыру турында уйлап торырга вакыт. Хәтта тәүлегенә дүрт-биш сәгать кенә эләгә торган йокысын да тыныч кына йокларга ирек бирмиләр, кайбер мәсьәләләрне төн уртасында торып хәл итәргә туры килгән чаклары да бик еш була.

Бүген дә Миңнулланы бик иртә уяттылар. Кичә волостьның бер авылында фронтка кешеләр җыеп озату белән шөгыльләнеп, аннары партячейка җыелышы үткәреп йөреп, Карыйга төнге берләрдә генә кайтып яткан иде ул. Ә иртәнге биштә волком дежурные килеп җитте:

— Әйдәле, наным Гайсин, синсез эш чыгарып булмый анда. Бажук авылы мужиклары үзләренең комбед персидәтелен тотып алып килгәннәр дә каталажкагызга ябып куегыз шушы бәндәне дип тинтерәтәләр. Волком персидәтеленнән башка беркемне дә ябарга хакыбыз юк безнең дигән идек, бик каты тавыш күтәрделәр. Персидәтелнең үзен алып кил, алайса, диләр. Араларында берсе аеруча нык җикеренә. «Өяз ривкумыннан килгән вәкил мин, давай әйткәнне тизрәк үтә», ди. «Югыйсә, үзеңне дә ариставайт итәрбез», ди.

Миңнулла Бажук председателен — япон һәм герман сугышларында катнашкан, соңгысыннан бер кулын өздереп кайткан Харисов Мөхлис агайны яхшы белә иде. Волостьта иң ышанычлы һәм иң эшлекле председательләрнең берсе ул. Тик Миңнуллага ошап бетмәгән бер ягы бар: чамадан тыш таләпчән һәм кирәгеннән артык кызыбрак китүчән.

Миңнулла волкомга килеп кергәндә дә Мөхлис агай дежурный белән каты гына әрепләшеп тора иде.

— Нихәл, Мөхлис агай? Тагын кысыр хатыннан бала таптырып йөрисеңме әллә? — диде Миңнулла, уенын-чынын бергә кушып.

— Син алай уенга борма әле, иптәш Гайсин. Бу юлы мин таптырмыйм, бу юлы минем үземнән таптырырга маташалар әле!

— Кемнәр ул? Ни өчен?

— Кем икәнен шайтан белгәнме аның! Ниндидер бер дурак нәрсә килеп чыкты да аристовайт итеп алып килде мена!

— Әйдә, коридорда тормыйк, кереп сөйләшик әле! — дип, Миңнулла Мөхлис агайны бүлмәсенә алып кергән иде — шаккатып калды: бүлмә тәмәке төтене белән тулган һәм шул төтен эчендә уңлап кеше ду килеп сөйләшеп утыралар иде. Барыннан да гаҗәбрәге шул булды: теге кешеләрнең берсе Миңнуллага инде күптәннән таныш — әлеге «милләт хадиме» Хәйретдинов Хәйрулла иде.

Хәйрулла да аны танып алды бугай: нидер лыгырдап торган авызын япты да, секунд эчендә кара көеп, телсез калды. Миңнулла тиз генә сакчы янына чыгып:

— Отряд командирына әйт, хәзер үк биш кеше алып монда, минем янга килсен! — диде. Үзе бүлмәсенә яңадан керде: — Сез кайда, иптәшләр, волком председателе бүлмәсендә утырасызмы, әллә каравыл өендәме?

— Без персидәтелне көтеп утырабыз! — диде араларыннан берсе.

— Бик әйбәт. Менә мин булам инде председатель. Ә хәзер, менә бу иптәшегездән башкаларыгыз (ул Хәйрулланы күрсәтте) барыгыз да бүлмәдән чыгып торыгыз!

— Алар минем белән килгән кешеләр. Аларның да әйтәсе сүзләре бар! — дип, Хәйретдинов ризасызлык белдерә башлаган иде, ләкин Миңнулла:

— Мин берьюлы ун-унбиш кешене тыңлый алмыйм: Наполеон булып Наполеон да берьюлы тик ике кеше белән сөйләшә алган! Бер дә курыкмагыз, алар белән дә вакыты җиткәч сүз булыр! — дип, эшне бик коры тотты. — Я, синнән башлыйк, Мөхлис агай, — диде ул Бажук мужикларын чыгарып җибәреп, форточканы ачып куйгач. — Кемнәр һәм ни өчен кулга алдылар сине?

— Кичә кич, — дип башлады Мөхлис агай, — минем янга идарәгә менә шушы кеше килеп керде дә: «Мин өяз вәкиле, халыкка аңлатасы нәрсәләр бар», дип, төнләләтеп җыелыш җыйдыртты. Җыелышка килгән кешеләрдән: «Ярлылар комитетыгыз ничек эшли? Сезне кыерсытмыймы?» дип сораштыра башлады. Андый чакта, үзең беләсең, зарла-

нучылар табыла инде ул. Берсе әйтә, камбид кешеләре минем ашлык суга торган машинамны алды, ди. Икенчесе әйтә, минем атымны алып фәлән кешегә бирделәр, ди. Җиребезне кисеп алдылар, дип тә кычкыра башладылар. Артык малларын законлы төстә алганны әйтми бит алар. Алдылар, ди и шуның белән вәссәләм! Ә менә бу адәм, — ул тагын Хәйруллага ишарәләде, — тегеләрне тыңлап торды да прәме шул җыелыштагы халык алдында ук, ул атларны нинди дикрит нигезендә канфискатсияләдегез, җирләрне нинди дикрит нигезендә кисеп алдыгыз, фәлән дә фәсмәтән дип мине тыкырдата башлады. Ә безнең кулда чыгарып күрсәтергә бернинди дә дикрит юк. Вулыстан язып җибәрелгән күрсәтмәләр белән авыл ярлылары җыелышларының беркетмәләре генә бар бездә. Мин шулай дип әйткәч, менә шушы имансыз нәрсә бөтен халык алдында торып басты да:

— Сез боларның берсен дә закон нигезендә эшләмәгән, шуңа күрә менә шушы минуттан мин сезнең камбидны таратам, камбид председателен кулга алам, — диде. Аннары халыкны таратты да мине үзе белән менә монда алып килде. Ярлылар комитеты тарафыннан үзләрен кимсетелгән дип санаучылар да аңа ияреп килде. Әлеге ун кеше әнә шулар иде инде. Менә шул, иптәш Гайсин.

Мөхлис абзый сөйләгән хәлләргә Миңнулла күңеленнән бәя бирә барган иде. Ләкин бер дә алай законга каршы килә торганын тапмады. Барысы да әле шушы елның 11 июнендә Ленин имзасы белән игълан ителгән декрет нигезендә эшләнгән кебек тоелды аңа. Урыннардагы совет власте бит ул ярлылар комитетлары. Шулай булгач, авылларда тигезлек урнаштыруны гамәлгә шул комитет ашырмыйча кем эшләсен ди инде?

— Мөхлис агай сөйләгәннәр дөресме? — диде Миңнулла Хәйруллага.

— Мин барысын да законча эшләдем! — диде теге, бик батыр итеп.

— Июнь аенда ярлылар комитетлары һәм җирле советлар турында декрет чыккан иде. Сез ул декрет белән танышмы?

— Таныш.

— Шулай булгач!

— Анда ярлы халыкны кимсетмәскә кушкан.

— Әйе, ярлы халыкны шул менә! Ә Бажук комбеды ярлыларны түгел, байларны гына «кимсеткән».

— Байлар инде барысы да качып бетте.

— Калганнары да җитәрлек әле аларның! Әйтегез әле, сез кем? Һәм нигә сез волком белән сөйләшмичә, аның рөхсәтеннән башка Бажукта җыелыш үткәрдегез?

— Без күптәнге танышлар бит инде, иптәш Гайсин! — диде Хәйрулла, ыжлап та бирмичә.

— Мин ул турыда әйтмим. Кайда һәм кем булып эшлисез дим мин!

Кесәсеннән алып, Хәйретдинов Миңнуллага командировка кәгазе сузды. «Моны күрсәтүче Хәйретдинов Хәйрулла Хәйретдин улы, — диелгән иде анда, — җирле партия һәм совет органнарына агитация-масса эшен яхшыртуда практик ярдәм итү өчен Карый һәм Ашап волостьларына җибәрелә. Бу эшне тормышка ашыру барышында җирле совет органнары иптәш Хәйретдиновка һәрьяклап булышлык күрсәтергә тиеш...»

Үз күзләренә үзе ышанмыйча, Миңнулла командировка бланкасына язылган әлеге сүзләрне тагын бер кат укып чыкты. Ләкин анда барысы да дөрес, барысы да нәкъ менә шулай иде. Хәтта өяз идарәсе комиссариатының печатенә хәтле ап-ачык булып төшкән һәм РКП(б)ның өяз партия ячейкасы секретаре имзасы да дөрес иде. Тик өяз идарәсе комиссариатының командировканы теркәү номеры гына куелмаган иде

анда. Ә ул куелган булырга тиеш, чөнки шул хакта катгый күрсәтмә бар иде. Миңнулла менә шуны искәрткәч, Хәйретдинов:

— Миңа аны теркәтергә кирәк икәнен әйткән кеше булмады, — дип җавап бирде.

«Кем белә инде аның дөресен генә, — дип уйлап алды Миңнулла. — Бәлки, чыннан да, бу адәм үзе белмәгәндер, ә искәртүче булмагандыр».

— Ярый, — диде Миңнулла, ризалашырга мәҗбүр булып. — Анысы шулай да булсын ди. Ә менә өяздән килгән, хәтта губерна үзәгеннән килгән вәкилләрнең дә волбашкарма рөхсәтеннән һәм волбашкарма вәкиле катнашыннан башка бер генә авылда һәм бер генә төрле җыелыш та үткәрергә хакы юк икәне мәгълүмме сезгә?

— Мин укомда яңа гына эшли башладым. Барлык күрсәтмәләрне белеп бетермәвем дә мөмкин.

«Сөйләшә белә, кабих! Неужели әле кайчан гына совет властеның кан дошманы булып йөргән шушы адәм, фикерен үзгәртеп, безнең җырны җырлый башлады микән?..»

— Сез партия әгъзасы түгелсездер бит, Хәйретдинов?

— Нигә алай шикләнеп кенә сорау бирәсез? Узган елдан бирле партия әгъзасы инде мин!

— Мин милли шура турында түгел, коммунистлар партиясе турында сүз алып барам, Хәйретдинов! — диде Миңнулла, тегене шаярып сөйләшә дип уйлап һәм ипи шүрлегенә менеп төшүдән үзен кыенлык белән генә тыеп.

Ул Хәйретдиновның бүтән теләсә нинди сүзенә, теләсә кем булуына ышанырга әзер, әмма аның коммунистлар партиясе члены булуын һич тә күз алдына китерә алмый иде.

Ләкин Хәйрулла аны шаккатырып үзенең партия билетын сузды. Билет, чыннан да, Хәйретдинов исеменә бирелгән иде! Барыннан да гаҗәбрәге шул, Хәйретдиновның бу билеты РКП(б)ның өяз комитеты тарафыннан бирелгән.

— Соң син әле моннан бер ай элек кенә контр идең бит, Хәйретдинов, ә билетыңда партиядә унҗиденче елдан бирле тора дип язылган. Моны ничек аңларга инде?

— Мин беркайчан да контр булмадым! — диде теге, күзен дә йоммыйча. — Аклар лагеренда партия заданиесен үтәп кенә йөрдем мин!

— Барсай мужикларына сөйләгән нотыгың да партия заданиесен үтәү йөзеннән идеме?

— Әйе.

«Карале син бу паразитны, кызармый да бит, ичмаса!»

— Безнең өйгә җиде төн уртасында килеп кереп, минем абыйны таптырырга теләп, әнинең теңкәсенә тиюең һәм соңыннан безнең сарыкны суйдырып алып чыгып китүең дә партия кушуы буенча булмагандыр бит?!

— Әйе, анысы да партия кушуы буенча! Гайсин акларга сатылган дигән хәбәр таралган иде. Шуңа күрә азрак тикшерү үткәреп алырга туры килде.

Юк, тегенең сүзләренә дә, документларына да ышанып җитә алмады Миңнулла. Хәйретдиновның өяз вәкиле булып килүен, күрсәтмәләр бирергә хокукы бар икәнлеген, аның күрсәтмәләрен үтәмәсә, соңыннан үзенә кыенга туры килүе мөмкинлеген бик яхшы белеп торса да, бу юлы бернинди кагыйдәгә дә буйсынмаска булды:

— Сез мине гафу итегез, Хәйретдинов, — диде ул, — кайбер нәрсәләрне ачыклаганга кадәр мин сезне кулга алып торырга мәҗбүрмен.

— Кемне? Мине, өяз башкарма комитеты вәкилене? Миңа кагылырга бернинди дә хокукың юклыгын беләсеңме син, Гайсин? — дип, Хәйретдинов әтәчләнә башлаган иде, әмма Миңнулла аның белән

артык вакланып тормады. Тегенең партия билетын да, командировка кәгазен дә үзенең сейфына салып куйды да, инде килеп җитеп, әмер көтеп торган отряд командирына:

— Менә бу кешене кыпызыга илтеп ябыгыз әле, иптәш Ногманов! — диде.

Аннары Хәйретдиновның биографиясен һәм партиягә ничек, кайчан кергәнлеген бик җентекләп тикшереп, шул хакта үзенә хәбәр итүләрен үтенеп, шуңарчы аны сак астында тотачагын әйтеп, өяз башкарма комитеты председателе һәм өяз партия ячейкасы секретаре исемнәренә язу язды да шул язуны бер кызылгвардиячегә биреп, Усыга җибәрде. Шуннан соң, безнең дә синә сүзебез барые, дигән теге Бажук «кимсетелгәннәре» исенә төшеп, алары ни җырлар икән, аларын да тыңлап карарга кирәк, дип коридорга чыккан иде, волком дежурные:

— Юк инде алар, иптәш Гайсин. Башлыкларын сак астында алып киткәнне күргәч, шыпырт кына таралып бетте алар! — диде.

## 9

Ишеткәне булса да, Миңнулланың Матвеевканы моңарчы күргәне юк иде әле. Урман буена сыенып утырган матур гына бер авыл икән. «Контрларга чыннан да бик уңай икән шул монда, — дип уйлап куйды Миңнулла, Григорий Петровичның волкомда әйткән сүзләрен исенә төшереп. — Урман орынып тора: ашлыкны гомер таба алмаслык итеп яшерергә мөмкин». Авыл зур түгел. Йөз-йөз егерме йорттан артык булмас. Чиркәүләре дә күренми. Димәк, бик борынгы авыл булырга тиеш түгел. Аннары тагын шунысына игътибар итте Миңнулла: авыл өйләренең түбәләре күбесенеке я калай, я черепица яки такта белән ябылган, бер генә салам түбә дә юк. Каралтылары да нык. Күбесе биек койма белән уратылган. Ә бит, яшерен-батырын түгел, рус авылларында өйләр гадәттә зур булса да, каралтылары болай төзек һәм нык булмый торган иде. Бу авылда зур-зур таш келәтләр дә байтак күренә. Хәтта икешәр катлы йортлар да бар. «Димәк, тормышлары таза боларның. Мөгаен, иген игүдән тыш, тагын ниндидер кәсеп белән шөгыльләнәләр булса кирәк», — дигән нәтиҗәгә килде Миңнулла.

Авылга килеп кергәч беренче очраган ир уртасы кешедән, ярлылар комитетыгыз кайда? дип сораган иде, теге:

— Безнең андый нәрсәне ишеткәнебез юк! — дип җавап бирде.

— Ә авыл советы бармы соң?

— Әнә шул тыкрыктан уңга борылгач, сул яктан икенче йорт председательнеке булыр.

Теге кеше күрсәткән өй турына килеп, Миңнулла атыннан сикереп төшүгә өр-яңа урыс капка ачылып китте дә баһадирдай киң җилкәле, имән түмәркәседәй нык һәм юан гәүдәле, каны бәреп чыгарга торган кып-кызыл йөзле утыз-утыз икеләр тирәсендәге бер ир килеп чыкты. «Авылга кереп җитмәдек, инде икенче тап-таза ир кешегә юлыктык. Болар нигә фронтта түгел икән соң?» Миңнулла әнә шулай уйлап алган арада капкадан чыккан кеше каш астыннан гына сөзеп карап, Миңнулланы һәм аның белән килгән кызылгвардиячеләрне тикшереп чыкты да, ясалмарак кына елмаеп:

— Исәнмесез? Кемнәр буласыз, кайдан киләсез? — диде.

Ул шулай сөйләнгән арада Миңнулланың колагына болдыр баскычыннан кемнәрдер бик ашыгып кына төшеп, абзар ягына йөгерешкән шикелле тоелды.

— Саумысыз, — диде Миңнулла. — Авыл Советы председателе сез буласызмы?

— Әйе,

— Алайса, бик яхшы. Без волкомнан идек. Минем фамилиям Гайсин. Ә сезгә ничек дип мөрәҗәгать итәргә?

— Волкомның кайсы бүлегеннән?

— Мин волком председателе булам. Сезнең авыл хәлләрен белеп китәргә дип килү иде. Кайда сөйләшәбез: өегезгә алып керәсезме, авыл Советыгызның махсус бинасы бармы?

Миңнулла әнә шулай кыю тотынгач, теге шактый йомшарып:

— Мин — Сидор Андреевич Шишков, — диде. — Безнең әлегә авыл Советы бинабыз юк. Монда, минем өйдә генә сөйләшербез. Бер генә минут көтеп торыгыз инде, зинһар. Безнең өйдә тәртипсезрәк чак иде. Рәхим итеп, атларыгызны ишегалдына урнаштыра торыгыз!

Сидор Андреевич шактый озак торып чыкты. Ләкин бу юлы иң якын туганнарын каршыларга чыккандай бик ачылып чыкты һәм Миңнулланы да, аның белән килгән дүрт кызылгвардиячене дә кыстыйкыстый өйләренә, аның да әле түр ягына ук алып керде. Анда инде өстәл әзерләнгән, табын тутырып ризык куелган иде. Эчемлекләре дә җитәрлек күренә. Өй эче кәбестәле аш исе, ит исе һәм аракы исе белән тулган. Кыскасы, бу йортта кунаклар булганлыгы әллә кайдан сизелеп тора. Ләкин өйдә Сидор Андреевичның хатыны һәм ике баласыннан башка беркем дә юк. «Бая хуҗа безнең каршыга чыгып сөйләштереп торган арада ишетелгән тавышлар кунакларныкы булган, күрәсең, — дип фикер йөртте Миңнулла. — Кызык: нинди серле кунаклар булды икән ул? Хуҗа нигә аларны безгә күрсәтүдән курыкты икән?..»

Сидор Андреевич табынга кыстый башлады. Мондый ризыклардан баш тарту гөнаһ булыр иде. Аннары утыз-кырык чакрым юл килеп, тамаклары да ачыккан иде. Миңнулла кыстатып тормады. Иң алдан өстәл артына үзе кереп утырды да тартыныбрак торган гвардиячеләренә:

— Әйдәгез, иптәшләр, рас әзер ашка туры килгәнбез икән, ашап алыйк, — диде һәм хуҗаның шешә ачып стаканнарга аракы сала башлавын күреп: — Ә сез ул нәрсә белән мәшәкатьләнеп тормагыз, Сидор Андреевич, безнең арада эчә торган кеше юк! — диде.

Бәлки күңелләреннән бик үк риза булмаучылары да булгандыр, әмма гвардиячеләр Миңнулланы дөрес аңладылар һәм барысы да берьюлы диярлек, әйе, әйе, Сидор Андреевич, беребез дә эчми безнең дип, аның сүзен куәтләделәр. Хуҗа да ялынып тормады:

— Ихтыярыгыз, алайса. Теләмәгән кешенең авызыннан коеп булмый. Ну, мин үзем, гафу итегез, бераз тотыйм әле,— дип, ярты стакан эчте дә ул хакта сүз шуның белән бетте.

Бер тын ашап алдылар. Сүзне Сидор Андреевич башлады:

— Сез шул продналог мәсьәләсе буенча килгәнсездер инде, иптәш Гайсин?

«Теге җиденең берсе шушы үзе түгел микән әле?» дип уйлап алды Миңнулла. Алдан ук өркетеп куймас өчен артык исе китмәгәндәй генә җавап бирде:

— Аның белән дә кызыксынабыз.

— Тәк-тәк! — диде хуҗа, Миңнулланың җавабыннан бик үк канәгать булып бетмичә. — Тагын да мөһимрәк эшләрегез бармыни әле бездә?

— Әйтегез әле, Сидор Андреевич, ярлылар комитеты бармы сезнең авылда?

— Юк.

— Нигә юк?

— Авыл советы әйбәт кенә эшләп килгәч, аны оештырып торуның хаҗәтен күрмибез.

— Кемнәр ул «без»?

— Совет членнары һәм халык.

— Ә эшче-крестьян Кызыл Армиясенә кешеләр җыйнау мәсьәләсе ничегрәк тора? Соңгы айда, мәсәлән, армиягә авылыгыздан ничә кеше озаттыгыз?

— Бу айда китүче булмады. Ә узганында өяздән бер иптәш килеп вәгазьләгәч, ике кеше үзләре теләп киткәннәр иде.

— Ә сез совет дәүләтенең унсигез яшьтән алып кырык яшькә кадәр булган ир-атларның хәрби хезмәткә яраклылары барысы да армиядә хезмәт итәргә тиеш, дигән карарын беләсезме?

— Безгә ул хакта күрсәтмә килгәне юк әле. Кайчан чыккан иде икән соң ул карар?

— Моннан өч ай элек үк инде. Сезнең аны белмәвегез сәер, бик сәер, Сидор Андреевич!

— Өяздән дә, волость үзәгеннән дә еракта яшибез бит, иптәш Гайсин. Һәр яңалык безгә бик соңлап килә.

— Дәүләткә икмәк тапшыру мәсьәләсендә эшләрегез ничегрәк? Һәр крестьян семьясы үзенә ашамлык һәм чәчүлектән арткан икмәген дәүләткә тапшырырга тиеш икәнлеген беләме авылыгыз халкы?

— Беләләр. Анысын кат-кат аңлаттык без аларга.

— Ничек соң, аңладылармы, тапшыралармы? Күпме икмәк җыеп озаттыгыз?

— Җыюын күп кенә җыйган идек. Тик дәүләткә тапшыра алмадык. Усыга илтергә барган чагында олауларга юлбасарлар һөҗүм иткән дә бөтен икмәкләрен талап алып киткәннәр.

— Кызганыч, бик кызганыч. Ә авылыгызда партия ячейкасы бармы, Сидор Андреевич?

— Юк, ләкин партиягә керергә теләүчеләр бар. Мәсәлән, мин үзем дә керер идем.

— Авыл халкының гомуми җыелышларын кайда уткәрәсез?

— Минем җыелышлар уткәргән юк әле. Күптән түгел, сентябрь аеннан гына председательлек итәм әле мин. Ә болай җыелышлар каравыл өе янында уткәрелә торган иде.

— Алайса, менә болай итегез: шул каравыл өе янына халыкны җыйнагыз! Әлеге шул продналог, РККАга мобилизация, партиягә кабул итү мәсьәләләре хакында халык белән сөйләшеп алырга кирәк булыр. Авыл советыгызның йомышчысы бардыр бит?

— Барын бар анысы. Ләкин халыкка мин үзем дәшеп чыгармын. Йомышчыга гына артык исе китми безнекеләрнең.

— Анысы сезнең ихтыярда, Сидор Андреевич. Ләкин сәгать икегә халык җыелып беткән булсын. Монда эшне бетереп, мин бүген үк кайтып китәргә тиеш.

— Тырышып карармын, әмма, ай-һай, икегә үк җыйнап булыр микән.

— Әйдә, алай булгач, икәүләп өй борынча йөреп чыгабыз.

— Што сез, што сез, иптәш Гайсин! Волком председателен өй борынча халык җыеп йөртергә ярыймы соң? Юк, юк! Хәзер, мин үзем, үзем!... Безнең авыл зур түгел бит, хәзер җыеп алабыз без аларны!

— Сезнең авылда Степанов Григорий дигән кеше бармы?

— Степанов Григорий... Григорий Степанов... Петрович түгелдер?

— Әйе, Петрович!

— Бар андый адәм.

— Нindиерәк кеше ул?

— Ничек дип әйтергә инде сиңа? Ярлы гына, куштан гына бер карт инде шунда.

— Сез аны җыелышка кадәр минем янга чакырыгыз әле, зинһар.

— Ярый, чакырырбыз.

Сидор Андреевич сәгать икенче яртыга әйләнеп кайтты. Ләкин Григорий Петрович һаман килеп житмәгән иде әле. Миңнулла ник озаклады икән ул агай дип сорарга авызын ачкан гына иде, Шишков үзе үк әйтеп бирде:

— Степанов өйдә юк икән. Күрше авылга тегермәнгә киткән.

— Кызганыч, ләкин ни хәл итмәк кирәк. Ә халык жыелып бетәме инде?

— Мин әле генә каравыл өеннән кайттым. Нигәдер килгән кеше күренми әле анда. Бераз көтәргә туры килер инде.

Ике дә тулды. Өч тә үтеп китте. Дүрт тә булды. Ә каравыл өендә яңгын сакчысыннан һәм Миңнулла белән Сидор Андреевичтан башка адәм заты күренми иде әле. Миңнулла бу хәлгә бик нык гаҗәпсенеп, нигә жыелмый икән халык, әллә сез аларга бөтенләй әйтмәдегез үкме, дип сорагач, Сидор Андреевич:

— Үзем дә аптыраган инде. Барысына әйтеп чыктым, киләбез дип калганнар иде. Ни көтеп ята торганнардыр, шайтан белсен! — дип куйды. Әмма үзе, Миңнулла ни кыстап караса да, авылны тагын бер кат әйләнеп чыгарга теләмәде: — Бер әйтелгән бит инде, житкән. Килергә тиешләр! — дип, гел үз сүзендә кала бирде.

Ахыр чиктә ул хаклы булып чыкты. Бишенче ун минутларда жыела башлаган халык бишенче яртыга жыелып та бетте. Жыелышка житмеш-сиксәнләп кеше килгән иде.

Сидор Андреевич жыелышны ачып җибәрде дә «сүзне кадерле кунагыбыз, волком председателе иптәш Гайсинга» бирде.

Миңнулла продналогтан башлады. Фронттагы кызыл сугышчыларга һәм шәһәрләрдәге завод-фабрика эшчеләренә икмәк житмәвен, аларга бары тик крестьяннар гына ярдәм итә алуын һәм ярдәм итәргә тиешлеген аңлатып бирде дә:

— Ләкин, иптәшләр,— диде,— менә шушы бик тә мөһим эшкә нигәдер сез салкын карыйсыз. Шушы көнгәчә совет дәүләтенә бер пот ашлык та тапшырганыгыз юк икән әле!

— Как так тапшырмаган! Әле узган атнада гына йорт башыннан өчәр пот та бишәр потлап жыйдылар бит! — дип кычкырдылар халык арасыннан.

— Анысы шулай. Ләкин ул икмәкне сез совет дәүләтенә түгел, бәлки аның дошманнары кулына тапшыргансыз ич! — диде Миңнулла.

— Ну, анысы инде безнең гаеп түгел. Аннары килеп, ул икмәкне талап алган кешеләр дә шул ук бер алла бәндәләре бит. Аларның да тамагы бар, аларга да ашарга кирәк ләбаса! — диде калын тавышлы бер кеше.

Жыелыштагылар, кайсы аны хуплап, кайсы аның белән килешмичә, нык кына шаулаша башладылар. Ләкин калын тавышны хуплаучылар күбрәк иде. Шуңа Миңнулла бу мәсьәләне куертып, тавышка куеп тормады:

— Ярый, артык ашлыгыгызны дәүләткә үз ризалыгыгыз белән бирергә теләмисез икән, продотряд китертеп жыйнатып алдырырга туры килер, алайса! — диде дә Кызыл Армиягә кешеләр мобилизацияләү мәсьәләсенә күчеп, совет хөкүмәтенең шул турыдагы декретын укыды.

— Аңладыгызмы? — диде ул, тып-тын калган жыелышка мөрәҗәгать итеп.

— Аңлавын аңладык, ну, без сугышка бармыйбыз! — дип кычкырды берсе. — Житәр, сугышып туйдык инде!

Тагын берничә кеше «шулай», «дөрес», «беребез дә сугышка барырга теләми» дип, тегене яклап тавышланышып алдылар.

«Нишлибез инде хәзер» дигәнне аңлатып, Миңнулла Сидор Андреевичка карады. Ә Сидор Андреевич берни дә булмагандай тыныч кына утыруын дәвам итте. Аның бу мәсьәләгә битарафлыгы кыяфәтенә үк чыккан иде. «Димәк, моңа таянып булмаячак» дигән фикергә килде Миңнулла. Инде бер башлаган эшне ничек тә ахырына җиткерү өчен мәсьәләне тавышка куйды:

— Кем дә кем совет дәүләтенең гомуми хәрби бурыч турындагы декретына җавап итеп, үзе теләп фронтка китәргә риза — шуларның кул күтәрүләрен сорыйм?

Бер кул да күтәрелмәде.

Бу авыл советының исеме генә бар, эше юк икәнлеге, шуңа күрә дә контр элементлар өстенлек алганлыгы көн кебек ачык иде хәзер Миңнуллага. Мондый шартта бер мәсьәләне дә ирекле рәвештә, тавышка кую юлы белән хәл итү мөмкин түгел иде. Шуңа Миңнулла җыелышны таратырга да иртәгә иртән отряд белән өй борынча йөреп, эшне урында хәл итәргә дигән фикергә килде:

— Ярый, иптәшләр. Алайса, җыелышны шушының белән тәмамлыйбыз. Өйләрегезгә таралырга мөмкин.

— Юк әле, көн тәртибендә тагын бер мәсьәлә бар иде бит әле! — дип кычкырды теге Калын тавыш.

Инде караңгы төшкән, ә өстәл янындагы бердәнбер фонарьның яктысы шул өстәл тирәсеннән ерак китә алмаганлыктан, ул кешенең үзен күреп булмый иде. Миңнулла, аның сүзләрен болай гына, кызык өчен әйтелгән сүзләр генә дип уйлап, җавап биреп тормаска иткән иде. Ләкин җыелыштагылар берсе дә урыннарыннан кузгалмагач һәм теге адәм әлеге соравын тагын бер кабатлагач:

— Сез нинди мәсьәлә хакында әйтәсез? — дияргә мәҗбүр булды.

— Партиягә дә язасың икән дигәннәрие бит сине.

Бүтән мәсьәләләргә каршы чыккач, монысына да каршы булачак инде болар, дип, Миңнулла ул турыда сүз дә кузгатып тормаска уйлаган иде. Ә алар, әнә, үзләре башлады.

— Партиягә язмыйлар, абзый кеше, — диде Миңнулла. — Партиягә кабул итәләр. Әллә партиягә керергә исәбегез бар идеме?

— Бар иде шул менә!

— Бик әйбәт. Җыелыштан соң, рәхим итеп, минем янга килерсез дә сөйләшербез-киңәшербез.

— Безнең арада партиягә керергә теләүчеләр тагын бар әле! — дип тавыш бирделәр халык арасыннан.

— Шулаймы? Алайса, болай итик: теләге булган иптәшләр барыгыз да калыгыз, ә башкаларга өйләренә кайтырга мөмкин.

Җыелыштагыларның берсе дә урыннан кузгалмады.

— Бәлки сезне тыңларлар?! — диде Миңнулла, Шишковның һаман шулай гамьсез утыруына исе китеп.

— Әйткәнне ишеттегезме? — диде теге, ваемсыз гына итеп. — Партиягә керергә теләгән кешеләр генә калсын диелде.

— Ә без барыбыз да керергә телибез! — дип кычкырды Калын тавыш.

— Сүз коммунистлар партиясенә кабул итү турында булачак, иптәшләр, — диде Миңнулла.

— Беләбез!

— Ә коммунистлар партиясенә тик эшчеләр һәм ярлы крестьяннар гына кабул итәлә! Һәм һәркем аерым-аерым кабул итәлә.

Җыелыштагылар тагын ду килә башлады:

— Ул нинди кеше аралау ди тагын!

— Кайда монда гаделлек?

— Без бөтенебез берьюлы керергә телибез!

— Барыбызны партиягә алмыйсың икән — яхшылык көтмә!

Эшләр болайга киткәч, Миңнулла моның алдан уйлап куелган провокация икәнен төшенеп алды да:

— Тавышланмагыз, иптәшләр, таралышыгыз. Болай аяк өсте генә хәл итә торган мәсьәлә түгел бу. Җыелышны иртәгә иртән дәвам итәрбез. Шуңарчы мин иптәшләр белән сөйләшеп, киңәшеп куярмын да нәкъ уртак бер фикергә килербез, — диде.

Әмма халык һаман таралырга уйламый да иде әле.

— Сез ник бер сүз дә дәшмисез, иптәш Шишков? — диде Миңнулла, Сидор Андреевичның телен йоткан шикелле тын гына утыруына җене чыгып.

Тик шуннан ары гына теге йокысыннан уянып киткән кешедәй сискәнеп куйды да, сикереп урыныннан торып:

— Ишеттегезме сез җыелыш ябык дигәнне?! Тагын ничә тапкыр кабатларга кирәк? — диде.

Ул моны артык каты итеп тә әйтмәгән иде. Ләкин җыелыштагылар минуты белән таралыштылар да беттеләр.

— Теләсәгез, сез ул халыкны «Барыня»га да биетә аласыз, ахрысы, Сидор Андреевич! — диде Миңнулла, кайтырга чыккач. — Моның сере нәрсәдә: куркамы алар сездән, әллә шулай нык хөрмәт итәләрме?

— Төрлесе бардыр инде, — диде Сидор Андреевич. — Ә тыңларга тиеш алар мине. Үзләре сайлап куйган кешене дә тыңламасалар — кая китә ул аннары? Шулай да бүген канәгать түгел әле мин алардан.

— Артык шаулашканга әйтүегезме?

— Анысы да булды. Аннан да бигрәк, озак җыелдылар. Сез бит бүген кайтып китмәкче идегез. Ә хәзер менә кунарга туры килер инде. Төнләләтеп юлга чыгып йөрмәссез бит. Якын гына ара түгел. Аннары төрле кораллы бандалар да күбәйде бу араларда.

— Кунарга туры килер шул инде болай булгач. Эшлисе эшләрнең берсенең дә юньләп очына чыга алмадык бит әле. Иртәгә иртүк сезнең белән һәм авыл советы членнары белән өй борынча йөреп, кемнең күпме ашлыгы барын исәпкә алырга да артыгын дәүләткә тапшыру чарасын күрергә кирәк булыр. Шунда берочтан фронтка барырга яраклы ир-атларның исемлеген дә терки барырбыз.

— Ыһы, шулай итәрбез.

— Сидор Андреевич, әлеге бөтен авыл халкын берьюлы партиягә кертергә тырышу кем коткысы белән эшләнгән нәрсә икән ул?

— Бер дә әйтә алмыйм шул, иптәш Гайсин.

— Шулаймы. Ярый, анысы соңыннан ачыкланыр. Әйтегез әле, Сидор Андреевич, җыелышта нигә алай битараф утырдыгыз сез? Нигә бер мәсьәлә буенча да миңа ярдәм итмәдегез?

— Начальник кеше үзе беләдер ни эшләргә кирәген, дип уйладым мин. Шуңа белер-белмәс тыкшынып, комачаулыйсым килмәде.

«Ай-һай, шулай булды микән? Киресенчә, мине көлкегә калдырырга түгел идеме икән исәбең?» дип уйлап алды Миңнулла. Ләкин уен тегеңә әйтмәде. Чөнки ул әле Сидор Андреевичны бик аз белә, ялгышырга да мөмкин иде...

Кай арада өлгергәндер, Сидор Андреевич Миңнулла белән килгән кызылгвардиячеләрнең дүртесен дүрт фатирга урнаштырып та куйган иде инде. Ә Миңнулланы ул үзләренә алып кайтты. Бу авылның кайбер кешеләренә карата да, Сидор Андреевичның үзенә карата да Миңнулла күңелендә сәбәбе әлегә үзенә дә бик үк анык булмаган ниндидер шик туган иде. Шуңа ул, дөнья эшен белеп булмый, төнлә андый-мондый хәл килеп чыга калса, бөтенебез дә бергә булу хәерле дигән фикергә килде:

— Юк, Сидор Андреевич. Сез безнең барыбызны да бер фатирга урнаштырыгыз инде!

— Алай булгач, нишләргә икән соң? — дип, Шишков бераз уйланып торды да: — Әһә, алайса, болай итәбез. Ишегалдында минем тагын бер бәләкәй өй бар анда. Хәзер шуны ягып җылытабыз да — эше бетте! — диде.

Бәләкәй дигән өе дә әйбәт кенә булып чыкты тегенең. Ике агач караваты, дүрт кешегә җитәрлек урын-җире дә бар иде. — Егетләрең шунда ятсын, ә үзең зур өйдә кун,— дип, Сидор Андреевич бик кыстап караса да, Миңнулланың күңеле тартмады.

— Мин яшь кеше, миңа монда да ярар. Ә зур өйдәге йомшак урында менә бу агай йоклар, — дип, иң өлкән кызылгвардиячене калдырып, үзе бәләкәй өйгә чыкты.

Алар ут сүндереп яткач күп тә үтмәде, ишегалдында кемнәрдер бик каты шаулаша башлады. Ни булды икән дип, Миңнулла сикереп торып чалбарын кия генә башлаган иде, фонарь тотып, ажгырып, алар янына балта һәм күсәкләр тоткан алты кеше килеп керде.

— Ни булды, агайлар? Ник болай кычкырышасыз? — диде Миңнулла.

— Кычкырышабыз икән, значит, сәбәбе бар! — диде мир үгезедәй тазасы һәм Миңнуллага инде таныш калын тавышлысы. — Давай, киен дә чык әле безнең белән урамга. Шунда сөйләшербез!

«Әһә, менә син нинди шәп кеше икән! — дип уйлап алды Миңнулла. — Барысыннан да күбрәк тавышланып, җыелышны таркатуың гына җитмәгән, инде монда да килеп җиткәнсең. Димәк, ата контр инде, болай булгач!»

— Нәрсә сөйләшмәкче буласыз сез? Нигә җыелышта әйтмәдегез әйтәсе сүзләрегезне? — диде Миңнулла, сабырлыгын югалтмыйча.

— Давай, телеңә күп салынма! — диде Калын тавыш.— Ыштаныңны тизрәк төймәлә дә — киттек! Шунда барысын да аңлатырбыз без сиңа!

Бүтәннәре дә шаулаша башлады:

— Әйе, әйе, шунда күрсәтербез без сиңа күрмәгәнеңне!

— Карале син, анасының табут тактасын... безнең актык икмәкне талап алып китеп, үзебезне сугышка, пуля астына озатмакчы була икән!

— А ну, давай, тизрәк кыймылда!

Инде аңлашылды: бу кешеләр яхшы ният белән йөрүчеләр түгел. Юк, боларга ияреп чыгарга һич тә ярамый иде хәзер!

— Әйтәсе сүзләрегезне иртәгә әйтерсез, — диде Миңнулла. — Ә хәзер, барыгыз, кайтып ятыгыз! Мин бүген сезнең белән сөйләшергә теләмим.

Ул арада, нигә алып чыкмыйсыз инде шул кызыл этне, дип, өйгә тагын җиде-сигез кеше килеп керде. Хәл тәмам куркынычка әйләнде. Ичмаса, гвардиячеләр дә ярдәм итә алырлык түгел — кылыч, мылтыклары түр почмакка сөяп куелган, ә үзләре торырга өлгермәгәннәр иде.

Теге яңа кергән кешеләр ябырылып үзенә таба килә башлагач, Миңнулла өстәлдә яткан «кыярын»[1] тиз генә үрелеп алды да:

— Туктагыз, мужиклар! Тагын бер генә адым атласагыз да, менә шушы бомбаны ташлыйм һәм барыгызны да шартлатам! — дип кычкырды.

Аның шул тәвәккәллеге ярап куйды. Бунтчылар шүрләп шып туктап калдылар.

— Хәзер үк чыгып китегез моннан! — диде Миңнулла, тегеләргә өннәренә килергә ирек бирмичә.— Мин өчкә кадәр санаганчы чыгып китмәсәгез, бөтенегез дә күккә очачаксыз! Бер... Ике...

---

[1] Формасы кыярга тартым булганга, ул заманда бомбаны шулай дип атаганнар.

Миңнулла җиңде: бунтчылар шыпан-шыпан гына башта өйдән, аннары сүгенешә-сүгенешә ишегалдыннан үк чыгып киттеләр. Ул арада гвардиячеләр сикерешеп торып, киенеп беткән иде инде.

Сез нигә миңа ярдәмгә килмәдегез, нигә шундый бунтчыларга юл куясыз, дип әйтмәкче булып, Миңнулла Шишков янына зур өйгә керергә теләгән иде, өйалды ишеге тыштан бикле булып чыкты. Шишков кайдыр киткән. Кая китте икән? Гаҗәп, өйләрендә хатыны, ике баласы һәм бер гвардияче агай да бар иде бит әле анда. Аларны өстән бикләп китте микәнни?..

Бунтчылар әле һаман таралышмаган, Миңнулланы сүгеп, һаман капка төбендә торалар. Яңадан котырып килеп керә күрмәсеннәр дип, Миңнулла капканы эчтән бикләде дә, Шишковның кайдан һәм ничек кайтып кергәнен саклап торырга кушып, йортның ал һәм арт капкалары төбенә берәр гвардияче куйды. Үзе калган ике гвардияче белән әлеге бәләкәй өйгә керде дә, аз гына булса да ял итеп алырга ниятләп, чишенеп тормыйча гына урынга ятты.

Ләкин мондый чакта адәм баласының күзенә йокы керәмени? Миңнулла ирексездән әле яңа гына булып үткән хәл турында уйлана башлады. Уйланмаслык та түгел бит. Кара син ул контр элементларны! Җыелышны өзүләре генә җитмәгән, Миңнулланың үзен дә үтермәкче булып килгәннәр. Имеш, ул аларны фронтка, үлемгә җибәрергә дип килгән. Имеш, икмәкләрен тартып алырга җыена... Үзе өчен түгел, совет дәүләтен саклап калу өчен көрәшкә җибәрергә тели ләбаса ул аларны! Закон буенча йөри. Икмәкләрен дә келәтләреннән себереп алып чыгарга җыенмый. Чәчүлеккә һәм семья членнарына яңа өлгергәнгә җитәрлектән артыгын гына җыймакчы иде бит ул. Шулай дип, җыелышта шар ярып әйтеп тә бирде. Тагын ник явызланып йөри икән бу агайлар? Кем коткысы белән шушылай төнләләтеп бунт күтәрмәкче булды икән болар?.. Ә Шишков үзе кайдыр чыгып тайган. Миңнулланы үтергәннән соң җавап бирергә туры килсә, берни белмим, берни күрмәдем, мин ул чакта бөтенләй өйдә үк юк идем, дип әйтмәкче булгандыр инде ул. Кем белә, бәлки җыелышны соңга калдыруны да шул ук Шишков юри оештырган булгандыр. Председатель булуыннан файдаланып, корткычлык белән шөгыльләнеп ятмый микән ул? Нәрсәдер бар монда, бар... Дүрт кешелек отряд белән генә тәртип урнаштыру мөмкин булмас бу авылда. Соңыннан, зуррак отряд белән килеп, совет властен бөтенләй яңабаштан оештырырга кирәк булыр. Ә хәзер... Хәзер Шишковның кайтканын гына көтеп торырга да, кайтып керү белән аны кулга алып, Карыйга алып китәргә һәм шунда ныклап торып сөйләшергә кирәк булыр... Авыл агайларының холкы кызык: нинди җикеренеп, кабып йотардай булып килеп кергәннәр иде, бомбаны шартлатам дигәч, минут эчендә чыгып тайдылар. Кешене үтермәкчеләр, ә үзләренең җан кадерле...

Миңнулла менә шуларын уйлап ятканда урам як капка төбендә торган сакчы килеп керде дә:

— Зур гына сакаллы бер кеше килде анда. «Мин — Степанов. Миңа Гайсин кирәк, аның белән сөйләшәсе сүзем бар», ди.

— Хәзер үк минем янга керт! Үзең сакта торуыңны дәвам ит!

— Я алла! — диде Григорий Петрович, Миңнулла янына кергәч,— Исән икәнсең әле, улыкаем! Үтерергә теләгәннәр бит сине! Әйткән идем бит мин сиңа бездә ныклы совет власте юк әле, килгәндә әйбәт кенә кораллы отряд алып кил дип. Сөйлә әле, балакай: ничек башыңны саклап ала алдың?

Миңнулла өстәлдә яткан бомбага ымлады:

— Әнә шул нәрсә коткарды. Ә сез моңарчы кайда булдыгыз, Григорий Петрович? Мин сезне авылыгызга килү белән чакырткан идем, Шишков, өйдә юк, тегермәнгә киткән, дип кайтып әйтте.

— Тегермәнгә?
— Әйе!
— О-о-о-о! Алайса, барысы да аңлашыла! Аның эше икән, димәк. Ә ул үзе көндез минем өйгә килеп керде дә: «Мин бүген Полянкага барган идем, шунда кызың Мария очрады. «Зинһар, әйт әле әтигә, тизрәк килеп житә күрсен, улыбыз бик нык авырый дип калды», диде. Барсам — оның жен урынына уйнап йөри. Мария әйтә, мин Шишковны күргәнем дә юк, ди. Шуннан уйга калдым: рас Шишков мине монда алдалап жибәргән икән, димәк, аңа миннән котылып тору кирәк булган. Димәк, ниндидер этлек эшләргә әзерләнә. Ул бик яхшы белә, мин авылда чакта барысын да бик яхшы күреп-белеп торам. Төнге каравылчы бит мин. Рас, мин әйтәм, Шишков мине алдаларга уйлаган икән, тукта, болай авыз ачып, куныл ятмыйм, шыпырт кына кайтып,ниләр мәтәштергәнен карап карыйм әле моның. Шулай дип уйладым да — әйдә авылга. Кайтсам, әйтәләр: каравыл өендә жыелыш булды, диләр. Анда ниләр булганын да сөйләп бирде күршем Петр. Шунда жыелыштан кайтканда теге беркөн мин әйткән контрларның, болай булмый бу, бүген төнлә волком әтәченең муенына кызыл муенса тагарга яки бүтән берәр төрле әмәлен табып юк итәргә кирәк, дип сөйләшкәннәрен дә ишетеп калган. Менә шуннан ары мин...
Григорий Петровичның сүзе шунда бүленеп калды, чөнки сакчылар, аркасына мылтык терәп, Шишковны алып кереп киләләр иде.
— Бу нинди тамаша бу, иптәш Гайсин? Мине тоткарларга ни хаклары бар аларның? — дип, Шишков Миңнулланы күрү белән бик кызып тотынган иде, Миңнулла, аңа бөтенләй игътибар итмичә, сакчыларга:
— Арестантның кулын бәйләгез! — диде.
Шишков тагын да ныграк тавыш куптара башлагач, йоклаган кешеләрне уятмасын дип, авызын да томалаттылар. Аннары олы өйнең ачкычы кайда икәнен сорады. Шишков белмим дип баш чайкагач:
— Яхшылык белән әйтмәсәң, өйалды ишегеңне ватабыз,— дип тә куркытып карады. Әмма Шишков һаман белмим дип барды. Тик Миңнулла, тотып атам хәзер, дип маңгаена наган терәгәч кенә яшергән жиреннән ачкычны алып бирде.
Кече якта, берни тоймыча гырлап, Миңнулла белән килгән кызылгвардияче агай йоклап ята һәм аның авызыннан аракы исе килә иде. «Тәки алдалаган — искерткән икән үзен Шишков-контр!» дип уйлап алды Миңнулла. Аны уятырга кушты да олы якка үтте. Зур агач караватта, өсләрендәге юрганнарын ачып ташлап, ике сабый — Шишков малайлары йоклый, ә хатыны Клавдия түтәй, өстенә киенгән килеш, бер почмакта сулкылдап елап басып тора иде.
— Елама, Клавдия түтәй, үзеңә дә, балаларыңа да тимәбез без, — диде Миңнулла, бичара хатынны кызганып.
— Ә Сидорны нишләтәсез?
— Аны үзебез белән алып китәргә туры килә.
Клавдия түтәй кычкырып ук еларга тотынды.
— Ой-йой-йой! Аллакай гынам! Аллакай гынам минем!..
Аның тавышына уянып, балалары да куркышып еларга тотынды. Шул гөнаһсыз сабыйларга карагач, тәннәре чымырдап, күңелләре әллә нишләп китте Миңнулланың. Әйе, әтиләренең совет властена дошман, корткыч икәнен белми шул алар. Тик яраткан әтиләре итеп кенә беләләр. Ихтимал, Шишков аларны үзе дә бик яраткандыр, аларга карата гадел булырга тырышкандыр, аларга гел яхшылык кына эшләгәндер.
Миңнулла Шишковка хатыны һәм балалары белән хушлашырга кушты. Шишков балаларын да, хатынын да кочып-кочып үпкәннән соң тегеләр өчесе дә, аңа ябышып, отыры үзәк өзгечрәк итеп елый башла-

дылар. Шуңа Миңнулланың гвардиячеләргә, әйдә, алып китегез инде тизрәк, дип әйтергә теле бармады. Ул арада Григорий Петрович килеп, аның колагына:

— Әллә калдырасыңмы, энекәш, балалары бик кызганыч бит, күз яшьләре төшәр, — диде.

— Үзем дә шулайрак уйлап тора идем, Григорий Петрович. Ләкин калдырсак, корткычлыгын тагын дәвам итәр бит ул.

— Итмәс. Шүрләде инде ул.

Шуннан соң да байтак икеләнеп торды Миңнулла. Ахырдан балаларны кызгану хисе җинде һәм ул үз кулы белән Шишковның кулларын чиште дә:

— Ярый, Сидор Андреевич, балаларың һәм Клавдия түтәй хакына бу юлга кичерәм мин сине. Ләкин кара аны, алга таба да контр эш алып баруыңны дәвам итсәң — миңа үпкәлисе булма! Шушы көннәрдә үк сезнең авылга тагын киләчәкмен. Шуңарчы продналог җыюны юлга сал! Ярлылар комитеты оештыр! Кызыл Армиягә яраклы ирләтларыгызның исемлеген төзеп куй!

— Бөтенесен дә эшләп куям, иптәш Гайсин! — дип Шишков Миңнуллага мең-мең рәхмәтләр әйтеп калган иде. Ләкин...

## 11

Миңнулла Матвеевкадан кайтканга ике тәүлек тә тулмаган иде, яман хәбәр китерделәр: төнлә каравылда торган чагында Григорий Петровичны үтергәннәр иде.

Үнбиш кешелек отряд белән Миңнулла шул ук көнне Матвеевкага барды. Григорий Петровичны танырлык та түгел — шул тикле каты кыйнаганнар.

Миңнулла эшне авыл советы председателе Шишков белән сөйләшүдән башламакчы булган иде, ул нияте барып чыкмады: Сидор Андреевич өйләрендә юк һәм аның кайда икәнен берәү дә, хәтта хатыны Клавдия түтәй дә белми иде.

— Кичә кичке аштан соң өйдән чыгып киткән иде, шуннан бирле кайтканы юк, кайда йөри торгандыр? — дип җавап бирде ул, үзе дә бик нык кайгырып.

«Димәк, Григорий Петровичны үтерүдә Шишковның да катнашы бар инде, болай булгач! — дигән уй телеп үтте Миңнулланың миен. — Их, теге чакта кулга алгач ычкындырасы калмаган икән аны! Кызганган булдым бит. Аннары Григорий Петрович та балаларын кызганып, калып торсын дигән иде. Ә Шишков, паразит, әнә, Петровичның үзен кызганмаган! Ну, кабахәт җан! Ну, әгәр минем кулга тагын эләксәң...»

Миңнулла авыл советының бүтән членнарыннан сораштырып караса да, Григорий Петровичның үлеменә кагылышлы бернинди дә мәгълүмат ала алмады. Шуннан соң ул Матвеевка халкын кайгы митингысына җыярга кушты. Халыкны Григорий Петровичлар ишегалдына җыйдылар. Болдырга мәрхүмнең табутын чыгарып куйдылар да, шул табут янына басып, Миңнулла сүз алды. Ул Григорий Петровичның гаделлек сөюче, туры сүзле һәм чын күңеленнән совет властена бирелгән кеше булганлыгын әйтеп китте дә:

— Шушы яхшы кеше инде менә безнең белән бергә эшли алудан, сөйләшә алудан мәхрүм, — диде. — Аның гомерен контрлар кискән. Ул контрлар — сезнең авылныкы. Кайберләре, бәлки менә хәзер дә сезнең арагызда басып тора торгандыр әле. Аларны табарга һәм хөкем итәргә кирәк. Ләкин моны без — волком хезмәткәрләре генә башкарып чыга алмыйбыз. Сезнең ярдәм кирәк безгә, иптәшләр! Григорий Петровичның үлеме — авыл советы председателенең корткычлык юлы-

на басуы нәтиҗәсе. Менә хәзер дә председатель Шишков каядыр юкка чыккан. Моннан алдагы килүемдә миңа каршы бунтны да, һичшиксез, ул оештырган булгандыр. Кыскасы шул: сезнең авыл советы үз вазифасын үти алмады, иптәшләр. Совет властен ныгыту өчен тырышасы урында, авыл ярлыларына һәрьяклап ярдәм итәсе урында, корткычлык эше алып барган ул. Шуңа күрә менә шушы минуттан авыл советыгыз таратылган дип исәпләгез. Ә хәзер, әйдәгез, Григорий Петровичны мәңгелек йортына илтеп кайтыйк та, каравыл өе янына җыелып, авыл советының яңа составын сайлап куярбыз. Кемнәрне сайлау турында уйлаша торыгыз. Шунысын исегездән чыгармагыз: авыл советы составына тик ярлылар гына сайланырга тиеш!..

## 12

Миңнулла бүген дә теге көнге шикелле тавыш-гауга чыкмаса ярар иде дип шикләнгән иде. Әмма җыелыш гаҗәп тыныч һәм эшлекле үтте.

— Сезнең арагызда коммунистлар партиясе члены бармы? — диде Миңнулла, Григорий Петровичны җирләп кайткач, яңадан җыйналган халыкка мөрәҗәгать итеп.

Дөресен әйтергә кирәк, ул моны коммунист булуына ышанып түгел (әле өченче көн генә берәү дә юк иде бит), болай гына, дөнья эшен белеп булмый дип кенә сораган иде. Ләкин аның гаҗәпләнүенә каршы, халык арасыннан «бар!» дигән тавыш ишетелде. Ул да булмады, тавышның иясе үзе дә алгарак үтеп:

— Мин — коммунист, иптәш Гайсин, — диде.

Чынлап сөйли микән бу кеше дип, Миңнулла тегеңә сынабрак карады. Башына колакчын бүрек, өстенә солдат шинеле кигән, урта буйлы, сул кулын сөлге белән бәйләп муенына аскан утызбиш-кырык яшьләрендәге бу кеше алай шаярып сөйләшүчегә охшамаган иде.

— Монда, минем янга рәхим итегез, иптәш! — дип, Миңнулла тегене үз янына дәшеп китерде.

Агайның исеме Сергей, фамилиясе Семенов, атасының исеме Степан икән. Шушы авылда туып-үскән. Ярлы крестьян малае. Шушы елның сентябрь аенда үзе теләп акларга каршы сугышка киткән. Пермь губернасында, Өченче армия сафында хезмәт иткән. Шунда партиягә кергән. Көнгер юнәлешендә дошманга каршы сугышта яраланган. Ләкин аны госпитальгә алмаганнар. Синең ярың әллә ни авыр түгел, син аяклы яралы, аннары туган җирең дә якын гына, кулың төзәлгәнче өеңдә дәвалана тор, ә бездә авыр яралыларга да урын җитми, дип кайтарып җибәргәннәр.

— Бик әйбәт булган әле кайтарулары! — диде Миңнулла, чын күңеленнән куанып. — Югыйсә, сезнең монда бер коммунист та юк иде.

— Сез менә бу кешене беләсезме? — диде аннары, халыкка мөрәҗәгать итеп.

— Беләбез! — дип кычкырдылар аңа.

— Яхшы беләсезме?

— Яхшы беләбез!

— Алайса, авыл советы составына мин менә шушы иптәшне тәкъдим итәм. Кем дә кем Семенов Сергей Степановичны авыл советына член итеп сайларга ди — кулларыгызны күтәрегез!

— Яхшы. — Миңнулла үзе белән рәттән басып торган отряд командирына карады: — Яле, тиз генә санап алыйк, Федор Михайлович!

Сергей Степановичны сайларга ризалык белдереп, кырык алты кеше кул күтәргән булып чыкты.

— Ә каршылар? — диде Миңнулла.

Каршылар егерме өч кеше булды.

— Бер якка да кул күтәрмәүчеләр?

Андыйлар жиде кеше иде.

— Шулай итеп,— диде Миңнулла,— күпчелек тавыш белән иптәш Семенов Сергей Степанович Матвеевка авыл советына член итеп сайланган дип исәпләргә! — Аннары карандашын тешләп ни язарга белмичә аптырап калган беркетмә язучыга карап: — Беркетмәгә менә шулай дип язып куярга кирәк! — диде.

Тагын ике кешене сайларга кирәк иде.

— Кемдә нинди тәкъдимнәр бар, иптәшләр? — диде Миңнулла.

Бер кеше, миндә тәкъдим бар, дип кулын күтәреп алгарак үтәргә итенә башлаган иде, ләкин аны, тик кенә тор син, Фрол, сүз монда байлар советы турында түгел, ярлылар советы турында бара, дип аңа ирек бирмәделәр. Сергей Степанович тәкъдиме белән советка тагын ике ярлы кешене сайладылар.

Аннары Миңнулла яңа сайланган совет алдында торган бурычларга тукталып, хәзерге чорда шул бурычларның иң мөһиме дәүләткә икмәк тапшыруны юлга салу икәнен аңлатты.

— Ә сез, — диде ул, жыелыштагыларга мөрәжәгать итеп, — авыл советына менә шул ифрат дәрәҗәдә мөһим бурычны тизрәк гамәлгә ашыру өчен кулыгыздан килгәнчә ярдәм итәргә тиешсез. Сезнең авылда икмәк бар. Мәсәлән, мин үзем дә жиде кешегезнең яшерелгән икмәкләре булуын беләм. Кимендә иллешәр поттан артык икмәкләре бар аларның. Ә Кызыл Армиягә икмәк кирәк! Завод эшчеләренә икмәк кирәк. Аларга көненә нибары бер әчмуха бирелә торган икмәкнең дә житмәгән чаклары була. Ә монда иллешәр потлап икмәк яшереп яталар. Шушы жыелыш алдында катгый итеп әйтеп куям: икмәкләрен яшергән кешеләр әгәр иртәнгә кадәр үзләре килеп миңа икмәкләренең кайда икәнлеген әйтеп бирмәсәләр — үзләренә үпкәләсеннәр. Без аларны, совет дәүләтенә каршы корткычлык эшләүчеләр буларак кулга алып, үзегезнең авыл халкы алдында ук атып китәчәкбез! Миндә икмәк барын белми торгандыр әле, дип уйламасын ул кешеләр. Минем кулда Григорий Петрович язып калдырган исемлек бар. Ул исемлектә кемнең икмәге кайда яшерелгәнлеге дә күрсәтелгән. Григорий Петрович төнге урам каравылчысы иде бит. Ул барысын да күзәтеп, белеп торган. Кулаклар шуңа үтергән аны. Тагын шунысын да искәртеп куям: икмәкләрен үз ихтыярлары белән дәүләткә тапшырырга риза булган кешеләргә тимәячәкбез. Ә бүтәннәре рәхим-шәфкать көтмәсен...

Аннары Миңнулла сүзне икенче көн тәртибенә — партиягә кабул итү мәсьәләсенә күчереп, коммунистлар партиясе членнарының бурычларын, хокукларын аңлатты һәм партия сафына тик ярлылар гына кабул ителүен әйтте дә:

— Менә шул бурычларны үтәргә әзер торган иптәшләрнең кул күтәрүләрен сорыйм? — диде.

Жыелыштагыларның тик икәве генә кул күтәрде.

— Беркөн бөтен авылыгыз белән партиягә кермәкче булган идегез бит, хәзер кире уйладыгызмыни? — диде Миңнулла, бу хәлгә азрак сәерсенеп.

— Беркөнгеләр бүген монда юк инде, энекәш! — диде кул күтәрүчеләрнең берсе. — Син отряд белән килгәнеңне белгәч, аннары Григорий Петровичлар ишегалдында каты гына итеп сөйләп тә алгач, сыпыртты инде алар жыелыштан.

— Зыян юк, жыелыштан китсәләр дә, совет властеның гадел хөкеменнән ерак китә алмаслар! — диде Миңнулла. — Ә партиягә керергә теләгән иптәшләр белән жыелыштан соң аерым сөйләшербез.

Кызыл Армия һәм аңа ярдәм итү мәсьәләсенә күчкәч, Сергей Степанович сүз сорады. Аның ни сөйләячәген Миңнулла белми, шуңа аңа

сүз биргәндә эшне бутап ташламаса ярый инде, дип шикләнебрәк кенә биргән иде. Әмма Сергей Степанович сәяси яктан да, ил һәм фронт хәлләреннән дә хәбәрдар һәм хәйран шома телле кеше булып чыкты. Башта халыкка Совет хөкүмәтенең шушы елның унбишенче гыйнварендә кабул ителгән «Эшче-крестьян Кызыл Армиясен төзү турында»гы карарын аңлатты, аннары июль аенда Советларның V Бөтенроссия съезды булып, анда Совет Конституциясе кабул ителүен һәм ул конституциядә совет халыкларына ирек, тигез хокук бирелү белән бергә, социалистик Ватанны дошманнардан саклап калу өчен унсигез яшьтән алып кырык яшькә кадәр булган ир-атларның хәрби хезмәт итүе мәҗбүри итеп куелуын сөйләп бирде дә сүзен партиянең Урал өлкә комитеты мөрәҗәгатеннән: «Уралның ирек сөюче уллары, көрәшкә күтәрелегез! Кызыл Армия сафларына басыгыз! Сезнең тирәдәге Урал таулары ярыкларында, чокыр-чакырларында хыянәтчеләр һәм контрреволюционерлар үзләренең каберләрен тапсын! Кызыл Урал куркыныч астында! Барыгыз да кулларыгызга корал алыгыз!» — дигән юлларны укып тәмамлады. Степан Сергеевичның нотыгын хуплап кул чаптылар.

Җыелыштан соң теге ике иптәшне партиягә кабул итеп, Матвеевка авылы тарихында беренче партия ячейкасы төзеделәр. Аның секретаре итеп Степан Сергеевич сайланды.

Аннары авыл советы членнары арасында эш бүлештеләр. Арабызда синнән дә тәҗрибәлерәк кеше юк, дип, бертавыштан тагын шул Степан Сергеевичны авыл советы председателе итеп сайладылар.

Авыл Советы һәм партия ячейкасы членнары бергәләшеп, ашлыкларын яшереп ятучыларның исемлеген төзеделәр. Андыйлар, ягъни кимендә 50 поттан артык ашлыгы булган кешеләр — мәрхүм Григорий Петрович әйткәнчә, җидәү генә түгел, егерме өч булып чыкты.

Дәүләткә тапшырырга тиешле икмәкләрен әле тапшырып бетермәгән һәм тапшырырга алай атлыгып тормаган кешеләр дә байтак иде. Аларның исемлеген төзеп, үзләрен авыл советына чакыртып сөйләшергә булдылар.

Ахырдан Кызыл Армиягә кешеләр җибәрү мәсьәләсенә тукталып, армия хезмәтенә ярарлык ир-атларның исемлеген төзеделәр. Бу авылда андыйлар да күп — утыз ике кеше иде. «Башка авылларның ир-атлары барысы да диярлек сугышта. Дөрес, бөтенесе дә безнең якта түгел. Дошман ягында йөрүчеләре дә бар... Утыз-кырык чакрымда гына фронт сызыгы. Бер якта аклар, бер якта безнекеләр. Аклар, ничек кенә итеп булса да, Пермьгә бәреп керергә, тимер юлны үз кулларына төшереп, Урал аръягындагы гаскәрләре белән кушылырга тырыша. Ә бу авыл мужикларына әллә бар ул сугыш дигән нәрсә, әллә юк. Сәбәбе нәрсәдә соң моның?»

— Бөтен хикмәт урманда! Урманның якын булуында! — диделәр Миңнуллага. — Кызыллар килеп армиягә җыя башласа да, аклар килеп мобилизация игълан итсә дә, урманга кереп качалар. Урманда аларның кыш торыр өчен землянкаларына кадәр бар, дип сөйлиләр. Менә күрерсез әле, теге беренче исемлеккә кергән кешеләрне иртәгә эт белән эзләп тә табып булмас. Төнлә шыпырт кына сызып бетәр шулар!..

Ләкин асылда эшләр алай ук начар булмады. Йорт саен тикшереп йөри башлар өчен, иртән отрядына күрсәтмәләр биреп торганда ук беренче исемлеккә эләккән кешеләрнең бишесе, үзләре килеп, Миңнулладан, син кичәге сүзеңдә торасыңмы, энекәш, дип сорадылар да, Миңнулла, әйткән сүз — аткан ук, дигәч, артык икмәкләрен үзләре алып килеп тапшырдылар. Тагын дүртесенекен тентү вакытында, җидесенекен авыл советы һәм партия членнары күрсәтүе буенча таптылар. Шулай итеп, егерме өч кешенең уналтысыннан дүрт йөз потка якын икмәк җыеп алынды. Ләкин җидесенең икмәкләрен дә, үзләрен дә таба алмадылар.

Бу яктан теге агайның сүзе хак булып чыкты. Әмма икмәкнең җыйналган кадәресе дә аз түгел иде. Аннары егерме ике кешене фронтка озаттылар.

Ләкин иң мөһиме шул: Матвеевкада, ниһаять, чын мәгънәсендә совет яклы кешеләрдән гыйбарәт булган авыл советы, чын мәгънәсендә коммунистлардан торган партия ячейкасы төзелде!

Ә теге контр элементлар, әлегә качып котылсалар да, әллә кая китә алмас, бүген булмаса иртәгә аларның койрыгы кысылачагына Миңнулланың шиге юк иде.

## 13

Матвеевка байларыннан җыеп алынган икмәкне унбиш олауга төяп Карыйга кайтып кергәндә, Хәйретдинов Хәйрулла мәсьәләсе буенча җибәрелгән гвардияче Усыдан әйләнеп кайткан һәм Колчин аңа менә шушы язуны биреп җибәргән иде:

«Иптәш Гайсин! Мин синең Хәйретдиновка карата күргән кискен чараңа бик гаҗәпләндем. Без монда тикшереп карадык. Аның биографиясендә бер дә алай шикләнерлек нәрсә юк. Хәйретдинов унҗиденче елдан бирле партия члены. Шушы язуны алу белән үк аннан гафу үтен һәм аны тоткыннан азат ит!

Бездәге мәгълүматларга караганда, сезнең яктагы волостьларда хәлләр көннән-көн кыенлаша — контрлар активлаша бара. Ничек тә түзәргә тырышыгыз! Хәзергә сезгә корал белән дә, кешеләр белән дә ярдәм итә алмыйбыз, чөнки үзебездә дә эшләр сәгать саен кискенләшә бара. Рухыңны төшермә! Җиңү барыбер безнең якта булачак!

Коммунистларча сәлам белән — Е. Колчин».

Колчинның бу җавабы Миңнулланың җен ачуын чыгарды. Чөнки аның мәсьәләне җентекләп тикшереп тормавы, ашык-пошык кына, кул астындагы документларга карап кына җавап биргәнлеге көн кебек ачык иде. Ә иң яманы: Емельян Петровичның Миңнулла әйтеп язган фактларга ышанмавы ярылып ята иде. Әгәр ул Миңнуллага ышанган булса, үзең кара инде, Гайсин, мин сиңа ышанам, ничек кирәк тапсаң, шулай эш ит ул Хәйретдинов белән дип, яки, һич тә булмаса, син аны сак астында безгә озат, без монда яхшылап тагын бер кат барысын да тикшербез, дип язган булыр иде. Ә ул үз-үзенә бик нык ышанып, Миңнулла сүзләрен бөтенләй искә дә алмыйча, «азат ит!» дип боерган. Ә бит ул аңа Хәйретдиновны инде күптәннән һәм яхшы белүен, аның совет властена кан дошман икәнен ап-ачык итеп язып җибәргән иде, югыйсә!..

Миңнулла башта, әллә үз кулым белән атып үтерим микән шул кабахәтне, аның контр икәнлеген исбатлый торган фактлар җитәрлек бит инде, дип тә уйлаган иде. Әмма соңыннан бу заманда ниләр генә булмый, бәлки Хәйретдинов, чыннан да, аклар ягында партия заданиесе буенча гына йөргән булгандыр, бәлки ул, чыннан да, коммунисттыр дигән шик күңеленә килде дә Емельян Петровичның боерыгын үтәргә булды. Ләкин гафу үтенергә күңеле һич тә тартмады.

— Бар, Хәйретдинов, — диде аңа Миңнулла, — бу юлга азат итәм мин сине. Әмма, кара аны, бу якларда бүтән эзең дә булмасын!

— Рәхмәт, Гайсин! Бу изгелегеңне мәңге онытмам! — дип өтәләнеп чыгып китте теге.

Миңнулла өйләренә төшке ашка кайтып килмәкче булып, курткасын киеп торганда, аның янына, бик ашыгып, өч хәрби килеп керде.

— Мин — Пенза полкының батальон командиры Мидхәт Мостафин! — диде аларның өстенә кайры тун кигән һәм бил каешына наган тагканы.

— Бик әйбәт. Ә мин волком председателе Гайсин Миңнулла булам. Үтегез, утырыгыз!

Соңгы көннәрдә Миңнулла хәрбиләргә инде күнеккән, фронтка китеп баручы частьларның командирлары аның янына еш сугыла торганнар иде. Кайсылары Карыйда кунып китәргә ниятли дә солдатларын фатирларга урнаштыру өчен ярдәм сорап керә. Кайсыларыча олаулар кирәк була. Кайсыларының азык-төлек мәсьәләсе койтылаңган була да шул җәһәттән ярдәм итүне үтенеп киләләр иде. Әлеге батальон командиры да шундыйрак бер үтенеч белән кергәндер дип уйлаган иде Миңнулла. Ләкин эш ул көткәнгә караганда күп мәртәбә җитдирәк булып чыкты.

— Безнең утырып торырга да, озаклап сөйләшергә дә вакытыбыз юк, иптәш Гайсин,— диде теге агай.— Хәл бик җитди: без чигенергә мәҗбүрбез, аклар үкчәгә диярлек басып килә! Ә сез хәзер, менә шушы минуттан ук, волкомыгызны һәм волкомда эшләүче коммунистларның семьяларын эвакуациягә әзерли башлагыз!

— Кайдан килә соң ул аклар? — диде Миңнулла, тегеңә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

Фронт сызыгының бу якларга да якынлашып килүен, Колчак бандалары кысрыклавы нәтиҗәсендә безнең гаскәрләр чигенергә мәҗбүр булуын Миңнулла белә иде. Карыйның дошман кулына калу мөмкинлеген дә сизенеп йөри иде. Ләкин ул хәл менә шушылай кинәт кенә, көтмәгәндә генә килеп чыгар дип башына да китерми иде. Гомумән, артык борчылырга урын юк, чөнки волостька караган авыллардан бер дә андый хәвефле хәбәрләр ишетелми иде. Әмма Мидхәт агай уйнап сөйләшми иде булса кирәк:

— Подъелничная—Верхотурка—Комарово юнәлешеннән!— диде ул.

Монысы инде Миңнулла өчен бөтенләй көтелмәгән нәрсә иде. Ни өчен дигәндә, ул юнәлеш иң нык, иң ышанычлы санала иде моңарчы. Анда Кама җыелма полкы тора. Аның командиры Козьминыхны Миңнулла бик әйбәт белә — полкка азык-төлек белән ярдәм иткәне бар иде. Шул чакта Миңнулла аның белән андый-мондый хәл килеп чыгып, волкомны эвакуацияләргә туры килә калса, корал һәм сугышчылары белән ярдәм итү хакында сүз куешып та кайткан иде. Ни карады икән соң анда ул Козьминых? Нигә акларны болай тиз генә үткәреп җибәрде икән?

— Козьминых дошманга сатылган! — диде Мидхәт агай.

Аның бу сүзләре Миңнулланың башына чүкеч белән суккандай булды.

— Сез ни әйткәнегезне белеп әйттегезме, иптәш Мостафин? — диде ул шаккатып.

— Мин моны бик белеп әйтәм, энем! Күп сөйләшеп торыр чак түгел, хәзер үк эвакуация чарасына керешегез!

— Алай булгач, иң башта икмәкне чыгарып калырга кирәк була инде. Ә аны без үз көчебез белән генә майтара алмабыз. Ярдәм итә алмассызмы икән безгә?

— Анысыннан гына эш калмас. Икмәгегез байтакмы әллә?

— Тугыз йөз потлар чамасы булыр.

— Кайдан килде ул кадәр хәзинә?

— Байлардан һәм продналог түләргә тиешле крестьяннардан җыйдык.

— Кайда ул икмәгегез? Нигә дәүләткә тапшырмадыгыз?

— Соңгы ике көн эчендә җыйналган икмәк ул. Биш йөз потлабын әле бүген генә алып кайттык. Шуңа Осага озатырга өлгермәгән идек. Ә икмәкнең кайда икәнен күрсәтергә хәзер берәр иптәшне җибәрермен сезнең белән.

— Аңлашылды. Алайса, без аны хәзер!..

— Сезнең уегызча, аклар кайчан Карыйга килеп җитәчәк, иптәш Мостафин?

— Иң күп куйганда да ике сәгатьтән монда булачак алар! — диде комбат, бер дә икеләнеп тормыйча.

— Ә сез аларны Карыйга кертмичә күпме тоткарлый алырга ниятлисез?

— Аңламыйм, ничек инде «тоткарлый алырга?»

— Соң сез безне бөтенләй сугышсыз гына дошман кулына калдырып китәргә җыенмыйсыздыр лабаса?!

— Ә-ә-ә-ә! Син әнә нәрсә турында әйтәсең икән! Юк инде, агай-эне, аклар белән тартышырлык мөмкинлегебез юк безнең. Соңгы ике тәүлек эчендә генә дә, әнә шул каршы торырга тырышып, батальонның яртысыннан артыграгын югалттым инде мин. Ул чакта, ичмаса, санаулы гына булса да, патроннарыбыз бар иде. Ә хәзер кеше башына бирәр патроныбыз да юк. Шулай булгач, ничек итеп баштанаяк коралланган дошманны тоткарлый алмак кирәк?

Батальон командиры Миңнуллага әнә шулай дип җавап бирде дә, ничек ашыгып килеп кергән булса, шулай ук ашыгып чыгып та китте.

Миңнулла бер киңәшчесез, бер ярдәмчесез торып калды. Бөтен нәрсә аның җаваплылыгында иде хәзер. Дөрес, икмәк мәсьәләсе хәл ителде, анысы дошман кулына калмас: батальон командирының икмәк өчен чукынырга әзер икәнлеге кыяфәтеннән үк күренеп тора иде. Ләкин икмәкне урнаштырудан тыш та эшлисе эшләр бетәсе түгел иде бит әле. Барыннан да элек, волком документларын җыйнап-төреп куярга кирәк. Аннары килеп, волком аппаратында эшләүче иптәшләрне, аларның семьяларын һәм, гомумән, ак бандалар кулына калырга теләмәгән Карый кешеләрен бөтенесен дә ничектер җайлап кына, артык өркетмичә генә эвакуациягә әзерлисе бар. Әти-әниләрен калдырып китү шулай ук куркыныч: аклар Карыйга басып кергәч, малаегыз волком председателе булган икән, коммунист икән дип, теге чакта Хәйрулла тинтерәткән шикелле тинтерәтә башлаулары, хәтта кулга алулары да бик мөмкин. Ниһаять, Зәйнәп... Ул кыз волкомның халык мәгарифе бүлегендә бик теләп һәм тырышып эшли башлаган иде. Зәйнәп волостька кергән авылларның укый-яза белә торган һәм совет яклы булган кешеләрен җыйнап, балаларны яңача, советча укыта башлау мәсьәләсе буенча киңәшмә үткәргәч, шул киңәшмәдә катнашкан өяз мәгариф бүлеге вәкиле — тәҗрибәле педагог һәм коммунист иптәш — аны бик нык ошатып:

— Бу кызны мәгариф бүлегенә алып дөрес иткәнсез, иптәш Гайсин. Яшь кенә булса да, тырыш, кыю һәм иң мөһиме: эшне оештыра белә икән. Кыскасы, укыту-тәрбия мәсьәләсендә «ходай биргән» сәләте күренеп тора! — дип канәгать булып киткән иде.

Шул киңәшмәдә һәр авылга кимендә берәр укытучы билгеләнгәннән соң, Зәйнәп ул авылларга укыту биналары, ягъни мәктәпләр булдыру мәсьәләсен хәл итү өчен янып йөри башлаган иде. Байтак авылларда мәктәп биналары билгеләнгән дә иде инде. Ләкин, кызганычка каршы, Зәйнәп ул эшне ахырына кадәр җиткерә алмады — өченче көн кинәт кенә тиф белән авырып китеп, аяктан егылды. Хәле бик авыр. Вакыт-вакыт саташып китеп, кешеләрне дә танымый тора. Аны алып китәргәме, калдырып торыргамы? Алып китсәң, болай да хәл эчендә генә яткан кешенең бөтенләй өзлегеп китүе мөмкин. Калдырып китәр идең, беренчедән, фатир хуҗасы үзе дә кылт-мылт кына йөри торган карчык. Икенчедән, аклар басып кергәч, Карыйдагы контрлар Зәйнәпне шул ук сәгатендә «сатачак». Дөрес, Зәйнәп әлегә партия члены түгел түгелен. Ләкин аклар партия членнарын гына түгел, совет органнарында эшләгән кешеләрнең барысын да дошман саныйлар бит! Аннары шунысы да бар: Карыйга аклар белән бергә Шакир-кабахәт тә килеп кермәс дип кем әйтә ала?..

## 1

Пенза полкының батальон командиры ничек кенә ашыктырса да, эвакуациягә ике сәгать эчендә әзерләнеп чыгып китә алмадылар. Һәм алай ашыгуның кирәге дә булмады. Мостафин батальоны үтеп киткәч, Карыйга аклар түгел, үзенең штабы белән Бирск бригадасы командиры Василий Иванович Дедкин килеп керде дә:

— Эвакуациягә китәргә туры килер, анысыннан бөтенләй үк котылып булмас, — диде. — Ләкин артык кабаланмагыз. Яхшылап җыеныгыз. Коммунист семьяларының берсен дә калдырмагыз. Чөнки аклар гадәттә эшне коммунистларның семья членнарын җәзалаудан башлыйлар. Без, һич югы, иртәнгә кадәрле булса да дошманны Карыйга кертмәскә тырышырбыз!..

Күчәнә башлагач мәшәкате күп була икән аның. Волком әйберләрен олауларга төяп озатып җибәргәнче генә дә тәүлеккә якын вакыт үтеп китте. Ярый әле, шул кичтә Фәйзулла Чиркандыдан кайтып җиткән иде. Эвакуация олауларын Миңнулла аның җаваплылыгына тапшырып җибәрде. Фәйзулланың әтисе Сәгыйдулла агай да, мин дә аклар кулына калмыйм, монда калсам, Шәйхетдинов әйләнеп кайтачак та, теге чакта үзе белән ияреп китмәгәнгә ачу итеп, әбизәтелне минем башка җитәчәк ул, дип олаулар белән китәргә булды. Гомер буе ат җигеп юл йөргән кеше булуын искә алып, Миңнулла аны Фәйзулланың ярдәмчесе итеп билгеләде.

Ә Миңнулланың әти-әнисе Карыйдан китәргә теләмәделәр. Әнисе кырт кисеп:

— Без үзебезнең Карыйдан бер җиргә дә китмибез, улым. Шушы яшебезгә җитеп, бу дөньяда берәүгә дә зыян китергән кешеләр түгел без. Шулай булгач, Колчак солдатлары гына түгел, Никулай патша үзе килсә дә куркырлык эшебез юк! — диде.

Бәлки әти китү ягындадыр, бәлки ул әнине китәргә күндерә алыр, дип өметләнгән иде Миңнулла. Шуңа:

— Әллә китү хәерлерәк булыр микән, әти? — дип әйтеп караган иде. Әмма әтисе бу юлы да аның өметен акламады:

— Әнкәң әйтсә — белеп әйтә, улым, калырга туры килер инде, — дип җавап бирде дә, терлекләргә печән биреп керим әле дип, ишегалдына ук чыгып китте.

Әнисенең бер әйткән сүзеннән кире кайта торган гадәте булмавын яхшы белгәнгә күрә, Миңнулла ул хакта бүтән сүз озайтып тормады.

Ә Зәйнәп мәсьәләсе тәки хәл ителмичә һәм бик үкенечле булып калды.

Каласыңмы, китәсеңме? дип сорарга Миңнулла башта аның янына барган иде. Ләкин кыз җан тиргә батып, саташып ята булып чыкты. Аннары Миңнулла киңәш сорап әнисенә килде.

— Безнең теге волкомның мәгариф бүлегендә эшли торган кыз тиф белән авырый бит әле, аны нишләтик икән, әни?

— Авыру кешене кузгатып йөрү ярамас, улым! — диде әнисе.

— Калдырып китү дә хәвефле шул. Ни юньләп карар кешесе юк аның. Аннары килеп, волкомда эшләгәнен белсәләр, аклар бер-бер хәл ясавы да бар.

— Үзе нәрсә ди соң ул бала, сорадыңмы үзеннән?

— Сөйләшә алырлык түгел шул.

— Алайса, әйдә хәзер үк барыйк та үзебезгә апкайтык без аны, улым! Гафифә карчык андый хастаны тәрбия кылырлык кеше түгел,

үзе кеше тәрбиясенә мохтаҗ ул, бичара. Мин үзем карап торырмын ул баланы. Бәлки әле сез чыгып киткәнче хәле дә арулана башлар да, китәсе килсә — китәр, каласы килсә — калыр.

Әни кеше сизмиме соң? Сизенә иде бугай ул Миңнулланың Зәйнәпне яратканын. Һәм моның шулай булуын күңеленнән хуплый да иде бугай. Бер көнне Миңнулла төшке ашка кайтмагач, аңа төшке аш китерә килгән чагында волкомда Зәйнәпне күреп:

— Бигрәк тә мәхәббәтле инде, шушы бала, үз кызым шикелле күрәм үзен! — дип тә әйтеп куйган иде.

Зәйнәпне өйләренә алып кайткач, аны чыннан да үз кызы шикелле якын итеп карый башлады. Кыз икенче көнне аңына килеп, сөйләшә башлагач:

— Күптән үзебезгә апкайтасы калган икән аны! Әнә безнең йортка килү белән хәле рәтләнә башлады, балакайның! Юк, беркая да җибәрмим мин аны,— дип куанычыннан ни эшләргә дә белмәде.

Әмма Зәйнәпнең каласы килми. Ул:

— Китәм! — дигән иде.

Ләкин...

Усыга аклар бәреп кергәнлектән, ул якка юл тотарга һич ярамый. Көңгер дә куркыныч астында, анда бару шулай ук мөмкин түгел. Аннары килеп, олы юл буйлап барырга гомумән мөмкинлек юк, чөнки анда бертуктаусыз — кайсы чигенү ягына, кайсы акларга каршы — безнең гаскәрләр агылып тора иде. Әмма иң кыены шул булды: волком олауларын кая таба озатырга икәнен Миңнуллага беркем, хәтта бригада командиры Василий Иванович та тәгаен генә әйтә алмады. Маршрутны, тәвәккәлләп, Миңнулланың үзенә сайларга туры килде. Шишмәрә — Харис авыллары аша Таныкка бара торырга кушты ул Сәгыйдулла агай белән Фәйзуллага. Ә үзе волкомның кызылгвардиячеләр отряды белән Карыйда калды. Чөнки Василий Иванович, махсус приказ биреп, Карый отрядын үзе командалык итә торган Бирск отряды составына керткән һәм аның командиры итеп Миңнулланы билгеләгән иде.

Миңнулла Карыйда каласы булгач:

— Алайса, мин дә калып торам, киткәндә үзең белән алып китәрсең, яме! — дип, Зәйнәп тә калган иде.

Миңнулла отрядына Василий Иванович бригаданы азык-төлек һәм аклар бик нык кыса башлап, чигенергә туры килгәндә кирәк булачак транспорт белән тәэмин итү бурычын йөкләгән иде. Бригада Карыйны саклап өч тәүлек буена каты сугыш алып барды. Ул көннәрдә Миңнулла үзенең отряды белән гел транспорт мәсьәләсе белән генә шөгыльләнде: волостьның әле дошман кулына эләкмәгән авылларыннан иллегә якын җигүле ат җыйнап алып кайтты. Дөрес, ул атларны бөтенләйгә түгел, вакытлыча, бригада йөкләрен икенче җиргә күчерү өчен генә җыйдылар. Соңыннан хуҗаларына кайтарып бирелергә тиеш иде ул атлар. Ләкин ат хуҗалары барысы да диярлек үзләре иярәп килде. Миңнулла аларга:

— Хәвефле юлга чыгасыз бит, агай һәм апайлар, алай-болай юлда дошман белән бәрелешергә туры килеп, пуля-мазар тиеп куйса, ни эшләрсез? — дип әйтеп караса да, аны тыңларга теләмәделәр:

— Я атларны калдырасың, яки атлар белән үзебезне дә алып барасың! — диделәр.

Кызганычка каршы, Миңнулланың шиге урынлы булган булып чыкты. Бригада йөген төягән олаулар Карыйдан кузгалып күп тә китмәгән, аклар засадасына юлыккан һәм шунда теге ат хуҗаларының уникесе һәлак булып калган иде.

Бирск бригадасы киткәннән соң да Миңнулла үз отряды белән Карыйда бер төн кунды әле. Чөнки Василий Иванович аңа:

— Син, Гайсин, отрядың белән Карыйда каласың һәм, бригаданың чигенүен тәэмин итеп, соңгы чиккә кадәр дошманны тоткарлап торасың! — дип боерып киткән иде.

Чамасыз озын тоелган гыйнвар төне чагыштырмача тыныч узды. Дошманның бер тапкыр биш кешелек атлы разведкасы, икенчесендә тугыз кешелек чаңгычылар группасы Карыйга килеп керергә омтылып караганнар иде, әмма отряд егетләре аларны якын да җибәрмәделәр. Шул бәрелеш вакытында ике колчакчыны әсир иттеләр. Әсирләрнең әйтүенә караганда, Карыйдан биш-алты чакрымдагы күрше авылда акларның күп санлы гаскәре тупланган. Ләкин аклар алга барырга шикләнәләр, чөнки Карыйда кызылларның көче зур дип уйлыйлар, шуңа үзләренә ярдәмгә яңа көчләр килгәнне көтеп торалар икән.

— Ә өстәмә көчләр кайчан килеп җитәргә тиеш соң? — дип сорагач, әсирләр, анысын тәгаен генә әйтә алмыйбыз, ләкин бер-ике көнсез булмас әле, дип җавап биргәннәр иде. Әмма асылда алай булып чыкмады.

## 2

Әле яхшылап яктырылып та җитмәгән иде, Карыйның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш ягыннан чакрым ярым киңлегендәге фронтны иңләп, дошман һөҗүмгә күтәрелде. Ә Миңнулла отрядында нибары егерме өч кеше булып, аларның дүртесе авылның икенче башындагы юлны саклап торырга җибәрелгән иде. Мондый хәлдә меңләгән аклар гаскәренә каршы торып азаплanудан мәгънә булмас иде. Шуңа Миңнулла болай да бик санаулы гына булган патроннарны аттырып тормады:

— По ко-оням! — дип команда бирде дә теге дүрт иптәшне дә алып китү нияте белән, отрядны ияртеп, авылның икенче башына ыргылды. Ләкин авылның ул очыннан дошман сугышчылары инде бәреп үк кергән һәм урра кычкырып, күпергә якынлашып киләләр иде. Ә безнең сакчыларның берсе дә күренми. Алар ни караган, нигә дошман бәреп кергәнне сизми калганнар — бу хакта Миңнуллага берни дә мәгълүм түгел иде. Хыянәт иткәннәр дияргә дә нигез юк. Чөнки шул дүрт кешенең берсе Миңнулланың бертуган абыйсы — Зәйнулла иде ләбаса! (Ул аягы яраланып, әле атна-ун көн элек кенә фронттан кайткан һәм,ярам артык зыянлы түгел, атка атланып йөрергә була, тик ятканчы, ичмаса, аз булса да файдам тияр, дип, волком отрядына язылган иде.) Бүтәннәре хыянәт итсә дә, ул үз энесенә хыянәт итмәс бит инде. Йомшаграк холыклы булса да, беркайчан да иманын сата торган кеше түгел иде ул. Аннары фронттан шактый үзгәреп, сәяси яктан активланып, тереләнеп кайткан иде...

Ләкин ни булса да булган, сакчыларның берсе дә күренми иде. Ә аклар өч яклап һаман якынлаша, һаман боҗраны кысып киләләр.

Зәйнәп тә Миңнулла белән китәргә тели һәм Миңнулла аны алып китәргә вәгъдә дә биреп куйган иде бит әле. Ләкин хәзер, эшләр менә шушылай көтелмәгәнчә килеп чыккач, аның өйләренә кайтып ат җигеп (авыру Зәйнәпне бары шулай гына алып китеп була!) торыр арасы калмагач, аклар кулына эләкмәс өчен, ул, секунд та тормыйча, авылдан чыгып китәргә мәҗбүр иде. Ул:

— Отряд, минем арттан! — дип боерды да, атын читән аша сикертеп, кыр өсләтеп кенә авылдан чакрым ярым чамасындагы урманга таба элдертте.

Үз сугышчылары дип уйладылар булса кирәк, башта аклар аларга атмады. Тик отряд инде урман буена барып җиткәч кенә ут ачтылар. Шулай да отрядның ике атын, бер кешесен яралап өлгерде кабахәтләр! Яралы атларны калдырып китәргә туры килде, ә яралы агайны, ияргә салып, үзләре белән алдылар.

Туып-үскән җирләре булганлыктан, Миңнуллага бу урманның һәр сукмагы таныш иде. Әнә шул үзе генә белгән сукмаклар буйлап, бик зур саклык белән Миңнулла отрядын Карыйдан сигез чакрымдагы Бажук авылына алып барды. Бажук урамнары гаскәриләр белән дыңгычлап тутырылган иде: безнең гаскәрләр, чигенеп баручы гаскәрләр. Миңнулла алар янында тоткарланып торырга теләмәде. Отряд Бажукны ындыр артлатып үтте дә, тагын урман сукмаклары буйлап, арыга — Шишмәрә авылына таба китте. Шулай итеп, Зәйнәп-сылу аклар басып кергән Карыйда калды. Зәйнулла абыйсы белән теге өч кызылгвардиячечең язмышлары Миңнуллага шулай ук билгесез иде.

3

Миңнулла отряды Шишмәрәгә килеп җиткәндә кышкы ялкау кояш инде батып та бара иде. Олы юл белән килгәндә Шишмәрә Карыйга әллә ни ерак түгел, нибары утыз биш-кырык чакрым гына. Ә менә бүген кача-поса урман сукмаклары аша килеп җиткәнче көн үтеп китте. Инде кар шактый калын иде, шуңа атларны артык куып булмады. Болай да салкын көн кичке якта тагын да ныграк суытып җибәрде. Аннары атларны да ял иттерергә кирәк иде. Шуңа Миңнулла бүген Шишмәрәдә кунарга ниятләп, авыл советын сораштыра башлаган иде, Карый волкомының обозы да шушы авылда туктаган икәнлеге мәгълүм булды. Фәйзулла белән аның этисе Сәгыйдулла агай җитәкчелегендәге ул обоз Шишмәрәгә өченче көн үк килеп җиткән. Ләкин дошманга юлыгудан шикләнеп, Сәгыйдулла агай шунда туктап торуны кирәк тапкан. Шикләнергә нигезләре дә булган шул: Шишмәрәгә килеп җитәр алдыннан аларга ниндидер кораллы бандалар һөҗүм иткән һәм арттагы ике олауны кулларына төшергәннәр икән. Ул олауларда килүче биш кеше (икесе ир-ат, бүтәннәре хатын-кызлар) дә шунда тегеләр кулына эләккән.

— Ярый әле, Шишмәрә якын булды, — диде Фәйзулла Миңнуллага.— Ераграк чакта һөҗүм иткән булсалар — харап иде безнең хәлләр!

— Син үлемнән шулай нык куркасыңмыни, Фәйзулла?

— Үзем өчен курыкмыйм ла! Үлдең — беттең. Нәрсәсе бар аның ул хәтле. Хатын-кызлар, бала-чагалар бар бит безнең белән. Шуларны кызгандым.

Вакытның һәр минуты алтынга тиң: Шишмәрәгә төнлә аклар килеп җитүе мөмкин — олауларны монда калдырырга ярамый иде. Отряд кешеләре һәм атлары инде нык кына йончылган булса да, Миңнулла Шишмәрәдә ялга тукталып тормаска, олауларны Харис авылына — тынычрак урынга алып китәргә карар кылды.

Аларны юлга әзерләгән арада аяк өсте генә диярлек тамак ялгап һәм атларын ашатып-эчертеп алдылар да тагын кузгалдылар. Отрядының яртысы белән Миңнулла үзе алдан китте, яртысын обозларны арттан саклап барырга калдырды.

Юлда аклар белән дүрт тапкыр чәкәшеп алырга туры килде. Дөрес, алар унар-унбишәр кешеле аерым группалар гына иде. Әмма барыбер шактый зыяннары тиде: отрядның өч кызылгвардиячесен үтерделәр, олауда бара торган ике кешене яраладылар, атларга дигән фураж төялгән өч олауны кисеп алып калдылар, бер атны яраладылар. Акларның үзләренә дә ару гына эләкте: җиде атлары, биш-алты кешеләре сафтан чыгарылды.

Ләкин болар гына отрядның югалтуын барыбер җиңеләйтә алмый иде. Миңнулланың тик бер генә юанычы бар: «Ярый әле, башлары житеп, Фәйзулла белән Сәгыйдулла агай Шишмәрәдә отрядны көтеп тор-

ган. Үзләре генә юлларын дәвам иткән булсалар, бандитлар берсен дә калдырмыйча кырып бетерәсе икән. Ярый әле, сабыр иткәннәр»,— дип кенә азрак тынычландырды ул үзен.

4

Отряд Харис авылына килеп кергәндә сәгать иртәнге тугыз тулып унынчы киткән иде. Кешеләр дә, атлар да арыган, ачыккан. Аларны фатирларга урнаштырырга, ял иттереп, кунып китәргә кирәк, шунсыз юлны дәвам итү мөмкин булмаячак. Авыл халкының әйтүенә караганда, бу тирәләр әлегә шактый тыныч, акларның күпләп күренгәне юк. Аннары авылның, биш-алты гына кешедән гыйбарәт булса да, үзенең дә кызылгвардиячеләр отряды бар һәм ул отряд членнары, чиратлашып, Харисның ике башында, олы юл өстендә дежур торалар иде. Шуның өстенә тагын ул отрядның командиры да Миңнуллага таныш кеше — аклар кулында тоткында чагында Богородскидан Алмазга тикле этапта Миңнулла белән бер бәйдә барган, бергә качарга җыенган Сәмигулла агай булып чыкты.

Сәмигулла агай барыбер үз дигәнен иткән: аклар аны теге чакта Алмазга алып барып япканның өченче көнендә үк качып китеп, туптуры шушы үзләренең Харис авылына кайткан. Июль аенда контрлар оештырган бунт вакытында бу авылның ярлылар комитеты да таркатылган һәм Сәмигулла агай кайтып төшкәндә дә башлыксыз торган булган. Шуннан Сәмигулла агай тәвәккәлләп комбед председателе вазифасын үтәүне үз өстенә алган һәм ару гына эшләп килә икән.

Миңнулланы танып алгач, ул бот чабып, исе китеп торды. Аннары:

— Әйткәнием бит мин сиңа исәнлектә очрашырга язсын дип! Менә тагын очраштык бит, энекәш! — дип, аркасыннан кагып куйды.

Сәмигулла агай да ял итеп, кунып китү ниятен хуп күрде һәм олауларны икешәрләп-өчәрләп фатирларга үзе урнаштырып йөрде. Ә Миңнулланы:

— Андый-мондый хәл килеп чыгып, маминт кына күтәрелергә туры килә калса, бер күчтә булуыгыз хәерлерәк булыр, — дип, отряды белән бергә ике катлы бер зур йортка урнаштырды.

Узган көн ак бандалар белән чәкәләшкән чакта яраланган атны суеп, итен үзләре белән алып килгәннәр иде. Итле аш пешереп, табынга утыргач, өй турына унлап җайдак гаскәриләр килеп туктады. Барысының да аркаларында сугыш мылтыгы, бил каешларында — кылыч. Тик берсенең генә мылтыгы юк. Анысы бил каешына агач кобуралы маузер таккан, иңенә кыр сумкасы, күкрәгенә бинокль аскан иде. Озынчарак каратут йөзле, кыска кара сакаллы, үткен каршлы, урта буйлы, өстенә нык кына кыршылган күн тужурка, башына кызыл тасмалы папаха кигән ул кеше иң беренче булып өйгә килеп керде дә:

— Исәнмесез, иптәшләр? Сез кемнәр буласыз? Командирыгыз кем? — диде.

— Исәнмесез? Мин — командир, — диде Миңнулла. Әмма нишләп йөрүләрен әйтергә ашыкмады. Сораучының кем икәнлеген ачыкламыйча торып, капчыкны чишеп ташларга ярамый иде.— Фамилиям — Гайсин. Исемем — Миңнулла. Ә сез үзегез кем буласыз?

— Кара син аны нинди кыю сөйләшә! — диде маузерлы кеше. — Сиңа ничә яшь, иптәш Гайсин?

«Иптәш» сүзен юри басым ясап әйтте.

Миңнуллага әле өченче көн генә унсигез тулган иде.

Дөресен әйтсәм, маузерлы тагын, нигә бик яшь, фәлән дә фәсмәтән дип төпченә башлар, дип уйлады ул. Шуңа:

— Егерме өчтә! — дип җавап бирде.

— Оһо! — диде маузерлы.— Ә мин сиңа унҗиде-унсигездән ары юктыр дип уйлаган идем.

— Сез минем сорауга җавап бирмәдегез бит әле? — диде Миңнулла. Бу хәрбинең сүзне гел шаяру ягына борырга теләвенә эче поша башлаган иде аның.

— Ах, да, кичер, иптәш Гайсин,— диде маузерлы, дустанә елмаеп. — Кичер, зинһар, онытып торам икән. Блюхер мин.

Миңнулланың чәчләре үрә торды.

— Урал партизаннары отряды командирымы? — диде ул, тегенең сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

Блюхер турында ул инде шактый күп ишеткән, газеталардан да укыганы бар иде. Һәм әнә шул ишеткәннәре, укыганнары нигезендә Миңнулла аны инде яратып та өлгергән иде. Ләкин ул аны ничектер гайре табигый итеп, Алып батыр сыман таза, дәү кеше итеп күз алдына китерә иде. Ә бу... Шул күкрәгенә аскан бинокле белән бил каешына аскан маузеры булмаса, үзе белән килеп кергән кызылармеецлардан һич тә аерылып тормас иде.

— Оһо! — диде Блюхер.— Болай булгач, миңа үзем турында сөйләп тә торасы юк икән! Әйе, нәкъ шул кеше мин. Бәлки хәзер сез дә үзегез белән яхшылабрак таныштырырсыз, иптәш Гайсин?

Миңнулла аңа барысын да аңлатып бирде дә:

— Табын әзерләгәндә килеп кергән кешегә безнең халыкта мактап йөрисең дип әйтәләр. Сез дә менә мактап йөрисез икән әле. Әйдәгез, табынга рәхим итегез, — диде.

— Без монда нәкъ менә шул тамак ялгап алу нияте белән тукталган идек тә! — диде Василий Константинович. — Ләкин без күбәү — унбер кеше. Сез ашыгызны безгә исәп тотып пешермәгәнсез бит.

— Зыян юк, Василий Константинович. Бары — бергә, югы — уртак, диләр безнең халыкта. Ашы җитәр, анысын мул итеп әзерләргә кушылган иде. Тик менә...— Миңнулла әйтергәме-юкмы дип икеләнеп калды.

— Нәрсә «тик менә?»

— Ат ите пешергән идек без, Василий Константинович.

— Ах, әнә нәрсә! Сез руслар ат итен ашар микән дип әйтмәкче буласыз инде, әйеме? Бер дә борчылмагыз, иптәш Гайсин. Талымлап тора торган заман түгел хәзер! — Ул үзе белән кергән кызылармеецларга карады: — Шулай бит, егетләр?

Аңа бертавыштан:

— Так точно, иптәш командир! — дип җавап бирделәр.

Ашын да, итен дә кунаклар бик яратып ашады. Василий Константинович карап торырга шактый кырыс, күңелсез адәм булып күренсә дә, асылда йомшак күңелле, җор сүзле кеше икән. Отряды белән дошманга каршы көрәшә-көрәшә, Урал тауларын үтеп безнең якка чыккан чагында үзенең партизаннарына коралны да, кием-салымны да, азык-төлекне дә дошманның үз кулыннан тартып алырга туры килгәнлеген мәзәк итеп сөйләп алды да:

— Хәзер дә эшләр җиңел түгел. Колчакның көче күп, аңа бөтен дөнья капиталистлары ярдәм итә,— диде.— Ләкин җиңү барыбер безнең якта булачак! Чөнки хаклык безнең якта. Эшче халык безнең якта! Ә Халык белән Хаклык икесе бергә булганда — аларны бернинди корал белән дә җиңеп булмый!

Хуҗаларына рәхмәт әйтеп, табын яныннан купкач, Василий Константинович Миңнулланың үзен генә дәшеп алды да:

— Так,— диде.— Инде ни эшләргә, кая юл тотарга уйлыйсыз?

— Мин үзем Сарашка бару мәслихәтрәк булмасмы дип тора идем?

— Нинди максат белән?

— Бездәге мәгълүматларга караганда, Сараштa хәзергә тынычрак икән. Шуның өстенә анда Кызыл Армия частьлары да байтак, аларга Сарашны ничек итеп булса да саклап калырга боерык бирелгән, ди. Аннары, минем белүемчә, анда телефон да бар. Пенза бригадасы командиры иптәш Дедкин карамагында безнең бу отряд. Ул үзе белән бәйләнеш тотарга боерган иде. Бәлки мин ялгыша торганмындыр. Бәлки сез яхшырак киңәш бирерсез, Василий Константинович?

— Юк, шуннан да яхшырак киңәш бирә алмыйм, иптәш Гайсин, — диде Блюхер. — Без монда Сараш аша үтеп килдек. Әйе, хәзергә анда тыныч. Аклар тиз генә үтеп керә алмас Сарашка. Киресенчә, андагы безнең гаскәрләр үзләре һөҗүмгә әзерләнәләр. Шунда юл тотудан да хәерлесе булмас сезгә. Тик олы юлдан бармагыз. Аклар засадасына эләгүегез мөмкин. — Ул сумкасыннан карта алды да, шул картадан күрсәтеп, аңлатырга тотынды. — Менә моннан, урман эчләтеп, бәләкәй юллардан, Искилде, Танып авыллары аша барыгыз, ярыймы! — Аннары ул үз отряды кешеләренә мөрәҗәгать итте: — Я, бөркетләр, җылындыгыз, тамакларыгызны туйдырдыгыз. Ә хәзер иптәшләргә барысы өчен дә бик күп рәхмәт әйтик тә по ко-о-оням!

— Сер булмаса, әйтегез әле, Василий Константинович, сез кая барасыз? — диде Миңнулла, озатырга чыккач.

— Республика реввоенсоветына чакырганнар, шунда барам, — диде Блюхер. Аннары: — Ярый, иптәш Гайсин, сау булыгыз! Уңыш телим сезгә! — диде дә, адъютанты инде әзерләп тотып торган атына җиңел генә менеп атланып, юырттырып китеп барды.

### 5

Отряд та, олаулар да Сарашка хәвеф-хәтәрсез барып җиттеләр: бәхетләренә каршы, юлда ак бандалар очрамады.

Василий Константинович белеп әйткән: Сараштa безнең гаскәрләр, чыннан да, бик күп иде. Шунлыктан үз җаваплылыгындагы алтмышлап кешегә ничек фатир табарга инде дип борчылган иде Миңнулла. Ләкин бу мәсьәлә дә чагыштырмача ансат хәл ителде.

Сараштa волком телефоныннан тыш, фронт телефон станциясе дә урнашкан иде. Шул станция аша Миңнулла, Бирск бригадасы командиры Василий Иванович белән бәйләнешкә кереп, үзләренең хәлен аңлатты.

— Молодец, — диде аңа комбриг, — Сарашка килеп бик яхшы иткәнсез, иптәш Гайсин! Хәзер отрядың да, олауларың да шунда торып торсын. Якын көннәрдә безнең бригада Карый һәм Ашап волостьларын дошманнан азат итәргә тиеш. Шуннан соң олауларыгызны кире алып кайтырсыз. Ә хәзергә отрядың белән Сарашка якын-тирәдәге авыллардагы кулак амбарларын тикшереп, яшереп яткан икмәкләрен җыйный тор! Бригаданың иң кыен мәсьәләсе — азык-төлеккә бәйле мәсьәлә.

— Тырышырбыз, Василий Иванович. Сез үзегез кайда соң хәзер?

— Мин хәзер Усыда, өяз башкарма комитеты бинасында!

— Ничек инде ул Усыда? — диде Миңнулла, исе китеп.— Усыны аклар басып алды дип үзегез әйткән идегез бит!

— Әйе, алганнар иде. Ләкин без аларны аннан бәреп чыгардык инде! Ярый, боерыкны үтә, иптәш Гайсин. Эшнең барышы турында миңа көн саен телефон аша хәбәр итеп тор!

Икмәк мәсьәләсендә эшләр менә болайрак тора иде. Күрше авыллардагы байларның амбарлары барысыныкы да шып-шыр. Булган икмәкләрен башта аклар, алардан калганын безнекеләр алып бетергән. Яшергән икмәкләре барын-югын бирәү дә әйтә алмый. Булса да кар асты-

нан эзләп табу мөмкин түгел иде. Шулай да байларда икмәк бар, тик ул сугылмаган, эскертләргә өеп куелган килеш тора.

Ә сугу машиналарын я ватканнар, я яшергәннәр. Ләкин Миңнулла барыбер җаен тапты. Чәпләр ясатып, үзләре белән килгән коммунист семьяларындагы эшкә яраклы кешеләрдән һәм отрядындагы кызыл гвардиячеләрдән теге игеннәрне суктыра башлады. Шулай итеп, ике йөз җитмеш потлап арыш һәм бодай суктырган иде инде ул.

Ә бүген эшләре тагын да әйбәт бара: бер байның сугу машинасын яшергән җиреннән табып алып, шуның белән фуражга солы суктыра башлаганнар иде.

Көндезге сәгать уннарда Миңнулланы телефонга чакырдылар. Василий Иванович шалтыраткан икән.

— Нигә минем боерыкны үтәүнең ничек барышы турында хәбәр итмисең? Мин сиңа көн саен хәбәрләшеп торырга кушкан идем бит. Ә синең инде өченче көн бер тапкыр да шалтыратканың юк! — диде ул Миңнуллага, шактый нык ачуланып.

Миңнулла аңа әллә ничә тапкыр шалтыратып караган иде. Әмма ул сөйләшергә теләгәндә Василий Ивановичны таба алмыйлар, ә Василий Иванович үзе шалтыратканда Миңнулла каядыр киткән чак туры килә иде булса кирәк.

— Ну, ничек соң анда синең эшләр? — диде Василий Иванович, Миңнулла шул хакта аңлатып биргәч, йомшара төшеп.— Икмәк әзерли аласыңмы азрак?

— Көн-төн шуның артыннан йөрим инде, Василий Иванович.

— Йөрүен аны ахмак та йөри ала. Нәтиҗәсе бармы соң ул йөрүнең? Күпме ашлык әзерләдең?

— Ике йөз җитмеш потлап арыш белән бодай суктырып куйдык инде. Бүген атларга фуражга солы сугабыз. Машина ватылмаса, кичкә утыз-кырык потлап солы булырга тиеш.

— Неужели! — диде Василий Иванович куанып.— Синнән бернинди дә хәбәр булмагач, рәт чыкмады бугай моннан дип, бик каты ачуланып йөри идем үзеңә. Болай булгач, рәхмәттән башка сүз юк инде. Карале, энекәш, анда сезнең тегермән яклары ничегрәк тора. Берочтан тарттырып та алып булмас микән ул ашлыкны?

«Бәлки сиңа ипи итеп пешереп тә бирергә кирәктер», дип уйлап алды Миңнулла. Ләкин Василий Ивановичның үзенә алай дип әйтергә батырчылык итмәде. Күңеленнән дошман кулына эләкми калган тегермәнле авылларны барлап чыкты. Андый авыл икәү иде. Тегермәннәре эшлиме аларның, юкмы — анысын Миңнулла белми иде. «Икесенең берсендә ничек тә эшли торгандыр әле», дип уйлап алды да:

— Тырышып карарбыз, иптәш бригада командиры, — дип җавап бирде.

— Тырыш әле, улкаем, яме! Югыйсә, эшләр кыен безнең монда...

Шул сәгатендә үк Миңнулла һәр ике авылга да тегермәннәрнең хәлен белешеп кайтырга кешеләр җибәрде.

Кичкә мәсьәлә ачыкланды. Тегермәннәрнең тик берсе генә төзек һәм аның да ташы бик акрын әйләнә булып чыкты. Берни эшләр хәл юк. Шулай булса да, Миңнулла икенче көнне иртүк шул тегермәнгә ике олау бодай җибәрде.

Ташы акрын әйләнсә дә, тегермән һаман тарта торды һәм әзер онны бригадага алып китә бардылар. Шулай да тартасы ашлык байтак, тагын өч-дүрт көнгә җитәрлек иде әле.

Ләкин аны тартып бетерә алмадылар. Бер көнне кичкә кырын Василий Иванович үзе Сарашка, Миңнулла янына килде:

— Давай, хәзер үк үзегезнең олауларыгызны юлга әзерли башла! Кире Карыйга кайтасыз. Ашапны аклардан чистарттык, хәзер Карый

өчен сугышабыз. Сезнең олаулар кайтып җиткәндә, Карый да безнең кулда булачак! — диде ул.

Туган авылларына кайтырга чыккач, кешеләр генә түгел, хәтта атлар да аеруча бер дәрт белән ашкынып атлаганнар иде. Тик аларга Карыйга кайтып җитү насыйп булмаган икән. Василий Иванович дөрес әйткән. Ашап, чыннан да, Бирск бригадасы кулында, хәтта бригаданың штабы да шунда күчеп өлгергән. Ә Карый һаман дошман кулында иде әле. Аклар аны калдырып китәргә һич тә җыенмыйлар иде.

Хәлнең менә шушылай четерекле икәнен күреп, Миңнулла олауларны яңадан Сарашка илтеп торырга да ниятләгән иде. Әмма Василий Иванович бик ышандырырлык итеп әйтте:

— Алай мәшәкатьләнеп йөрүнең кирәге юк, Гайсин. Бүген без, һичшиксез, Карыйны алачакбыз! — диде.

## 6

«Бүген» дә үтте, аннан соң да ике көн узып китте, әмма Карый һаман дошман кулында кала бирде.

Канкойгыч авыр сугыш көн-төн дәвам итә. Бригада солдатлары утыз биш градуслы суыкта тәүлекләр буена җылы өй күрмичә, япан кырда кар өстендә ятып, әледән-әле атакага күтәрелеп, дошманга каршы батырларча сугыш алып бара. Соңгы көннәрдә коралга да кытлык әллә ни зур түгел: теләгәнчә атарлык ук булмаса да, патроннары, снарядлары һәм гранаталары да бар. Ләкин дошман көчле. Аның чигенергә нияте юк кына түгел, киресенчә, үзе һөҗүмгә күтәрелергә план корып ята. Сугыш барышында әсир ителеп, безнең кулга эләккән солдатлары да шул турыда әйтә, дошман ягыннан өзлексез явып торган пуля һәм снарядларның көннән-көн арта баруы да шуны күрсәтеп тора иде.

Миңнулла бик үтенеп сораса да, Василий Иванович аның отрядын сугышка кертмәде.

— Синең хәрби хезмәткә өйрәтелмәгән һәм гомумән сугышка яраклы булмаган ул кешеләрең белән генә әллә ни зур эш майтарып булмас, Гайсин. Бригаданың үз сугышчылары да аз түгел, тик аларны туйганчы ашатырга гына кирәк. Тамаклары тук булса — берсе биш кешегә торырлык алар. Син бу як авылларда кайда нәрсә барын, кемнең кем икәнен бик яхшы беләсең. Давай, син бригаданы азык-төлек белән тәэмин итүне кайгырт! — диде.

Сүз дә юк, сугышчыларны икмәк белән тәэмин итү, әлбәттә, бик мөһим. Моны Миңнулла бик яхшы аңлый. Ләкин, шулай булса да, үзенең туган авылы өчен барган сугышта мылтык тотып катнашасы килгән иде аның. Ә авылы — Карый, әнә, орынып кына тора. Иң күп куйганда да алгы сызыктан чакрым, чакрым ярым чамасында гына. Кычкырыбрак сөйләшкән чакларында дошман солдатларының тавышларына кадәр ишетелә. Шул авылда аның әнисе белән әтисе... Шунда аның сөйгән кызы Зәйнәп... Миңнулла алар белән саубуллаша да алмыйча китеп барды бит теге чакта... Алар аны ике күзләрен дүрт итеп көтәләрдер... Улларының икесе дә совет яклы, икесе дә коммунист, икесе дә Кызыл Армиядә икәнен белеп, аклар бик каты җәберләмәсә генә ярый инде үзләрен... Аннары килеп, абыйсы Зәйнулланың да кайда булуы һәм, гомумән, исәнме-түгелме икәнлеге билгеле түгел бит әле Миңнуллага. Ә белергә һич тә җай юк. Карыйга барып килү турында уйларга да ярамый: анда акларның бер полк һәм чехословакларның бер батальон гаскәре тора. Кешене түгел, чыпчыкны да якын җибәрмиләр. Аннары Миңнулланың алайлар итеп, үз кайгысын кайгыртып йөрергә хакы да, вакыты да юк. Чөнки ул — отряд командиры. Аның отрядына сугыш-

чан вадание — бригаданы азык-төлек белән тәэмин итү бурычы йөкләнгән.

Якын-тирәдәге авылларның барысында да диярлек бандитлар булып киткән. Ә алар аягы баскан җирдә юньле нәрсә каламыни? Халыкның чәчүлеккә дип, күз карасыдай итеп, үзләре ач булсалар да, ашамыйча саклап торган икмәкләрен, карап торган бердәнбер атларын, сыерларын гына түгел, хәтта соңгы кәҗәләренә тикле талап алып киткән ул кабахәтләр! Ә ир-атлары безнең Кызыл Армия сафларында булган семьяларның исә, икмәкләрен һәм малларын гына талап калмыйча, үзләрен дә атып, я асып үтереп киткәннәр. Кыскасы, гади халыктан икмәк юнәтүгә исәп тотып булмый, киресенчә, ачтан үлмәсеннәр өчен, аларның үзләренә ярдәм итәргә кирәк иде.

Ә шулай да Миңнулла отряды үзенә йөкләтелгән бурычны үтәп чыкты! Ярлы халыкның соңгы кадак ашлыгын тартып алсалар да, ак бандалар байларга кагылмаган иде. Киресенчә, Василий Иванович бригадасы кысрыклый башлагач, ашыгыч кына чигенергә мәҗбүр булып, үзләре белән алып китәргә өлгермәгән икмәкне әлеге шул байларга калдырып киткән иде алар. Ә байлар халыкның үз икмәген үзенә ун бәясенә сатып, спекуляция белән шөгыльләнеп яталар. Үз икмәкләрен исә инде күздән үк бик нык яшергәннәр: ындыр артларына, бакчаларга күмгәннәр; каралты коймаларын ике катлап, койма араларына тутырганнар; тезмәгә печән араларына тыкканнар; урман куелыкларына базлар казып, шул базларга илтеп күмгәннәр; идән асты базына тагын бер баз казып, шул базларга тутырганнар; изге урын дип тормаганнар, чиркәү һәм мәчет идән асларына яшерүгә кадәр барып җиткәннәр иде.

Барыбер барысын табып алып чыктылар. Отряд гвардиячеләре дә бик нык тырышты, әлбәттә. Ләкин, барыннан да бигрәк, бу эштә авыл халкының ярдәме зур булды. Байлардан табылган ике пот икмәкнең бер поты авыл ярлыларына бүлеп биреләчәк, дип игълан иткәч, әш аеруча җанланып китте, биш көн эчендә бригада сугышчыларын өч атна туйдырып торырга җитәрлек икмәк җыйналды. Шул ук вакытта ачлыктан инде шешенә башлаган авыл ярлыларына да шактый зур ярдәм булды. Отряд эшен бетереп киткән чакларда ул бичаралар елыйелый рәхмәт укып калдылар.

Әмма барыннан да мөһимрәге шул: әлеге икмәк әзерләү барышында һәр авылның 95 процентын тәшкил иткән ярлы халыкта Кызыл Армиягә һәм совет властена карата ышаныч туды. Колчакның солдатлары гына түгел, Колчак үзе килеп үгетли башласа да, совет властена булган иманы какшамаячак инде ул халыкның...

Анысы шулай. Ләкин Карыйдагы дошманның кораллы да, сугышчылары да Бирск бригадасыныкыннан ике-өч мәртәбә артык һәм аны чигенергә мәҗбүр итү мөмкин түгеллеге көн кебек ачык иде. Башта бик оптимист булып йөрсә дә, соңыннан Василий Иванович та моның шулай икәнлегенә, ниһаять, ышанды булса кирәк. Егерме икенче февраль көнне Миңнулланы штабка чакыртып китерде дә:

— Мылтык тотып сугыша алырдай гвардиячеләреңне генә үзең белән калдыр да бүтән барлык кешеләреңне һәм обозыңны тылга озату чарасына кереш! — диде. — Бригаданың фланглары ышанычлы түгел. Ә күршеләребезнең хәле безнекеннән дә начаррак. Усыны тагын дошман басып алды. Өяз башкарма комитеты таратылган, аның урынына Икенче армиянең политбүлеге каршында өяз революция комитеты оештырылган. Бер бездә генә түгел, бөтен Көнчыгыш фронтта хәлләр кыенлашып бара. Өченче армиядә дә югалтулар бик күп. Монда, Көнгер һәм Пермь юнәлешендә, Англия, Япония, Америка капиталистлары тарафыннан һәрьяклап бик яхшы тәэмин ителгән Колчак армиясенең яңа көчләре, чехословак гаскәрләре сугышка керде. Тиздән безгә чиге-

нергә туры киләчәк. Шуңа күрә обозыңны һәм кешеләреңне тизрәк озатып калырга кирәк.

— Кая озатырга икән соң аларны, Василий Иванович?

— Кая озатыргамы? Тукта, карап карыйк әле... — Ул, иңенә аскан кыр сумкасыннан алып, картасына текәлде. Көньяк, көнбатыш һәм көнчыгыш яклар тоташы белән дошман кулында. Тик төньякка таба гына чигенергә мөмкин иде.

— Югары Сипкә озатырга кирәк булыр. Хәзерге шуннан да ышанычлырак урын юк! — диде Василий Иванович.

## 7

Миңнулла отряды волком олауларын Югары Сипкә илтеп, тәүлек ярым вакыт үткәреп кайтканда, Бирск бригадасы Ашапны калдырып, Чиркандыга чигенергә мәҗбүр булган һәм анда да көч-хәл белән генә тотынып тора иде. Василий Иванович Миңнулланы күрүгә, ни хәл барып кайттыгыз, дип сорашып та тормастан:

— Молодец, Гайсин, бик вакытлы кайтып җиттең! Гвардиячеләрең минем карамакка кала. Ә үзең хәзер үк артиллерия батареясына барып кайт әле. Ул батареяга Овчинники — Турай һәм Овчинники — Воронино юлы буйлап бәреп керергә омтылган дошман гаскәрләрен тоткарларга боерык бирелгән иде. Ләкин нигәдер юньләп атканнары ишетелми,— диде.

Миңнулла барганда, батарея командиры лаякыл исерек һәм авыл башындагы бер йортта ниндидер ике хатын-кыз белән рәхәтләнеп эчеп, күңел ачып утыра иде. Аның белән сөйләшүдән мәгънә чыкмаслыгын белеп, Миңнулла батарея тупчылары янына барды.

— Нигә дошманга атмыйсыз? — диде Миңнулла, ачуланып.

— Бушка атудан ни файда? — диде берсе. — Координацияләүче юк. Шуңа дошман якынлашкач туры наводка белән генә атарга мәҗбүрбез.

Миңнулла ни эшләргә дә белмичә аптырап торган арада, атын кушаяклатып чаптырып, Василий Иванович үзе килеп җитте.

— Ни булды? Нигә атмыйсыз? — диде ул, нигәдер тупчыга түгел, Миңнуллага мөрәҗәгать итеп.

Миңнулла хәлне аңлатып бирде.

— Ах, сволочь Егоров! — диде Дедкин. — Менә эш нәрсәдә икән! — Аннары адъютанты белән ярдәмчесенә боерды: — Барыгыз шул хәерсезнең коралын алып, үзен дә, кәнизәкләрен дә бәйләп, штабка илтегез! — Тегеләр киткәч, Миңнуллага борылды: — Я, Гайсин, әйтеп кара әле: минем урында син булсаң, менә шушындый хәлдә ни эшләр идең?

— Командирлыктан азат итәр идем.

— Мин дә күптән шулай эшләгән булыр идем дә, ләкин батарея белән командалык итәргә бүтән кешем юк шул минем! Шуңа түзәргә туры килә. Ә ул, адәм актыгы, шуны бик яхшы белә һәм, патша армиясендәге гадәтен куып, вакыт-вакыт менә шушылай чыгырыннан чыгып китә. Эх, нишләргә соң инде, ә? Снаряд булмаса да бер хәл иде. Снарядлар җитәрлек була торып, дошманга ут яудырырга мөмкинлек юк бит!

— Рөхсәт итсәгез, батарея утын үзем координацияләп карар идем, Василий Иванович,— диде Миңнулла.

Коры теләк, яхшы атлы булып күренер өчен генә әйтелгән сүз түгел иде бу. Герман сугышында Гәрәй абзыйның адъютанты булып йөргәндә Миңнулла аннан артиллерия эшенә дә бераз өйрәнеп калган иде. Дөресрәге, син әле яшь, дөнья булгач бәлки кирәге чыгар, дип, Гәрәй абзый аны үзе өйрәткән иде.

— Әгәр шушы батарея белән командалык итә алсаң, ул чакта мин сине...

Василий Иванович сүзен әйтеп бетерергә өлгермичә калды, чөнки аның янына икенче батальон командирының элемтәчесе йөгереп килде дә, еларга җитешеп:

— Иптәш комбриг, аклар алгы сызыкка бөтенләй якынлашты, тиздән урап ала башлаячаклар. Комбат берәр чара күрүегезне үтенде! — диде.

— Хәзер, хәзер, — диде Василий Иванович, сабыр гына итеп. — Хәзер бирербез без аларның кирәкләрен. Бар, улкаем, бар, комбатыңа шулай дип әйт. Бер адым да чикмәскә боерды Дедкин, диген! — Аннары Миңнулланың иңенә кулын куйды: — Я, энекәш, аллага тапшырдык. Бөтен ышаныч синдә. Ничек тә дошманны тоткарларга, ничек тә иртәнгә кадәр генә булса да түзәргә кирәк! Армия командующиеның боерыгы шундый.

Алар, кара болыт шикелле ишелеп, һөҗүм итеп килә. Ә безнең алгы сызыктагы пехотачылар, каушап калып, тәртипсез рәвештә чигенә башлаганнар иде. Тик Миңнулла командасы буенча туплар беренче залпны биргәч һәм Василий Иванович, үзе аларның каршына чыгып:

— Бер адым да чигенмәскә! Минем боерыкны тыңларга! — дип, бик зәһәр итеп кычкыра башлагач кына тукталды алар.

Ә тупчылар тагын рәттән өч залп биреп, снарядлар дошман солдатлары арасына төшеп ярыла башлагач, аклар куркып, тукталып калды. Бу хәлиткеч момент булды. Дошманның каушап калуын күргәч, гайрәтләнеп китеп, безнең пехотачылар да чигенүдән туктап ут ачтылар. Аклар ятарга мәҗбүр булды. Алар да мылтык һәм пулеметлардан бик нык ата башлады. Күрәсең, туплары килеп җитмәгән булгандыр — туптан атмыйлар, шуңа күрә өстенлек әлегә безнең якта иде.

Шулай ике яктан да атышып, ләкин бер як та уңышка ирешә алмыйча, тәмам караңгы төшкәнче тартыштылар. Аннары атуны туктатырга боерык булды. Безнең як туктауга, шуны гына көтеп торган шикелле, аклар да тынып калды.

Сугыш тукталса да, ут позицияләреннән китмәскә дип боерган иде бригада командиры. Көндез дә җилсез һәм куе зәмһәрир суык булган иде. Ләкин сугышчылар туктаусыз хәрәкәтләнеп, нервыланып торганлыктан, ул турыда уйларга вакыт юк, шуңа әллә ни зыянлы тоелмаган иде. Ә менә атышлар тынгач һәм караңгы төшкәч исә, җилекләргә үтеп туңдыра башлады. Миңнулланың үзенә ул хәтле үк куркыныч түгел, аның аягында өйләреннән киеп чыккан, әле олтан да салынмаган яңа киез итек, башында җылы төлке бүрек. Әтисенең бүреге. Улының эвакуациягә китәргә тиешлеген белгәч, әнисе:

— Хәзер картуз киеп йөри торган чак түгел. Кыш уртасына кереп барабыз. Ки әтиеңнең шушы бүреген, кимәсәң, мәңге риза-бәхил түгел! — дип көчләп кидерде.

Рәхмәт аңа! Фуражка кигән булса, менә хәзер нишләр иде? Дөрес, күн курткасының җылысы әллә ни түгел түгелен. Ләкин аягы белән башы җылыда булгач, түзәргә була. Ә менә тупчыларның хәле яман. Күбесенең аякларында чорнау урап кына кигән ботинка. Төкреген җиргә төшеп җитмәс борын ката торган шушы суыкта япан кырда төн кунарга тиеш алар. Инде төнге унберенче, ләкин ашарга китергән кеше юк әле. Җылы аш ашап алганда да азрак хәл булып китәр иде. Авыл да ерак түгел кана. Нибары дүрт-биш йөз метрлар чамасында гына. Ләкин анда барырга ярамый: позициядән бер адым да китәргә рөхсәт юк. Катып үлмәс өчен, солдатлар әүмәкләнешкән, биешкән, йөгерешкән булалар. Ләкин көн буе сугыш мәхшәрендә кайнаган сугышчыларның да түземе төкәнергә мөмкин ич. Әле алда ел озынлыгы төн бар лабаса! Ә Василий Ивановичтан бернинди хәбәр юк иде. «Бу тупчыларны монда тоту акыллы кеше эше түгел. Беренчедән, дошман төнлә һөҗүм итмәс. Чөнки ул узган көн дә көне буе сугышты. Аның солдатлары да тимер тү-

гел, аларга да ял итәргә кирәк. Икенчедән, батареядан алда, ким дигәндә ярты чакрымда, бригаданың пехотачылары тора. Дошман атакага ташлана калса, аны башта шулар тоткарлаячак. Шулай булгач, тупчыларны авылга алып кайтып, җылы өйгә урнаштырудан һәм чиратлап кына булса да йоклатып алудан да хәерлесе булмас. Шушы ук кешеләрнең иртәгә тагын сугышасылары бар бит. Ял итеп алсалар, иртәгә яхшырак сугышачак алар», дигән фикергә килде Миннулла һәм, тәвәккәлләп, тупларны да, тупчыларны да авылга алып кайтты. Аннары шул турыда Василий Ивановичка әйтмәкче булып һәм тупчыларны ашату мәсьәләсен хәл итүне дә күздә тотып, бригада штабына барды. Миннулла рапорт ясаганда, боерык булмыйча торып позициядән киткән өчен комбриг ачуланыр инде дип шикләнебрәк торган иде. Хәвефләнүе бушка гына булды.

— Бик дөрес эшләгәнсең! — диде комбриг куанып.— Батареяны алып кайтып бик яхшы иткәнсең! Разведка мәгълүматларына караганда, безнең каршыдагы дошман гаскәрләренә ярдәмгә тагын акларның Ишим полкы да китерелгән. Ихтимал, алар иртән тагын һөҗүмгә күтәрелер. Ә бездә аларга каршы торырлык көч юк инде. Үткән көндә дә югалтулар бик зур булды. Хәзер барлык частьларга да, дошманга сиздермичә генә позицияләрен калдырып, чигенә башларга боерык бирәм. Шулай кирәк. Бүтәнчә мөмкин түгел. Ә син бар, хәзер үк батареяң белән Фокага таба кузгал!

— Ә Егоров айнымадымыни соң әле?

— Ә ул хәзер мәңге айнымаячак! — диде Василий Иванович, кырт кисеп.— Аттым инде мин аны. Мин аның кыланышларына алыштырырга кеше булмаганга гына түзеп килгән идем.

— Димәк, аның үлеменә мин сәбәпче булган булып чыгам?!

— Нигә син буласың ди!

— Мин аны алыштырмаган булсам, ул бүген дә исән булыр иде бит.

— Юк, исән булмас иде. Тәмам гарык иткән иде инде ул безне. Бар, Гайсин, боерыкны үтә!

— Ә волком олаулары нишләр икән соң, Василий Иванович? Алар да минем җаваплылыкта бит!

— Алар өчен кайгырма! Урынбасарларың бар бит синең анда. Мин аларга обозларыгызны да, кешеләрегезне дә Фокага күчерергә боерык бирдем инде.

## 8

Волком олаулары Фокага барып житә алмаган. Атлары арганлыктан, Фокадан дүрт-биш чакрымдагы бер бәләкәй генә авылда туктап торалар иде.

Батарея сугышчылары һәм атлары ярдәме белән олауларны Фокага илтеп житкергәч, өяз ревкомы да шушы волостька караган Михайловский заводында урнашканлыгы мәгълүм булды.

Фатирларга урнашып, атларын тугарырга да өлгермәделәр — Миннулланы ревкомга чакырттылар. Ревком председателе Олег Николаевич Шапошников дәштергән иде аны. Ул Миннулланың кайдан килүен, ни эшләп йөрүләрен сорашты да, шул сәгатеңдә үк бригада командиры Василий Иванович белән телефоннан сөйләшеп, аны батарея командиры вазифасын үтәүдән азат иттерде. Аннары ревкомның чираттан тыш утырышын үткәреп, шул утырыш карары нигезендә Миннулланы Яңа Уртавыл волостена ревком председателе итеп билгеләделәр. Аның карамагына Кызыл Яр, Елпачиха һәм Сараш волостьларыннан эвакуацияләнгән һәм совет органнарында эшләү буенча аз-маз тәҗрибәләре булган иптәшләрне (алар барысы унбер кеше иде) тапшырдылар да:

— Үзегезне фронтка барабыз дип исәплəгез — Яңа Уртавыл хәзер фронт полосасында! — дип, юлга чыгарып җибәрделәр.

Озатып калганда Шапошников Миңнулланы читкәрәк алып китеп:

— Барып җиткәч, синең карамакка тапшырылган бу иптәшләргә, сәләтләкләренә карап, эшне үзең бүлеп бирерсең, яме! — диде. — Барып урнашу белән иң элек, ревком председателе буларак, 28 нче дивизия командиры Азинның үзен күреп сөйләш һәм алга таба аның күрсәтмәләре буенча эш итәргә кирәк булыр. Ул волостьта моңарчы продналог җыюга бөтенләй игътибар ителмәгән. Төп эшең итеп икмәк хәзерләүне сана! Эшләгән эшләрегез һәм ревкомдагы хәлләр турында язма рәвештә йомышчы аркылы миңа хәбәр итеп тор! Сау бул! Эшеңдә уңыш телим!

Яңа Уртавыл өяздәге иң зур волостьларның берсе булып, буйга кырык, аркавы егерме биш чакрым мәйданны биләп тора иде. Өяздә эшләгән чагында Миңнулланың бу якларда да булгалаганы бар, ә Тирән Күл, Важады һәм Сөзәк Тау авылларын аеруча яхшы белә иде ул. Тирән Күлнең ярлылар комитеты председателе Миңнуллага Яңа Уртавылга капыл гына барып кермәскә, башта отряды белән разведка ясап кайтырга киңәш итте:

— Югыйсә, ул тирәдә хәлләр бик ышанычлы түгел, бәлагә тарыгыз бар, — диде ул.

Шуңа Миңнулла олауларны Тирән Күлдә калдырып, ун кешелек отряд белән Яңа Уртавылга китте. Анда хәлләр Шапошников әйткәнгә караганда да хәтәррәк булып чыкты: волком аппараты үзенең төп эшен — авылларда совет властен ныгыту һәм аңа ярдәм итү, ярлы крестьяннар мәнфәгатен кайгырту турында уйламый гына түгел, киресенчә, корткычлык белән шөгыльләнә: ярлыларны кимсетә, аларга түли алмаслык налоглар сала, ә байларны яклый, аларга һәр җәһәттән ярдәм итеп килә икән. Авылның биш-алты атаклы контры аклар ягында хезмәт итеп йөри, шул ук вакытта семьялары белән дә тыгыз элемтә тоталар, хәтта ун-унбиш көнгә бер өйләренә дә кайтып киткәлиләр икән. Кыскасы, волком составында ышанычлы, Миңнуллага ярдәм итәрдәй юньле кеше дә юк иде.

Менә шул мәсьәләне ачыклагач, ул волком членнарын җыйнады да аларга Усы ревкомының Яңа Уртавыл волкомын тарату турындагы карарын укыды.

— Без ул карарга буйсынмыйбыз! — дип, волком членнарыннан берничә кеше тавыш күтәрә башлаганнар иде дә, Миңнулла бик коры гына итеп:

— Димәк, сез совет властена да буйсынмыйсыз? Ә андый кешеләрне кулга алырга туры киләчәк! — дигәч, авызларын йомып шыпырт кына кайтып киттеләр.

Аннары Миңнулла үзе белән килгән иптәшләрдән ревком төзеде. Ревкомда финанс, хәрби, җир, азык-төлек, тәэминат, идарә бүлекләре оештырылды, аларга бүлек мөдирләре билгеләнде. Ревком председателе булуы өстенә, Миңнулла хәрби һәм идарә бүлекләре белән җитәкчелек итүне дә үз өстенә алды. Харитонов Игнатий укый-яза белүче, заманында диңгезче булып хезмәт иткән, эш рәтен белә торган тәвәккәл һәм акыллы кеше иде. Шуңа аны үзенең урынбасары итеп билгеләде. Ә Хәбибрахманов, киресенчә, йомшак характерлы, армиядә гомумән хезмәт итмәгән, тыныч шартларда гына эшләргә өйрәнгән, ләкин үз эшен һәр вакыт җиренә җиткерә торган иптәш булып чыкты. Аны Миңнулла хуҗалык һәм социаль тәэминат бүлеге мөдире итеп билгеләде.

Юлда килгәндә үк Миңнулла Уртавыл волостена керә торган авылларның ындырларында сугылмаган эскертләргә игътибар иткән иде. Яңа оешкан ревкомның беренче эше итеп ул әнә шул мәсьәләне күтәрде. Волостьның әлегә аклар басып алмаган авылларыннан ярлылар

комитеты председательләрен чакыртып китереп, аларга Кызыл Армия гаскәрләрен азык белән тәэмин итү — бүгенге көннең төп бурычы икәнлеген аңлатты.

— Шушы бурычны үтәмәгән комбед председательләре хәрби приказга буйсынмаган булып саналачаклар һәм, сугыш чоры законнары нигезендә, кискен җавапка тартылачаклар! — диде.

Бу эш тизрәк гамәлгә ашсын өчен, шул ук җыелышта һәр авылга ике җаваплы кешене (берсе ревком вәкиле, берсе комбед председателе) билгеләделәр.

Яңа Уртавыл үзе дә ике мәхәлләле зур авыл. Ныклап торып тотынганда аннан да байтак икмәк җыеп алырга мөмкин икәнлеген әйткәннәр иде инде Миңнуллага. Шул хакта халык белән сөйләшү өчен авылның гомуми җыелышын җыйдыртты. Волость авылларына икмәк әзерләүне оештырырга барырга тиешле ревком членнарын да шул җыелышка чакырды. Докладны үзе ясады. Башта илдәге гомуми хәлләрне, совет дәүләте алдында торган мөһим бурычларны аңлатты. Шуннан губерна, өяз хәлләренә кайтты һәм, ниһаять, үз волостьлары алдында торган конкрет бурычлар турында сөйләде. Докладны, нигездә, игътибар белән тыңладылар. Ләкин ахырдан, фикер алышулар башлангач, өстенә яңа сары кайры тун, пеләш башына кара бәрхет түбәтәй кигән бер агай торып басты да:

— Сайравын матур сайрыйсың син, җегет, — диде. — Ике сүзеңнең берендә сәвит блачы дисең, аны саклап калырга кирәк, аны саклап калыр өчен фрунттагы салдатларга икмәк кирәк, икмәк тапшырыгыз, дип давайлыйсың. Ә менә минем шуны беләсем килә: без сәвит блачына ярдәм итәбез итүен дә, әмма дә ләкин сәвит блачы үзе ник бер дә ярдәм итми икән соң без керәстиянгә? Бүтәне турында әйткән дә җук инде, хәтта чалбар тегеп киярга манфактура да кайтармый башлады бит соңгы вахытларда! Алга таба да болай барса, шыр-ялангачка калдырмас микән безне ул сәвит блачы?

«Каян китереп төрттерергә кирәген белә бу адәм!» — дип уйлап алды Миңнулла, аптырабрак калып. Аннары, шыпырт кына, үзе белән рәттән президиум өстәле янында утырган Уртавыл ярлылар комитеты председателеннән сорады:

— Нindirәк кеше бу? Продналогын түләп бетергәнме?

— Бер кадак икмәк тә биргәне юк! — диде председатель.

Миңнулланың эченә җылы кереп китте һәм ул Пеләшнең үзенә сорау бирде:

— Иң элек син миңа шуны әйт әле, агай: совет властена үзеңнең күпме ярдәм иткәнең бар? Мәсәлән, конкрет алганда, быел дәүләткә күпме икмәк тапшырдың?

— Карак белән дөнья тулган хәзерге заманда тапшырырсың сиңа! Узган атнада унҗиде пот әзерләп куйганыем, иртәгә илтеп бирәсе төнне бөртеген дә калдырмыйча урлап апчыгып киттеләр.

Теге агайның бу җавабына каршы Миңнулла ни дип әйтергә дә белмичә төртелеп торган арада, Уртавылның комбед председателе сикереп торды да:

— Урлатырга теләгән кешенекен шулай урлыйлар инде, Мәҗит абзый! — диде. — Син караклар да фәлән-фәсмәтән дигән булып, авыл халкына яла якма, яме! Ул икмәгеңне кемнәр «урлаганын» бик яхшы беләбез без. Малаең армия хезмәтеннән качып урманда дезертирлыкта йөргәч шулай була инде ул!

— Син аның кайда йөргәнен каян беләсең? Күргәнең булды мәллә? — диде Пеләш, ачуыннан чөгендер шикелле кызарып.

— Күргәнем булды шул! — диде председатель. — Синең икмәгең урланганнан ике көн элек кенә төнлә өегездән чыгып китеп барганда күрдем.

— Күргәч тоталар аны!
— Бик тотасы идем дә эләктерә алмый калдым шул — ул атлы, ә мин җәяү генә идем.
Тик шуннан ары гына Пеләш телен тешләп, тынып калды. Баштарак нык кына шаулаша башлаган бүтәннәр дә койрыкларын кысарга мәҗбүр булдылар.
Җыелыш, продналоглары түләнмәгән кешеләр ике-өч көн эчендә түләп бетерергә тиеш, дигән карар кабул итте. Суктырылмыйча эскертләрдә яткан игеннәрне җыйнаулашып сугып, ашлыгын дәүләткә тапшырырга дип яздылар.
Чиктән тыш ярлы семьяларга һәм сугыш инвалидларына комбедның ярдәм фондын булдыру мәсьәләсен шулай ук карарга кертеп, законлаштырып куйдылар.

## 9

Ә икенче көнне Миңнулла Азин дивизиясе штабына барды. Штаб Казан тимер юлындагы Куяды станциясендә урнашкан иде. Ул килгәндә штаб начальнигы да, дивизия командиры Азин үзе дә урыннарында юк, частьларга киткәннәр иде. Аларны өч сәгатькә якын көтеп торырга туры килде. Командир белән штаб начальнигы икесе бергә кайттылар. Штаб дежуры Миңнулланың командир белән сөйләшергә теләвен әйтеп чыкканнан соң ун минут чамасы үткәч, Азин аны үзе дәшеп кертте.
— Тыңлыйм сезне, ни йомыш? — диде Азин, кырыс кына итеп.
— Мин Яңа Уртавыл ревкомы председателе Гайсин. Усы өяз ревкомы кушуы буенча, сезнең белән элемтә урнаштырырга дип килдем.
Миңнулланың «Гайсин» дигәне аңа «Азин» дигән кебегрәк ишетелде булса кирәк. Владимир Мартынович беркавым Миңнуллага текәлеп карап торды да, тагын да кырысрак итеп:
— Нинди Азин ул тагын? — диде.
— Азин түгел, Гайсин!
Шуннан соң гына Владимир Мартыновичның йөзе яктырып китте:
— Алай булса, икенче эш!
Аннары ул Миңнуллага урын тәкъдим итте. Миңнулла утыргач, аның документларын сорап алды. Аларны җентекләп тикшереп чыкты һәм бу юлы инде шактый ягымлы итеп:
— Яхшы, — диде. — Партия члены сын, иптәш Гайсин?
— Әйе.
— Яхшы. Димәк, синең белән житди сөйләшергә мөмкин булачак.
— Әлбәттә.
Азин Миңнулланың кайда туып үскәнен, кайларда укыганын һәм эшләгәнен, Уртавылга ничек килеп җитүләрен, килгәч ниләр эшләүләрен сораштырды. Аннары:
— Соңгы көннәрдә безнең фронт полосасында Колчак шпионнары күбәеп китте. Сезнең тирәләрдә сизелмиме андыйлар? — диде.
— Өзеп кенә әйтүе читен,— диде Миңнулла.— Бу якка килеп эшли башлавыма нибары өченче генә көн бит әле. Дезертирлыкта йөрүчеләр бар икән. Мөгаен, шуларның кайберләре аклар белән элемтә тота торгандыр.
— Обязательно ул дезертирлар кайтып йөри торган йортларны күзәтү астына ал. Кил әле бирерәк! — дип, ул Миңнулланы үз янына чакырып утыртты да Яңа Уртавыл волостеның барлык авыллары да күрсәтелгән картасын алып, аңа конкрет задание бирергә кереште. — Менә, — диде ул, Ушья-Тау авылын күрсәтеп, — сез шушы авылдан алып Яңа Уртавылга һәм Яңа Уртавылдан алып Урадыга кадәрге арада ышанычлы сак урнаштырырга тиешсез! — Аннары Азин кулындагы карандашы белән Яңаулга төртте.— Дөрес, бу авыл сезнең волостька

керми. Бирск өязенә карый ул. Һәм үзе волость үзәге булып тора. Ләкин син менә шушы Яңаул станциясендә яшерен пост булдыр. Һәм ул пост белән даими тыгыз элемтә тот. Ә икмәк әзерләргә керешүең бик шәп булган. Хәзер иң кирәкле нәрсә — икмәк! Азык-төлек әзерләүне алга таба да дәвам ит! Бигрәк тә байларның амбарларын кат-кат тикшерегез. Килеп, үзегездәге хәлләр белән мине таныштыруың өчен рәхмәт. Киләчәктә шулай элемтәдә тор. Уңыш телим!

Азин, эшне беткәнгә санап, капыл гына урыныннан купты һәм саубуллашу өчен кулын сузды.

Сузган кулны кире кагып булмый иде, Миңнулла да аңа кул бирде. Ләкин китәргә ашыкмады.

— Менә сез, иптәш дивизия командиры, — диде ул, — безгә Ушья-Таудан алып Урадыга кадәрге арада сак урнаштырырга боерык бирдегез. Минем белүемчә, ул ара ким дигәндә унбиш километр, ә минем отрядта нибары егерме ике генә кеше. Әле кичә генә шуларның бишесен укырга җибәрергә, унысын Кызыл Армия карамагына тапшырырга дип өяздән күрсәтмә килде. Шулай итеп, волком отрядында нибары җиде кеше кала. Алар белән ничек саклармын икән мин ул унбиш-егерме километр араны да ничек Яңаулда яшерен пост урнаштыра алырмын икән? Аннары бит безнең корал ягы да бик сыек, иптәш дивизия командиры.

— Отрядыңны зурайтырга, кимендә илле кешегә җиткерергә кирәк! — диде Азин.— Укырга китәргә тиешлеләрен тотма, җибәр. Ә Кызыл Армиягә хәзергә берсен дә озатмый тор. Мин Усының өяз ревкомы белән бу хакта үзем сөйләшермен, ул яктан тыныч бул. Шулай итеп, унҗиде кешең кала. Тагын утызны волость авылларыннан үзең җыйнарсың. Ә мин сиңа бер генә солдатымны да бирә алмыйм, Гайсин, чөнки һәр кешем санаулы, һәр кешем алтынга тиң хәзерге моментта!

— Кеше белән ярдәм итә алмасагыз, һич югы, бераз корал бирегез инде, иптәш Азин?

— Яз, нәрсәләр кирәк? — диде Азин, син бәйләнчектән барыбер котылып булмас дигәндәй, кырыс итеп.

Миңнулла егерме сугыш мылтыгы, йөз граната, биш ящик мылтык патроны, биш йөз наган патроны сорап гариза язды. Азин аның гаризасын укыды да, син нәрсә, корал заводы бар дип беләсеңме әллә бездә, дигән шикелле итеп, күзен тутырып беркавым карап торды. Ләкин бер сүз дә әйтмәде, Миңнулла гаризасы өстенә кыйгачлап: «Биш рус винтовкасы, ун граната, бер ящик винтовка патроны, 200 наган патроны биреп җибәрергә», дип язды. Аннары Миңнуллага сузды һәм:

— Бар, складтан алырсың. Шушыннан артыгын берничек тә бирә алмыйм. Коралны үзегез табарга тырышыгыз: акгвардиячеләрне һәм шуныңише бүтән контрларны күбрәк кулга төшерегез дә коралларын үзегезгә алыгыз! — дип, ишеккә кадәр килеп, аны озатып калды.

## 10

Февраль аенда фронтта әллә ни зур үзгәрешләр булмады. Күрәсең, көннәр бик салкын торгангадыр, аклар алай зурдан кубып һөҗүм итмәде. Ләкин алар кул кушырып, тик кенә ятмый, бик тырышып сугыш эшенә өйрәнәләр. Тирә-як авыллардагы ярлы халыкның актык сарык һәм сыерларын талап суялар. Соңгы кадак оннарын тартып алып, шул оннан көмешкә куып, типтереп яталар. Шуның өстенә, авыллардагы контр элементлар да ул бандалар белән тыгыз элемтә тота, аларга һәрьяклап ярдәм итеп тора иде.

Шунлыктан бу чорда ревкомның эше җиңеләймәде генә түгел, киресенчә, тагын да арта төште. Яшерен рәвештә безнең якка үтеп кергән

ак бандалар һәм үзләре безнең якта булсалар да, күңелләре белән совет властеның бетүен теләп торган кулаклар тарафыннан эшләнгән корткычлыкларны тикшерү өчен волостьның берәр авылына барып кайтмый калган көне бик сирәк була Миңнулланың.

Менә бүген дә биш кешелек гвардиячеләре белән Кульга авылыннан кайтып килеше. Ярлылар комитеты утырышы барган вакытта тәрәзәдән атып комитет председателен яралаганнар һәм шул ук төнне өен дә яндырганнар иде. Чана җигеп йөрү хәвефле булганлыктан, (контрлар һөҗүм иткәндә качып котылырга алай бик уңайсыз) Миңнулла үзе дә, кызылгвардиячеләре дә җайдак иделәр. Көне алай чамасыз салкын булмаса да, бик җилле. Яхшы ук буранлап та тора. Кар кашларга, керфекләргә сылана. Юл бөтенләй диярлек кар астында калган. Әле ярый, атлар акыллы: үзләре чамалап баралар. Ул бичараларга да кыен: тез тиңентен кар ерып атларга кирәк бит. Җитмәсә, җиле каршы... Атларның да керфекләре ап-ак. Кисәк-кисәк аеруча котырып куйган җил карны бөтереп аларның колак һәм борыннарына да тутырмакчы. Шуңа күрә атлар әледән-әле пошкырып, башларын чайкап барырга мәҗбүр...

Ап-ак кыр уртасына куелган кара стена булып урман күренде. «Шөкер, исән-сау гына монда да килеп җиттек,— дип уйлап алды Миңнулла.— Димәк, кайтасы юлның яртысыннан артыгын узды дигән сүз. Әурманда ул кадәр үк салкын булмас. Юлы да арурак булырга тиеш — өстән әллә ни күп яумый бит. Бәлки урманны, биш-алты чакрым арады, юырттырып кына үтеп булмасмы әле...»

Урманга кереп бераз баргач, гвардиячеләр: «Бик туңдырды, азрак туктап, аякларны җылытып алыйк», — диделәр. Миңнулланың үзенең дә тешләре-тешкә тими башлаган иде, рәхәтләнеп риза булды. Атларыннан төштеләр дә тизрәк җылыныр өчен бияләй атыш уйнарга тотындылар. Шул уен белән мавыгып, алар урман юлыннан, борылыштан мичәп җигелгән бик шәп артлы чанага утырып өч кеше килеп чыкканны абайламыйча калдылар.

Бу очрашу чанадагылар өчен дә көтелгән хәл түгел булса кирәк, алар да бер мәлгә каушап калды. Ләкин алар алданрак исләренә килде: атларын туктатып, берсе пулеметтан, икесе наганнан гвардиячеләргә атарга керештеләр. Миңнулла мәсьәләне аңлап алып:

— Агач артына посыгыз да — сугышка! — дип команда биргән арада ике кызылгвардиячене сафтан чыгарып та өлгерделәр: берсе, башына пуля тиеп, шундук үлде, икенчесенең кулы яраланган иде.

Ә бандитлар, атларын кирегә борып алып, качып китәргә маташалар иде инде.

«Тере килеш ычкындырмаска кирәк!» дигән уй йөгереп үтте Миңнулланың башыннан. Һәм ул үзенең гвардиячеләренә:

— Атларына атыгыз! — дип боерды, үзе дә тегеләрнең бер атына төзәп, рәттән ике пуля җибәрде.

Кем пулясы тигәндер, бандитларның кирегә чаба башлаган атларының берсе башта сөрлегеп китте, аннары кызганыч итеп кешнәп җибәрде дә гөрселдәп егылды. Икенчесе, мичәүдәгесе, постромкаларын өзеп, чабып китте. Чанадагыларның икесе сикереп төшеп урманга кереп качмакчы булган иде. Ләкин гвардиячеләрнең пулясы икесен дә аяктан екты. Ә өченчесе, пулемет калканы артына ышыкланып чанада яткан килеш, һаман атуын дәвам итә иде әле. «Зыян юк,— дип уйлап алды Миңнулла, — атар-атар да патроннары беткәч бер туктар. Күпме генә тыпырчынса да, хәзер барыбер безнең кулдан ычкына алмый инде ул!»

— Атуны туктатырга! — диде Миңнулла үз гвардиячеләренә, чөнки калкан артына яшеренгән кешегә тидерү мөмкинлеге бик шикле иде. Аннары шул чанадагыга кычкырды: — Әй, син дә туктат файдасызга атуыңны да яхшы чакта үзең бирел!

Чанадагы кеше атудан туктады, ләкин бирелергә исәбе юк иде.
— Биш минут вакыт бирәм уйларга! — диде аңа Миңнулла. — Әгәр шуннан соң бирелмәсәң — безгә үпкәләмә!
— Тот менә!.. — дип татарчалатып сүгенеп җавап бирде теге. Аның тавышы бик нык таныш шикелле тоелды. Ләкин кем тавышы — анысын Миңнулла һич тә хәтерли алмады.
Миңнулла биш минут көтте. Шуннан соң гвардиячеләренә урман эчләтеп шуышып барып, теге явызны урап алырга боерык бирде...
Дүрт кешегә берүзе каршы тора алмаслыгын сизенеп, теге адәм эшне зурга җибәрмәс дип уйлаган иде Миңнулла. Ләкин ул көткәнчә булмады. Тере килеш бирелмәде чанадагы. Соңгы чиккә кадәр әле пулеметтан, әле наганнан ата-ата каршылык күрсәтте дә:
— Хыялланма мине тереләй кулыңа төшерергә, кызыл этәч! — дип, соңгы патронын үз маңгаена атты.
Миңнулла ялгышмаган, чанадагы контр, чыннан да, аңа таныш булган икән. Чирканды мулласы малае Хәйретдинов Хәйрулла иде ул.
Хәйрулланың кесәләрен тентегәннәр иде, бер кесәсеннән Колчак армиясе офицеры билеты, икенчесеннән коммунистлар партиясе билеты чыкты. Ә чана башына тыгылган ике капчыкка бик күп кәгазь һәм алтын акчалар тутырылган иде.
Хәйрулланың кая һәм нинди максат белән баруы булгандыр, анысын тәгаенли алмадылар. Кызганычка каршы, аның иптәшләре шулай ук икесе дә җан тәслим кылганнар иде.

## 11

Март башында, төгәлрәк итеп әйткәндә, дүртенче числода, чит ил капиталистлары тарафыннан корал белән дә, кием-салым белән дә тулысынча тәэмин ителгән йөз утыз мең кылыч һәм штыклы Колчак гаскәрләре бөтен Көнчыгыш фронт буйлап һөҗүмгә күчте. Колчакның планы — Уралдан көнбатышка таба барып, Иделгә бәреп чыгу һәм шунда акгвардиячеләрнең һәм интервентларның бүтән группалары белән кушылып, Мәскәүгә юл тоту иде.
Әйтергә кирәк, ул көннәрдә колчакчыларның һөҗүме шактый уңышлы барды. Алар унынчы мартта Бирскины, унөченче мартта Уфаны, унсигезенче мартта Минзәләне һәм Минзәлә өязенә караган Актаныш, Байсар, Пучы авылларын басып алдылар.
Уртавыл волостена аклар әлегә тоташ һөҗүм итеп килеп җитмәсәләр дә, аерым группалары белән халыкны талауларын көннән-көн ешайта баралар иде. Ревком карамагындагы илле-илле биш кешелек, аның да яртысы җәяүлеләрдән торган отряд белән генә егерме чакрым сузылган фронтта ышанычлы сак куеп, дошманга каршы уңышлы көрәш алып бару, әлбәттә, мөмкин түгел иде. Миңнулла өяз ревкомына да, егерме сигезенче дивизия командиры Азин исеменә дә шул хакта рапорт язып, һич югында, тагын бер илле кешелек отряд һәм корал җибәрүне сорап караса да, файдасы булмады. Ревкомнан, мөмкинлегебез юк, дип җавап бирделәр. Ә Азин: «Кешеләр белән дә, корал белән дә ярдәм итә алмыйм, иптәш Гайсин. Монда, фронтның алгы сызыгында, безнең эшләр сезнекеннән дә читенрәк. Отрядыңны җирле кешеләр хисабына тулыландыр. Коралны аклардан яулап алыгыз. Чигенергә аерым приказ булганга кадәр ничек тә түзеп тору кирәк! Әзерләгән икмәкнең һәр потын дивизиянең азык-төлек бүлегенә тапшыра бар!» — дип язып җибәргән иде.
Шулай да егерме сигезенче мартта өяз ревкомы боерыгы буенча волость ревкомы карамагына унике кешелек атлы отряд килеп төште. Һәм бик вакытлы килеп төште. Чөнки егерме тугызынчы мартта акларның бер ротасы Уртавылга һөҗүмгә ташланды. Менә шул чакта әлеге

атлы отряд бик ярап куйды. Теге көнне Хәйрулладан калган пулеметны алып кайтып, аңа шактый гына патроннар да юнәткәннәр иде. Шулай итеп, волком отрядындагы кораллы җитмешләп кеше һәм бер пулемет белән акларның кадровой солдатлардан торган ротасына каршы күтәрелделәр һәм тегеләрне чигенергә мәҗбүр иттеләр.

Ләкин аквардиячеләрнең моның белән генә тукталып калмаячагы, монысы аның капшап, разведка ясап караулары гына икәнлеге ачык иде. Разведка мәгълүматларына караганда, Уртавылга тегеләрнең ике полкы һөҗүмгә әзерләнә һәм ул һөҗүм иртәгә иртән башланырга тиеш иде. Шуңа күрә Миңнулла утызына каршы төндә Карый волкомы һәм Уртавыл ревкомы кешеләрен һәм әйберләрен Уртавылдан утыз чакрымдагы Чыгакул авылына озатты.

Разведка мәгълүматы дөрес булып чыкты: аклар утызы көнне иртүк ике полк белән Уртавылга һөҗүм башлап, аны урап алырга керештеләр. Мондый чакта барлы-юклы корал белән шул тикле зур көчкә каршы торудан мәгънә юк иде. Миңнулла отряды Важадыга чигенергә мәҗбүр булды.

Я Уртавылны сугышсыз-нисез кулга төшерү куанычыннан бәйрәм ясарга булганнардырмы яки авылны талау белән шөгыльләнгәннәрдерме — утыз берендә аклар күренмәде.

Утызында аклар Яңаулны да басып алганнар иде. Ә утыз берендә Миңнулла егерме сигезенче дивизия штабы белән телефон аша бәйләнешкә кереп, Азинның бронепоезд белән Балыкчы станциясеннән Яңаулга, аны аклардан азат итәргә дип киткәнлеген белде. Һәм ул Уртавылны калдырырга туры килгәнлеген әйтеп, алга таба ни эшләргә, кая барырга икәнлеге хакында киңәшеп кайту нияте белән Азинны эзләп үзе Яңаулга китте.

Яңаулны алгач, аклар станциядән бер-ике чакрым җирдә тимер юл рельсләрен һәм шпалларын сүтеп куйганнар икән. Азин бронепоезды шул төшкә җиткәч туктап калырга мәҗбүр булган. Шуны гына көтеп торган аклар, авыр тупларыннан атып, бронепоездны сафтан чыгарганнар. Дөрес, ахыр чиктә азинчылар Яңаулны аклардан кире кайтарган иде кайтаруын. Әмма «каты яраланган» бронепоездны «һушына китерә» алмаганнар иде әле. Миңнулла Азинны әле шул бронепоездны төзәттерергә тырышып йөргән чагында туры китерде.

Азинның бик ашыкканлыгы, кәефе шәптән булмавы кыяфәтенә үк чыккан иде. «Болай да кырыс кеше, мондый чакта хәлне аңлатканны юньләп тыңлап торса ярый инде», дип, Миңнулла аның янына шикләнебрәк кенә барган иде. Ләкин Азин аны куанып каршы алды:

— О-о-о! Иптәш Гайсин! — диде ул, аны шундук танып алып.— Бик шәп булды бит әле синең монда килеп чыгуың! Нихәл соң? — дип кул биреп күреште һәм мәш килеп шул тирәдә кайнашкан тимер юлчылар яныннан читкәрәк алып китте дә: — Ну, давай, сөйлә: сезнең эшләр ничек анда? Уртавылны кулыгызда тотасызмы әле? Икмәк әзерлисезме?— дип сораштырырга тотынды.

Миңнулла Уртавылны калдырып китәргә мәҗбүр булуларын әйткәч, Азин:

— Шәп түгел анысы! Мин килеп җиткәнче ничек тә түзеп торырга иде, — диде.

Миңнулла акларның Уртавылга ике полк белән һөҗүм иткәнлекләрен, шунлыктан аларга каршы торуның барыбер нәтиҗәсе булмаслыгын әйткәч кенә:

— Алайса, чигенеп дөрес иткәнсең! — дип, Миңнулла карары белән килешергә мәҗбүр булды. Аннары күңелсез генә дәвам итте: — Әйе, бу араларда бер сездә генә түгел, дивизиядә дә, бөтен фронтта да хәлләр кыенлашып китте шул. Вакытлыча чигенергә туры килә. Әле менә сиңа да, әгәр үзең килмәгән булсаң, ревкомны һәм большевиклар семьяла-

рын Михайловский заводына эвакуацияләргә кушып хәбәр иттермәкче идем. Бар, хәзер үк кайт та шул боерыкны үтәргә кереш!

— Мин ревком кешеләрен һәм олауларын Чыгакулга озаткан идем инде, иптәш дивизия командиры!

Азин башта ризасызлык белдереп, Миңнуллага күзенең агы белән карап алды. Аннары, «а нука-нука-нука» дип, кыр сумкасыннан картасын алып Чыгакулны эзләп тапты.

Чыгакул фронт сызыгыннан Михайловскийга караганда эчкәрерәк, тынычрак урында иде. Моның шулай икәнлеген Азин да төшенеп алды бугай, бу юлы инде Миңнуллага баягыча өтеп ала торган итеп түгел, җылы итеп карап: — Әйе, обозларыңны Чыгакулга эвакуацияләп, ихтимал, син дөрес иткәнсең, Гайсин! — диде. — Ә отрядың кайда хәзер?

— Ваҗадыда.

— Ул тирәдә хәлләр ничек?

— Анда да озак түзеп булмас, иртәгәләрдән дә соңга калмыйча дошман тагын һөҗүмгә күчәргә тиеш.

— Ә син ни эшләргә, акларны тоткарлау өчен нинди чара күрергә уйлыйсың?

— Менә шул хакта сездән киңәш һәм ярдәм сорарга дип килдем дә инде мин! Үз көчебез белән генә тоткарлый алмаячакбыз ул акларны. Уртавылга ике полк белән һөҗүм итте алар. Разведка мәгълүматларына караганда, аларга өстәмә көчләр килүе һаман дәвам итә. Әгәр аларны Ваҗадыга кертмичә торыйк дип санныйсыз икән, минем отрядка ярдәмгә кимендә бер полк җибәрүегезне үтенәм, иптәш дивизия командиры.

— Менә нәрсә,— диде Азин, гадәтенчә кискен тонга күчеп,— син давай, булмастай нәрсәләрне сорап баш катырма, яме! Сиңа полк түгел, бер солдат та бирә алмыйм. Минем дивизиянең фронты йөзләрчә километрга сузылган хәзер. Ваҗаданы дошман кулына бирмичә тору өчен мөмкин булганның бөтенесен эшлә. Дошманны бер сәгать тоткарлап торуның да әһәмияте зур хәзерге моментта!

Дивизия тикле дивизия командиры, ә үзе берни белән дә ярдәм итә алмый, дип күңеле төшеп, Миңнулла китәргә дип атына атлангач, Азин аның янына килде дә:

— Син миңа үпкәләмә, Гайсин, — диде. — Мөмкинлегем юк бит. Алга таба барлык мәсьәләләр буенча да өяз ревкомы күрсәтмәсе нигезендә эш итәрсең. Әгәр аклар бик нык кысрыклый башлап, чигенергә туры килсә, Михайловский заводына чиген. Сау бул! Колчак бандаларын туздырып ташлагач күрешербез дип уйлыйм.

— Ә сез нигә мине отрядым белән үз дивизиягез составына алмыйсыз соң, иптәш Азин?

— Бик алган булыр идем дә, өяз ревкомы рөхсәт итми шул. Мин хәтта синең үзеңне генә алырга да сорап караган идем, шуңа да риза булмадылар! Ярый, хуш хәзергә! Уңыш телим!

— Сезгә дә шулай ук, Владимир Мартынович!

Беренче апрельдә колчакчылар күп санлы гаскәр белән Ваҗадыга һөҗүм итте. Миңнулла отряды, Азин боерыгын үтәп, аларга каршы батырларча сугышты. Сан ягыннан аз булса да, отрядның позициясе уңайрак (отряд тау өстендә, ә аклар астан, болынлыктан һөҗүм итә) иде. Дошман никадәр генә ярсып килсә дә, аның өч атакасын отряд кире какты. Ләкин колчакчылар дүртенче тапкыр, бу юлы инде тагын да зуррак көч белән ябырылгач һәм отряд гвардиячеләренең патроннары беткәч, Миңнулла Ваҗаданы калдырырга боерык бирергә мәҗбүр булды. Авылның икенче башында инде иярләп куелган атларына атландылар да Чыгакул ягына юл тоттылар. Аннан Михайловский заводына китмәкчеләр иде. Ләкин Чыгакулда тукталып, кунып китәргә туры

килде. Чөнки ревком олауларына Чыгакулга җитәр алдыннан ак бандалар һөҗүм итеп, ике кешене үтергәннәр, өчесен яралаганнар икән. Олаучылар тагын һөҗүм булудан куркып, ары китәргә батырчылык итмичә, Чыгакулда торалар иде. Шуңа күрә Михайловский заводына икенче апрель көнне кич кенә барып керделәр.

Олауларын һәм отрядын фатирларга урнаштыру өчен ярдәм сорарга һәм ары таба ни эшләргә, кая барырга икәнен ачыкларга дип, Миңнулла өяз ревкомына килде.

## 12

Өяз ревкомы председателе урынында Шапошников түгел, бәлки Миңнуллага бөтенләй таныш булмаган бер кеше утыра иде.

— Соколов,— диде ул, Миңнулла кереп исәнләшкәч,— Сергей Владимирович.

Миңнулла үзләренең хәлен сөйли башлаган иде, ләкин Соколов аны тыңлап та бетермичә:

— Нигә, кем рөхсәте белән чигендең? Яңа Уртавылда акларның исе дә юк бит әле! Син — хыянәтче! Мин сине хәрби кыр судына озатам, коралыңны хәзер үк өстәлгә куй!—дип җикеренергә тотынды һәм шундук телефонга ябышып, милиция чакыртты.

Миңнулла бил каешына тагылган наганын алып, тегенең өстәленә куйды. Эчке кесәсендә бер ак офицердан алган браунингы да бар иде. Аны бирмәде. Ә Соколов тентеп тормады. Гомумән, бүтән сөйләшеп торуны кирәк тапмады Соколов. Аның чакыруы буенча кергән милиционерга:

— Мин бу кешене кулга алдым. Алып китегез дә утыртыгыз. Ә иртәгә Сарапулга хәрби кыр судына озату турында приказ бирермен! — генә диде дә шуның белән эшен бетерде.

— Әле мин отряд һәм ревком кешеләрен фатирларга да урнаштырмаган бит. Йөзгә якын кеше урамда көтеп тора мине! Бәлки шуларны урнаштырырга гына рөхсәт бирерсез, Сергей Владимирович?

— Алар өчен кайгыртуны мин үз өстемә алам, — диде теге. — Телеңә салынып торма, бар, атла!

— Нигә болай кулга алды ул сезне, иптәш Гайсин? — диде милиционер, урамга чыккач.

— Ә сез мине каян беләсез?

— Кече Ашаптан мин. Сез укомда эшләгәндә безнең авылга да килгәнегез булды бит.

— Әйе шул. Сезнең исем-фамилиягез ничек, иптәш?

— Иван Тимофеевич Поздяев.

— Бик әйбәт. Мине нигә кулга алдылар дисез инде сез, ә, Иван Тимофеевич. Алла белсен ни өчен икәнен! Ә ул Соколов нинди адәм соң? Кайчан куйдылар аны ревком председателе итеп?

— Бер атна чамасы гына әле безгә килеп эшли башлаганына. Кайдан килгәндер, нинди адәмдер — анысын әйтә алмыйм.

— Минемчә, ышанычлы кеше түгел ул!

— Ышанычлы булмаса, андый җаваплы эшне тапшырмаслар иде, иптәш Гайсин.

— Анысы шулаен шулай. Ләкин нәрсәседер, кай җиредер ошамады аның миңа.

Шул чак Миңнулланың күңеленә: «Әгәр бу милиционердан партиянең өяз комитетына алып кереп чыгуын үтенеп карасам, риза булмас микән?» дигән уй килде һәм ул шул фикерен Поздяевка әйтте.

— Рәхим итегез, — диде Поздяев, берсүзсез риза булып.

Партиянең өяз комитеты председателе Кибардин әле кайтып китмәгән, комитет секретаре Ясыйров белән нәрсә турындадыр сөйләшеп утыра иде. Миңнулла мәсьәләне аңлатып бирде дә:

— Сезнең бу Соколов дигән кешегез фронт хәлләре белән я бөтенләй таныш түгел, яки ул сатлык җан! — диде.— Уртавылда акларның исе дә юк әле, сез аны үзегез алдан ук дошманга ташлап качкансыз, ди. Ә мин аннан отрядны соңгы чиктә, дошманга каршылык күрсәтер чама калмагач кына алып киттем. Мин өченче көн генә егерме сигезенче дивизия командиры Азин белән сөйләшеп, аңа да хәлне аңлаттым. Миңа гына ышанмасагыз, ул тирәләрдәге хәлләрне Азинга шалтыратып белешә аласыз.

Кибардин белән Ясыйров Миңнулланы зур игътибар белән тыңладылар. Ләкин сак астыннан азат итмәделәр.

— Без сиңа ышанабыз. Әмма мәсьәләне ачыклаганга кадәр Соколов боерыгын үтәргә туры килә, — дип, Миңнулланы өяз милициясе бүлегенә җибәрделәр.

Милициядә аны бер буш бүлмәгә яптылар. Бераздан Поздяев аңа ипи белән сөт кертте. Тамак ялгап алгач бераз хәл булып китсә дә, Миңнулланы йокы алмады. Дошман кулына эләккән булса бер хәл: анда инде берни дә эшли алмыйсың, ул кадәр үк ачуың да килмәс иде. Ләкин менә җаның-тәнең белән хаклык өчен, совет властен саклап калу өчен көрәшеп йөргәндә сине хыянәт итүдә, ил сатуда гаепләсеннәр әле. Йокы качу гына түгел, акылдан язарсың бу хурлыкка!

Ә бит Миңнулла ревкомга килгәндә үзен шушылай ябып куярлар дип түгел, рәхмәт ишетермен дип көткән иде. Чыннан да, рәхмәт ишетерлек кенә эш башкармадымы әллә ул Уртавыл ревкомында?.. Михайловскийга килгәндә Миңнулла өяз ревкомыннан сорап, Карый якларына кайтып килергә дә (яшерен генә, авыл крестьянынча киенеп кенә, әлбәттә) ниятләп тора иде. Әти-әнисенең, абыйсының һәм бик авыр хәлдә калган Зәйнәпнең язмышлары һаман билгеле түгел, шуңа бик борчыла иде ул. Менә хәзер ул үзе тотканда, сак астында ятарга мәҗбүр... Ә бит Соколов аны аттырып үтерергә дә мөмкин. Хыянәтче дип, дошман күренмәс борын ук постын ташлап качып киткән, дип язып җибәрсә — хәрби кыр суды өчен шул бик җиткән! Кибардин тикшерербез дип калды калуын да, ләкин Пермьнән яисә армия штабыннан ниндидер бик ашыгыч, бик мөһим күрсәтмә килеп төшеп, Миңнуллаларны онытып җибәрүе дә ихтимал лабаса аның!..

## 13

Ябылуда ятуына тәүлек тулып килгәндә сакчы ишектән башын тыкты да.

— Әйдә, Гайсин, сине Соколов чакыра! — дип, үзе белән ияртеп алып китте.

«Ни эшләтмәк була икән ул мине? — дип уйлады Миңнулла юлда барганда. — Азат итәрме, әллә чыннан да кыр судына озатырга ниятләде микән? Әгәр шулай итәргә маташа башласа, билләһи, кесәмдәге браунинг белән башта аның башына җитәм, аннары үземә атам!..»

Кабинетында Соколов ялгызы гына иде. Йөзе чытык, нидәндер канәгать түгеллеге әллә кайдан сизелеп тора. Ул башта: «Бар, хезмәтеңне дәвам ит!» — дип, сакчыны чыгарып җибәрде. Аннары өстәл тартмасыннан кичә Миңнулладан алып калган наганны алып бирде дә:

— Мин сине кызгандым, иреккә чыгарырга булдым, Гайсин, — диде. Ашыкмыйча гына папирос кабызды, тирән итеп ике-өч тапкыр суырды. — Ләкин син революция алдындагы, совет власте алдындагы

жинаятеңне йолу өчен Яңа Уртавылга, волостьны эвакуацияләргә бүген үк кире китәргә тиешсең.

— Сезгә ничә тапкыр әйтергә кирәк инде Уртавыл аклар кулында дип! Анда барудан хәзер ни мәгънә? — диде Миңнулла, җен ачулары чыгып.

— Ансат эшне аны ахмак та эшли. Ә син мәнә кыен шартларда эшләүнең җаен тап! — диде Соколов, һаман үз кирелеген өстәп.

— Ярый, алайса, болай итәбез: Уртавылга, әйдә, сезнең белән бергәләп киттек, яме!

— Юк, мин үзем бара алмыйм! Минем урында булсаң, син үзең дә китә алмас идең. Мондый җаваплы моментта мин ревкомда булырга тиеш. Әгәр алай бик таләп итәсең икән, синең белән бергә аппараттан берәр иптәшне җибәрергә мөмкин булыр.

— Мөмкин генә түгел, кирәк! — диде Миңнулла.— Югыйсә, сез миңа тагын ышанмаячаксыз бит.

Соколов стена шакып күрше бүлмәдән бер юан гына, бәләкәй генә һәм бик куркак кыяфәтле кешене чакырып кертте дә аны Миңнуллага тәкъдим итте:

— Таныш булыгыз: ревкомның финанс бүлеге мөдире Култышев Иван Митрофанович.

Миңнулла да үз исем-фамилиясен әйтте.

Соколов Култышевка Миңнулла белән кая барырга, ни эшләргә туры киләчәген аңлаткач:

— Юлга хәзер үк кузгалырга кирәк, иптәшләр, — диде. — Башта Уртавылны, аннары волостька караган авыллардагы икмәкне эвакуацияләрсез. Ләкин, барыннан да элек, йөз илле-ике йөз баш җигүле ат җыйнап, монда минем карамакка озатырга кирәк булыр. Моны сугышчан бурыч итеп санагыз! Бу эшкә җаваплы итеп сине билгелим, иптәш Гайсин. Ә син, иптәш Култышев, иптәш Гайсинга ярдәмче булырсың. Мәнә сиңа, иптәш Гайсин, шул хакта мандат! — дип, бер кәгазь сузды. Анда болай дип язылган иде:

**РСФСР** **Мандат**

**Усы өяз ревкомы**
**3 апрель, 1919 ел**
**№ 1319**
**Михайловский заводы**

***Моны күрсәтүче Гайсин Миңнулла Хәлиулла улы Усы ревкомы тарафыннан Яңа Уртавыл волостена эвакуация уткәрү өчен җибәрелә.***

***Волостьтагы авыл ярлылар комитетлары үзләренең эшләрен ип. Гайсин күрсәтмәләре нигезендә алып барырга тиеш.***

*Ревком председателе —* *С. СОКОЛОВ.*
*Секретаре —* *А. КАТРЯЕВ.*

— Синең бу мандатыңа исе китәр инде колчакчыларның! — диде Миңнулла, басыла башлаган ачуы яңадан кабарып.

— Әгәр ревком боерыгын үтәргә теләмисең икән, мин сине тагын кулга алырга мәҗбүр булачакмын, Гайсин! — дип, янә милиция чакырмакчы булып, Соколов телефон трубкасына тотынды.

«Юк инде, бүген алай ансат кына кулга ала алмассың син мине!» дигән уй йөгереп үтте Миңнулла башыннан һәм ул, наганын тартып чыгарды да, теш арасыннан гына:

— Куй трубканы урынына, Соколов, югыйсә, атам! — диде.

Соколов секунд эчендә агарып чыкты, өтәләнеп трубканы кире куйды. Сизелер-сизелмәс кенә аның кулы да калтырый башлады. Кыскасы, аның аптырап-каушап калганлыгы әллә кайдан күренеп тора иде. Миңнулла күңеленә кечә үк килгән, провокатор түгел микән бу адәм, дигән шик тагын да арта төште һәм ул:

— Әйдә, киен Соколов, партия өяз комитетына, Кибардин янына барабыз! — диде.
— Миңа боерык бирергә хакың юк икәнен беләсеңме, Гайсин? — дип, Соколов башта карышырга маташа башлаган иде, ләкин Миңнулла, совет властена каршы эш итә торган кешеләрне минем хәтта атарга да хакым бар, дип, бик каты тотынгач, буйсынырга мәҗбүр булды.
Миңнулла үзенең болай итәргә хакы булмавын да, моның өчен үзен утыртып куярга мөмкин икәнлекләрен дә бик яхшы белә иде. Ләкин шул ук вакытта, әлегә ачык дәлиле булмаса да, Соколовның совет яклы кеше булмавына да бөтен күңеле белән инанган иде. «Провокатор булмаган кеше мин әйткәнгә ышаныр, йөзгә якын кешене эвакуация ясарга дигән сылтау белән инде күптән дошман кул астында калган Уртавылга җибәрергә боерык бирмәс иде!» дип фикер йөртте ул. Шуңа тегене җилтерәтеп партиянең өяз комитетына алып барган иде. Кызганычка каршы, уком председателе Кибардин урынында юк, каядыр киткән булып чыкты. Ә уком секретаре Ясыйров, Миңнулланы тыңлап та бетермәстән:
— Син үзеңне генә коммунист дип, тик мин генә совет власте өчен янып йөрим дип уйлама, Гайсин. Без барыбыз да коммунистлар һәм барыбыз да, нәкъ синең шикелле үк, совет иленең дошманнарына каршы көрәшәбез. Һәркайсыбыз үзенә тапшырылган эшне башкара һәм шуның өчен үзе җавап бирә! Минемчә, синең иптәш Соколовка бәйләнергә бернинди нигезең дә, хакың да юк. Әгәр соңыннан кыен хәлдә калуыңны теләмисең икән, бар, хәзер үк аның боерыгын үтәргә кирәш! — дип кырт кисте.
Моннан ары да карышып торуның мәгънәсе булмаячагы көн кебек ачык иде.
— Ярый, — диде Миңнулла, ниһаять, сыкранып кына ризалашырга мәҗбүр булып, — ярый, мин сезнең боерыкка буйсынам. Ләкин, карагыз аны, бу эшнең ахыры өчен җаваплылыкны мин үз өстемә алмыйм.
— Син боерыкны үтә! — диде Соколов, Ясыйров та аның яклы булганга аеруча кодрәеп.
— Ә безнең волком кешеләре һәм олаулар кайда соң хәзер? Аларны ни эшләтергә боерасыз?
— Алар өчен хәсрәтләнмә, — диде Соколов, — мин аларны юллап озаттым инде!
— Ничек озаттың? Кая озаттың син аларны? — дип, Миңнулла тегенең өстенә килә башлаган иде, араларына Ясыйров килеп кереп, якалашырга ирек бирмәде.
— Хафаланма инде юкка! — диде Соколов, бик нык каушаган булса да, сиздермәскә тырышып. — Әллә кая түгел, Уртавыл волостена бара торырга куштым мин аларга!
— Кайчан җибәрдең аларны?
— Бүген иртән.
— Ә отряд кайда минем? Аны да берәр җиргә озатмагансыңдыр ич?
— Тугыз кешең калды, утыз сигезен фронтка озатырга туры килде.
— Әһә, син мине шул кабахәтлекләрне тынычлап эшләр өчен ябып тоттыңмыни әле, әшәке җан! — дип, Миңнулла наганын алды да Соколовка төбәп атып та җибәрде.
Ул аның маңгаена тидермәкче иде. Ләкин нәкъ курокка баскан чагында гына әлеге шул Ясыйров аның кулын аска басты һәм пуля Соколовның сул ботына эләкте. Ләкин Соколов аягында торып калды һәм Миңнулла өстенә ыргылып аның кулындагы наганын сугып төшерде. Култышев, коты алынып, чыгып йөгерде. Соколов Миңнулланы тибеп екты һәм кобурасыннан наганын алды. Ул, ихтимал, Миңнулланы шунда атып та үтерер иде, тик бу юлы да араларына Ясыйров кереп, коткарып калды. Кыска һәм юантык гәүдәле, карап торырга үшән генә булса да, ул агай гаҗәп житез һәм көчле кеше булып чыкты: Соколов

наганын Миңнуллага төзи башлауга, яшен ташыдай атылып, тегенең наганын каерып алды. Шуннан соң гына, ниһаять, тынып калды алар. Аннары ике милиционер ияртеп Култышев та әйләнеп керде.

Милиционерлар кергәч, бу кабахәт җан Соколов мине тагын япты-рып куя инде болай булгач, дип уйлаган иде Миңнулла. Шул хакта тегенең әмер бирүен көткән иде. Соколов, чыннан да, әмер бирде. Ләкин аның әмере Миңнулла уйлаганча түгел иде:

— Нигә авызыгызны ачып калдыгыз? — диде ул милиционерларга.— Әйдәгез, яраны бәйләргә ярдәм итегез!

Өстәл тартмасында мамыгы да, бинты да, йодысы да бар икән. Соколов чалбарын төшереп, күрсәтмәләр биреп торды, тегеләр булдыра алганча тырышып, аның ярасын бәйләделәр. Ярасы алай зыянлы түгел, пуля Соколовның сум итен тишеп кенә үткән иде.

— Икенең берсен сайла, Гайсин, — диде Соколов тыныч кына итеп, — я хәзер үк минем боерыкны үтәргә чыгып китәсең, яки мин сине тагын кулга алырга мәҗбүр булачакмын.

Тоткында ятуга караганда иректә булу хәерлерәк иде Миңнуллага. Аннары аны олаулар белән киткән кешеләр язмышы да бик нык борчый иде. Шуңа ул, аягы һич кенә тартмаса да, Култышевны һәм отрядыннан калган тугыз кызылгвардиячесен ияртеп, Михайловскийдан чыгып китте.

## 14

Дүртенче апрель киче иде бу. Көндез җепшетеп, кояш ашап иләкләткән юл кары туңып, пыялага әверелгән. Ул пыяла ат тояклары астында чылтырап ватылып бара иде. «Их, акгвардиячеләрне дә менә шушы пыяла карны ваткан шикелле ансат кына сытып барасы иде», дип уйлап куйды Миңнулла.

Урман әчләреннән үткән чакта инде уяна башлаган бөре, ылыс һәм нарат сагызы исләре аңкый. Ул исләр борынны рәхәт кытыклап кына калмыйча, эчкә, тәннең бөтен күзәнәкләренә үтеп кереп, күңелләрне җилкендерә. Инде туйдырып бетергән ияргән төшеп, җәяүләп, шушы хуш исләр белән тулы һаваны сулап, урман моңын, урман тавышын тыңлап, таңга кадәр Зәйнәп белән серләшеп йөрисе килә Миңнулланың...

Ләкин бу мөмкин түгел. Аңа хәзер ашыгырга, мөмкин кадәр олауларны куып җитәргә тырышырга кирәк. Югыйсә, аларның дошман кулына барып кабуы бик мөмкин.

Әмма аның бу теләге тормышка ашарга язмаган икән шул. Степановка авылына килеп җитәргә ярты чакрым чамасы калганда, аларны бер төркем хәрбиләр туктатты. Степановкага Икенче армиянең бер часте килеп урнашкан, теге солдатлар шул частьның сакчылары икән. Сакчылар Миңнулланы часть командиры янына алып бардылар. Кичә бу частька армия штабыннан вәкил килгән булган. Ул да часть командиры янында иде. Алар белән сөйләшкәч, Миңнуллага менә нәрсә мәгълүм булды: әлеге часть Степановкага килеп кергәндә Соколов озатып җибәргән Усы һәм Уртавыл волкомнары олаулары да шунда барып җитеп, ялга тукталган булганнар. Ләкин армия штабыннан килгән вәкил — интеллигент кыяфәтле һәм ут борчасыдай җитез хәрәкәтле, үзе татар булса да, русчаны су урынына эчә торган бер агай иде ул — аларга озаклап ял итеп торырга ирек бирмәгән. Кая баруларын, ни эшләп йөрүләрен сорашып белгән дә:

— Уртавыл күптән колчакчылар кулында, ул якка барырга һич тә ярамый безгә! — дип, хәрби олауларга ияртеп, волком олауларын Сарапул — Әгерҗе — Вятские Поляны маршруты белән тылга озаткан иде.

Алайса, без дә кузгалыйк тизрәк, югыйсә, куып җитүе тагын да кы-

енлашыр дип, Миңнулла да үзенең кечкенә отряды белән олаулары артыннан китмәкче булган иде, әмма армия штабы вәкиле:

— Алай итүнең хаҗәте юк. Алар үзләре дә әйбәт кенә барып урнашыр. Ә сез, иптәш Гайсин, хәзер ятып ял итеп алыгыз да иртәгә кире Михайловскийга кайтып, өяз ревкомы карамагында эш итә башларсыз! — диде.

— Менә бу иптәш ревком вәкиле,— диде Миңнулла, Култышевка ымлап. — Ул ни әйтер икән соң?

— Минемчә дә, Михайловскийга кайтырга кирәк. Никадәр тизрәк кайтсак, шул кадәр яхшырак булачак! — диде Иван Митрофанович.

Кайтуын кайтасы да, ләкин Соколов аларга ике йөзләп җигүле ат алып кайтырга кушкан иде бит әле. Менә шуңа күрә, һич югында, ун-унбиш баш җигүле ат алып кайтып булса да ярар дип, Миңнулла Шумково авылына кагыла кайтырга уйлады.

Шумковода аларның эшләре әйбәт кенә булды. Кичтән акларның уң кешелек отряды килеп, Шумково авылына утыз биш җигүле ат әзерләп, йорт башына берәр мич ипи пешереп һәм йөз капчык он хәстәрләп куярга әмер биреп киткән булганнар икән.

Колчакчыларны сөенешеп көтеп алган контр элементлар, куштанланып, унөч җигүле ат, утыз дүрт капчык он әзерләп куйган һәм авыл халкына үзләренең оннарын биреп, кырык бер мич икмәк салдырганнар. Ул икмәкне җыйнап алып, инде олауларга да төяп куйган булганнар. Тик аклар аларны алып китәргә генә өлгермәгән. Бандитлар кулына калганчы үзебезнең халыкка эләксен, ичмаса, дип, Миңнулла икмәкне дә, олауларны да үзләре белән Михайловскийга алып кайтырга карар кылды.

## 15

Алар кайтып кергәндә, Михайловскийда Усы ревкомы урнашкан бина урынында кара күмер генә өелеп калган иде. Ни булганын сорашырга дип, Миңнулла партиянең өяз комитетына барды. Ләкин анда да берәү дә юк, бөтен бүлмәләр буп-буш иде.

Инде ни кылырга, кая барырга белмичә торганда, Миңнулла янына бер рус карчыгы килде дә:

— Син Гайсин түгелме, улкаем? — дип сорады.

— Әйе, мин Гайсин булам, әбекәй.

— Алайса, мә, Петр Иванович моны сиңа тапшырырга кушып калдырган иде,— дип, карчык Миңнуллага конверт бирде.

— Сез Петр Ивановичның кеме буласыз? — диде Миңнулла, конвертны ачып, эчендәге хатын алган арада.

— Беркеме дә түгел. Мин укомның җыештыручысы идем.

Миңнулла хатны укырга тотынды: «Иптәш Гайсин! — диелгән иде анда.— Югарыдан килгән күрсәтмә нигезендә, уком Михайловскийдан эвакуациягә китәргә тиеш булды. Казан губернасының Арча өязенә барачакбыз. Шушы язуны алу белән син дә, үзең белән булган барлык иптәшләрне җыйнап, әлеге маршрут буенча юлга чык. Моны укомның катгый боерыгы дип сана.

Соколов мәсьәләсендә син мең тапкыр хаклы булгансың, иптәш Гайсин. Әйе, хыянәтче булып чыкты ул. Бүген төнлә ревком карамагындагы барлык акчаны, бөтен кыйммәтле әйберләрне һәм Кызыл Армиягә озатырга дип авыллардан җыйган утыз сигез җигүле атны алып, үзенең иярченнәре белән Колчак ягына качып киткән. Киткәндә Ясыйровны атып үтергән. Һәм документларга да ут төрткән. «Их, кичә атып үтергән булсам шул кабахәт җанны!» дип уйлап алды Миңнулла һәм язуны укуын дәвам итте: — Ул явызның тагын да кабахәтлекләр эшләве мөмкин. Әгәр аның имзасы белән сиңа берәр төрле күрсәтмә килә

калса, зинһар, ути күрмә аны! Әгәр үзеңә алай-болай очрап куя калса, уйлап та тормыйча кулга ал шул контрны! Нигә алдың дип җавапка тарттыра башласалар, минем шушы язуны күрсәтерсең.

Сау бул. Тизрәк безне куып житәргә тырыш.
Кибардин. 5/IV.1919.»

— Уком кайчан авылдан чыгып китте? — диде Миңнулла әле һаман үзе янында басып торган теге карчыкка.

— Бүген иртәнге сәгать җиделәрдә.

Миңнулла сәгатенә карап алды — уникенче киткән иде.

— Рәхмәт апа, аманәтеңне үтәвең өчен!

— Рәхмәт белән тамак туймый, улыкаем. Коры рәхмәт белән генә калдырма инде син мине. Азрак ярдәм дә итеп кит!

Акча бирмәкче булып, Миңнулла кесәсеннән бумажнигын чыгарган иде, карчык кулын гына селекте:

— Юк, улыкаем, акча кирәкми миңа! Хәзерге заманда акчаның кадере юк аның. Син миңа, булдыра алсаң, берәр бөтен генә булса да икмәк калдырып кит, икмәк булмаса, он да, ярма да ярый. Тик ашый торган әйбер генә булсын!

— Өеңдә кемнәрең бар, әбекәй?

— Берүзем генә мин. Синең шикелле ике малаем бар иде дә, берсен аклар үтергән, икенчесе исәнен исән бугай әле дә, тик ул миңа ярдәм итә алмый шул — фронтта. Кибардин барында ярый иде, ул рифкумнан ипи паегы бирдертеп тора иде. Тик ул да китеп барды шул инде менә.

Карчыкның шушы сүзләрен тыңлагач, Миңнулланың күз алдына үз әти-әниләре килеп басты. Алар да менә шушы карчык шикелле тилмереп йөрмиләр микән?..

— Тукта, әбекәй, мин олаулар янына барыйм әле.

— Ай, рәхмәт, улыкаем, ай, рәхмәт! — дип такмаклап, карчык җайдак Миңнуллага ияргән иде дә, Миңнулла аны кызганып, шушында капка төпләрендә генә көтеп торырга кушты һәм тиз генә олаулар янына барып, өч бөтен пешкән икмәк җибәрттерде.

## 16

Никадәр тырышсалар да, өяз комитеты олауларын куып җитә алмадылар. Хикмәт дүрт-биш сәгатькә соңга калып чыгуда гына түгел иде монда. Фронт хәлләре сәгатьләп кыенлаша бара иде. Шуңа күрә олауларны аклар кулына төшерүдән сакланып әллә нинди урау юллардан үтәргә мәҗбүр булдылар. Шулай да унҗиде олауның бишесен югалтырга, бер кызылгвардиячене һәм Култышевны юлда җирләп калдырырга туры килде. Ә турыдан барган булсалар, хәлләре тагын да хөртирәк булган булыр иде.

Өяз комитеты олаулары Арчада тукталган иде. Икенче армия вәкиле тарафыннан хәрби олаулар белән бергә Вятские Поляны юнәлешенә озатылган Карый һәм Яңа Уртавыл волостьлары олаулары да исән-сау килеш бу якларга килеп җиткән икән. Алар Арчадан дүрт-биш чакрымда гына Кәче авылына урнашканнар иде.

Партиянең Усы өяз комитеты председателе иптәш Кибардин Миңнуллага башта олауларны Арчада торган хәрби частька тапшырырга кушты. Аннары Карый һәм Уртавыл волкомнарының печатен, архивын һәм барлык материалларын өяз комитетына тапшырдылар. Отрядындагы кызылгвардиячеләрне һәм Сәгыйдулла агай малае Фәйзулланы Арчадагы хәрби частьның штабы карамагына алдылар. Карый һәм Уртавыл волостьларыннан эвакуациягә килгән кешеләрне, шул исәптән, олаулар башлыгы булып килгән Сәгыйдулла агайны да, Кәчедә урнаш-

тырып, социаль тәэминатка куйдылар. Ә Миңнулланың үзен Казанга, Икенче армиянең политбүлеге карамагына җибәрделәр.

Ул көннәрдә Казаннан Кукмарага, Кукмарадан Казанга поездлар бик еш йөреп торса да, аларга утыру мөмкин түгел: Казаннан килүчеләре фронтка баручы солдатлар, сугыш кораллары белән, Казанга баручылары сугышта яраланган сугышчылар белән шыгрым тулы була иде. Шуңа күрә Миңнулла Казанга җайдак кына барды.

Икенче армиянең политбүлегендә аны Таежников фамилияле бер кеше кабул итте. Күе кара мыеклы, утыз биш-кырык яшьләр тирәсендәге ул агай Миңнуллага Арчадан Усы өяз комитеты тарафыннан бирел җибәрелгән белешмә-характеристиканы бик җентекләп укып чыкты да, бүтән берни дә сорап тормастан:

— Яхшы, — дип кире сузды. — Хәзер губерна хәрби комиссариатына барыгыз. Анда сезгә кунарга урын һәм паек бирерләр. Шунда кунарсыз, ял итәрсез дә иртәгә иртән яңа төзелеп ята торган мөселман бригадасының командиры Ибраһимов карамагына барырсыз. Мин сезнең хакта аңа телефоннан әйтеп куярмын. Уңыш телим сезгә!

Миңнулла шул чорда төзелә башлаган татар бригадасы турында белә иде инде. Ул бригаданың Алатырь шәһәрендә тупланулы да һәм аның Икенче армия составына кертелү-кертелмәве икеле икәнлеге дә мәгълүм иде аңа. Ә аның бары тик Икенче армиядә, аның да Азин дивизиясендә каласы килә иде. Шуңа ул Таежников янынннан чыгып китәргә ашыкмады һәм, тәвәккәлләп:

— Мине Икенче армиядә калдыруыгызны үтенер идем? — диде.

— Мин сезнең үтенечне бик рәхәтләнеп канәгатьләндерер идем, иптәш Гайсин. Икенче армиягә дә сезнең шикелле сугыш эшен һәм политик эшне әйбәт белә торган кешеләр бик кирәк. Ләкин алай эшләргә минем хакым юк. Чөнки Республика Революцион Хәрби Советының татар милләтеннән булган барлык сугышчыларны, ә командирларны һәм политхезмәткәрләрне бигрәк тә, төзелеп ята торган татар бригадасына җибәрергә дигән катгый күрсәтмәсе бар.

— Анысы шулайдыр. Ләкин һәр кагыйдәнең чыгармасы була бит, иптәш Таежников. Үтенечемне канәгатьләндерсеннәр өчен, миңа кая, кемгә мөрәҗәгать итеп карарга киңәш бирәсез?

— Бу мәсьәләне тик Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясенең политбүлек мөдире генә хәл итә ала. Ләкин, белмим, ул да уңай хәл итәр микән сезнең үтенечне. Чөнки татар бригадасына сугыш эшен белә торган тәҗрибәле командирлар җитми. Ә мин сезне Ибраһимовка полк командиры урынбасары яки аерым батальонның командиры итеп тәкъдим итәргә ниятләгән идем.

— Ышанычыгыз өчен рәхмәт, иптәш Таежников. Шулай да мин башта Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясенең политбүлек начальнигы Камил Якуповка мөрәҗәгать итеп карар идем.

— Әллә сез аны беләсезме?

— Күреп түгел, газеталарда басылган мәкаләләре буенча гына.

— Күреп белгән булсагыз, тагын да яхшырак буласы икән дә, ни хәл итәсең бит. Мин каршы түгел, теләсәгез аңа мөрәҗәгать итеп карагыз.

Дөресен әйтергә кирәк, Миңнулла Камил Якупов янына кергәндә, сиңа тагын ни җитми инде, барысы да менә шушылай, синең шикелле үз мәнфәгатең генә кайгыртып, минем янга килә башласа, кая китә ул анннары, дип ачуланмагае дип шүрләбрәк кенә кергән иде. Ләкин кереп аны күрү белән курку-каушавы шундук бетте. Чөнки Камил Якупов, дәрәҗәсе зур булса да, ифрат ягымлы адәм икән. Кыйгач кара кашлы, яфраклары кабарып торган кылыч борынлы, кечкенә, әмма үткен күзле, артка тарап куелган озын, калын коңгырт чәчле ул кеше Миңнулланы

күптәнге танышыдай якын итеп каршылап, кул биреп күрешге дә бүлдермичә генә аның гозерен тыңлады. Шуннан ары иплап кенә:

— Совет властен яклап кайсы армиядә сугышсагыз да, барыбер түгелмени, иптәш Гайсин? — диде.

— Барыбер түгел шул, иптәш Якупов! — диде Миңнулла, тегенең артык каты кыланмаганына куанып һәм шуңа батыраеп китеп. — Безне чигенергә мәҗбүр иткән дошманны шул ук юллардан кирегә кууда катнашасым килә минем. Үземә таныш җирләрдә сугышканда совет властена ярдәмем күбрәк булыр дип уйлыйм.

— Бары шул гынамы Икенче армиядә калырга теләвеңнең сәбәбе?

«Тагын атаң башы кирәкмени инде сиңа?» дип уйлап куйды Миңнулла һәм ни әйтергә белмичә төртелеп калды. Минем анда Кошкарев, Шишков, Соколовлар кебек контрлар белән исәп-хисапны өзәсем бар, диярга теләсә дә, ул аларны белми бит, дип, кире түнде. Әти-әнисенең, абыйсы Зәйнулланың һәм, ниһаять, сөйгән кызы Зәйнәпнең язмышларын ачыкларга омтылуын әйтергә шулай ук җөрьәт итмәде. Шушындый зур эшләр турында сүз барганда вак-төяк шәхси нәрсәләр белән баш катырып торалармыни, дип, Якупов ачулануыннан шикләнде. Әмма шулай да ул һаман үз фикерен алга сөреп:

— Моннан да житдирәк сәбәпнең булуы мөмкин дә түгел, минемчә. Һәм сез минем үтенечемне кире какмассыз дип ышанам, иптәш Якупов! — диде.

Миңнулланың бу сүзләре, этисе әйтмешли, фәрештәнең амин дигән сәгатенә туры килде, ахры: Якупов сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды да, бүтән бер сүз дә әйтмичә, Миңнулла белешмәсенең арткы ягына: «Иптәш Гайсинны Икенче армиядә калдырырга мин каршы түгел», дип язып һәм кул куеп бирде.

— Рәхмәт сезгә, Камил абый! — диде Миңнулла, куанычыннан очып китәрдәй булып.

— Исән бул, энекәш! Уңыш телим сиңа! Ә хәзер Таежниковка бар, — дип, Якупов аны ишек төбенә тикле илеп, кул биреп озатып калды.

* * *

Башта аны Икенче армия штабы каршында оештырылган политхезмәткәрләр курсында ун көн укыттылар. Аннары ул чорда Әгерҗе тирәсендә акларга каршы кискен сугышлар алып бара торган 28 нче дивизиянең (Азин дивизиясенең) 247 полкына беренче батальон комиссары итеп билгеләп, фронтка озаттылар.

Ул килеп җитәсе көнне генә әлеге батальонның командиры дошман пулясыннан һәлак буласын һәм батальонда эшне аңа комиссар булып түгел, командир булып башлап җибәрергә туры киләчәген Миңнулла белми иде әле.

1971—1975.

# МОҢ ҺӘМ НӘФРӘТ ПАРЧАЛАРЫ

Килеп чыгышы, туган теле, гореф-гадәтләре ягыннан безгә якын кардәш уйгыр халкының әдәбияты татарлар арасында борын-борыннан яратып укыла килгән. Соңгы елларда Л. Моталлап, Һ. Искәндәрев, И. Бәхтия һ. б. шагыйрьләрне, фольклор әсәрләрен тәрҗемә итү әдәбиятларыбыз дуслыгын тагын да көчәйтә төште. Әмма шушы көнгә кадәр уйгыр прозасы укучыларыбыз игътибарыннан читтәрәк кала килә иде. Чөнки, аның беренче үрнәкләре унтугызынчы гасырда Билал Назыйм тарафыннан ук тудырылса да, ул чын мәгънәсендә безнең гасырның утызынчы елларында гына барлыкка килде һәм сугыштан соңгы елларда чәчәк атты, рус, казакъ, үзбәк һ. б. телләргә тәрҗемә ителә башлады. З. Самадый, Ж. Бусаков, М. Зөлпикәрев романнары, Ж. Мусаев, Ә. Аширов, Й. Ильяс, К. Төхтәмев повестьлары һәм күпләгән хикәяләр менә шул хакта сөйли.

Көнчыгыш Төркстанның төп халкы булган уйгырлар үзенең бәйсезлеген саклар өчен гасырлар буе Кытай, Җунгар дәүләтләре явына каршы көрәшеп килде. Мөстәкыйльлеген югалткач, политик һәм экономик яктан тигез хокуклылыкка ирешү, телен, гореф-гадәтләрен, культурасын саклау һәм үстерү хакына күп тапкырлар баш күтәрде. Совет иленең япон самурайларын тар-мар итүе, демократик КХР төзелү Кытай составындагы 4 миллионлы уйгыр халкына да милли автономия биргән иде. Әмма маочыларның соңгы еллардагы котырынган шовинистик политикасы революция казанышларын юк итеп, азчылык милләтләрне бөлгенлеккә төшерде, көчләп кытайлаштыру дәһшәтенә дучар итте. Халык кичергән фаҗигаләрне тасвирлау, кара золымга каршы көрәш сәхифәләрен ачу, хезмәт ияләренең якты омтылышларын, әхлак сафлыгын, батыр рухын гәүдәләндерү, табигый ки, уйгыр әдәбиятының вөҗдан һәм намус эшенә әйләнде.

1920 елда Кашгарда туган, Өремҗе югары мәктәбен тәмамлаган Йосыфбәк Мөхлисев тә туган халкы өстенә төшкән җәбер ачысын татырга мәҗбүр була. Гоминданчылар аны егерме дүрт яшендә ук төрмәгә яба, Чәүчәк шәһәренең баш күтәргән халкы аны бер елдан соң зиндан газапларыннан коткара. Яшь егет дәртләнеп «Ялкынлы утлар» драмасын, «Уйгыр кульъязмалары каталогы» монографиясен иҗат итә. Ул арада милли кадрларны эзәрлекләү башлана һәм Й. Мөхлисев тагын тоткынлыкка элгә — хезмәт лагерена җибәрелә. Моннан инде ул 1961 елда СССРга качып кына котыла.

Хәзер нигездә Казагыстанда һәм Урта Азия республикаларында яшәүче уйгырлар ике йөз меңгә якын. Балалары туган телдә белем ала, уйгырча газеталар, китаплар чыгарыла, радиотапшырулар бара, милли театр эшли. Й. Мөхлисев тә монда, ниһаять, иҗат эшенә мөмкинлек таба. «Садыйр пәһлеван», «Маяк» романнарын, «Насретдин әфәнде Кашгарда», «Йосыф Хас Хаҗип» пьесаларын, «Гасырлар һәм әсәрләр» монографиясен яза һәм филология фәннәре кандидаты исемен казана.

**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ.**

# Йосыфбәк Мөхлисев

КАШГАР ДӘФТӘРЕ ХАТИРӘЛӘРЕННӘН
НОВЕЛЛАЛАР

## Анам җавабы



Бала чагымнан ук миңа бәхетсезлек юлдаш булды. Еш кына уйлаган уем эшкә ашмады, кылган гамәлем көткән уңышны китермәде. «Тумыштан тәкъдиремә шулай язылдымы икән әллә?» дип баш ваттым. Бер көнне, шул серне белер өчен, хәзер инде мәрхүм булган анам янына килеп:

— Әнкәй, ләүхелмәхфүздә миңа бәхет язылмаган микән әллә? Яисә бәхет дигәннәре улыңны алдагы көннәрдә көтәме? — дип сорадым.

Изге китапларда әйтелгәнчә, һәр адәмнең бу дөньяда кыласы яхшылыгы, яманлыгы ул үзе туганчы ук язмыш тактасына язып куела икән. Аны алдан ук белергә дә була, имеш. Мәсәлән, Искәндәр Зөлкарнәен дөньяга «шаһлык мөгезе» белән килсә, Чыңгыз хан бер йодрыгын йомарлап туган икән. Галимнәр ул йодрыкны ачып карагач, учыннан чыпчык йөрәге кадәр кан төере чыгып, аның җиһангир[1] булачагы турында хәбәр биргән ди. Кайбер бәхетсезләр җир тетрәгәндә туса, бәхетлеләр кыш җәйгә авышып, табигать гүзәл яшьлеген кичергәндә дөньяга килә. Мин туган чагында да язмышымның нинди буласына ишарә иткән әнә шундый берәр вакыйга булмаган идеме?

— Булды, углым, булды, — диде әнием көенечле тавыш белән. — Нәкъ син туган көнне Кытай гаскәрләре Кашгарны тагын талый башлаган иде...

## Официант Турдахун

Шәһәребездәге зур ашханәләрнең берсендә Турдахун исемле гаҗәеп кунакчыл бер официант эшли иде. Иртәдән кичкә кадәр меңләгән кешене татлы тел, ачык йөз белән каршы алып, һәммәсенең күңелен таба белә торган бу ягымлы кешене халык шуның өчен «официантлар әүлиясе» дип атады. Бүтәннәр кебек, мин дә аны хөрмәт итә идем.

Беркөнне шуның хозурына кереп, яртышар өлеш ләгъмән белән рагу сорадым. Яртышар өлеш белән генә мин туеп җитмим, гадәттә, һәр икесен тулы өлеш ала торган идем. Ашның бәясе сиксән тиен, ә бүген кесәмдә акча да нәкъ шул кадәр генә — барын да ашарга тотып бетерсәм, кинога керә алмаячакмын.

Аш бирелү белән ашханә ишегеннән «уйгыр культура-агарту оешмасы»ның бер хезмәткәре кереп, ишек төбенә зур бер тактага языл-

[1] Җиһангир — дөньяны яулап алучы.

гән игъланны сөяп чыгып китте. «Бүген кино булмый. Татар культура-агарту җәмгыяте һәвәскәрләре «Хыялый доктор» исемле комедия куя. Билет бәясе алтмыш тиен», дип язылган иде ул игъланда.

Театр дигәндә үлеп китәм. Әмма билеты кыйммәтрәк, нәкъ утыз тиенем җитмәячәк...

Ашны ничек ашаганымны да белмим. Бизәкле кытай тәлинкәсе бик тиз бушап, ялтырап калды. Хәзер башымда бер генә уй — театрга бару. «Әгәр шушы тәлинкәне чәлдереп, аны утыз тиенгә залогка салсам?» дип уйлыйм. Йөрәгем урыныннан купты. Залга күз салсам, ниятемне тормышка ашырырга комачаулый торган официант күренми. Тәлинкәне алып тиз генә куеныма тыктым да исәп-хисапны өзәр өчен кассага киттем.

— Официант, кунактан күпме алырга? — диде кассир, миңа ымлап.

Турдахунның әллә кайдан:

— Сиксән тиен! — дигән тавышы ишетелде.

Мин аптырап калдым: «Нигә сиксән тиен?!»

— Нәрсә булды, әллә ялгыш исәпләгәнме? — диде кассир, күземә карап.

— Әйе, хата җибәргән, ахры! — дидем мин, дерелди башлаган иреннәремне көчкә тыеп. Кассир миңа борчылган бер төс белән карап алды да:

— Официант, бу кунакка дөресләп исәплә бир әле! — дип кычкырды.

— Дөресе шул инде, — диде Турдахун, ачык чырай белән кассага якынлашып.— Егет яртышар өлеш ләгъмән белән рагу ашады — бәһасе илле тиен була. Әмма ул туеп җитмәде, ахры, ашны тәлинкәсе-ние белән кабып йоткан!

— Ватканмыни?

— Әйе...

Турдахун миңа наян гына карап күз кысты. Мин комач кебек кызарып киттем. Кесәмдәге сиксән тиенне кассирга ташладым да, алны-артны карамыйча, тиз генә урамга чыгып киттем.

Менә шул көннән бирле Турдахунны бүтән күргәнем юк, ләкин аның мине әдәпле генә итеп акылга утыртуы һич тә йөрәгемнән чыкмый.

## Шагыйрь фикере

Шәһәребездә Әмирхөсәен әфәнде дип исеме чыккан туры сүзле бер шагыйрь яши иде. Туры сүзле булганы өчендерме, чапаны тезенә дә җитми иде. Әлеге сыйфатын истә тотып, халык аңа «сыйрат күпере казые» дип исем кушкан иде.

Кайсыдыр елны бәйрәм көннәрнең берсендә аның күршесендә яшәгән бер укытучы вафат булды. Мәрхүмнең гомере халыкны кайгыртып үткәнгә, җеназасына бик күп кеше җыелды. Моны бәйрәм көн нәтиҗәсе дип аңлаган берәү:

— Нинди олы мәртәбә күрсәтеп күмү бу, ә, Әмирхөсәен әфәнде?! Ходай бездәге әманәтен дә шушындый бәйрәм көннәрендә алса, нинди яхшы булыр иде, — дип куйды. Бу сүзгә каршы шагыйрь, көлеп җибәреп:

— Әгәр ходай гадел булса, сездәге әманәтен кытайлар бәйрәмендә алыр, тәкъсир! — дип җавап бирде.

Әлеге сүз башлаучы кеше кытай патриотизмы йоккан аумакай бер адәм иде. Ул, бер кызарып, бер агарынып, халык төркеме эченнән чыгып китәргә ашыкты.

## «Беләмен»нең файдасы

Ул һәр вакыт, нинди генә эш чыкса да, «беләмен» дип тотына, әгәр соңыннан башкара алмаса, бер дә исе китмичә: «Гафу итегез, белмәгәнмен» дип, җиңел генә котыла иде. Бер көнне мин аның менә шул гадәте белән кызыксындым.

— Һәй, абзыкаем,— диде ул, җилкәмнән кага-кага көлеп,— акыллы бала икәнсең, минем шул сүзләремә хәйран калдыңмы? Аңлатып бирәбез аны. Безнең заманыбыз — белүчеләр белән белмәүчеләр заманы бит. «Белмим» дисәң, сиңа беркайда да сан юк. Ә эшкә керешеп тә, аны ерып чыга алмасаң, «белмәгәнмен» дисең дә котыласың. Аның өчен сине беркем дә хөкем итә алмый.

Мин менә шушы юл белән егерме еллап эш йөртеп киләм. Әле бүген дә шулай, насыйп булса, киләчәктә дә... Тыныч гомер итәр өчен моннан да уңайлырак юл юк.

Ул, мәгърур төстә башын күтәреп, сакалын сыйпап куйды. Ихлас биреп тыңлап торуымны күрде булса кирәк:

— Әйе, шулай... Аңың булса, син дә шул юлны тот,— дип киңәш итте.

Берничә ел үткәч, мин аны төрмәдә очраттым. Гаҗәпләнеп:

— Менә тамаша! Абзый, сезме бу, әллә...— дип авыз ачкан гына идем:

— Әйе, абзаң үзе,— диде ул, күрешүебезгә әллә ни сөенмәстән, әмма һич тә сер бирергә уйламыйча гайрәтләнеп. — Барыбер, монда да шул ук хәйлә коткара, шул ук юл белән яшим. Ходайга шөкер, минем монда кергәч тә кайберәүләр кебек тәрәтханә чистартып, таяк ашап йөргәнем юк. Чип-чиста ашханәдә йөзендә иман нуры булган кешеләр белән хезмәт итәм. Әгәр бу юлны тотмасам...

— Әйе шул, ул юлны тотмасагыз, күпчелек белән бергә иректә булыр идегез,— дидем мин, тәкатем бетеп.— Сезнең кебек шәхси рәхәтнең колы булганчы, кайгы-газап күле булу яхшырак түгелме, абзыкаем?

## Сәгать

1943 елда безнең сәгатьләребез вакытны шул хәтле «үзенчә» күрсәтә башладылар — иртән эшкә кайберәүләр бер сәгать алдан барса, икенче берләребез кырык-илле минутка соңга кала.

Моның сәбәбе бер генә иде: гоминдан администрациясе шәһәребездәге бөтен радиоалгычларны җыеп алды һәм безнең Мәскәүне ишетә алмавыбызга бер елдан артык гомер узды.

Вакыт, әлбәттә, хезмәт тәртибен күзәтеп бару өчен генә кирәк булмый. Ул бөтен эш-хәрәкәтнең дә үлчәве ләбасә. Шуңа күрә без бу турыда җитди сүз ачып, бер уртак карарга килмәкче булдык.

— Вакытны барыбыз да бер төрле исәпләп барыр өчен фәкать Гафур Һаҗыйм җәнабләренең сәгатенә таянырга кирәк, — диде беренче сүз алган Зөнүн бай һәм көмеш чылбырлары бөтен гәүдәсе буйлап асылынып төшкән кара бәрхет янчыктан тәлинкә хәтле сәгатен

кулына алды. — Минем сәгатем дә гел дөрес йөри, әмма Гафур Һаҗыймныкына җиту кая инде ул!..

— Әлбәттә, шулай!.. Гафур Һаҗыймның сәгате утыз ике ташлы алтын сәгать бит ул! Шул да дөрес йөрмичә, кемнеке йөрсен? Төзәтсәк, аныкына карап кына төзәтик дип, Хәсән Һаҗыйм исемле икенче бай да, Зөнүн бай сүзен куәтләп, зур сәгатен кулына алды.

Бер-ике генә кеше Гафур Һаҗыйм сәгатенә кыйбланы борды, башкаларга үз сәгатьләре кадерлерәк, үзләренеке дөресрәк йөри булып күренә иде. Бәхәс яман куерып китте. Бер сәгать буена сүз көрәштереп тә, берсе икенчесе белән килешә алмагач, җиңешкән өч байның сәгатьләре сайлап алынды. Ахыр чиктә чәкәләшкән өчәү арасыннан беренче башлап телгә алынган кеше — Гафур Һаҗыймныкы өстен танылды, һәрберебез сәгатьләребезне аның алтын сәгатенә карап дөресләп куйдык.

Бәхәс июль аенда булды. Бу айда иртәнге эш вакыты сәгать тугызда башлана. Сүз көрәштерүнең иртәгесен ышанычлы Гафур Һаҗыйм вакыты буенча эшкә килсәк, гоминдан вакытыннан җитмеш биш минутка кичегеп кузгалганбыз. Бу үзе зур бәла чыгарды. Бездән ничек үч алырга белми йөргән гоминдан администрациясе соңга калуны сылтау итеп, кайберләребезгә шелтә бирде, кайсыларыбызны хәтта эштән дә куып чыгарды. Соңыннан сорашып белдек: бөтен шәһәрне саташтырган Гафур Һаҗыйм сәгате 1927 елны хаҗга барганда халыкара Гринвич вакытына туры китереп дөресләнгән булган икән һәм ул шушы көнгә кадәр дөресләнмичә йөри бирә икән.

## Остаз һәм мин

Без укый торган башлангыч мәктәпнең география укытучысы дәрес саен:

— Җәгъръфия гыйлеменең әһәмияте шунда ки, дөньяның һәммә җирен күрмәсәң дә, күргән кебек буласың. Мәсәлән, менә минем Лондонга барганым юк. Әмма аны күрдем дисәм, ялган булмас. Чөнки мин аның һәммә җирен күргән кеше кебек күз алдыма китерәм. Әгәр сез бу гыйлемне тырышып өйрәнсәгез, үзегез өчен яңа дөнья ачарсыз, — дип сөйли иде.

Мин география һәм тарихны башка фәннәргә караганда күп өлеш артыграк яраттым. Укытучым ни дисә, мин дә бүтән җирдә шуны кабатлап, үземнән кечеләрне генә түгел, хәтта өлкәннәрне дә күзем күрмәгән, колагым ишетмәгән серле дөнья белән таныштырып мавыктыра башладым.

Бер елны безгә кунакка килүчеләр арасында Истанбул исеме телгә алынды. Әле моннан берничә ел элегрәк кенә хаҗга барганда шул шәһәрдә булган бер хаҗи:

— Истанбулның зур базары бар, — диде дә төртелеп калды. Кызык ишетергә теләп тә, аннан нәүмиз калган тыңлаучыларның берсе эче пошып:

— Хаҗи абзый, сез ул шәһәр турында сөйләп бирәм дип әвәрә булмагыз. Истанбулны сездән соңрак күргән яшь энекәшебез сурәтләп бирер! — дип, миңа төртеп күрсәтте.

Төркиягә аяк басмаганымны яхшы белгән иптәшләрем алдында, миңа мәшәкатьле вазифасын мирас итеп, инде күптән кара җир астына кергән остазымны битәрләүдән файда юк иде:

— Истанбулның алты мең урамы арасында иң матуры — Бәюглы, — дип сөйләп алып киттем мин...

## Ходайның милләте кем?

Шинҗанда милли мәсьәлә бик кискен куелган авыр көннәрнең берсендә бер яшь язучы миннән:

— Ходай бармы ул? — дип сорады.

— Әгәр булса? — дидем мин, аның нәрсә әйтергә теләвен төшенергә тырышып.

— Милләтен белим дигән идем...

Көлештек. Соравы җавапсыз калды. Таралыштык. Аннан соң ике ел вакыт узды. Яз җитте. Апрель башында җылы кояш нурлары астында ачыла башлаган чәчәк бөреләре соңрак төшкән салкыннарда өшеп, исән калган яфраклары да куырылып китте. Шушы манзарага күз салып килгәндә әлеге энекәшкә юлыктым.

— Я, белдеңме ходайның милләте кем икәнен? — дип сорадым мин аңардан.

— Белдем, — диде ул, суыктан өшегән чәчкәләрне җитди генә күздән кичереп, — аның милләте кытай икән...

Тетрәнеп киттем. Чөнки кытай милләтчеләренең безгә китергән золымы белән ходайның үсемлекләр дөньясына салган афәте арасында берниндидә аерма юк иде.

## Мөкатдәс кирелек

Безнең урамда мангуҗо кытайларыннан Җаң фамилияле берәү ашханә ачкан иде. Аракы, хәтта әфьюн белән сәүдә итә торган бу кеше бик бай, әмма хәттин ашкан саран, шуңа күрә халык аның турында:

— Ул үзе нишләгәнен үзе белми, тимер сыгып май чыгара икән, — дип сөйли иде.

Чыннан да, комсыз кеше иде Җаң. Ул бер чеметем чәен кызганып, еллар буе ап-ак су эчте. Бармак башы хәтле ит ашаган көннәрдә, «болай булса ничек баемак кирәк» дип, төн буе йокламыйча, хатыны-балаларының теңкәсенә тия иде. Аның бу сыйфатын күпләр өнәми, «үз башына җыя» дип сөйлиләр иде.

Бер көнне шушы сәүдәгәрнең өе турысыннан узып барганда, хатыны каршыма йөгереп чыгып:

— Егет, ярдәм итегезче, ул асылынды! — дип елап җибәрде.

— Ни өчен? — дип, мин хәйран калып хатынга карадым, тик ул нәрсә дә булса аңлатудан гаҗиз иде. Озак төпченеп торыр чак түгел, йөгереп өйләренә кердем. Җаң түшәмгә асылынган, йөзләре күгәреп киткән. «Башына нинди кайгы төште икән соң?» — дип уйладым мин.

Бәхеткә каршы, җаны чыгып өлгермәгән иде. Аны тиз генә элмәктән алдым. Менә шунда өстемә салкын су койдыларммыни — башын күтәргән Җаң күзен ачар-ачмас ук мине тирги башлады:

— Һай, шомлык! Минем үлү-үлмәвемдә синең ни эшең бар? Бу бөлдергеч дөньядан китеп котылыйм дисәм, мәрхәмәтле бәндәләр килеп тыкшына! Шуны хәтереңдә тот: синең кебек йомшак күңелле мәми авыз булганчы, минем кебек мөкатдәс саклык корбаны булу мең артык!.. — диде.

Бу вакыйгага булып узганга егерме еллар бар инде. Җаң әллә кайчан үлеп туфракка әйләнде. Мин соңыннан гына аның асылынуына өендә утыз тиенлек чыгым ясалу сәбәп булуын белдем. Менә сиңа мөкатдәс саклык корбаны!

## Иң газизе нәрсә?

Бала чагымда мин күп кешедән: «Дөньяда ашау-эчүдән дә татлырак нәрсә бар?» дип сораганда, «йокы» дигән җавап ишетә идем. Әлбәттә, бу җаваптан мин канәгать идем, чөнки ятсам, бер дә кымшанмыйча ун-унике сәгать йоклый алам. Врачлар «йокы — ярты дөнья» дип бушка гына әйтмидер, күрәсең.

Әмма яшем-буем үсеп, акылым-зиһенем киңәйгән саен, татлы йокыларым кача башлады. Хәтта агарып таң атканчы керфек какмый торган хәлләргә төштем. Бу нинди сер? Нинди шаукым? Кайда ул әлеге татлы йокыларым?!

Инде бу сорауга: «Дөньяда мәхәббәттән дә татлырак нәрсә юк!» дигән җавап табуым бик табигый иде. Үзем дә раслый алам: унсигез яшьтә җиһанда мәхәббәттән дә татлырак нәрсә булсын!

Тора-бара миңа «дөньяда иректән дә татлы нәрсә юк» дигән сүзләр дә бик дөрес тоелды. Чыннан да шулай ич: ике мәртәбә төрмәгә эләгүем ул сүзләрдә хакыйкать барлыгын исбатлады. Кыйналган саен, үлемгә хөкем ителгән иптәшләремнең кыяфәтен күргән саен тереклекнең нечкә җебе хакында уйламый чарам юк иде.

Ә хәзер? Әгәр дә берәр кеше әлеге сорауны бүген миңа бирә торган булса:

— Дөньяда ватаннан да газиз нәрсә юк! — дип җавап бирер идем мин. Чөнки йокы үзеңнең туган илеңдә генә татлы, ватаның булмаса, ул бушлыкны мәхәббәт кенә дә бетерә алмый. Ә Ватаннан читтәге ирекнең кемгә хаҗәте бар?

## Ихтыяр көче чыганагы

Мин төрмәдә Касыймҗан исемле бер тоткынның хикәятен тыңладым.

Бервакыт аны, газаплаганнан соң, камерага сөйрәп керттеләр дә юеш җир идәнгә ыргыттылар. Мулла, хәленнән килгәнчә, егетнең яраларын бәйләде.

Касыймҗан, һушына килгәч, бераз хәл җыеп ятты да берничә ел элек үз башыннан кичергән бер вакыйганы сөйләде. Шуны тыңлагач, мин аның ни өчен инде бишенче тапкыр сорау алуга түзүен, бирешмәвен һәм үлмәвен төшендем. Касыймҗан хикәятен хәтеремдә калганча тәгәл итеп сөйләп бирермен дип уйлыйм.

«...Мин инде тауларда бишенче көн адашып йөри идем. Беркайчан да яшеллек күрмәгән, кояш көйдереп бетергән бу шәрә тау тезмәләренең бер дә чиге күренми иде. Суны инде әйткән дә юк, теш арасына салырлык үсемлек тамыры да табып булмый.

Һәр сәгать саен хәлемнең бетә баруын сизәм. Колакларым шаулый, буш ашказаным җыерылып, калак сөякләрем чәнчешә. Шуның өстенә тагын суыта төште. Сырган куртка һәм чалбарым теткәләнеп, сәләмәгә әйләнгән, башымдагы җиңел кәләпүшем бөтенләй диярлек җылытмый. Ахыр чиктә мин, тәмам хәлдән таеп, бер яссы таш өстенә аудым. Кемнеңдер оста куллары махсус шомарткан кебек күренгән ул таш кояш нурларында ялтырап, үзе яктылык чыганагына әверелгән сыман иде. Йомшак булып тоелганга анда яту рәхәт иде. Мин беравыкка арыганлыгымны да, ачыкканлыгымны да оныттым. Кинәт минем өстә — зәңгәр күктә күгәрчен өере күренде. Алар парлашып әйлән-бәйлән уйнаган күк бөтереләләр иде.

«Әнә ул тормыш. Нинди матур! Ә мин җан бирәчәкмен...» Шунда ук башыма килгән уйны куып, үз-үземә боердым: «Тор, Касыймҗан, бар, су эзлә, кешеләрне эзлә! Яшәү өчен ахыргача көрәш!» — дидем.

Тамагым кибеп, тәкерегем беткәнгә, телем бүрәнә кебек авыр әйләнә иде. Тордым. Күз алларым караңгыланып, башым әйләнә башлады. Киселгән агач кебек авып китәр хәлдә, арыганлыкны, әлсерәвемне җиңеп, алпан-тилпән алга атладым. Курткамны чишеп җибәрдем — күкрәгем ут кебек яна иде...

Шулай утыз метрлап җир киткәч, мин абындым да яңадан әлеге таш янына шуып төштем. Күпмедер вакыт хәрәкәтсез йөзтүбән яттым. Аннары зур тырышлык белән чалкан әйләндем һәм тагын күктәге күгәрченнәрне күрдем. Хәзер алар күбрәк булып, нәрсәдәндер хәвефләнгән сыман тәртипсез бөтереләләр иде.

«Лачын сунарга чыккандыр, күрәсең, — дип уйладым мин күгәрченнәр өстендә, биектә очкан ерткыч кошны күреп. — Их, лачын корбаны булган кошларның берсе монда егылып төшсә икән!»

Кинәт күкрәгемә нәрсәдер бик каты бәрелеп, мине аркага екты. Шундук кычкырып җибәрдем һәм, бөтенләй ачлык, арыганлык җәфаламаган кеше төсле, көтелмәгән бер җитезлек белән курткам итәген каплап алдым.

Минем кайчандыр лачын тарафыннан эзәрлекләнгән күгәрчен үзенең җанын кешегә ышанып тапшырырга мөмкин дип ишеткәнем бар иде. Кулымны куеныма тыккач, шул кошның йомшак гәүдәсенә орындым. Аның нәни йөрәгенең тибеше дә ишетелә иде. Комсыз карашымны калтыраган кошка төбәп: «Нәрсә эшләргә соң?» дип уйладым. Ничек кенә ачыккан, хәлдән тайган булсам да, уйлану һәм фикер йөртү сәләтем югалмаган иде әле. Кошны күкрәгемә кысып, мин тагын: «Тормыш катлаулы нәрсә! Кыргый күгәрчен үзенә котылыр урын эзләп кешегә сыена, аның куенына кереп кача, ә мин, кеше, җанымны саклап калыр өчен аны үтерергә тиеш... Ул чакта мин кеше буламмы соң? Әллә инде ерткычка ук әйләндем микән?» дип икеләнә башладым.

Үз-үземне көчкә тыеп торам. Менә хәзер үк кошның муенын борып, тешләремне аның йомшак итенә батырырга әзермен. Аннары икеләнүемне җиңеп, үз-үземә: «Тукта! Кеше булуыңны исеңдә тот!» — дим.

Шул вакыт, нигәдер, бала чагымда әтиемнән ишеткән бер гыйбрәтле хикәя исемә төште. Мондый хәлдә хатирәләргә чумуым бәлки сәер дә тоелыр, әмма булганны булмады дип әйтә алмыйм...

«Улым, — дигән иде әтием, — кеше үзенең акылы аркасында гына кеше дип атала. Акыл — табигатьнең бөек бүләге. Беркайчан да башыңны югалтма, улым. Менә мин сөйләгәнне тыңла әле.

Бер заман бик бай сәүдәгәр яшәгән, ди. Ул Мавәрәәннәһергә юлга чыкканда һәр вакыт юлда кол сатып ала һәм хәзер без Аму-Дәрья дип атый торган Җәйхүнгә җиткәндә, аны хәнҗәр белән чәнчеп елгага ата — канечкеч Җәйхүн кәрванын йотмасын өчен, корбан бирә торган була. Җәйхүнне юкка гына «канечкеч» димиләр шул.

Бервакыт кәрван Җәйхүн ярына туктап, чираттагы корбанны бирергә җыенганда, аның белән Мавәрәәннәһергә баручы бер хикмәт иясе сатып алынган колны коткарып калырга ниятләнгән икән. Ул кәрван хуҗасыннан: «Корбан бирү мәҗбүримени?» — дип сораган. «Әйе, — дип җавап биргән кәрван хуҗасы, — югыйсә, без елганы кичә алмаячакбыз». Ул инде бәхетсезнең бугазын кисәр өчен хәнҗәрен кайрый икән. «Корбан булып нәрсәсе санала соң — тәнеме, канымы?» — дип төпченә икән хикмәт иясе.— Берничә тамчы канны гына агызып, җанын саклап калырга да була ич...» Шул сүзләрне әйтеп, ул колны су буена алып килгән һәм аның бармагын кисеп

берничә тамчы канын Җәйхүн дулкыннарына тамызган. Дулкыннар шунда ук юашланып, тынып киткән, мескен кол исән калган...»

Мин менә шушы вакыйганы хәтерләгәч, үземә нишләү кирәклеген белә идем инде... Күгәрченнең озын каурыен йолкып алдым да аның ачык күзәнәкләреннән кан тамчыларын суырдым. Авызым юешләнеп, тамак кибүем бетеп китте. Шуннан соң мин күгәрченне һавага чөйдем. Ул шундук очып китмәде, әлбәттә, башта салмак кына түбән төште, калтыранып канат кага-кага, җирдә сикеренде, аннары гына биеккә таба омтылды һәм күккә менеп күздән югалды...

Әллә үземне-үзем ышандырдым, әллә берничә тамчы кан миңа чынлап та шифалы тәэсир итте — тәнемдә көч артуын сизеп, таштан торып киттем.

Тауларда сирәк очрый торган үләнне эзләп йөрүче өч карт очрап, якындагы авылга бара торган юлны күрсәттеләр, су эчерделәр, ашаттылар. Менә шулай мин исән калдым...»

Касыймҗан сорау алулар арасында безгә менә шушы тарихны сөйләде. Гоминданчылар аны җәзалап, җәфалап бетерделәр, тик минем ышануымча, ул коточкыч газаплауларга дучар булганда да кешелеген югалтмаган, дусларын сатмагандыр, коткаруны сорап, җәлладларга ялынмагандыр...

## Кем гаепле?

Миңа унбиш яшь иде. Базар буйлап барганда бер юан кешенең унике яшьләрдәге малайны кыйнавын күрдем. Малай ябык, гәүдәсе әйтерсең үтә күренмәле, шундый юка! Ә аны җәзалаучы кеше — киресенчә, куе кара сакаллы, тәк баскан юан беләкле, алып кадәр ир. Малайның авызыннан кан агып чыккан, ир кеше исә һаман корбанны дөмбәсли...

Ниндидер бер хатын җыелган халыкка, җаны әрнеп:

— Нишләп коткармыйча карап торасыз? Мескен бала атасына нинди начарлык эшләгәндер дип беләсез? — дип кычкырды.

— Ул аның атасы түгел лә,— дип җавап бирде кемдер битараф кына.

— Алайса, кеше баласын кыйнарга аның ни хакы бар?

— Малай гаепле, сәүдәгәрнең кавынын урлаган. Аңа бу да әз әле, караклыгы өчен колагын өзәргә кирәк.

Утыз еллап вакыт узды... Кичә урамнан кайтканда мин бөтенләй төрле күренешкә юлыктым. Яшь егет, хунвейбин, бер кулы белән алтмыш яшьлек картның якасыннан эләктергән, икенчесе белән кизәнә-кизәнә йөзенә ора. Карт дерелди, сакаллары тузгыган, тавыштыны чыгарлык рәте дә калмаган, суккан саен сөер генә ыңгыраша.

Шул тирәгә бер төркем халык җыелган. Алар картның нинди җинаять эшләгәнен әйтә алмадылар. Теге гоминдан заманнарындагы кебек, башбаштаклык корбанын бу юлы да якларга җөрьәт итүче күренми иде...

Уйгырчадан ТӘУФИКЪ ӘЙДИ тәрҗемәсе.

# ПАРТИЯНЕҢ XXV СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

## КАМАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**ДЕКАБРЬ, 1974 ЕЛ**

КамАЗда декабрь удар ай итеп игълан ителде. Төзүчеләр, монтажчылар эш темпын арттырганнан-арттыра баралар.

Узган ел Кама буендагы зур төзелеш өчен чыннан да гомуми уңышларны билгеләүче ел булды. Июль аенда автогигантның беренче карлыгачын — ремонт-инструменталь заводын Дәүләт комиссиясе эксплуатациягә кабул итте. Сентябрь аенда тимерчелек производствосы корпусларында технологик җиһазларны монтажлауга керештеләр. Октябрьда КамАЗ ТЭЦында өченче энергоблок эшли башлады. Бөек Октябрьның 57 еллыгы алдыннан пресс-рам производствосында беренче пресслар куелды.

Төзүчеләр һәм монтажчылар хәзер яңа этапка аяк бастылар — җыю производствосында төп конвейерны монтажлау башланды. Бу мактаулы хокукны социалистик ярышта СССР Махсус төзелеш һәм монтаж министрлыгына караган специальләштерелгән 7 нче тресттагы Чаллы монтаж идарәсенең В. А. Осипенко бригадасы яулап алды. Төзүчеләр арасында «Автозаводстрой» идарәсенең Ю. И. Лазарев җитәкчелегендәге балта осталары-бетончылар бригадасы яхшы эш үрнәкләре күрсәтте.

Автомобиль комплексының җыю производствосында уннарча төрле конвейерлар эшләячәк. Ә монысы иң зуры булачак: бер тасмасының гына да озынлыгы — 673 метр, авырлыгы — 1 мең 100 тонна, куәте — елга 75 мең автомобиль. Аннан икенче линия сафка басачак.

Конвейер фәннең һәм техниканың соңгы казанышларына таянып конструкцияләнгән. Автомобильләрнең авыр узелларын һәм агрегатларын эш урыннарына автоматлар китерәчәк, шуның нәтиҗәсендә бер үк вакытта төрлесе-төрле сигез модификацияле йөк машиналарын җыярга мөмкин булачак.

**«Правда», Мәскәү.**

КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Л. И. Брежнев Франциягә килер алдыннан Париж газеталары Советлар Союзы белән Франция арасындагы экономик элемтәләрнең үсеш перспективаларын һәрьяклап яктырттылар, президент В. Жискар д' Эстэнның Франциянe Европадагы социалистик илләрнең мөһим экономик партнерына әверелдерергә исәпләвен билгеләп үттеләр. «ЭКО» газетасы Л. И. Брежневның Франциягә килүе «ике халык арасында үзара дуслык һәм ризалашу интересларына хезмәт итәр» дип ышаныч белдерә.

— Безнең фирма,— ди «Рено» милли автомобиль кампаниясенең президенты һәм генераль директоры Пьер Дрейфюс, — социалистик илләр, беренче чиратта Советлар Союзы белән күптән инде үзара файдалы элемтә урнаштырды. Без, әлеш-чә, әлбәттә, «Москвич» эшләнеп чыга торган заводларны үзгәртеп коруга катнаштык, ә хәзер КамАЗ төзелешенә катнашабыз. Безнең Сандувилл заводларында Советлар Союзында ясалган пресслар эшли. 1971 елда мин Фләнда Брежнев әфәндене сәламләү бәхетенә ирештем. Аның тагын да Франциягә килүе совет-француз экономик хезмәттәшлеген киңәйтергә һәм ныгытырга ярдәм итәр дип ышанам.

**«Социалистическая индустрия» газетасының Париждагы хәбәрчесе хәбәреннән.**

Чаллыдан ерак түгел Яңа Зәй эшчеләр поселогында КамАЗ автомобильләре өчен көпчәкләр ясау заводы төзелә.

Билгеле булганча, Кама автомобиль комплексы күп кенә зур заводлардан тора. Бу заводлар җыю производствосындагы төп конвейерны узеллар һәм агрегатлар белән тәэмин итәчәк. Зәй көпчәк заводы — комплексның җиденче заводы.

**«Советская Россия», Мәскәү.**

Чаллыда Татарстандагы беренче универсам ачылу алдында.

Универсам техниканың соңгы казанышлары белән җиһазландырыла: автомат төрү аппаратлары, вакуум тасмалар, транспортерлар, куәтле суыткыч җайланмалар, селекторлы элемтә, радиоузел.

**«Комсомольская правда», Мәскәү.**

Кама автомобиль заводы конвейерлары хәрәкәткә килер көн якынлаша. Елга 150 мең йөк машинасы, 250 мең дизель моторы — заводның проект куәте шундый. Аның конвейерларыннан, 1,6 минут саен автомобиль, бер минут саен двигатель чыгып торачак.

Билгеләнгән эш ритмын автомат идарә системасы тәэмин итәчәк, ул 300 гә якын эшне башкарачак.

КамАЗ заводлары белән автомат идарә итү системасының үзенчәлеге шунда: ул КамАЗның үзе белән бергә сафка басачак.

**АПН, Мәскәү.**

Россия Федерациясендә Идел буе — иң зур зона. Ул Калинин шәһәреннән Астраханьга хәтле сузыла. Анда ундүрт Художниклар союзы гына бар. Узган унъеллыкта Идел буе художникларының дүрт күргәзмәсе булды. «Зур Идел-74» күргәзмәсе зур масштабы белән игътибарны үзенә тарта: анда 663 авторның 1575 әсәре куелган.

Күргәзмәнең девизы — «Безнең замандаш». Андагы әсәрләрдә Идел буенда бүгенге көн хезмәте: электростанцияләр, гигант заводлар коручылар, авыл кешеләре, нефтьчеләр сурәтләнә. КамАЗ төзелеше, «Красное Сормово» заводы эшчеләре, Татарстан нефтьчеләре, Чувашстанның космонавт Николаев исемендәге колхозы кешеләре художникларның игътибарын җәлеп иткән.

Күп кенә әсәрләргә образларны гомумиләштерүгә, эшче профессиясенең романтикасын калку итеп сурәтләүгә омтылыш хас. Ю. Босконың (Куйбышев) «Кыю кешеләр. Чын егетләр» әсәре, В. Скобеевның (Казан) «Камада акчарлаклар», «КамАЗ» полотнолары яктылыкны нечкә сиземләү, күтәренке рухлы булулары белән аерылып тора.

Күргәзмәдә төрле яшьтәге, төрле профессия кешеләренең портретлары белән дә танышырга мөмкин. Аларга хезмәт кешесенең иң яхшы сыйфатларын җыеп, калку итеп сурәтләргә омтылыш характерлы. В. Кудelькинның (Казан) КамАЗ монтажчысы Ганиев портреты, Р. Имашевның (Казан) «Геодезист кыз» әсәре шундыйлардан.

«Зур Идел-74» күргәзмәсе — бишенче «Совет Россиясе» күргәзмәсенә әзерлек буенча мөһим этап.

**«Правда», Мәскәү.**

Сабан туе нәрсә ул?

А. Твардовский үзенең «Василий Теркин» поэмасында бу сүзне бик ятышлы кулланган. Ул сүз инде хәзер халыкара, күп мәгънәле сүз булып йөри. Нинди генә вакыйганы «Сабан туе» дип исемләмиләр?!

Без, КамГЭС поселогыннан чыгып, Иске Чаллы аша киттек. Менә асфальт сулга борылды, аннары гади юл буйлап Камага таба атладык. Болынлыктан каршыга «Яңа шәһәр — Сабантуй» дип язылган автобус күтәрелә.

Кичә бу рейс юк иде.

Иртәгә дә ул булмаячак.

Әмма сабан туен КамАЗ кешеләре КамАЗ колачы белән бәйрәм итәләр. Кама буйлап йөзләрчә төрле машиналар тезелеп киткән, әйтерсең автобаза. Хәтта бер бульдозер да бар. Аны да транспорт итеп файдаландылармы икән әллә? Әллә андый-мондый кирәге чыгар дип китерелгәнме?

Сабан туе кино да, спектакль дә, танец кичәсе дә түгел. Ул елга бер генә мәртәбә була. Шуңа күрә бүген шәһәр буп-буш — барысы да болынга чыккан.

Халыкның иге-чиге юк. Берәүләр кырык мең ди, икенчеләре йөз мең дип бәхәсләшә. Кем санап бетерсен аны?

Татарларда сабан туе — хезмәт бәйрәме, язгы кыр эшләре тәгәлләнгәч тантана итәләр аны. Ә КамАЗ сөрми дә, чәчми дә. Аның хезмәте бүтән. Әмма сабан туеның рухы, күтәренкелеге, күңеллелеге КамАЗ өчен бик ятышлы.

Бер якта егетләр бүрәнә өстеннән бер-берсен егып төшерү өчен печән тутырылган капчык белән дөмбәсләшәләр. Менә ат чабышы башлана. Ә бу якта көрәш бара. Батырга тере тәкә бирелә, диләр.

Ярышлар күп төрле, кайсысын карау кызыклырак булыр икән?..

Батырлар, җиңеп чыгучылар тиешле бүләкләрен алды, ә ярышлар әле һаман дәвам итә. Яшьләр бүләк өчен түгел, күңел өчен ярышалар. Аларга тере тәкә дә, паласлар да, бүтән төрле бүләкләр дә кирәкми, мөһиме — үз-үзеңә ышаныч хисе яулап алу.

Көрәш — мәхәббәт, юмартлык, тыйнаклык кебек үк, үзе бүләк бит ул!

«Социалистическая индустрия», Мәскәү.

«Кондиционер» заводы Кама автомобиль гигантына еллык планда билгеләнгәнгә караганда ясалма климат җайланмаларының соңгы партиясен элегрәк җибәрде. Бу агрегатларда югары басым белән һава өрдерә торган куәтле насослар кулланыла. Синтетик материаллардан ясалган фильтрлар элеккеләргә караганда ике мәртәбә чыдамлы.

Ясалма климат җайланмалары КамАЗ корпусларына сәгатенә 125 миллион кубометрга якын саф һава өрдерәчәк, һаваның тиешле дымлылыгын, температурасын автоматлар көйли.

ТАСС, Харьков.

«Юрий Павлов бригадасы корпус түбәсен ябуда заданиене өч тапкыр арттырып үтәде».

«Николай Ефтеев бригадасы еллык планны 25 ноябрьда тутырды».

Мондый сугышчан листокларны — «Молния»ләрне һәр объектта очратырга мөмкин. Төзелештә производство алдынгылары күп. Бары тик агымдагы елда гына да КамАЗдан 526 төзүче хөкүмәт бүләкләре белән бүләкләнде. Уннарча бригадалар тугызынчы бишьеллык планын үтәделәр.

Төзелешнең алгы сызыгы хәзер — яңа заводларның гигант корпусларында. Аларның күбесенә инде җылылык үткәрелде.

Декабрь аенда якынча өч йөз мең квадрат метр мәйдан монтажлауга бирeләчәк. ТЭЦның дүртенче энергоблогы, су чистарту станциясе сафка баса, 230 квадрат метр торак мәйданы, 9 мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре, берничә кибет һ. б. объектлар эксплуатациягә бирелә.

КамАЗга илебезнең төрле почмакларыннан, чит илләрдән килә торган җиһазларны монтажлый башлау төзүчеләрне эш оештыруда яңа, прогрессив методлар эзләргә этәрә. Соңгы вакытта агым методы киң таралды. Аңа барлык төр һөнәрле төзүчеләр берләшә.

«Экономическая газета», Мәскәү.

Күптән түгел Байкал — Амур магистрале белгечләреннән бер төркем КамАЗда булып китте. Тимер юл төзелешенең баш инженеры Александр Погребной очрашу вакытында болай диде:

— Беренче адымнар катлаулы. Менә без монда идарә итү системасын, эш участоклары арасында элемтә оештыру мәсьәләсен өйрәнәбез.

Иң мөһиме: КамАЗ комплекслап төзелә. Бу комплексның ике әйләнәсе бар. Берсе — Кама буенда, төзелеш мәйданында. Икенчесе — бик киң, ул төрле министрлыкларны, промышленностьның төрле тармакларын, йөзләрчә заводларны үз эченә ала.

Кама буенда заводлар комплексын салу барышы илебезнең куәтле экономик потенциалы шушындый уникаль предприятиеләрне төзергә сәләтле икәнлеген күрсәтә. Шушындый катлаулы объектлар төзелешендә производство белән идарә итү системасы камилләшә, эшнең иң яхшы методлары, техник яңалыклар тикшерелә. КамАЗ тәҗрибәсе — яңа зур объектларны корачак төзүчеләргә, монтажчыларга зур мәктәп.

«Правда», Мәскәү.

## Мәдинә Маликова

# МЕҢ ДӘ БЕР СЫНАУ

Мине башта аның һөнәре кызыктырды.

Ни генә димәсеннәр, дөньяда ирләр кулыннан гына килә торган һөнәрләр дә бар, дип саныйм. Әйтик, менә балта остасы яки корыч эретүче булу. Янсә зур самолетларның конструкторы булу. Аэродромнарда тезелеп торган мәһабәт ак самолетларга да эре кызыл хәрефләр белән ир-егетләрнең фамилияләре язылган: «Ту» — Туполев, «Як» — Яковлев, «Ил» — Ильюшин... Йөзләрчә кешеләрне бер омтылыш белән болытлардан югары күтәреп, берничә сәгать эчендә меңнәрчә чакрымнарга илтеп җиткерә торган лайнерлар төзү — бары тик тирән акыллы, нык куллы, гайрәтле ир солтаннарының гына кулыннан килә торган эш, дип уйлыйм мин.

Шуңа күрә Казан авиация институтының двигательләр төзү кафедрасында татар кызы Мәхфүзә Максутованың докторлык диссертациясе яклавы турындагы хәбәр миндә зур кызыксыну уятты. «Ниндирәк кеше икән? Андый зур уңышка ничекирешә алды икән?» дип уйладым. Хатын-кыз кешегә ирләр эшли торган өлкәләрдә уңыш казануның никадәр авыр икәнен беләбез... Ирләр арасында эшләгән хатын-кызларның кайберләре һәр яктан ир-атка охшарга тырышалар, кырысланалар, катылаңалар. Әмма андый чакта да уңыш җиңел бирелми: каттый сүзле кырыс хатыннарга ирләр эчтән көлеп карыйлар.

Гомумән, бик четерекле мәсьәлә бу. Максутова бу мәсьәләне ничегрәк хәл кылды икән?

«Ахыр чиктә фән әһелләре арасында да төрле кеше була, — дип уйладым мин. — Ихтирамга лаегы була, очраклы рәвештә генә уңышка ирешкәннәре дә бар. Дөнья бу! Бәлки әле ул күтәреп мактарлык галим дә түгелдер».

Шулай кызыксынып һәм бераз шикләнеп, мин Максутова белән танышырга булдым. Телефоннан эзләп таптым. Ягымлы яңгыравык тавыш җавап бирде. Без институтның ишек төбендә очрашырга сүз куештык.

Нәкъ билгеләнгән минутта мине озын буйлы, нык гәүдәле, аксыл чәчләрен баш артына өеп куйган түгәрәк йөзле хатын-кыз каршы алды. Аның салмак, төгәл хәрәкәтләреннән, башын югары тотышыннан үз дәрәҗәсен белү, горурлык сизелә, ә якты күзләреннән татар хатыннарына хас тыйнаклык бөркелә иде.

Кабинетка кереп утыруга, ул беренче сүз итеп:

— Сез юкка минем белән кызыксынасыз,— диде.— Мин гап-гади кеше. Газет-журнал битләрендә урын алырга лаеклырак кешеләр күп иң.

Аның тавышы кечкенә кабинетта шактый каты яңгырады. Ул журналист халкын гомумән өнәп бетермәгәнен дә сиздереп куйды. Мин бераз аптырап киттем: бу ни дигән сүз? Кайбер хатын-кызларга хас кыланчыклыкмы, тыйнаклыкмы, әллә чыннан да галимнәр арасында тотып алып мактарлык кеше түгелме ул?

Ярый, дидем үз-үземә, фәндә нинди ачышлар ясаган икән, шуны белеп карыйк әле.

## Чишмә башы

Кайберәүләр самолетны диңгез белән чагыштыралар. Беренче карашка бу чагыштыру сәер тоелса да, анда зур хакыйкать бар: диңгез бик күп елгаларның, хисапсыз чишмәләрнең суын үзенә җыйган кебек, самолет та күп коллективларның, йөзләрчә һәм меңнәрчә кешеләрнең иҗат һәм хезмәт җимеше буларак туа. Берәүләр очкычның канатын, икенчеләр фюзеляжын проектлаштыра, өченчеләре идарә системасын, дүртенчеләре ягулыгын яхшырту өстендә эшли... Мәхфүзә Максутова двигательләрнең куәтен арттыру өлкәсендә эшләүче галимнәрнең берсе.

Максутова кандидатлык диссертациясен дә, докторлык диссертациясен дә турбиналарның характеристикасы буенча яклаган. Турбиналар күп төрле — «егермеләп» диделәр миңа институтта. Һәркайсының төзелеше үзенчә. Максутова шул турбиналарның эчендә төрле шартларда, төрле эш режимнарында барган процессларны өйрәнә, аларны төзегәндә куллану өчен төгәл хисаплау формулаларын булдыру өстендә эшли. Әлбәттә, бер ялгызы түгел, шәкертләре белән. Аның кул астындагы биш кеше кандидатлык диссертациясен яклаганнар инде. Максутованың хезмәтләре моторларның куәтен арттыруга, ягулык расходын киметүгә юнәлтелгән. Алар кимрәк ягулык тотып ераккарак оча торган самолетлар төзергә мөмкинлек бирәләр. Килер бер көн, бер алган ягулык белән җир шарын әйләнеп чыгарлык очкычлар төзелер, бу уңышта Максутованың да өлеше булыр.

Бүгенге көндә Мәхфүзә Кәримовнаның калькаларында безне тагын да югарырак күтәрәчәк, тиз араларда тагын да ераккарак илтәчәк очкычларның йөрәк тибешен тасвирлаган сызымнар туа. Аның бүгенге хезмәтләре — киләчәктә диңгез булып җыелачак чишмәләрнең бер чыганагы.

Шунысы да бар: чишмәләрнең суы тамчысына кадәр диңгезгә коймый, бер өлеше дым булып күтәрелә дә болытларга кушыла, күпмедер кадәресе кырлар-бакчаларны сугара. Фән казанышлары да шулай ук төрле өлкәләрнең үсүенә илтә. Максутова хезмәтләренең әһәмияте самолет моторларын яхшырту белән генә чикләнми. Турбиналы двигательләр хәзерге зур корабларны йөртә, алар җылылык бирүче электр станцияләренә дә куела, аларны автомобильләргә кую мәсьәләсе дә көн тәртибенә килеп басты. Хәтта ракеталарга да Максутова хезмәтләренең кагылышы бар.

Гомумән, ил күләмендә турбинистларның саны чагыштырмача күп түгел икән. Шуңа күрә алар төрле шәһәрләрдә эшләүче коллегаларының уңышлары белән һәр вакыт кызыксынып торалар. Мисалга, Максутованың оппонентларыннан берсе Хәрби академия укытучысы, профессор, контр-адмирал Жаров булган.

Гаҗәп тә кызыклы, катлаулы һәм бүгенге көн өчен бик әһәмиятле икән Максутованың һөнәре.

Кайчандыр Ньютонның маңгаена алма килеп төшкән дә, ул шунда маңгаен уып, җисемнәрнең бер-берсенә тартылуы турындагы законны ачкан, дип сөйлиләр. Хәзерге заманда башына алма төшкән саен бөек ачышлар ясаучылар юк. Бу хәл фән үскән саен ачышлар ясауның, табигать серләренә тагын да тирәнрәк керүнең авырлашуы турында сөйли. Хәзерге заман галиме, нинди генә даһи булмасын, бер ялгызы зур ачышлар ясап дөньяны шаккаттыра алмый. Чөнки фәнни тикшеренүләрне бары тик катлаулы аппаратлар, приборлар ярдәмендә тулы коллективлар гына алып бара ала.

Маңгаена алма төшкән саен ачыш ясый торган галимнәрнең кешелек сыйфатлары, холкы-фигыле фән өчен, тарих өчен бик үк мөһим дә булмагандыр бәлки. Алар ялгыз эшләгәннәр, башкаларның язмышы аларның кәефенә бәйле булмаган.

Ләкин бүгенге галимгә — коллективта эшләүчегә, җитәкчегә, шәкертләр тәрбияләүчегә — кешелек сыйфатлары бик кирәк. Чөнки күп нәрсә аның талантына гына түгел, кешеләрне оештыру сәләтенә, аларның күңеленә ачкыч таба белүенә, башкаларга мөнәсәбәтенә, аларны эшкә рухландыра белүенә бәйле.

Бу җәһәттән Максутованың галимнәр арасында тоткан урыны нindирәк? Абруе нинди?

Мин бу турыда аның җитәкчеләре, шәкертләре, хезмәттәшләре белән сөйләштем. Әйтергә кирәк, Мәхфүзә Кәримовна турында сүз чыккач, галимнәр күзгә туры карап җитди сөйләшәләр. Институтның фәнни эшләр буенча проректоры, профессор Марат Вахитов:

— Мәхфүзә Кәримовнаның авторитеты зур, — диде һәм сүзен раслап түбәндәге дәлилләрне китерде: Максутова институтның иҗтимагый эшләрендә актив катнаша. Ул берничә ел моторлар төзү факультетының деканы булган, ТАССР Верховный Советының ике чакырылышына депутат итеп сайланган хезмәттәшебез.

Двигательләр төзү кафедрасы мөдире, профессор Виктор Иосифович Локай:

— Сез аны күпме генә мактасагыз да, мактап бетерә алмаячаксыз. Без аны фән эшлеклесе буларак та, иптәш, дус буларак та, мөлаем хатын-кыз буларак та ихтирам итәбез. Сәләтле тикшерүче, тырыш һәм таләпчән ул. Аның белән эшләгәндә җаның тыныч, чөнки беләсең: ул беркайчан да артыңнан сүз сөйләп йөрмәс, уйлаганын күзеңә карап әйтер. Шул ук вакытта гаҗәп сак һәм сизгер кеше ул. Кешеләр алдында гына түгел, үз вөҗданы каршында да намусы пакь аның, чөнки гомере буе дөрес юлдан барды, дөрес яшәде.

Г. С. Җирицкий, В. И. Локай, М. К. Максутова, В. А. Стрункиннар язган «Очу аппаратлары двигательләренең газлы турбиналары» исемле дәреслек буенча бүгенге көндә бөтен ил студентлары укый. Максутова — двигательләр төзү буенча КАИда чыга торган фәнни хезмәтләрнең дә җаваплы редакторы икән.

Доцент Виктория Николаевна Занадворова:

— Без Мәхфүзә Кәримовна белән егерме ел бергә эшлибез, — диде. — Мин аның көченә дә, зиһененә дә сокланып туймыйм. Ул тикшеренү нәтиҗәләреннән иң мөһимен, иң кирәклесен тотып ала белә, дөнья кадәр катлаулы формулаларны хәтерендә саклый. Аның янында тик утыру, яисә юк-бар белән шөгыльләнү мөмкин түгел, ул тирә-юнендәге бөтен кешене эш белән мавыктыра белә. Ул бит, кая, диссертация яклыйм әле, дәрәҗәгә ирешим әле, дан казаныйм, дип тырышмады, фән үсеше өчен тырышты, башка-

ларны да шуңа өйрәтте. Аның докторлык диссертациясе дә егерме еллык фәнни хезмәтләренең табигый бер нәтиҗәсе булып килеп чыкты.

Виктория Николаевна миңа вузда фәнни-тикшеренү эшләре алып баруның үзенчәлекләрен аңлатып бирде. Вузның төп бурычы — студентлар укыту, шуңа күрә биредә фәнни-тикшеренү эшләренә мөмкинлекләр, махсус институтлар белән чагыштырганда, кимрәк. Әйтик, лабораториядәге турбиналар да аларга бушка гына бирелмәгән. Аларны алу өчен, Максутова группасы завод белән хуҗалык договоры төзегән, заводның заказын үтәп, тикшерүләр үткәргән. Тикшерүләр өчен кирәкле җиһазларны, бу очракта турбиналарны, завод биргән, соңыннан, договорда каралган эшләр тәмамлангач, турбиналар институтта калган. Бары шуннан соң гына галимнәр, ул турбиналарны кирәгенчә үзгәртеп, үзләренә кирәкле тикшеренүләрне үткәрергә мөмкинлек алганнар.

Заводлар белән мондый мөнәсәбәт урнаштыру да җиңел эш түгел, диделәр миңа. Моның өчен заводлар алдында галим буларак абруең югары булу кирәк. Ә Максутованы беләләр, аңа ышаналар.

Мин ул лабораториядә булдым, турбиналарны миңа уннан бер куәтенә генә эшләтеп күрсәттеләр. Тавыш шул кадәр көчле — янында торган кеше белән сөйләшерлек түгел. «Менә ни өчен Максутова кычкырыбрак сөйләшә икән, ул шушы тавышта сәгатьләр буе утырырга күнеккән бит!» дип уйладым.

Мәхфүзә Кәримовнаның шәкерте, техник фәннәр кандидаты Геннадий Вавилов:

— Төрле чак була, кайчак бернинди нәтиҗәгә ирешә алмый айлар буе азапланасың, төшенкелеккә биреләсең, өметсезләнәсең,— диде. — Андый чакларда Мәхфүзә Кәримовна белән бер сөйләшсәң, җаннар тынычланып, күңел күтәрелеп китә. Шундый кеше ул.

Вавилов минем турбиналарга тоташкан торбаларга, изометрик үлчәү щитларына шаккатып карап торганымны күрде дә:

— Хәйран калырлык нәрсә юк,— дип куйды.— Гап-гади хезмәт. Берәүләр заводта эшли, без — монда. Бары шул гына.

Аның бу сүзләре Мәхфүзә Кәримовнаның: «Макталырга лаеклырак кешеләр дә күп», — дигәнен исемә төшерде. Мин аның хезмәте белән кызыксынып килгән идем бит. Ә алар үз эшләрен бик мөһим, ләкин гадәти хезмәт дип санаййлар, һөнәрләре белән масаймыйлар. Кылану да, ясалма тыйнаклык та түгел, бары тик үз эшләренә аек, җитди караш бу.

Күп кешеләр белән сөйләшкәч, эшен тирәнрәк аңлагач, миндә дә Мәхфүзә Кәримовнага карата соклану хисе туды. «Мондый кеше бала чактан ук бик яхшы тәрбия алган, яшьтән галимнәр белән аралашкан булырга тиеш», дип уйладым.

## Фәнгә илтә торган сукмаклар

Чын укымышлы булу өчен кимендә өч буын кешеләре университет тәмамлаган булырга тиеш, диләр: бабаң тәмамлаган булсын, атаң тәмамлаган булсын, үзең тәмамла.

Ярым шаярып әйтелгән бу сүзләрдә күпмедер дәрәҗәдә дөреслек тә бар. Чын галим булу өчен зур белем алу гына җитми әле. Чын галим булу өчен кешенең күз күреме киң, фикере тирән булырга тиеш, ул тормышның мең ваклыгыннан олы бер мәсьәләне тотып ала белергә тиеш. Бу сыйфатлар интеллигент гаиләсендә, укымышлы кешеләр арасында җиңелрәк тәрбияләнә, чөнки балага ана сөте белән диярлек керә.

Ләкин Мәхфүзә үскән елларда галимнәрнең алай озаклап, берничә буын гомере эчендә тәрбияләнүен көтеп торырга мөмкинлек булмады. Илебез алга таба гигант сикереш ясаган чорда гади кешеләр арасыннан чыккан, халыкка тугрылыклы галимнәр, бик күп фән эшлеклеләре кирәк булды. Мәхфүзә Кәримовна — гади халык арасыннан фән дөньясына килгән күпләрнең берсе.

Ул Ленинградта хезмәткәр гаиләсендә туган, җиде яшендә атасыз калган. Аның әнисе, гаилә башлыгын җирләгәч, Казанга, туганнары янына кайткан, техник секретарь булып, кассир булып эшләгән. Алар туган-тумачалары белән зур гаилә булып, унөч-ундүрт җан бергә яшәгәннәр. Мәхфүзәне бала чактан фән өлкәсенә әзерләүче, даһилыкка этәрүче булмаган. Бары шуны гына әйтергә мөмкин: зур семьяда студентлар күп булган. Бәлки шулар белән аралашу аңарда белемгә омтылыш тудыргандыр.

Мәктәптә дә Мәхфүзә башкаларга һәр яктан үрнәк итеп куярлык укучы булмаган. «Шаян идем,— дип сөйли ул үзе,— күрәсең, шактый ук тәрбиясез булганмын. Әти күзе юк иде бит. Минемчә, әтисез калган гаиләләрдә балалар һәрьяклап дөрес тәрбия ала алмыйлар. Кайчакларда әнием, тагын синең аркаңда ачуланырлар инде, дип, мәктәпкә барырга куркып тора иде».

Ләкин ике укытучы — математика белән әдәбият укытучылары — кызны яратканнар, башкаларга үрнәк итеп куя торган булганнар. Ул, гомумән, бу ике фән арасында зур уртаклык таба, «Математиканы яраткан кеше әдәбиятны яратмый калмый»,— ди. Әдәбиятны яратуы Мәхфүзәнең, зирәк акыллы булуы өстенә, күңеле нечкә, хисләре тирән булуы турында сөйли. Күрәсең, аның шәхесе формалашуда әдәбият бик зур роль уйнагандыр.

Һәр шәхес бик күп шартларның тәэсире, төрле кешеләрнең йогынтысы нигезендә үсә. Әгәр дә без бу шәхесне тәрбияләгән кешеләрне атап чыгарга теләсәк, шактый зур исемлек төзергә туры килер иде: әнисе Мөршидә апа, туганнары, иптәшләре, ниһаять, исемнәре бөтен илгә шаулаган, Мәхфүзә белән очрашмасалар да, аның хыялына, омтылышларына кереп урнашкан кешеләр — Папанин, Чкалов, Марина Раскова...

Утызынчы еллар яшьләренең идеалына әверелгән бу батыр очучылар Мәхфүзә күңелендә дә зур урын алганнар. Күпләр шикелле ул да, канатлы машиналарны иярләп, күз күрмәгән ерак илләргә барып җитү, боз диңгезләрен кичү турында хыялланган.

Шушы хыял, шушы омтылыш Мәхфүзәне авиация институтына китергән дә.

1940 елны авиация институтының яңа гына ачылган моторлар төзү факультетына укырга кергәндә, Мәхфүзә үзенең булачак һөнәрен шактый томанлы итеп күз алдына китергән. Мәктәптә укыганда ул ерак очышлар турында хыялланган булса, булачак һөнәре аны аудиторияләрдә лекцияләр укырга, сызымнар, формулалар өстендә утырырга, институт подвалындагы лабораторияләрдә турбиналар белән бихисап тикшеренүләр үткәрергә мәҗбүр иткән.

Үз юлын тапканмы ул? Бу сорауга Мәхфүзә Кәримова үзе дә анык кына җавап бирә алмый, һәрхәлдә, аның турында артык баш ватмый. Һөнәрен яшьлек хыяллары белән тәңгәл китереп карасаң, «ялгышкан бу» дияргә була. Фәндә ирешкән уңышларын күздән кичерсәң, «Бу кеше тормышта нәкъ үз урынын тапкан»,— дияргә кала. Аның холкы-табигате белән ныклап танышкач, «Ул кайда гына эшләсә дә, зур уңышка ирешә алган булыр иде, шундый ук авторитет казаныр иде», дигән фикергә киләсең.

Мин бу сорауны очраклы рәвештә генә куймадым. Фәндә уңыш казану кешене тулы бәхетле дип санарга нигез бирми әле. Тормыш катлаулы. Хезмәтендә күпмедер дәрәҗәгә ирешкән кешеләрнең дә үзен бәхетсез хис итүе мөмкин. Бар андыйлар, галимнәр арасында да бар.

Язмыш Мәхфүзәнең башыннан сыйпап кына тормаган. Сабый чактан атасыз калган ул, яшьлек чорында сугыш китергән авырлыкларны кичергән. Кешедән ким кичермәгән... Башка бик күп хатын-кызларны ялгыз калдырган бу афәт аны да аямаган, аның да яшьлек дусты яудан кайтмаган. Ул беренче мәхәббәтенә тугрылыклы булып калган, гомер юлын кичәр өчен башка ярлар сайламаган. «Югыйсә, гаҗәп сөйкемле иде, шат күңелле иде, әгәр теләсә, үзенә тиңне тапкан булыр иде», — диләр аның турында. Күз өстендә каш кебек күренекле, мөлаем хатын-кыз ялгыз булса, өстәвенә, ул ир-ат арасында эшләсә, аның турында хагы да, нахагы да күп сөйләнә. Әмма Мәхфүзә турында беркайчан да гайбәт сүзе йөрмәгән.

Ул чор кызларыннан ялгыз калучылар күп иде, арада, сыңар канатлы икәнлекләрен бер генә минутка да онытa алмыйча, аһ-зар белән гомер кичерүчеләр дә шактый. Кызганыч алар, әмма нихәл итәсең...

Ә минә Мәхфүзә Кәримовнага карата кызгану хисе уянмый. Аның янында булганда, ничектер, югарырак күтәреләсе, зур, мөһим, күңелле нәрсәләр турында уйлыйсы килә. Чөнки киң карашлы, олы фикерле кеше янында икәнеңне тоеп торасың.

Ул үз өлкәсендә моңарчы беркем тапмаган юл-сукмакларны ярырга алынган, аңарчы беркем төшенә алмаган серләрне ачарга омтылган. Ул үзе теләп җилкәсенә алган бу җаваплылыкның авырлыгын да, уңышсызлыкларның ачысын да шактый күп тойган. Шул ук вакытта шатлыкларның иң зурысын татыган, иҗади хезмәт китергән җимешнең тәмен белеп чиксез куанган чаклары да күп булган. Мин аның ачышларын монда китерә алмыйм, аларны шул өлкәдә эшләүчеләр генә тулысынча аңлый ала. Ләкин минә шушы ике дистә ел эчендә булган үзгәрешләргә күз салыйк әле. Бернинди тукталышсыз океаннар кичә торган гигант самолетлар барлыкка килде. Беркайда туктамыйча, айлар буе юлда булып, меңнәрчә тонна йөкләрне җир шарының иң ерак портларына илтә алырлык кораблар төзелде. Ниһаять, куәтле ракеталар кешене космоска чыгарды.

Фән казанышлары бер бина, бер гүзәл сарай кебек үсә, аңа бик күпләр кирпеч сала. Соңгы елларда бу өлкәдә ирешелгән уңышларда Максутованың да өлеше бар, фән сараена аның да кирпечләре куелган. Ул үзе китергән һәр кирпечкә исемен язып калдыру турында кайгыртмый, ләкин шушы бөек казанышларда өлеше барын тою аның тормышына зур мәгънә бирә, аның кешелек дәрәҗәсен күтәрә.

Ул күп нәрсәләр белән кызыксына, әдәбияттан да, сәнгатьтән дә тәм таба белә. Аның шәхси китапханәсендәге театрга багышланган китаплар гына да кайбер режиссерларны кызыктырырлык. Мәхфүзә Кәримовна бакча үстерә, тәмле бәлешләр пешереп, әнисе белән каракаршы утырып чәй эчәргә ярата, матур кием-салымның, бизәнү әйберләренең кадерен белә.

— Хатын-кыз йомшак, сөйкемле булырга тиеш,— ди ул.— Аны йомшак табигатьле булу бизи.

— Ләкин сез үзегез йомшак түгелдер әле, — дип каршы төштем мин. — Сез ирләр белән бер дәрәҗәдә нык итеп сөйләшә белергә тиеш. Андый җирдә сүзең үтсен өчен егет кеше булырга кирәк, һәм сез шундый.

— Әгәр алай икән, димәк, мин начар хатын-кыз! — Аннары бераз уйланып торды да: — Хатын-кыз үзенең йомшаклыгы белән көчле ул, — дип өстәде. — Әйтик, ирләр ничаклы гына кызсалар да, тавышлары калтырар дәрәҗәгә җитсә дә, хатын-кыз алдында тупас сүз ычкындыра алмыйлар, тыелырга, ипле итеп сөйләшергә мәҗбүр булалар. Хатын-кыз ирләр коллективын артык кырысланудан, күңел катылыгыннан саклап кала ала.

Мин аның белән килешми булдыра алмадым.

Әгәр дә кеше, мин хезмәт юлында кулымнан килгәннең барын да эшләдем, иҗатта талантым мөмкинлек биргән барча үрләрне яуладым, матурлыкның кадерен белдем, намусымны керсез сакладым, кешеләргә яхшылык эшләп куандым, дип әйтә ала икән, минемчә, ул кеше үзен, һичшиксез, бәхетле дип санарга тиеш.

## Фәнгә кемнәр кирәк?

Кемнәр килә фәнгә? Институт укытучысы буларак, галим буларак, Максутова бу мәсьәлә белән бик нык кызыксына. Хәзерге заман яшьләрендә фәнгә омтылыш зур. Ләкин кайберәүләр бу өлкәдә эшләүнең үзенчәлекләрен аңлап бетермиләр.

Максутова белән танышканнан соң, мин фәннең, беренче чиратта, кешедән зур хезмәт таләп иткәнен һәм һәр вакытта да дан китермәгәнен тагын бер кат аңладым.

— Фән эшлеклесе, беренче чиратта, нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

Бу сорауга Мәхфүзә Кәримовна һич тә уйлап тормыйча:

— Эш сөю һәм кешелеклелек, — дип җавап бирде.

Мин мондый җавап көтмәгән идем.

— Ә талант? — дип сорадым.

— Талант, сәләт мәсьәләсенә минем үз карашым бар. Минемчә, бөтенләй сәләтсез кеше булмый, һәркем нәрсәгә дә булса сәләтле. Һәм ул, аңласа, аңламаса да, үз күңеле тарткан, үз кулыннан килгән хезмәткә омтыла. Калганын инде тырышлык, эш сөю хәл итә.

Чыннан да, хәзерге вакытта фәнне алга этәрүче төп эшне даһилар түгел, нәкъ менә тырыш, сәләтле кешеләр башкара да бит инде.

Мин Мәхфүзә Кәримовна кебекләрнең күбрәк булуын теләр идем. Ләкин кеше кешегә бөтен яклап та охшаш булып бетә алмый. Шуңа күрә мин аны ихтирамга лаек галим иткән төп сыйфатларны аерып атарга телим.

Димәк, иң мөһиме — эш сөю. Фәнгә мөнәсәбәте булган һәркем белә: кайчак бик озак тикшеренүләр үткәргәннән соң да кинәт маңгаең белән таш кыяга килеп бәрелгәндәй буласың. Кире чигенергә, яңа юнәлеш табып, өр-яңадан юл салырга кирәк. Мең сынауны үткәннән соң мең дә беренчесен башларга туры килә.

Эдисон электр лампочкаларының җепселләрен нинди материалдан эшләргә белми гаҗиз булган, диләр. Ул, шәкерте белән икәүләп, алты йөздән артык төрле җепсел куеп, лампочка ясап караган — барысы да янып чыга икән. «Никадәр хезмәтебез бушка китте бит!» — дигән галимнең шәкерте, ниһаять, өметсезлеккә бирелеп. «Юк, — дигән аңа Эдисон, — без алты йөз туксан алты мәртәбә бик тә кирәк эш башкардык. Хәзер башка берәүгә дә ул материалларны сынап карарга кирәк булмас, хәзер кирәклесенә юлыгу ансатрак булыр».

Төшенкелеккә, өметсезлеккә бирелгәндә дә, Мәхфүзә Кәримовна башкаларны юатырга көч таба. Анда да һәркайсының җаен белә: бе-

рәүләр белән шаярып сөйләшә, икенчеләренең хәленә керә, өченчеләрен шелтәли.

— Мәхфүзә Кәримовна! Ничек шулай каты әйтә аласыз? Болай да күземә ак-кара күренмәгән чак лабаса!

— Ә мин синең үз-үзеңне кызганып утыруыңны теләмим.

Әйе, шулай, фәндә үз-үзеңне кызганмый эшли белергә кирәк.

Инде хәзер Максутова атаган икенче сыйфатка — кешеләрне яратуга килик. Мәхфүзә Кәримовнаның кешеләр турында кайгыртучанлыгы институтта дан булып йөри икән. Бер мисал. Кырык беренче елны студентларны урман кисәргә җибәргәннәр. Аларга бик авыр шартларда эшләргә туры килгән. Чатлама суыкларда бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы агач аударалар, төнлә көчкә кайтып егылалар икән. Шул вакытта, бер кыз салкын тиеп авыргач, Мәхфүзә кара төндә күрше авылга барып, аңа сөт алып кайтып эчергән. Гомумән, ул анда кызларны эшкә дәртләндерүче дә, юатучы да булган.

— Ул үзен мактаганны яратмый, — диде миңа Виктория Николаевна.— Менә, мәсәлән, ул бер студент кызга ике ел буе үз хезмәт хакыннан стипендия түләп торды. Күрә: кызның укырга теләге бар, ләкин «өчле» алды, стипендиясез калды, башка ярдәм килер урыны юк. «Укы, стипендияне үзем түләрмен»,— диде аңа Мәхфүзә Кәримовна. Мин аның акчасы артык иде дип әйтә алмыйм, кандидат кына иде бит әле. Мәхфүзә Кәримовна үзе бу турыда авыз ачарга да ирек бирми, кылган яхшылыгымны кеше гомере буе исендә тотсын, үзен миңа бурычлы санасын дип эшләмәдем мин ул эшне, ди.

Инде килеп, Максутова атаган сыйфатларга мин тагын үземнән икене өстәр идем.

Аның беренчесе — фикер иреклеге. Максутова кануннарга ышанудан ерак тора. Кешеләргә карата да, фән законнарына карата да аның үз карашы бар. Әгәр үзенчә фикер йөртә белмәсә, ул фәндә яңа сүз әйтә дә алмас иде, билгеле.

Тагын бер сыйфат — тугрылык. Мәхфүзә Максутова — табигате буенча тугрылыклы кеше. Ул беренче мәхәббәтенә дә тугрылыклы булып калган, хезмәтенә дә. Мең сынаулар, мең киртәләр аша үтеп, бер максатка, бер омтылышка бара алган кеше генә зур эшләр башкарырга сәләтле.

Бу сыйфатлар — эш сөю, кешелеклелек, киң фикерле һәм тугрылыклы булу — бер фән әһелләренә генә түгел, бөтен кешегә дә кирәк лабаса!

Әйе, мин аның янына хатын-кызлар арасында сирәк очрый торган хезмәт кешесе булганы, шул өлкәдә уңышка ирешкәне өчен кызыксынып һәм бераз шикләнеп тә барган идем. Тора-бара аның, хезмәтеннән бигрәк, кешелек сыйфатларына сокландым. Кызларыбыз арасында андыйларның күбрәк булуын тели күңел. Юк, мин барлык кызларны да турбинист булырга өндәмим. Ләкин, кабатлап әйтәм, Мәхфүзә Максутова кебекләр күбрәк булсын иде. Эшчеләр арасында, сатучылар арасында, урам себерүчеләр арасында, укытучылар, врачлар арасында — кыскасы, һәртөрле һөнәр ияләре арасында тормышның мең дә бер сынавын намус белән үтәрлек андый кешеләр күбрәк булсын иде.

Тормышыбыз андый булып үсәргә тулы мөмкинлекләр бирә, чорыбызга шундыйлар кирәк!

# ХЕЗМӘТ ШАТЛЫГЫ



*Күренекле язучыбыз Газиз ага Иделлегә 70 яшь тулды.*

*Газиз Иделле (Усманов) 1905 елның 26 декабрендә Астрахань шәһәрендә эшче семьясында туган. Көнкүрештәге авыр шартлар аны бик яшьли хезмәт юлына бастыра, эшчеләр тормышына якынайта. Ул яшьтән үк, төрле заводларда эшләп, үз көнен үзе күрергә мәҗбүр була.*

*Бөек Октябрь тудырган яңа тормыш шартлары булачак әдипнең өзлексез алга, яктыга, аң-белемгә омтылышына нык терәк бирә, ерак офыкларны якынайта. Ул Свердловск шәһәрендә техникумда укый һәм шул елларда ук матбугатка якыная, «Сабан һәм чүкеч» газетасында, «Шәпи агай» исемле сатирик журналда корректор булып эшли. Бу хезмәте аңа журналистика һәм әдәбият дөньясы белән якыннан танышырга ярдәм итә һәм, күп тә үтми, аның беренче хикәяләре, очерклары басылып чыга.*

*1926 елдан башлап Газиз Иделленең тормышы Казанга, Татарстанга бәйле. Ул монда «Безнең юл» журналында, «Кызыл Татарстан» газетасында, радиокомитетта җаваплы эшләр башкара. Ә 1930—40 нчы елларда армиядә дивизия газетасы редакторы вазифасын үти.*

*Әдипнең күп әсәрләре журналист хезмәте йогынтысында, конкрет кешеләр язмышына бәйле рәвештә язылганнар. Аның беренче хикәяләр җыентыгы («Пумала башлар») 1930 елда чыга. Бөек Ватан сугышы елларында язылган «Очрашу», «Күпер» җыентыкларында Газиз Иделле совет сугышчыларының батырлыгын, аларның югары патриотик һәм әхлакый сыйфатларын тасвирлый.*

*Укучылар Газиз Иделлене «Дәүләт Бәдриев» һ. б. пьесалары буенча драматург буларак та беләләр. Аның яшь язучылар иҗатына, сәхнә әсәрләре һәм спектакльләргә багышланган мәкаләләре үз чорының культура тормышында күренекле урын тоттылар.*

*Газиз Иделленең иҗаты актив иҗтимагый эшчәнлегеннән аерылгысыз. Ул һәрчак язучылык хезмәтен партия һәм җәмәгать эшләре белән бергә бәйләп алып барды.*

*Язучы әле дә иҗат дәрте белән рухланып яши. Укучылар аның соңгы елларда язган истәлекләрен зур кызыксыну белән кабул итте.*

# Газиз Иделле

# БЕРЕНЧЕ ОСТАЗЫМ

Газиз Иделленең «Беренче зур сәяхәт» дип исемләнгән истәлекләре, кыскартылып, журналыбызда басылган иде (1973 ел, 3, 5, 6, 7, 8 саннар). Укучыларның да фикерләрен, киңәшләрен искә алып, автор кульъязма өстендә тагын да җентекләп эшләде, яңа язылган бүлекләр белән дә тулыландырып, күптән түгел аны нәшриятка тапшырды. Яңа бүлекләрнең берсе укучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителә.

Сәяхәттән кайткач, күп тә үтмәде, Гомәр Гали мине үз янына, журнал редакциясенә эшкә алды: «Әйдә безгә, редакциядә эшләргә, секретарь кирәк»,— диде. Журналында беренче хикәяләрем басыла башлаганнандыр дип аңладым мин бу җылылыкны. Әлбәттә, мондый тәкъдимгә шатланып риза булдым. «Безнең юл», соңра «Атака» журналларында Гомәр Гали белән бергә, аның кул астында эшләү безне тагын да якынайтты.

Аннары мин Самарада хәрби хезмәттә чагымда аның белән хатлар да язышкалап тордым.

Хәрби хезмәтемне (инде комсостав дәрәҗәсендә) дәвам иттерү өчен Казанга килеп төшкәч тә беренче булып кочак җәеп каршы алучы шул Гомәр абый булды, үзләрендә кунак итте. Хәзерге Кави Нәҗми урамы 24/20 номерлы йортта өч бүлмәле квартирада торалар иде. Гаилә зур түгел, тормыш иптәше Хәрирә ханым һәм беренче бәбиләре Алсу...

Әле буйдак елларым бит, төрле частный квартираларда бүлмә-почмак алып яшәп яткан чаклар. Гомәр Гали үзе тәкъдим итте: борчылма, бездә торып тор, диде. Шулай, безнең командование миңа аерым бүлмә биргәнгә чаклы бер ай чамасы аларда яшәдем һәм бер дә «артык кеше» дип караучы булмады миңа. Киресенчә, Гомәр абый үзе дә, Хәрирә ханым да бик кунакчыл, ягымлы мөнәсәбәттә булдылар.

...Инде бер башлагач, истә калганнарның барысын да язмый булмый, ахры. Гомәр Гали белән беренче танышып китүем исә бер дә алай шома гына булмавын хәтерлим, ничектер сәеррәк тә, күңелсезрәк тә булып чыккан иде ул.

...Көннәрдән бер көнне, яза-сыза торгач, бер хикәям барлыкка килде. Ә мондый вакыйга, зурмы-кечкенәме ул, автор өчен, билгеле, гаять шатлыклы көн була. Бигрәк тә башлап язучы, яшь язучы өчен. Бигрәк тә хикәям үземә ошагач, бик оста язылган булып күренгәч... Шулай, күтәренке күңел белән Мәдәният йортына чаптым (хәзер ТЮЗ бинасы). Икенче катта — «Безнең юл» редакциясе...

Бара торгач, күтәренке кәеф, ашкынулы дәрт ничектер суына да төште димме... нишләптер борчыла ук башладым: Гомәр Гали абзаң ни дияр бит әле...

Инде бер килеп җиткәч, кире борылып китеп тә булмый — тәвәккәлләп янына кердем. Берүзе нәрсәдер язып утыра иде. Мин, кыяр-кыймас кына, менә бер хикәя китергән идем, дип кульъязмамны аңа суздым. Бер күтәрелеп миңа карап алды. Каләмен бер читкә куйды. Җыелыш-мазарларда күзенә чагылгалаганмындыр, әллә ни сорашып тормады, шунда ук укый да башлады. Тын да алмый аның хөкемен көтәм. Беренче хикәя бит. Бик әйбәт язылган булуына үзем бер дә шикләнмим, югыйсә әммә... хәзер менә редактор алдында коелыбрак төштем. Аның хәрәкәтләрен, чыраендагы үзгәрешләрне күзәтәм. Юк, әлегә берни тотып ала алмыйм мин аларда. Тынычсызлануымнан, каушавымнандыр бу...

Хикәя әллә ни зур түгел иде, бик тиз укып та чыкты. Алдында бер-бер артлы тарала-җәелә барган кәгазь битләрен бергә җыеп алып, кире миңа таба этәреп куйды да, урыныннан торып, бүлмә буйлап йөреп китте. Башта берничә генә җылы сүз әйтте ул («Хикәя яза башлагансың икән, ярый, ярый...» кебегрәк), аннары тиз үк ким-

челекләрне бәйнә-бәйнә ачып салды. Йомшак кына сөйли башлаган иде, кызып китүен үзе дә сизми калды бугай — төмам пыр туздырып ташлады минем бу «иҗат җимешемне»... Нигә дип бу бүлмәгә килеп керүемә үкенеп бетә алмадым.

Дөресен генә әйткәндә, аның тәнкыйте минем аңыма үтеп керә алмады төсле, ул мәлдә миндә шундый бер психологик шок сыман нәрсә булып алды ки, нишләптер, үзем менә аның бик ачык, аңлаешлы сүзләрен, фикерләрен ишетеп утырам, ә һич тә кабул итә алмыйм, аңларга тырышу урынына, ниндидер киреләнү-ачу сыман хис биләп алган иде, ахры, мине... Һәм, вакытын алуыма гафу үтенеп, тизрәк чыгып китәргә ашыктым.

Әнә шулай булган иде безнең беренче «иҗади очрашуыбыз».

Күпмедер вакыт аңыма килә алмый йөрдем. Аның сүзләре колакта һаман яңгырап торды:

— Төп образың җитәрлек ачылмаган...

— Әдәби-художество алымнарың йомшак...

— Кыска хикәя күп вакыйгаларны, күп кешеләрне сыйдыра алмый, ә син анда күпне күрсәтергә, күп нәрсә әйтергә телисең, ә асылда нәрсә әйтергә теләвеңне аңлап булмый...

— Әдәби тел өстендә бик ныклап эшләргә кирәк әле сиңа, күбрәк коры газета теле белән язасың... Художестволы итеп тасвирлаудан бигрәк, диалогларың артык күп. Хикәя пьеса түгел бит ул...

— Гомумән, монда хикәя дигән нәрсә юк әле...

Шундый фикерләренең һәркайсы буенча «хикәямнән» конкрет мисаллар китереп сөйләде ул, югыйсә...

Боларны сүзгә-сүз китерүем түгел, әлбәттә, әмма редактор Гомәр Галидән ишеткән тәнкыйть сүзләренең төп мәгънәсе шуларга кайтып калганлыгы хәтердә һаман саклана.

Инде нишләргә?

Беркадәр суынгач, салкын кан белән, яңадан кат-кат укып чыгам әлеге «хикәямне». Инде аны үземнеке дип түгел, ә бүтән кеше кульязмасы итеп укып карыйм. Шулай укуның файдасын да күрә-аңлый башлыйм кебек. Шунда үзем өчен сәер бер хәл дә ачылып китә. Башта, язып бетергәч тә, үзалдыма укыган саен ошый, укыган саен ошый иде ул, ә менә хәзер кат-кат укыган саен ошамый, укыган саен ныграк, төмам ачу китеребрәк ошамый шул бер үк кульязма... Шулай икән шул, хикәя мәкалә язу түгел икән ул, югыйсә, моңа кадәр журналистика өлкәсендә эшләрем шома гына барган иде кебек...

Әйе, Гомәр Гали бик хаклы булган!

Димәк, шулай булгач, яңадан кулга каләм алып торуның, ягъни хикәя-мазар язып маташуның кирәге дә калмады кебек. Мөгаен, шулай булган да булыр иде, әгәр дә...

Әйе, әгәр дә мин кульязмамны тиз-тиз йомарлап алып, чыгып китәргә дип кабаланганда, аның хәтердә иң сеңеп калган соңгы сүзләре — төкъдиме, киңәше булмаган булса...

Эшендә, иҗатында, тормышында сизелерлек темпераментлы ул Гомәр Гали. Еш кына кызып китүчән дә була, характеры-табигате шундый аның, әмма бик тиз басыла да белә ул. Мөгаен, әлеге минутларда мин бик аяныч булып күренгәнмендер, — шунда ул, йомшарып, мине кызганып та куйды, ахры:

— Син, Газиз, алай бик борчылма, — диде ул җитди һәм үтемле тон белән, — әйткәннәремнән кәефең кырылмасын, башта шулай булгалый инде ул. Бу хикәяңне бер читкә салып куй да тагын бүтән бер хикәя язып кара, берне түгел, икене, өчне дә... шунда күрербез.

Күпмедер өмет чаткылары уята торган сүзләр иде болар, аның гадел, игътибарлы, кешелекле булуын да күрсәтә иде. Һәм мин, күз алдымда шундый Гомәр Галине тотып, икенче хикәя язарга утырдым. Кабаланмыйча. Уйланып. Кат-кат кучереп. Язып бетергәч тә редакциягә чапмадым бу юлы. Кульязмам көннәрме, атналармы ятты шулай суынып. Шуннан соң аны яңадан укып карадым. Әзер дигән кульязма тагын да шактый төзәтүләргә, яхшыртуга мохтаҗ булып чыкты. Аны тагын кучереп яздым да редакциягә илттем. Бу юлы инде Гомәр Галинең теләсә нинди хөкеменә риза идем.

...Ашыкмыйча, кайбер урыннарын кайта-кайта укыганын хәтерлим. Шунда Кави Нәҗми килеп керде. Гомәр белән исәнләште, аның алдындагы кулъязмага һәм миңа бер күз ташлап алды да янәшәдәге урындыкка утырды. Үзара сөйләшеп киттеләр. Уку өзелде. Шулай да сүз арасында Кавинең:

— Яшьләр киләмени?.. Яхшы, син, Гомәр, аларга игътибарлы бул, алмаш үстерергә кирәк... — мәгънәсендә әйткән сүзләрен ишетү күңелгә бик хуш килде.

Йомышлары җитдирәк булды, ахры, Гомәр инде кулъязманы бер читкә куйды, укуны артык дәвам иттермәскә булды (хикәянең күләме шактый зур иде). «Ярар, Газиз, үзем генә укып чыгармын инде, — диде. — Шулай да, бу хикәяң тәгесенә караганда әйбәтрәк күренә», — дип тә өстәде.

Ике зур әдипкә артык комачауламас өчен һәм дә беркадәр тыныч күңел белән чыгып киттем.

«Кабул булмаган корбаннар» исемле бу хикәям басылуга кабул ителде, типографиягә төшеп китте. Тик гранкаларын уку барышында Гомәр Гали минем алдыма тагын бер шарт куйды: имзаңны алыштыр, әдәбиятта Усмановлар күбәеп китте — Шамил Усманов, Хатип Усманов, Таһир Усманов... Шуларга өстәп тагын — Газиз Усманов... Булмый болай. Укучылар буталып бетәр. Үзеңә берәр псевдоним — яңа исем ал, диде. Бу — таләп формасында куелды. Нәтиҗәдә, моңа кадәр кыска хәбәрләр, мәкаләләр, очерклар, тәрҗемәләр, фельетоннар авторы булып килгән Газиз Усманов, шул хикәядән башлап, Газиз Иделле саналырга тиеш булды. Псевдоним табуы да җиңелдән түгел иде — Кутуй, Минский булыштылар.

«Безнең юл» журналының күләме ул елларда әллә ни зур түгел иде. Хикәям ике санга бүленеп басылды. Шуннан соң тагын «Икмәк һәм хатын», «Урал татар матур әдәбияты», «Тәнкыйтьче», «Саҗидәкәй» һ. б. хикәя, мәкалә, тәрҗемәләр...

Гомәр Гали ул елларда ук зур белемле, киң әтрафлы әдип, принципиаль тәнкыйтьче, актив җәмәгать эшлеклесе, таләпчән редактор булып танылган иде инде. Моны ишетеп, укып белү — бер, ә минә үз тәҗрибәмдә, үз җилкәмдә моның «тәмен-көчен» татып белү — бөтенләй икенче нәрсә ул.

Редакциядә эшләгәндә, килгән кулъязмаларның барчасы башта минем кулдан үтә, ә шигъри әсәрләрне исә Гомәр Гали фәкать үзе генә карап хәл кыла иде. Көчемнән килгән кадәр тырышам инде, төзәткәлим, кыскарткалыйм... ә зур әдипләрнең кулъязмаларына каләм тидерергә дә куркам. Миннән соң кулъязмалар Гомәр абый папкасына күчә. Үзе карап чыкканнан соң, аларны яңадан миңа кайтара. Кайбер кулъязмаларга карап, мин бөтенләй аптырап калам, тәмам коелып төшәм. Әйтерсең лә минем хезмәтем бөтенләй булмаган да, Гомәр абый үзе өр-яңадан редакцияләп чыккан! Ә ул ачуланмый да, көлеп кенә тора: «Редакция эше шундый бик җаваплы эш ул, — ди. — Яңадан карап чык та машинкага бир!». Һәрбер төзәтүләрен, кыскартуларын игътибар белән өйрәнәм...

Кемнең кем булуына карамастан, бик таләпчән ул Гомәр Гали. Әдәбиятта партиячел принципиальлек, югары идея-художестволылык өчен янып-көеп яши, эшли. Җыелыш-утырышлардагы чыгышларында, матбугатта басылып чыккан мәкаләләрендә чын художество әсәрләренә лаеклы бәя бирүе белән бергә, идеясе буталчык, я бик ачык булмаган әсәрләргә, төрле халтураларга каршы көрәштә аяусыз, мәрхәмәтсез иде ул.

Аның шундый сыйфаты үз-үзен тотышында да, үзара мөнәсәбәтләрдә дә чагылмый калмый иде. Гомумән, игътибарлы, кешелекле Гомәр, урынына күрә шаяртулардан, шукланудан да тартынмый торган Гомәр, кирәк чагында бик кырыс та, хәтта усал да була белә. Бу якларын да төрле вакытларда һәм шушы сәяхәттә дә күрсәткәләде ул. Әмма гадел иде һәм мондый очракларда аңа каршы сүз әйтергә урын калмый иде.

Гомәр Гали редактор да, тәнкыйтьче дә булу өстенә, ТАПП җитәкчесе дә бит әле. Агымдагы әдәби хәрәкәтнең гел үзәгендә була ул. Кайберәүләр кебек әкрен кыймылдауның нәрсә икәнен дә белми. Гел ашыга, алга иелебрәк бик кызу атлап йөри, чаба, артыннан һич өлгерерлек түгел. Аның барлык хәрәкәтләре-сөйләве, язуы, чыгышлары — барысы да кызу, үткен, кискен һәм гадел. Безнең күз алдыбызда, безне соклandырып, ашыгып, ашкынып яши, эшли, иҗат итә Гомәр Гали.

...Эш барышында килеп чыга торган мәсьәләләргә, әдәби вакыйгаларга бик тиз игътибар итүчән, әдәби хәрәкәттәге теге яки бу мәсьәлә, проблема, теге яки бу яңа әсәр турында беренче сүзне әйтүче дә ул була. Үз карашын әйтүдә бервакытта да, беркем алдында да тартынып тормый. «Сабыр итим әле, бүтәннәр ни әйтер бит» дип карау аның характерына ят нәрсә. Кайберәүләр аның бу гадәтен бик үк яратып та бетермиләр иде, әлбәттә... Кызу канлырак, имеш.

...Бик дус булып йөргән каләмдәшләре белән дә пыр тузып талашып киткән чакларын да күргәләгәнем бар. Аны кирелектә гаеппәп әйтелгән сүзләрне дә ишеттерүчеләр булды. Ләкин аның мондый «чыгымчылаулары» фәкать принципиальлекнең бер чагылышы гына иде.

Бик эшлекле дә, шау-шулы да җыелышларны, утырышларны әйтеп тә тормастан, редакциянең үзендә дә — көннәр буе җанлы хәрәкәт. Гомәр янына әледән-әле язучылар, шагыйрьләр килеп керә... Олылар да, яшьләр дә... Һади Такташ, Нур Баян, Гомәр Толымбайский, Мирсәй Әмир, Фатих Сәйфи-Казанлы, Фатих Кәрим, Нәкый Исәнбәт, Гадел Кутуй, Фатих Мөсәгыйть... Кульъязмалар белән дә, болай гына да... Һәркайсының үз характеры, теге я бу мәсьәләгә, әсәргә үз карашы... Үзеннән-үзе әңгәмәләр, фикер алышулар башланып китә, бәхәсләр дә булмый калмый.

...Гомәрләрдә кунак булып торган чагымда, хәтерлим, Такташ, Кавиләр кичләрен еш кына аның өенә үк килеп керәләр иде. Гомәрнең эш бүлмәсендә яки залда чәй янында әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә кагылышлы күп төрле темаларга бик кызыклы әңгәмәләр алып баруларының да шаһиты була торган идем.

Гомәр белән Такташ аеруча дустанә мөнәсәбәттә иделәр. Бер-берен аңлау, ихтирам итүгә нигезләнгән әйбәт дуслык иде бу. Гомәр Гали Такташ иҗатын бик кызыксынып күзәтеп, өйрәнеп бара, уңышлары турында да, кимчелекләре турында да аңа туры әйтә, ә Такташ исә Гомәр әйткәннәргә, язганнарга бик колак сала, күпчелек очракта, аеруча төп принципиаль мәсьәләләрдә, аның белән тулысынча килешә торган иде. Такташ иҗатының соңга таба нык сизелерлек рәвештә реалистик поэзиягә күчә баруында, политик үткенләнүендә Гомәр Гали йогынтысы аз булмады дияр идем. Аның ТАППка член булып керүе дә Гомәрне ихтирам итүе, аның карашын уртаклашуы нәтиҗәсе булгандыр дип уйлыйм.

Тарихи дөреслек өчен шуны да әйтеп үтәргә кирәк. Ул елларда — әдәбият фронтында төрле агымнар, «измнар», уң тайпылышлар яки үтә сул карашлар әле бөтенләй үк сүнеп бетмәгән чакта, кызу-кызу бәхәсләр, үзара бәрелешләр, көрәшләр булгалап торганда — Гомәр Гали кебек үтә актив эшчән шәхес өчен бер дә ялгышусыз туры сызык белән генә бару җиңел булмагандыр, әлбәттә, һәм, билгеле, шундый шартларда, аерым очракларда, аерым мәсьәләләрдә аның бик үк объектив булмаган чыгышларын да аңлашыла торган нәрсә дип карарга кирәк. Һәрбер фактны шул чорның үзеннән аерып алмыйча, объектив тикшергәндә моны аңлап һәм аңлатып була, Гомәрне характерлауда алар һич тә хәлиткеч түгелләр.

Шуңа күрәдер, без бүген дә әле юксынабыз, сагынабыз Гомәрне. Аны яхшы белгән замандашлары да, бүгенге әдәбиятыбызның Гомәргә, аның принципиаль зур тәнкыйть хезмәтләренә тиешле бәя бирә алган күренекле вәкилләре дә аны юксынып, олылап телгә алалар.

Шулай булмыйча!

«Мин тәнкыйтьтә, күп кимчелекләре булуга карамастан, һаман әле Гомәр Галине сагынам. Турылыгы, кыюлыгы, таләпчәнлеге өчен сагынам. Әдәбиятны урта кул шигырьләр басып китмәсен өчен Гомәр Галиләр кирәк» (Сибгат Хәким. «Тәнкыйтьче Т. Галиуллин белән интервьюсыннан». «Казан утлары», 12 сан, 1971 ел).

Әйбәт әйтелгән!

Тик шуңа өстәп, поэзия өлкәсендә генә түгел, гомумән, әдәбиятыбызның барлык тармаклары өчен дә кирәк ул Гомәр Галиләр, дияргә генә кала. Чөнки поэзия генә түгел, проза да, драматургия дә, әдәби тәнкыйть жанры үзе дә, хәтта мәктәп дәреслекләре дә аның игътибарыннан читтән калмадылар, аның хезмәтләре бүгенге көндә дә бик актуаль яңгырыйлар һәм бигрәк тә безнең яшь тәнкыйтьчеләребез өчен олы үрнәк хезмәтен үтиләр.


# КАЗАН КОНСЕРВАТОРИЯСЕНӘ 30 ЕЛ

Казан шәһәренең Ленин бакчасына урнашкан җыйнак кына бинада беренче дәресләр башланганга әле күптән дә түгел шикелле. Консерватория кебек югары музыка белеме бирү йорты өчен утыз ел гомер күпмени? Ләкин шул вакыт эчендә башкарылган эшләрне күздән кичерсәң, тулы бер дәвер үткәнен күрәсең. Бүгенге көндә безнең музыкаль культурабыз шундый дәрәҗәгә җитте ки, без бу өлкәдә әлек алдынгылардан саналган халыкларның музыка сәнгатьләре белән тиңләшү турында сүз алып бара алабыз. Шушы елның башында Мәскәүдә уздырылган РСФСР Композиторлар союзы секретариаты утырышында да нәкъ шушы хакта җитди сүз әйтелде. Татарстан композиторларының соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре башкарылган концерттан соң фикер алышканда, танылган совет композиторлары Р. Щедрин, А. Флярковский, В. Казенин һәм башкалар татар музыкасының уңышларын хуплап сөйләделәр һәм Казан консерваториясенең композиторлар классына югары бәя бирделәр.

Хәзерге вакытта Татарстанда актив эшләүче югары белемле музыкантларның һәм композиторларның күбесе — Казан консерваториясендә укып чыккан кешеләр. Алар арасында опера һәм балет авторлары Хөснул Вәлиуллин, Әнвәр Бакиров, симфоник әсәрләре, концертлар, инструменталь һ. б. әсәрләре белән танылган Алмаз Монасыйпов, Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин, Ренат Еникеев, Рафаэль Билаловлар бар. Алар татар музыкасын жанр ягыннан да, тел ягыннан да баетып, алда яңа офыкларны ачалар.

Бүген республикада консерватория тәмамлаган дүрт йөздән артык музыкант эшли. Шуларның ике йөз сиксәне — татар музыкантлары. Югары квалификацияле музыка белгечләренең үзебездә әзерләнүе яшь буынга музыкаль тәрбия бирү эшен киң күләмдә алып бару, яшь талантларны үстерү өчен зур мөмкинлекләр тудырды. Хәзерге көндә Татарстанда илле биш музыка мәктәбе эшли, музыкага аеруча сәләтле балалар консерватория каршындагы махсус урта мәктәптә белем алалар. Соңгы 10 ел эчендә Татарстанда тагын ике музыка училищесы ачылды. Культура институты һәм Казан педагогия институтының махсус музыка факультеты да берничә чыгарыш ясадылар инде. Быел унынчы сезонын ачкан Татарстан дәүләт симфоник оркестры да музыкаль сәнгатьне пропагандалауда һәм үстерүдә зур роль уйный. Бу казанышларның барысы да Казан консерваториясенең эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән.

Шәһәр урамнарына эленгән афишаларга гына күз салыйк. Менә Эльза Әхмәтова симфоник оркестр белән бергә фортепианода концерт башкара, Илһам Шакиров, Эмиль Җәләлетдинов зур концертлар бирәләр, Марат Әхмәтов белән Марат Сираҗетдинов татар композиторларының яңа әсәрләрен тамашачыга җиткерәләр, Рубин Абдуллин татарлардан беренче булып казанлылар өчен яңа музыка коралында — органда — уйный. һәр кичне Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында спектакльләр бара. Театр афишаларында эре кызыл хәрефләр белән танылган артистларның исемнәре язылган: РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы Зөләйха Хисмәтуллина, РСФСРның атказанган артисты Борис Аполлонов, ТАССРның халык артистлары Гөлшат Сәйфуллина, Идеал Ишбүләков, Рәйсә Билалова. Алар барысы



*Рәсемдә: Казан консерваториясе (сулда) һәм консерваториянең концерт залы бинаЛары.*

да — Казан консерваториясенең шәкертләре. Боларның һәммәсен күз алдына китергәч, Казанда консерватория ачылуның нинди җитди вакыйга булганлыгын аңлыйсың.

...1945 елның язы. Бөек Ватан сугышы әле бетеп җитмәгән, бөтен ил фронттан килгән хәбәрләр белән дулкынланып һәм кызыксынып яши. Меңнәрчә шәһәр-авыллар хәрабә хәлендә, миллионнарча кешеләр йортсыз-җирсез калган. Алда халык хуҗалыгын аякка бастыру, җимерелгән шәһәр-авылларны өр-яңадан торгызу, тыныч тормышны җайга салу кебек мөһим бурычлар тора. Шушы киеренке чорда, 1945 елның 13 апрелендә, СССР Министрлар Советы Казанда консерватория ачу турында карар кабул итә. Бу карар үзе генә дә партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең Урта Идел халыкларының музыкаль культурасын күтәрүгә нинди зур игътибар бирүе турында сөйли. Ленинчыл милли политика нигезендә, партия Үзәк Комитеты халыкларның милли музыка сәнгатен үстерүне максат итеп куя. Казан консерваториясенә дә бик җаваплы бурыч йөкләнә. Ул татар, башкорт, чуваш, мари, удмурт һәм башка тугандаш халыклар өчен профессиональ композиторлар, музыкантлар, җырчылар әзерләргә тиеш була. Аңарчы Идел буе республикаларының вәкилләре югары музыкаль белемне Мәскәү вузларында алалар иде. Утызынчы еллар башыннан алып Мәскәү консерваториясе каршында рабфак һәм милли опера студияләре эшләп килде.

Казанда югары профессиональ дәрәҗәдәге музыка училищесы эшләү, Мәскәүдә белем алып кайткан талантлы композиторлар булу, шәһәребезгә сугыш вакытында эвакуациягә килгән квалификацияле белгечләрнең тупланеп калуы консерваториянең эшен тиз арада һәм югары таләпләргә җавап бирерлек итеп көйләп җибәрергә мөмкинлек бирде. Аның җитәкчесе итеп талантлы композитор Нәҗип Җиһанов билгеләнде. Ул шул көннән бирле утыз ел буена консерваториянең алмашсыз ректоры булып эшли.

Консерватория ишекләре 1945 елның 10 октябрендә ачылды. Анда укыту эшен башлап җибәрү өчен, җирле кадрлар белән бергә, Мәскәүдән, Ленинградтан тәҗрибәле педагоглар чакырылган иде. Күренекле профессорлар М. А. Пятницкая, М. А. Юдин, Г. И. Литинский, Г. М. Коган, заманында Казан опера театрының атаклы җырчысы булган Е. Г. Ковелькова, В. Г. Апресов, А. С. Леман, Мәскәүдә белем алган композитор М. А. Мозаффаров, җырчы З. Г. Байрашева, музыка белгече Х. И. Терегулова һәм башкалар бөтен күңелләрен биреп эшкә керештеләр. Гаҗәп тату, бердәм һәм эш өчен янып торган коллектив туды. Укытучыларның күбесенә 30—40 яшь тирәсе иде. Студентларның күпчелеге алардан бик әзгә генә яшьрәк булып чыктылар, чөнки алар әле шинельләрен дә салырга өлгермәгән фронтовиклар иде. Музыка училищеларында сугышкача алган белемнәре шактый онытылган, автомат тотарга күнеккән бармакларның хәрәкәтчәнлеге кимегән булса да, 45 студент дәртләнеп укуга керештеләр һәм 1950 елда консерваториянең беренче дипломнарын алып чыктылар.

Хәзерге көндә консерватория Ирек мәйданындагы зур бинада эшли, аның орган урнаштырылган иркен концерт залы бар, махсус интернат-мәктәп, аспирантура ачылды. Консерваториядә 700 студент укый, 100 дән артык педагог эшли. Биредәге китапханәдә барлык кирәкле ноталар, китаплар тупланган, шактый күп пластинкалар, магнитофон язмалары җыелган. Ә Идел буе халыкларының музыкасы белән махсус кабинетта танышып була.

Консерваториянең эшчәнлеге укыту, музыкаль кадрлар әзерләү белән генә чикләнми, ул халык арасында зур музыкаль пропаганда алып бара, яшь буынга эстетик тәрбия бирүдә мөһим роль уйный. Аның педагоглары һәм студентлары җәйләрен Казанда, республикабызның төрле районнарында һәм күрше республикаларда концертлар куялар, лекцияләр укыйлар. 1950 елда студентлардан төзелгән симфоник оркестр республиканың утыз еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Татарстан нефтьчеләренә беренче концертын биреп кайтты. Шуннан бирле һәр җәй саен бу коллектив авылларга, химиклар янына, КамАЗга бара. Күп урыннарда аның концертлары ачык мәйданнарда үтә.

Консерватория Биектау районына шефлык итә. Студентлар бу районга гына түгел, КамАЗга төзүчеләр янына да аңлатмалы концертлар белән еш баралар. Төрле предприятиеләрнең цехларында, мәйданнарында, шыгрым тулы залларда студентларның тынлы оркестры, хоры һәм халык уен кораллары оркестры күп чыгышлар ясый. Мондый концертлар өчен студентлар уку программасыннан тыш та күп әсәрләр өйрәнәләр, татар һәм күрше тугандаш республикалар композиторларының яңа көйләрен беренче булып тамашачыга җиткерәләр.

Бу уңайдан консерваториянең иң яшь факультеты — халык уен кораллары (баян, домра) факультеты турында аерым әйтеп китәргә кирәктер. Аның ачылганына нибары 15 ел. Ләкин ул инде шактый уңышлар казанырга өлгерде. Факультетның оркестры белән ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, доцент А. В. Тихонов җитәкчелек итә. Оркестр барлыгы өч йөздән артык концерт бирде инде, ике тапкыр Мәскәүдә чыгышлар ясап, яхшы бәя алды. Бу коллективка халыкчанлык һәм зур осталык хас.

Факультетта укучы һәр студент шәһәрдәге йорт идарәләренең берсендә, яки мәктәптә, институтта ансамбль яисә оркестр оештырырга тиеш. Ул үз коллективы өчен үзе репертуар сайлый, әсәрләрне уен коралларында уйнау өчен эшкәртә, уйнарга да үзе өйрәтә. Соңыннан ул җитәкчелек иткән коллективның чыгышын педагоглар тыңлый һәм студентка зачет билгесе куя. Шулай итеп, консерваториядә укучылар беренче курстан алып яшүсмерләр белән, халык белән эшләргә күнегәләр.

Быел, Бөек Җиңүгә 30 ел тулу уңае белән, студентлар оештырган ансамбльләрнең беренче конкурсы уздырылды. Арада яхшы гына коллективлар барлыгы беленде. Бу башлангычның иҗтимагый әһәмияте бик зур — ул музыка сәнгатен киң халык массасына җиткерүдә бик яхшы чара булып тора.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор С. А. Казачков җитәкче-



*Рәсемдә: Консерватория ректоры, профессор Н. Җиһанов бер төркем студентлар белән.*

легендәге хор дирижерлары факультеты студентлары да мәктәп балалары һәм эшче яшьләр белән тыгыз элемтәдә торалар. Күп еллардан бирле факультетның хоры һәр шимбә саен нинди дә булса бер мәктәптә чыгыш ясый, татар, рус, чуваш композиторларының җырларын, классик әсәрләрне башкара, студентлар балаларга хор сәнгате турында, композиторлар турында гади, җылы итеп сөйлиләр. Шушы чыгышлар тәэсирендә, һәм, гомумән, хор сәнгате белән кызыксынуның артуы нәтиҗәсендә, соңгы вакытта мәктәпләрдә хорлар оештыру эшенә игътибар шактый көчәйде. Хорларга быел уздырылган смотр моны бик ачык күрсәтте. Консерваторияне тәмамлап чыккан В. Ульянов Киров районында менә дигән малайлар хоры оештырып, алар белән зур күләмле классик әсәрләр әзерләгән. С. Сәетгалиев исемендәге культура сараендагы, 36 нчы мәктәпнең кече классларындагы хорлар да мактауга лаек. М. Горький исемендәге клубта А. Садыйков җитәкләгән татар хорының соңгы уңышлары безне куандыра. Яңа һәм яшь хор коллективлары тәрбияләү эшендә Казан Пионерлар сараеның В. Лукьянов хоры, В. Ливанов җитәкчелегендәге Казан дәүләт университеты капелласы күпләр өчен үрнәк булып тора.

Бу өлкәдәге һәр уңыш безне шатландырмый калмый, чөнки республикабызда хор сәнгате башка кайбер республикалар белән ярышырлык дәрәҗәдә киң колач ала алмый әле. Әйтик, бездә, Балтик буе республикаларындагы кебек, бөтен халыкның бәйрәменә әверелдерерлек итеп җыр бәйрәмнәре үткәрү гадәткә кереп китмәгән. Бу өлкәдә тәрбия эше җитмиме, әллә андый бәйрәмнәр үткәрү өчен милли традицияләр җитәрлек нигез бирмиме — моның сәбәбен ачыкларга һәм бу өлкәдә эшне киңрәк җәелдерергә кирәк. Һәрхәлдә, консерватория студентлары бу юнәлештә бик кирәкле эш башкаралар һәм алар алдында торган бурычлар да зур.

Сәнгать уку йортының өлгергәнлеге башкаручылар конкурсларында да бик ачык күренә. Соңгы елларда гына да Франциядә, ГДРда, ЧССРда һәм башка илләрдә уздырылган халыкара конкурсларда безнең укучы һәм студентлардан Юрий Егоров, Ирина Лазарева, Римма Волкова, Людмила Донец уңыш казандылар, ә Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия конкурсларында Марат Әхмәтов, Маил Корбанов, Ренат Ибраһимов, Флера Хәсәнова, Людмила Леонтьева, Вафирә Гыйззәтуллиналар җиңү яуладылар.

Казан консерваториясе интернациональ уку йорты булып ачылды һәм үсте. Биредә югары музыка белеме алган төрле милләт кешеләре үз республикаларында милли культураны үстерүгә хезмәт итәләр. Идел буе республикаларының музыкаль уку йортларында эшләүче педагогларның күбесе — Казанда укыган кешеләр. Композиторлар союзларында да алар күпчелек тәшкил итә. Мәсәлән, Мари композиторлар союзының председателе, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе А. Луппов беренче мари балетын иҗат итте. Мари операсының тууы да Казан консерваториясе шәкертләре Э. Сапаев һәм И. Молотовларның эшчәнлеге белән бәйле. Чуваш композиторы Ф. Васильев «Шавырман» операсын бездә укыганда яза башлаган иде. Бу опера инде күп еллардан бирле Чабаксар театры сәхнәсеннән төшми уйналып килә. Беренче уңышлы чуваш балетларын да шулай ук Казанда белем алган Ф. Васильев белән М. Алексеев иҗат иттеләр. Тува композиторы А. Чыргал-Оол, калмык П. Чонгушев, ойрат композиторы алтайлы Б. Шульгин — барысы да безнең шәһәрдә укыдылар һәм үз халыкларының беренче профессиональ композиторлары булып танылдылар. Удмурт композиторлар союзы тулаем диярлек бездә укыган кешеләрдән тора.

Казан консерваториясе беренче елларыннан башлап Идел буе халыкларының музыкаль иҗатын өйрәнү һәм туплау эшенә керешә. Ел саен татар, рус, башкорт, чуваш, мари, удмурт, мордва халыкларының көйләрен җыю өчен студентлардан махсус экспедицияләр оештырыла. Шул экспедицияләрнең нәтиҗәсе буларак, халык көйләрен туплаган берничә җыентык әзерләнде. Ике меңнән артык көй язма хәлендә саклана.

Музыка белгечләре факультетында укучы студентлар күп кенә фәнни эшләр алып баралар. Диплом темалары соңыннан еш кына фәнни диссертацияләр өчен нигез булып китә. Мисал өчен, М. Нигъмәтҗановның татар музыкаль фольклорына багышланган диссертациясе нәкъ менә диплом эшеннән башланган иде. З. Сәйдәшева, Й. Исәнбәт, М. Фәйзуллаеваларның диссертация һәм фәнни эшләре дә — дипломнарының дәвамы. Бу эшкә аерым башкаручылар да өлеш кертә. Мәсәлән, И. Гобәйдуллина, татар композиторларының фортепиано өчен язылган әсәрләрен өйрәнеп, диссертация яклады. А. Хәйретдинов Татарстанда музыка укыту эшенең үсешен өйрәнде. Ә. Абдуллинның да кандидатлык диссертациясе татар халык көйләрен өйрәнүгә багышланган иде.

Алда күргәнебезчә, Казан консерваториясе педагоглары һәм шәкертләренең эшчәнлеге күп юнәлешләрдә бара. Идел буе халыкларының культура тормышына аның йогынтысы зур. Ләкин консерватория бөтен үрләрне яулаган, ирешергә мөмкин булганның барысына да ирешкән дип әйтү дөрес булмас иде. Юбилей көннәрендә без, уңышларга куану белән беррәттән, алда торган бурычларга да аек күз белән карыйбыз.

Илебез халкының музыкага омтылышы көннән-көн арта бара, яшь буынны тәрбияләүдә музыка сәнгатенең роле көчәйгәннән-көчәя, музыкаль кадрларга торган саен югарырак таләпләр куела. Консерватория ел саен йөздән артык яшь белгеч хәзерләп чыгара, әмма Татарстанның һәм күрше республикаларның ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндереп җиткерә алмый әле. Музыкантлардан тагын да зуррак белем, осталык, гражданлык хисләре белән яңу таләп ителә. Бүгенге көндә консерватория коллективы шушы изге бурычларны күздә тотып яши һәм эшли.

**Ч. БӘХТИЯРОВА,**
**сәнгать фәннәре кандидаты.**

Ильтани Илялова

# АКТЕР ОСТАЛЫГЫ

„Сәхнә сәнгате — игелексез сәнгать,— дип язган В. Г. Белинский,— чөнки аны иҗат минутында гына күреп була, шул чагында күңелгә көчле тәэсир итсә дә, ул соңыннан эзсез югала»[1]. Ихтимал, иҗат мизгелен язып-теркәп калуның катлаулы булуы, актер иҗатының сәнгатьнең күп төрләре белән бәйләнгән, үрелгән булуы аркасындадыр, бу темага караган фәнни хезмәтләр һәм тикшеренүләр дә аз очрый. Татар артистларының уен алымнары шулай ук үз тикшерүчеләрен көтә әле.

Әмма бер нәрсә бәхәссез: татар театры барлыкка килгән вакытта ук аның актерлар составы көчле булган. Театр турында язган тәнкыйтьчеләрнең барысы да шул фикерне куәтли.

Татар совет театры оешып кына килгән чорда ук: «Труппада көчле актерлар күп... Тулаем алганда, театр режиссурага түгел, ә индивидуаль актер уенына йөз тота»[2], — диган юллар языла.

«Театрның нык тупланган һәм эшкә сәләтле коллективы бар. Шул кадәресе бәхәссез... Күпчелек актерлар яхшы уен сәнгатенә һәм пластикага ияләр»[3],— дип язалар 30 нчы елларда.

«Театрның актерлар составы менә дигән. Теге яки бу актерны төрле спектакльләрдә күрсәгез, аның образга керү осталыгына сокланмый калмаячаксыз. Театрның иң яхшы артистлары сәхнәдә үзләрен искиткеч гади һәм иркен тоталар»[4]. Бу фикер 50 нче елларда әйтелә.

«Г. Камал исемендәге театрның көчле артистлары бер кыйммәтле сыйфатка ия: алар иҗат иткән геройлар безнең алга җанлы булып килеп басалар, аларның һәр психологик хәрәкәте тормышчан була»[5],— дип язалар безнең көннәрдә.

Шулай да бу фикерләрдә татар театрына хас алым, аларның төп уен стиле җитәрлек ачылмый әле. Ә татар театрының нык аерылып торган уен алымы булган һәм бар. Безнең актерлар иҗатының иң төп, иң ачык сыйфаты — тормыш-көнкүреш дөреслеге. Бу — татар артистларының реалистик традицияләрдә тәрбияләнгән үз мәктәбе. 1966 елда Ленинград шәһәрендә безнең театрның иҗат йөзен тикшергәндә: «Спектакльләрне реаль көнкүреш планында ачу театрның мөһим казанышы булып тора. Сезнең күпчелек артистларыгыз җанлы көнкүреш образлары иҗат итәргә сәләтле»[6],— диган фикер әйтелде.

Күрәсез, татар театрының кайсы чоры турында гына сүз бармасын, һәркем безнең артистлар уенындагы көнкүреш реализмына басым ясый. Димәк, өлкән буынның ак-

---

[1] В. Г. Белинский. Сайланма әсәрләр. Рус телендә, I том, Мәскәү, 1948 ел, 348 бит.
[2] «Современный театр» журналы, 1927 ел, 2 сан.
[3] «Красная Татария» газетасы, 1935 ел, 12 январь.
[4] «Советская культура» газетасы, 1958 ел, 10 июль.
[5] «Театр» журналы, 1967 ел, 9 сан.
[6] Академия театры музее, фонд 280, тасвирлама 5, саклау берәмлеге 68.

терлык сәнгате өлкәсендәге төп казанышы тормыш чынлыгы, ныклы реализм булып чыга. Матур бер традиция төсендә соңыннан ул яшь буын актерларга күчә барган.

Ләкин нигә нәкъ менә тормыш-көнкүреш чынлыгы? Моның нигезе кайда? Әгәр артка, татар театры формалашкан чорларга әйләнеп карасак, шул нәрсә ачыклана: беренче татар артистлары тәрбияләнеп үскән драматургия үзе тормыш-көнкүреш характерында булган. Театрның юл башында безнең драматургиягә нигез салган Г. Камалның нигездә мәгърифәтчелек рухында язылган реалистик драмалары һәм комедияләре торган. Аның артыннан әсәрләре татар совет драматургиясенең алтын фондына кергән К. Тинчурин, Т. Гыйззәтләр килә. Даими тестә тормыш-көнкүреш әсәрләре башкарып, безнең артистлар, бик табигый рәвештә, осталыкларын нәкъ менә шул юнәлештә камилләштерәләр.

Татар театрында күренекле тормыш-көнкүреш актеры Г. Кариевтан килә торган мәгълүм бер эстафета бар. «Кариев, әле генә базардан килеп, сәхнәгә менгән татар сәүдәгәренең нәкъ үзе иде»[1] — дип язган Г. Тукай. Г. Кариев талантының, һичшиксез, реалистик характерда булуы хакында сөйләгән дәлилләр бик күп. Алга таба тормыш-көнкүреш реализмы юнәлешен аның шәкертләре К. Тинчурин, З. Солтановлар дәвам иттерә. К. Тинчурин белән З. Солтанов үз нәүбәтләрендә Х. Әбҗәлилов, Х. Уразиков, Г. Булатова, М. Сульва, Г. Камская кебек күренекле артистларның остазларына әйләнәләр. Тагын да яшьрәк буын вәкилләре дә бу линияне үстерә, дәвам иттерә.

Революциягә кадәрге татар артистлары иҗатында, көнкүреш реализмы белән бергә, күтәренке, романтик линия дә яшәп килгән. Бу юнәлешнең башында беренче татар артисткасы С. Гыйззәтуллина-Волжская тора. Татар әдәбиятындагы, хосусан алганда, 20 нче еллардагы татар совет драматургиясендәге романтизм хакында без шул чордан калган әсәрләр буенча фикер йөртә алсак, татар артистлары иҗатындагы романтик башлангыч турында ачыктан-ачык беркайда да әйтелмәгән. Театрдагы өлкән буын артистларының истәлекләренә таянып, шулай ук театрның үзендә М. Мутин, Камал III, Ф. Ильская кебек артистлар булу фактыннан чыгып кына без романтик уен алымнары хакында күпмедер фикер йөртә алабыз.

Шулай итеп, театрның беренче оешкан чорыннан ук актер сәнгате өлкәсендә бездә ике юнәлеш — тормыш-көнкүреш реализмы юнәлеше һәм романтик юнәлеш үсеп килгән.

Шулай да бер хакыйкатьне онытмаска кирәк. Актер иҗатын, тапкырлау таблицасы сыман, артык гадиләштереп аңларга ярамый. Табигатьтә химик яктан саф матдә очратуы кыен булган кебек, сәнгатьтә дә бер генә төрле саф стильләр юк диярлек. Күп милләтле бөтен совет театрындагыча, татар артистларының уены да заман таләпләренә карап үзгәрә торган.

Революция һәм гражданнар сугышы елларында азат кешенең кайнап торган энергиясен гади көнкүреш чаралары белән генә күрсәтергә мөмкин булмаган. Чор рухы театр сәнгатеннән дә героика, романтика таләп иткән. Менә шуңа күрә дә Киевтә «Фуэнте-Овехуна», Мәскәүдә «Каин», Ташкентта «Юлбасарлар», татар театрында «Әлмансур», «Юлбасарлар», «Отелло», «Гамлет» куела. Шушы ук чорда сәхнәдә артисттан турыдан-туры плакатчыл уен таләп иткән агитацион әсәрләр дә бара.

Соңрак исә тагын революциягә кадәр һәм совет чорында язылган тормыш-көнкүреш пьесалары куела башлый. Ләкин бу чорда реализмны аңлау берьяклырак тәс ала, сәхнәдә көнкүреш детальләре белән артык мавыгу сизелә. «Сүнгән йолдызлар», «Американ» һәм безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән башка күп спектакльләр шул хакта сөйли. Ул пьесаларда уйнаган артистлар тышкы хәрәкәтләр белән күп мавыкканнар: өстәлгә, урындыкка барып тотынганнар, йолкынганнар, кулларын кая куярга белмәгәннәр. Артистлар геройның эчке халәтен ачуга тиешле дәрәҗәдә игътибарны юнәлтмәгәннәр. Хәер, персонажның үз-үзен тотыш логикасын белмәү образның асылына үтеп керә алмаудан гына түгел. Монда режиссерларның да гаебе бар, артистларга алар шундый юнәлеш бирәләр. Моңардан тыш, 20 нче елларда театр сезон саен сәхнәгә берничә дистә яңа спектакль чыгарып килгән. Шулай булгач, ре-

[1] Г. Тукай. Әсәрләр, IV том, 1955 ел, 157 бит.

петиция өчен һәр әсәргә бары 3—4 көн генә вакыт бирелгән, бу вакыт эчендә тулы канлы образ иҗат итү турында сөйләп тә торасы юк.

Театр сәнгате өлкәсендә барган кискен көрәш тә артистлар иҗатына йогынты ясамый калмый, билгеле. Ул көрәш репертуар политикасын да һәм совет театрының алга таба үсеш юлын да читләтеп узмый. Шул ук вакытта, төрле уен стильләренең бергә үрелеп баруы совет театрының зур иҗат мөмкинлекләре турында да сөйли. Тик ул чорда татар драматургиясендә идея-сәнгатьчә эшләнеш ягыннан тулы канлы сәхнә әсәрләре җитәрлек булмый. Аларда схематизм үзен нык сиздергән, бу исә, үз чиратында, артистлар иҗатына да йогынты ясамый калмаган.

Хәл тагын шуның белән катлауланган: 30 нчы елларның урталарына кадәр татар театрында психологизм һәм биологизм бер үк нәрсә дип карала, пьесада геройларның шәхси тормышын күрсәтү зарарлы күренеш дигән караш яшәп килгән. Бу — шулай ук актер сәнгатенә зур зыян китергән. 1930 елда ук татар матбугаты: «Режиссер С. Вәлиев психологик һәм биологик моментларны» күпертмәскә тырыша [1], дип язган икән, бу очраклы хәл түгел. Шул ук 1930 елда Г. Кутуй, «Хыял, романтика күп булган... мәхәббәткә зур урын бирелгән өчен», В. Катаевның «Авангард» әсәрен тәнкыйть иткән булса [2], С. Вәлиев исемсез, «массовый герой» образын иҗат итүне яклап чыга. Башкача әйткәндә, татар артистларын аңлы төстә тышкы охшашлык буенча гына образлар тудырырга юнәлтәләр. Әгәр психологик реализм позицияләрендә нык торган өлкән буын артистлар мондый «яңа методка» каршы булсалар, театрга 20 нче елларда килгән яшьләр күбрәк соңгы юнәлешкә иярәләр.

Мондый тенденция соңыннан театрның үсешенә тискәре йогынты ясый. «...Хәзергә барлык актерлар да образның социаль асылын ачарга, геройны аның бөтен катлаулыгы белән күрсәтергә өйрәнеп җитмәгәннәр, — дип яза газета. — Яшь актерлар асылда образның тышкы сурәтен иҗат итү белән чикләнәләр. Образ өстендә өстән-өстән эшләү режиссерларның тиешле дәрәҗәдә җитәкчелек итә белмәүләреннән килә» [3].

20 нче елларның ахырында һәм 30 нчы елларның башында «яңача уен стиленең төп сыйфатлары ачыклана башлый. Яңа иҗат алымын туендырып торган төп башлангыч заманның уңай герое, ягъни дөньяны үзгәртеп кору процессында үзе дә үзгәрүче кеше була. Сыйнфый аныклыгын тулысынча саклаган хәлдә, бу геройның психологик йөзе даими төстә конкретлаша бара, гомумидән индивидуаль як аерылып чыга. Плакатчыл шартлылыктан яңа кешене сурәтләүгә күчү шул процесска тәңгәл килеп тора»[4].

Көчле шатлыкны, һәр төрле шапырынуларны совет иленең, совет кешесенең көченә ышану хисе алмаштыра. Яшьлек кайнарлыгы үз урынын тәпле тәҗрибәгә бирә. Революция романтикасына көндәлек хезмәт романтикасы алмашка килә.

ГИТИС бетергән ике режиссерның — Ш. Сарымсаков белән Г. Исмәгыйловның — эшкә килүе театрның алга таба үсеше өчен бик әһәмиятле була. Алар театрга Станиславский системасына, МХАТчыларның эш стиленә мәхәббәт алып киләләр. 30 нчы елларның икенче яртысында «Габбас Галин», «Ташкыннар», «Таня», «Икмәк», «Мактаулы заман» кебек яңа спектакльләрне шул режиссерлар куя.

Ш. Шамильский, Н. Таҗдарова, З. Солтанов, Ф. Ильская, ул чагында әле яшьрәк булган Х. Әбҗәлилов, Х. Уразиковлар тере кеше образларын индивидуаль үзенчәлеге һәм психологик тәгаллек белән иҗат итәләр.

Икеләнүләр, бер читтән икенче читкә ташланулар дәверен узып, татар театры үзенең төп юлына — реализмга әйләнеп кайтта. Әмма революция һәм яңа совет чынбарлыгы тудырган зур эчтәлек белән баетылган, тулыландырылган хәлдә әйләнеп кайта.

Яңа стильнең үскән һәм чәчәк аткан чорында татар театрында талантлы артистларның бөтен бер плеядасы эшли. Кабатланмас индивидуальлеккә ия булган Ш. Шамильскийны шул плеяданың уң флангысында торучылардан санарга кирәк. Аңа чын, тирән хисләр, драматик характерның тулылыгы һәм тирәнлеге, өстәвенә, янып торган

---

[1] Карагыз: История советского драматического театра. Рус телендә. Мәскәү. 1967. 471 бит.
[2] Шунда ук.
[3] «Красная Татария» газетасы, 1935 ел, 12 январь.
[4] Новаторство советского театра. Рус телендә. Мәскәү, 1963. 234 бит.

темперамент, яктылыкка, шигърияткә, романтик биеклекләргә омтылу хас була. Ш. Шамильскийның эмоциональлеге ул башкарган геройларның эчке логикасын һәм үз-үзен тотышын дөрес күрсәтергә комачауламый. Ул үзенә ике остазның — С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның романтик күтәренкелеген һәм Г. Кариевның тормыш-көнкүреш реализмын сеңдергән талантлы шәхес була.

Сугышка кадәр театрда З. Солтанов, Н. Таждарова, Н. Арапова, Г. Болгарская, Г. Камская, Х. Әбҗәлилов, Х. Уразиков, М. Сульва, Ф. Ильская, Г. Булатовалар кебек сәнгатебезнең данын еракларга шаулаткан бик күп артистлар эшли.

Сугыш еллары сәнгатьтән алгы планга уңай герой мәсьәләсен куюны таләп итә. Тамашачыларга баштанаяк коралланган дошманга каршы көрәшүче совет кешесенең бөтен көчен һәм ныклыгын ачып бирергә кирәк була. Сугыштан соңгы чорга татар театры иҗади үсешнең төрле баскычларын узган бердәм коллектив булып килә.

Революциягә кадәр театрда анык билгеләнгән ике юнәлеш — романтик һәм тормыш-көнкүреш юнәлешләре яшәп килә, дидек. Совет власте елларында безнең артистлар, агитацион-плакатчыл, романтик, формалистик уен алымнары аша узып, яңа биеклеккә күтәреләләр. Ниһаять, идеялелекне тирән психологик дөреслек һәм характерларның эмоциональ яңгырашы белән бергә үргән социалистик реализм методы татар театрына заманга лаек сәхнә әсәрләре тудырырга мөмкинлек бирә.

60 нчы еллардагы яңарыш репертуарны баетудан башлана. Сәхнәгә татар драматургларының яңа пьесалары һәм тәрҗемә әсәрләре күпләп куела, классик мираска яңа мөнәсәбәт булдырыла. Режиссерлар белән бергәләп, артистлар театр сәнгатенең уен традицияләрен тәнкыйть күзе аша уздыралар. Нигез итеп реаль-психологик стиль алына, ләкин хәзер инде ул әсәрне идея-социаль яктан тирәнтен ачу белән баетыла, идеялелек үзе һәр образның, бөтен спектакльнең масштаблыгын, халыкчанлыгын күрсәткән төп сыйфат төсендә чагыла. Татар артистлары иҗатына хас романтик агым, шапырынулы пафостан бигрәк, шигърият һәм югары илһам төсен ала. Репертуарга, психологик драмалар белән бергә, чын мәгънәсендәге трагедия, фарс, мелодрама, водевиль, героик-романтик драмалар һәм халык драмасы кертелә. Спектакльләр ачык театраль форма, яхшы мәгънәсендәге тамаша төстен алалар. Һәр әсәрне куйганда, режиссер һәм актерлар теге яки бу формадагы яңа алымнарны табарга һәм ныгытып калырга тырышалар. Әһәмиятле һәр сәхнә әсәрен кую иҗади эзләнү, актер сәнгатенең төрле алымнарын үзләштерү юлында яңа бер баскыч төсен ала. Бер үк артистлар көчләрен төрле-төрле жанрларда, еш кына бөтенләй көтелмәгән әсәрләрдә сынап карыйлар. Болар барысы, ахыр чиктә, актер сәнгатенең иң яхшы традицияләрен үзләштергән һәм аны яңа сәнгать чаралары белән баеткан сәхнә осталарының үсеп чыгуына китерә. Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә без бүген бик күп пландагы актерларны күрәбез. Психологик драма татар театрының күптәннән үк иң яраткан жанры булып санала. Бүген дә бу жанр репертуарда төп урынны алып тора. Ләкин бүгенге артист әлеге традицион төрдәге спектакльләрдә дә моннан 20—30 ел элек уйнаган кебек уйнамый. Алай гына да түгел, бүгенге артист, аерым очракларда, үзенең гадәти амплуасы чикләреннән чыгып, капма-каршы жанрларда уйный ала.

42 яшендә үк РСФСРның халык артисты исемен алган Шәүкәт Биктимеров иҗаты шуның матур үрнәге булып тора. Аның геройлары һәр чакта да җиргә нык басып атлыйлар. Аларның барысы да үтә җир кешеләре, бик гадиләр. Безнең һәммәбез кебек үк, алар көндәлек борчылулар һәм мәшәкатьләр белән яшиләр. Артист шул гадилеккә хәтта махсус басым ясый. Шуңа күрә Ш. Биктимеров геройларын баштан ук яхшы танышларың кебек кабул итәсең. Әгәр ул иҗат иткән рольләрне искә төшерсәк, аларның һәркайсында башкаручының үзен танырга мөмкин. Артистның тышкы хәрәкәтләре: йөреше, сөйләү манерасы һәр әсәрдә бер үк төрле була. Ул һәр вакыт җиңел, вак адымнар белән, бераз гына чайкалып сәхнәдә йөри, үзенең йомшак, аз гына карлыккан баритон тавышы белән сүзләрен әзеп-әзеп, ачык итеп әйтә. Ш. Биктимеровның индивидуаль кешелек сыйфатларыннан ягымлылык, лирик җылылык ахырдан ул башкарган бик күп образларның аерылмас сыйфатына әйләнде. Ш. Биктимеров — психологик реализм юнәлешендәге артист. Бу мәсьәләдә ул татар артистларының бай традицияләре эзеннән бара һәм, шул ук вакытта, аларны дәвам иттерүче дә булып санала.

Ш. Биктимеровның иң яхшы рольләре зур гомумиләштерү көченә ия. Актер иҗат иткән образлар — үзләренең күп кырлы чагылышларында җанлы тормыш геройлары. Ул әшәке, пычрак Ислам («Әни килде»), алдакчы, җиңел холыклы буш куык Дульчин («Соңгы корбан») кебек поляр тестә капма-каршы рольләрне уйный. Ниһаять, Н. Погодинның «Баһадирлар»ында кыеннан да кыен — Ленин образы.

Ш. Биктимеров, Н. Гәрәева, Ш. Әсфәндиярова, Р. Таҗетдиновлар театрның күптәнге традицияләрен аеруча баеткан беренче спектакль «Гүзәлем Әсәл» булды. Бу спектакльдә артистлар герой хисләренең нәтиҗәсен бирү белән генә чикләнмиләр, алар фикер йөртәләр, анализ ясыйлар, янәшә куеп, чагыштырып карыйлар. Алар өчен персонажның гамәле үзе түгел, ә шул гамәлнең мотивлары мөһим. Бу спектакльдә артистлар геройның эчке тормышын, герой кылган гамәлләрнең эчке логикасын күз алдына бастырырга тырышалар. Шуңа күрә алар герой характерын бөтен катлаулылыгында күрсәтеп бирәләр.

Психологик спектакльләр хакында сөйләгәндә, Татар академия театрындагы кичерәш мәктәбенең ачык вәкиле булган Ш. Әсфәндиярова кебек актрисаны читләтеп узу мөмкин түгел. Академия театры артистларының өченче буын вәкиле Ш. Әсфәндиярова, үз яшендәге башка артистлар кебек үк, татар театрының традицияләрен дәвам иттерүче дә һәм яңа алымнар белән ул традицияләрне баетучы да. Ш. Әсфәндиярова һәр образның психологик асылын көчәйтеп ачарга сәләтле. Шуңа да ул иҗат иткән геройлар ифрат күп кырлы һәм күп сыйдырышлы була. Ул һәр образга аның характерының үсеш логикасыннан чыгып якын килергә тырыша. Ләкин шул ук вакытта теләсә кайсы рольдә Ш. Әсфәндиярованың үз поэтик индивидуальлеге чагыла. Ул иҗат иткән Диана («Сукыр»), Хәдичә («Гүзәлем Әсәл»), Тугина («Соңгы корбан»), Галина («Туган туфрак») кебек рольләрнең үзегеннән, кызыл җеп булып, артистканың яраткан темасы — кыенлыкларга бирешмәгән хатын-кызларның драматик язмышы уза.

Сәләтләре «Гүзәлем Әсәл»дә тулы ачылган тагын ике артист — Н. Гәрәева белән Р. Таҗетдиновка да нечкә психологизм хас.

Трагизмга якын эчке ялкын, киеренке драматизм, интеллигент натураның вакыты белән аскетик кырыслык, әхлакый максимализм югарылыгына күтәрелгән нечкә шигърилеге. Бәләкәй, нәфис гәүдәле, тирән карашлы актриса Наилә Гәрәевага хас бу сыйфатлар башта Әсәл образында, соңрак Гөлтекин («Айдын»), Изабелла («Чамасына күрә чарасы»), Энҗе бикә («Кол Гали») кебек рольләрдә тулы чагылды. Н. Гәрәева иҗат иткән образлар бик лаконик була, аларда бер артык хәрәкәт күрмәссең. Мимика бөтенләй юк дәрәҗәдә, бары тик тәэсирчән күзләре генә күңел түрендәгене сөйли. Аның геройлары күңелендә кайнаган хисләр ихтыяр көче белән пружина кебек кысылган була.

Н. Гәрәеваның партнеры Ринат Таҗетдинов үз геройларын төрле алымнар белән тудыра. Кайчак бер үк рольдә ул бөтенләй капма-каршы буяулар белән эш итә. Әйтик, Ильяс безнең алга төрле төсмерләрдә килеп баса: менә ул яшьлек дәрте ташыган егет; ул да түгел, үз-үзенә артык ышанган тәкәббер кеше. Менә ул чын күңелдән Әсәлгә гашыйк. Шунда ук тасвир чаралары да үзгәрә — нәзакәтлелек, йомшаклык, шигърилек пәйда була. Хәрәкәтләре тыйнаклана, эчке җыйнаклык барлыкка килә. Ниһаять, Ильясның өченче халәте — хисләрен белдерүдә соң чиккә җиткән саранлык, вакыты-вакыты белән ашкынып алу, әмма сулган, арган гәүдәсендә — көчсезлек, өметсезлек һәм үкенү хисе. Алга таба артист репертуарында Искәндәр («Хуш, Назлыгөл»), Надир мәхдүм («Сүнгән йолдызлар») кебек эмоциональ геройлар, Инсаф («Әни килде»), Чешков («Чит кеше») кебек кырыс персонажлар барлыкка килә. Эзопта («Эзоп») һәм Кол Галидә кыргый темперамент аскетик сабырлык белән кушыла, Дәүләт-бине («Айдын») сурәтләгәндә тагын яңалык — ясалма кылану, төчелек, нәзакәтле хәрәкәтләр.

Өлкән буын артистларның бер вәкиле булган Фуат Халитов та тирән психологик алым белән иҗат итә. Тормышчан булуы белән күңелләрне тетрәтерлек образларын тудыруга артист, бер караганда, аз гына да көч куймый кебек. Аның геройларының эчке тормышы шул кадәр реаль була, артист үз геройларының гамәлләрен шул кадәр шәп белә ки, образның җеп очы бер урында да өзелми, хәрәкәт барышында акылга хилаф берninди кимчелек булмый. Ул тудырган характерларның ка-

миллеге — әнә шуннан. Ф. Халитовның образлар иҗат итүдәге бу үзенчәлеге аның өлкән остазларыннан, бигрәк тә Ш. Шамильскийдан килә, дип әйтә алабыз. Ф. Халитов репертуарындагы Шадрин («Мылтыклы кеше»), Муса («Муса Җәлил»), Сәгъдетдин («Шамил Усманов»), Әхтәм («Ир-егетләр»), Прибытков («Соңгы корбан»), Рисположинский («Агай-эне ак мыек») кебек иң яхшы рольләргә шул сыйфат хас. Төрле характердагы уңай һәм тискәре рольләрне башкарып килгән Ф. Халитов — реалистик, психологик уен мәктәбенең типик вәкиле. Аны героик яки романтик рольдә күз алдына китерүе кыен. Ф. Халитов өчен һәр рольнең эчке монологы кыйммәт, ул шуны бөтен спектакль буена алып бара. Актер бер генә минутка да образ тормышы белән яшәүдән туктамый, партнерлары белән һәр вакыт тыгыз контактта була.

Олы буын вәкилләреннән Габдулла Шамуков шулай ук — психологик уен остасы. Татар театрының күп төсле палитрасында артистның иҗаты үзенә генә хас яклары белән аерылып тора. Г. Шамуков төрле жанрларда уйный, шулай да аның барлык персонажларында комизм элементы, күпмедер күләмдә чудаклык сизелә. Нәкъ менә шушы кабатланмас индивидуальлеге ул башкарган Хуҗа Насретдин, Купьелло («Бәйрәм кичендә»), Ксанф («Эзоп»), Муса («Американ»), Максуд («Әни килде») кебек рольләргә саф Шамуковча мөлаемлык бирә. Г. Шамуков бернинди комизм катнашмаган тулы канлы драматик характерлар тудырырга да сәләтле. Мәсәлән, күптән түгел иҗат иткән образларыннан Мәрвән («Ир-егетләр») һәм Шекспирның хәйләкәр, акыллы сарай хезмәткәре Полонийны хәтерләтүче Актай («Кол Гали») шундыйлар.

Психологик драма һәр чак театрның активында булды. Бу жанрда татар артистлары тормышчан бик күп образлар иҗат иттеләр. «Соңгы корбан», «Әни килде», «Ир-егетләр», «Эңгер-меңгер», «Хуш, Назлыгөл», «Чит кеше», «Борчылма, әнием» кебек спектакльләрдә менә дигән актер уеннарын күрдек.

Бөтен әсәрнең, шулай ук һәр рольнең социаль тирәнлеген ачу — бүгенге спектакльләр алдына куела торган төп таләп. Бу тенденция татар драматургларының пьесаларын һәм тәрҗемә әсәрләрне куйганда да ачык сизелә. Театрның яңа спектакльләрендә кеше тормышына, кеше аңында барган процессларга игътибарлы мөнәсәбәт ачык күренә. «Ир-егетләр» һәм «Чикләвек төше»ндәге кебек, идеяне уңай башлангыч аша ачамы, әллә «Әни килде», «Хуш, Назлыгөл»дәгечә, тискәре персонажларны фаш итү аша ачамы, театр актив төстә мещанлыкка, тук һәм ваемсыз көн итүгә, өч тиенлек бәхеткә каршы чыга. Шуңа бәйле рәвештә, режиссерлар акцентларны драмада чын белән ялганның көрәше эре планда күрсәтелгән төп моментларга ясыйлар.

Соңгы елларда куелган күп кенә спектакльләр мисалында актерның роль өстендә ни рәвешле яңача эшләүләре хакында да сөйләргә мөмкин. Элегрәк өлкән буын артистлар уенында башкаручының роль белән тулысынча тәңгәл килүе төп принцип булып санала иде. Яңа буын артистлар роль белән ахыргача тиңләшеп бетмиләр. Алар образның уй-тойгылары белән яшәп кенә калмыйлар, әле тагын, Б. Захаров язганча, образның фикерләре һәм хисләре уңае белән фикерли һәм хис тә итәләр. Актер сәнгатенең төп законы — тулысынча кушылу, актерны образ белән тәңгәлләштерү түгел, ә аларның диалектик берлеге. Әмма бу алым һич тә ялангач тамашага алып килми. Психологик тулылык үз көчендә кала. «Күк капусы ачылса», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Американ» кебек комедияләрдә әлеге алым аеруча ачык чагыла. Бу спектакльләрдә катнашкан артистлардан, һәр вакыттагыча, хисләр төгәллеге таләп ителә иде, икенче яктан, бу төгәллек буффонада, трюк формасына төренгән булырга да тиеш иде.

«Американ»да Искәндәр баштан ук «уен уйный». Шуңа күрә аңарда ике кеше — җаваплы бурыч үтәүче совет студенты һәм ата-бабалары җиренә кайткан «американец» бергә яши. Әлеге ике кеше белән бергә, тамашачы даими төстә өченче затны — актерның үзен дә сизеп утыра. Башкаручының үз шәхесе катнашу образга аерым бер колорит бирә. Студент ролендәге артистның үз «американец»ы өстеннән мыскыллап көлүе һәркемгә аңлашылып тора. Рольгә бу рәвешчә якын килү безнең театр өчен яңалык иде.

Равил Шәрәфиев — бүгенге татар театрының иң эксцентрик артисты. Аңа әнә шундый үткен формалар якын. Артист анык һәм ачык билгеләнгән комик талантка ия. Ләкин аңа шаянлык бөркелеп торган мәйдан тамашасы характерындагы көлке ту-

гел, ә сатирик яктан үткенәйтелгән, күпмедер дәрәҗәдә скептик-ироник пландагы комиклык хас дияр идем.

«Американ»да катнашучылардан Г. Шамуков, Ф. Халитов, Г. Надрюков, Ф. Әхтәмова һәм И. Гафуров та, заманча фикерләү логикасы буенча эш итеп, үз геройларын ачыктан-ачык сурәтләделәр. Бүгенге заман актерлары буларак, алар сәхнәдә персонаж тормышы белән яшәсәләр дә, образга үз мөнәсәбәтләрен дә ачык белдерделәр. Алар рольләрендә тормышчан иделәр, шул ук вакытта үз геройларыннан эчтән генә көлә дә белделәр, үзләре сурәтли торган кешеләрнең юләрлеген, кылган эшләренең мәгънәсез булуын фаш иттеләр.

«Американ»ны куйганда тупланган тәҗрибә алга таба Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» пьесасын сәхнәләштергәндә файдалы булды. Жанры буенча ул водевиль, аннан да бигрәк мюзикл. «Ламанч кешесе», «Вестсайд тарихы» кебек, безнең илдә киң таралган мюзиклар трагик һәм трагикомедик характерда иделәр, ә «Диләфрүзгә дүрт кияү» исә — саф комедия. Ләкин артистларның һәм режиссерларның эш алымы, образга якын килү принцибы бер үк. Бу спектакльләрнең барысында да уен, тамаша моменты өстен тора. Актер алдына бик кыен бурыч куела. Әгәр традицион психологик драмада артист, үзе уйный торган рольнең күңеленә тирән үтеп кереп, баштан ахырга кадәр шул образ булып калса, мюзиклда инде образга керә белү һәм, әгәр шулай әйтергә яраса, образдан чыга белү сорала.

Т. Миңнуллин комедиясендә дүрт кияү адым саен көлке хәлләргә эләгәләр. Әмма шулай да пьесадагы һәр персонаж анык билгеләнгән характер сыйфатына ия. Әйтергә кирәк, бу — Т. Миңнуллин драматургиясенең көчле ягы. Татар артистлары, бигрәк тә дүрт кияүне башкаручылар өчен төп кыенлык шунда, алар спектакль барышында үзгәреп торырга тиеш булалар. Яңалыкның «Американ»ны куйганда ук табылган икенче моменты — башкаручының үз герое юләрлегеннән ачыктан-ачык көлеп, аны мыскыллап уйнавында. Бу момент бигрәк тә Р. Шәрәфиев һәм Д. Ильясов уенында ачык күренде.

Деллюс Ильясов театрга 1949 елда ГИТИС тәмамлагач килә. Аның артистлык индивидуальлегенә интеллигентлык, нәзакәтлелек хас. Соңгы вакытка кадәр ул бары тик драматик пландагы артист булып саналып йөрде. «Чамасына күрә чарасы», «Фигароның өйләнүе», «Диләфрүзгә дүрт кияү» кебек спектакльләрдә катнашу аңарда сәхнә осталыгының моңарчы күрелмәгән яңа яклары — нечкә комедиячел башлангыч булуын ачты.

Героик-романтик жанрдагы эзләнүләрне Г. Камал исемендәге театр төрле спектакльләрдә — Бразилия драматургы Г. Фигерейдоның «Эзоп» әсәрен куйганда, башкорт легендасы буенча язылган «Нәркәс»тә, революцион драма «Шамил Усманов»та, тарихи трагедия «Кол Гали»дә алып барды. «Эзоп» театрның уен алымындагы тормыш-көнкүреш чынлыгын оформлениедә дә, актер уены планында да тулысынча кысрыклап чыгарды. Спектакльдә кайнар канлы, темпераментлы кешеләр белән очраштык. Спектакльнең героик-романтик яңгырашы, тулаем алганда, төп герой образы, шулай ук спектакльгә режиссер куйган акцентлар аша җиткерелде.

Ике гашыйкның трагик язмышы турындагы «Нәркәс» легендасыннан да театр романтик башлангыч эзләде. Спектакльдә көнкүреш, этнография юк. Ул кешене куркытып шомландырырлык та, шул ук вакытта көчле тәэсир дә итәрлек итеп бизәлгән иде: ерткыч кошларны хәтерләткән тау кыяларе, караңгы, шомлы тау куышлары... Спектакль бик бай бизәлгән, урыны-урыны белән хәтта артыграк та бизәлгән. Кайчакларда геройларны нинди милләт киемендә икәнен дә аерып булмый.

Шулай да бу очракта көнкүреш ваклыгыннан качарга омтылу спектакльне икенче бер чиккә — психологик дөреслек, ышандыру көче кимүгә алып килде. Нәтиҗәдә персонажларның хисләре абстракт төс алды. Тулы канлы конкрет характерлар тудырмый торып, артык гомумилеккә омтылу рациональлеккә китерде, тамашачы спектакльне салкын кабул итте. Сәхнәдә чын кеше тормышы күренмәде.

Башкорт театрыннан Казанга килгән яшь артистка Рәмзия Хисамованың Нәркәс ролен башкаруы гына спектакльнең бер казанышы булды. Артистка югары шигърияткә, эмоциональ тәэсир көченә ия образ иҗат итте. Р. Хисамованың мондый уңышы бик табигый күренеш, ул башкорт театры традицияләрендә тәрбияләнгән артистка, Нәркәс образында ул татар театрына хас психологизмны һәм башкорт артист-

ларына хас югары стильне бергә куша алды. Нәтиҗәдә гаҗәеп тормышчан һәм романтик күтәренке образ туды.

А. Гыйләҗев белән А. Яхиннның «Шамил Усманов» драмасы да романтик әсәрләр рәтенә керә. Мөлаем, яшь, чибәр Усманов — артист Наил Дунаев — үзенең сугышчыларын темперамент белән генә түгел, революция идеяләрен дөрес һәм гади итеп аңлатуы белән дә тәрбияли. Н. Дунаев, Ә. Шакиров (Карип), И. Баһманов (Каюм) башкарган рольләргә канатлы күтәренкелек хас, аларның хәрәкәтләре беркадәр экспрессив, сүзләре дәртле, характерлары эмоциональ көчле. Ләкин күтәренке стиль ялган пафоска алып килмәде. Бу аларның әсәр чынбарлыгында үз урыннарын дөрес аңлауларыннан килә. Алар — гасырлар буена сузылган коллыктан азат булган, азатлыкның кадерен һәм бәясен тирән аңлаган хөр рухлы кешеләр, үзләрен ахыргача бәйсезлек өчен көрәш эшенә багышлаган кешеләр. Героик тема героик төстә гәүдәләнгән характер да таләп итә. Искитмәле кыюлык, өлгерлек шуннан килә. Спектакльдәге геройларның үз-үзләрен тотышында җирдән аерылуның, абстракт пафосның эзе дә юк. Образның романтик омтылышы психологик һәм тормышчанлык ягыннан ышандырырлык булып чыкты.

Башка милләт язучылары әсәрләренең образларын гәүдәләндерү артистлардан аеруча күп көч сорый. Г. Камал исемендәге театр тәрҗемә әсәрләрне сәхнәгә куйганда төп игътибарны аларның социаль асылын ачуга юнәлтә. Милли үзенчәлеккә үтеп керү исә, әгәр актер образның үсеш логикасына тугрылыклы булса, үз индивидуальлеген саклаган хәлдә дә табигый килеп чыга. Чөнки теләсә кайсы милләт язучысының талантлы әсәрендә шул халыкның үзенчәлекләре чагылмый калмый. Шуңа күрә татар артистлары башка милләт вәкилләре образын башкарганда ике милләт культурасының синтезы барлыкка килгәндәй була. Театрда бүгенге совет театр сәхнәсенә хас төп тенденцияне — милли һәм интернациональ якларның бердәмлеген күзәтергә була. Ул иҗат методының берлеге һәм бер милләт культурасының икенче милләт культурасына булган тәэсире, татар театр сәнгатенә башка халыкларга хас сурәтләү чараларының органик төстә килеп кушылуы белән аңлатыла.

Безнең театрда кабатланмас үзенчәлекле бик күп осталар эшли. Көчле темпераментлы, эмоциональ Ринат Таҗетдинов, эксцентрикага, фарска тартым Равил Шәрәфиев, интеллигент табигатьле Шәүкәт Биктимеров һәм Наил Дунаев, лирик-драматик Шәхсәнәм Әсфәндиярова һәм Гөлсем Исәнгулова, кырыс һәм импульсив Наилә Гәрәева, социаль пландагы Фуат Халитов, комедиячел характерлы Габдулла Шамуков, драматик-трагик һәм гротекс юнәлешендәге Гәүһәр Камалова, төрлесе төрле характердагы Деллюс Ильясов, Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, Асия Галиева, Әнвәр Гобәйдуллин, Фирдәвес Әхтәмова, Рауза Әхмерова, Барый Әшрәпов, Һидият Солтанов, көнкүреш планындагы көчле артистлар Вера Минкина, Галия Нигъмәтуллина, Марзия Миңлебаева һәм Асия Харисовалар... Ләкин шул кадәресен билгеләп үтәргә кирәк, аларның берсе дә үз амплуасы белән генә чикләнми, кайвакыт үз индивидуальлекләренә бөтенләй туры килмәгән рольләр башкаралар.

Соңгы елларда сәләтле яшьләр үсеп чыкты. Хәлим Җәләлов, Наил Әюпов, Роберт Абдульмамбетов, Фирдәвес Хәйруллина, Илдар Хәйруллин, Наилә Ибраһимова, Илдус Вәлиев, Сәлим Мифтахов, Рәшит Шамкаев үзләрен кызыклы артистлар итеп күрсәттеләр. Алар барысы да Казан театр училищесын тәмамлап театрга килделәр. Театрның труппасы ел саен тулыланып тора, шуңа күрә анда төрле буын вәкилләре кулга-кул тотынып эшли.

Шулай итеп, театрыбыз сәнгате мәгълүм бер этап үткән. Алда — яңа горизонтлар, яңа бурычлар. Бүгенге театрдан дөнья драматургиясе ирешкән биеклекләрне үзләштерү юлында кыюлык һәм тәвәккәллек теләргә кала.

**Әхмәт Фәйзи**

# ТУКАЙ ҺӘМ РУС ӘДӘБИЯТЫ

Алдынгы татар интеллигенциясе һәм, беренче чиратта, язучылар өчен рус әдәбияты прогрессив характердагы фәнни һәм әдәби фикернең төп чыганагы була. Бу өлкәдә беренче зур адым итеп рус классикларының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүне санарга кирәк.

1905 елга кадәр Пушкин, Лермонтов, Крылов, Гогольнең аерым әсәрләре генә тәрҗемә ителә һәм күпчелек очракта уңышсыз тәрҗемә ителә. 1905 елдан алып, рус классикларыннан Пушкин, Лермонтов, Толстой, Тургенев, Чехов, Горький, Островскийның, шулай ук Л. Андреев, Куприн һәм башкаларның төп әсәрләре аерым басмаларда Тукай, Камал, Әмирхан, Рахманкуловларның югары сыйфатлы тәрҗемәләрендә күренә башлый.

Рус әдәбиятында дөнья культурасының бөтен даһилыгы чагылган. Көнбатыш Европа әдәбияты классиклары Данте, Шекспир, Гете һәм Сервантес рус теленә менә дигән тәрҗемәләре аркасында татар укучыларына барып җитә, рус теле, шул рәвешчә, татар халкын да гомум кешелек мәдәниятенең гениаль казанышлары белән таныштыру вазифасын үти.

Шулай да бу чорда әле татар язучыларының чит тәэсирләрне кабул итү дәрәҗәсе һәр очракта да бер төсле булмый. Аларның беришеләре тормышның натуралистик күренешләренә тартымлык күрсәтә, икенчеләре буржуаз көнкүрешне идеаллаштыра, арада саф сәнгать тарафдарлары, декадент шагыйрьләр һәм язучылар да була.

Әмма татар әдәбиятының алдынгы өлеше зур рус әдәбиятының төп сыйфатын тәшкил иткән таза җирлеккә тугрылыклы булып кала. Г. Тукай, М. Гафури, Г. Коләхметов, Г. Камал, Ш. Камал, Ф. Әмирхан һәм башкаларның иҗаты, елдан-ел критик реализм югарылыгына күтәрелә барып, нәкъ менә шул юлдан үсә.

Характерлы бер моментны читләтеп узарга ярамый. Югарыда исемнәре аталган язучыларның иҗаты, тегеләйме-болаймы, пролетариат әдәбиятына нигез салучы М. Горький иҗатына мөнәсәбәттә була. Әлеге язучыларның әсәрләрендә капитализм строе тарафыннан җәберләнгән кешеләрнең Горькийча сурәтләнгән образларын татар әдәбиятында беренче мәртәбә очратабыз. Бу хакта язучылар үзләре язалар. Г. Коләхметов, мәсәлән, «Яшь гомер» исемле пьесасының тышлыгына турыдан-туры: «Бу әсәр мәшһүр рус мөхәррирләреннән Максим Горькийга тәкълидән язылмыштыр»,— дип күрсәтә.

Г. Камалның «Бәхетсез егет» пьесасында «тормыш төбендәге» геройлар Горькийның «Кояш чыга да бата» дигән җырын татарча җырлыйлар һ. б.

Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестенда Каспий балык промыселлары эшчеләре тормышын сурәтләү Горькийның «Челкаш»ын, «Мальва»сын яки «Ана» романының геройларын хәтерләтә һ. б.

---

Мәкалә 1946 елда Г. Тукайның 60 еллыгына багышланган гыйльми сессиядә сөйләү өчен язылган булган. Моңарчы беркайда да басылмаган. Аны рус теленнән Ф. Миңнуллин тәрҗемә итте.

Тукай үзенең проза әсәрләрендә, зур рус язучысы, реакцион мещанлыкның явыз дошманы буларак, Горькийны махсус аерып күрсәтә.

Тукайны, шагыйрь буларак, барыннан да бигрәк, рус әдәбиятының реалистик рухы үзенә тарта. Бу — соңыннан Бөек Октябрь революциясе җиңүен оештырган һәм тарихта беренче булып хезмәт ияләре тормышын социалистик үзгәртеп кору эшен башлап җибәргән бөек халыкның әдәбияты була.

Татар халкы бөек рус халкына туганлык җепләре белән бәйләнгән. Һәм күп еллар бергә яшәү нәтиҗәсендә ул аның белән географик уртаклыкка һәм этнографик туганлыкка гына түгел, ә бәлки сәяси бердәмлеккә дә ирешә.

Шуңа күрә рус әдәбиятының демократик азатлык идеяләре Тукай иҗатында үзенә иң уңдырышлы җирлек таба. Әгәр Тукай әдәбият мәйданындагы беренче адымын А. Кольцовның «Что ты спишь, мужичок?» исемле шигырен иркле тәрҗемә итеп язган «Мужик йокысы» әсәре белән ясаган икән, бу бер дә очраклы хәл түгел. Эш шунда ки, Тукай рус шагыйренең әлеге шигырен тоташ хәерчелек һәм мохтаҗлык шартларында изелеп яшәгән һәм хәзер инде Беренче рус революциясенең шифалы нурлары тәэсирендә йокыдан уяну, үз-үзенә карау мөмкинлеге алган татар халкына чакыру итеп файдалана.

Иҗатының халыкчанлыгы, күтәргән темаларының социаль үткенлеге ягыннан Тукай, барыннан да элек, Н. А. Некрасовка якын.

Некрасов «халык кайгысын кайгыртучы» шигыйрь дип йөртелә. Шул ук сүзләрне Тукайга карата да кулланырга мөмкин. Һәр ике шагыйрь иҗатында изелгән кешеләрне, башлыча, ярлы крестьяннарны кызгану мотивлары өстенлек итә. Некрасов әсәрләренең герое — рус мужигы рус поэзиясеннән традицион дворян образларын кысып чыгара. Некрасов әсәрләрендә дворян типлары тискәре образ буларак кына һәм мужик тормышының хәерчелеге өчен гаепле кешене күрсәтергә кирәк булган очракта гына урын ала. Тукайда да шул ук хәл. Татар поэзиясендә беренче мәртәбә Тукай мужикны акыллы, зирәк, барлык кыенлыкларны җиңеп чыккан уңай персонаж итеп күрсәтә («Шүрәле», «Петр бабайның хикаяте» һ. б.). Шуңа да мужикның патша, становой, татар бае һәм мулла тарафыннан социаль изелүе аңа гаделсезлек булып күренә («Золым», «Сайфия», «Көзге җилләр», «Государственная дума», «Хөррият хакында» һ. б.). Некрасов кебек үк, Тукай аристократларны һәм байларны чын ачу, нәфрәт белән камчылый, аларны хезмәт халкының җелеген суыручы соры кортлар дип атый («Соры кортларга», «Матбага белән уйнаган бер байга», «Сайфия» һ. б.). Шагыйрьнең чиновникларга, дин әһелләренә мөнәсәбәте дә шундый ук («Дусларга бер сүз», «Мулланың зары», «Ишан», «Пыяла баш» һ. б.).

Некрасов кебек үк, Тукай үзе яшәгән чорның борчулары белән яна. Аны мужикның һәм эшченең көндәлек ихтыяҗлары борчый, шуңа да аның поэзиясе зур тәэсир көченә ия. «Государственная дума» шигырендә, дәүләт каршында мужикның мәнфәгатен яклап, ул болай ди:

**Ач-ялангач мужикларга**
**Кайда ирек, кайда җир! —**
**Ах, син, Дума, Дума, Дума,**
**Эшләгән эшең бума!**

**Бирәм, дидең, вәгъдә бирдең,**
**Күрсәт җирең! Кайда! Бир! —**
**Ах, син, Дума, Дума, Дума,**
**Эшләгән эшең бума!**

Завод-фабрикадагы коточкыч авыр эш шартларын сурәтләп («Казан», «Кярханәдә» шигырьләре), шагыйрь эшчеләрне көрәшкә чакыручан сәяси агитациягә кадәр күтәрелә («Тавыш хакында»).

Некрасов һәм Тукайның революционерларга зур мәхәббәт хисләре белән сугарылган шигырьләре бар. Некрасовның «Добролюбовка» дигән шигыре Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» шигыре белән ифрат аваздаш яңгырый.

Алга омтылу, киләчәккә, яшьләргә өмет баглау Тукайга да, шулай ук Некрасовка да хас. Үзенең тема һәм идеяләре белән генә түгел, аларны укучыга җиткерү формасы ягыннан да Тукай Некрасовка якын. Некрасов әсәрләрендә кирәк булганда

югары политик сатирага кадәр күтәрелә торган юмор Тукай иҗаты өчен дә характерлы. Тормыштагы сатирик якларны гомумиләштерү һәм аларны югары социаль яңгырашлы итү ягыннан Тукай шулай ук Салтыков-Щедринга да якын тора.

Пушкин («Деревня», «Вольность», «Памятник», «Декабристам» һ. б.), Лермонтов («Смерть поэта», «Прощай, немытая Россия», «Жалобы турка» һ. б.) шигырьләрендәге революцион мотивлар Тукай шигырьләрендә бер генә тапкыр кабатланмый. Аның «Авыл халкына ни җитми», «Соры кортларга», «Государственная думага», «Кярханәдә», «Сайфия», «Көзге җилләр», «Казан», «Толстой сүзләре» кебек шигырьләре, исемнәре саналган рус шагыйрьләренеке кебек үк, ярлы халыкка мәхәббәт һәм кызгану хисләре белән сугарылган, байларга һәм эксплуататорларга шундый ук нәфрәт, яңа социаль тәртипләр нигезендә бу тормышны үзгәртеп коруның зарурлыгына шундый ук ышаныч белән сугарылган.

Пушкинның «Узник» шигыре, йөз елдан соң, икенче бер торгынлык чорында, башка бер халык поэзиясе җирлегендә Тукай тәрҗемәсендә яңача ифрат урынлы яңгырады.

Крепостнойлык чорындагы мужик турында Пушкин болай дип язган иде:

**Склонясь над чуждым плугом, покорствуя бичам,**
**Здесь рабство тощее влачится по браздам**
**Неумолимого владельца.**
**Здесь тягостный ярем до гроба все влекут,**
**Надежд и склонностей в душе питать не смея...**

Йөз еллап вакыт узгач, моны «Золым» исемле шигырендә аның шәкерте Тукай кабатлый, ул аны, инде крепостнойлыктан котылса да, Столыпинның кара реакциясе җәбере астында изелгән мужикның ыңгырашуы итеп кабатлый:

**Мескен фәкыйрь, иркен сулыш та алмыйсың,**
**Аһ-ваһыңнан һичбер вакыт бушанмыйсың;**
**Көчләү сине сарих золым иман белән:**
**Иртәгә ач үлмәм дип тә ышанмыйсың.**

Тукай Пушкин, Лермонтов һәм XVIII, XIX, XX йөзләрдәге башка рус шагыйрьләренең иҗатына соклана. Әмма тәрҗемә һәм тәкълидләр өчен ул үз халкының социаль настроениесенә һәм милли үзенчәлегенә туры килгән әсәрләрне генә сайлап ала.

Мәсәлән, рус поэзиясенең анакреонтик[1] характердагы өлкәсе кул тимәгән килеш кала бирә. Чөнки андый шигырьләр татар укучыларының табигатенә һәм рухына аз туры килгән. Ул рус шагыйрьләре шигырьләрендә үз халкының фикер агышына һәм эстетик рухына җавап бирерлек тирән мәгънә эзли һәм аны таба да.

Шул ният белән ул рус шагыйрьләренең төп әсәрләренә генә түгел, ә бәлки аларның аз билгеле һәм тәмамланмаган әсәрләренә дә мөрәҗәгать итә. Пушкинның:

**Пока супруг тебя, красавицу младую,**
**Между шести других не заключал...**

— дип башланган шигыре, мәсәлән, шулай файдаланыла.

Бу Тукайга хатын-кызның шул чордагы татар тормышы өчен бик характерлы булган хокуксыз хәлен күрсәтү өчен кирәк була. Әлеге темадан файдаланып, Тукай берәр байның алтынчы яки җиденче хатыны булырга хөкем ителгән татар кызының аяныч язмышы турында элегия[2] яза.

Соңыннан ул теманы «Фәрьят» исемле оригиналь шигырендә тагын да киңәйтә төшә. Ул шигырь 1914 елда, М. Горький тәкъдиме белән, рус теленә тәрҗемә ителә һәм Лазарев институты җыентыгында басылып чыга. Бу шигырьдә реалистик форма белән фанатик семьяда кол хәленә төшерелгән татар кызының хикәяте бирелә.

Кирәк булганда, Тукай шигъри булмаган чыганакларга да мөрәҗәгать итә. Лев Николаевич Толстойның аерым хикмәтле сүзләре Тукай шигырьләренең нигезенә салына.

Тәкълидләрендә һәм ияреп язылган шигырьләрендә Тукай, кагыйдә буларак, үзе файдаланган әсәрнең татар укучысына якын һәм аңлаешлы булуыннан чыгып эш итә.

[1] Лирик поэзиянең бер төре. Аңа күңелле һәм ваемсыз тормышны, шәраб һәм мәхәббәтне мактап җырлау хас. Ред.

[2] Лирик поэзиянең бер төре; кайгылы, сагышлы шигырь. Ред.

Әсәр әлеге таләпкә никадәр күбрәк җавап бирсә, ул шул кадәр азрак үзгәртелә һәм оригиналдан турыдан-туры тәрҗемә төсен ала (мәсәлән, А. Кольцовның «Что ты спишь, мужичок?», Майковның «Три истины», Пушкинның «Узник» кебек шигырьләре). Ләкин күпчелек очракта Тукай теге яки бу әсәрнең төп мәгънәсен ала да аны үзенең шигъри фантазиясе көченә буйсындыра. Шуңа да аның ияреп язылган шигырьләре формалары һәм стильләре ягыннан оригиналь шигырьләреннән берни белән дә аерылмыйлар диярлек.

Тукай һәр вакыт рус әдәбиятының чакыру авазын ишетеп тора һәм ул шуны халык күңеленә илтеп җиткерергә тырыша. Мәкаләләренең берсендә ул болай дип яза: «Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, хамисез, мәнҗәэсез, фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы һәм аңлатучы егетләргә мохтаҗ. Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ». Башка берни дә түгел, ә үз халкына мәхәббәт һәм аңа хезмәт итәргә теләү хисе аны шушы сүзләрне язарга мәҗбүр иткән. Үзенең рус әдәбиятына бирелгәнлеген расләп, ул ачыктан-ачык: «Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам», дип яза. Һәм дусты Ф. Әмирханның язганнарын эчке бер горурлык белән рус әдәбиятының күренекле вәкилләренең әсәрләре белән чагыштырып: «Әмирхан юморының ачылыгы һәм тирәнлеге ягыннан — безнең Гоголь, стиленең гүзәллеге ягыннан — Тургенев, психолог буларак Достоевскийга охшаш»,— дип яза Г. Тукай.

Шуңа да ул татар массалары арасындагы аерым кешеләрнең рус әдәбиятының чакыру авазына битараф һәм гамьсез карауларын авыр кичерә, чаң суга, бераўләрне аталарча йомшак шелтә белән уята, икенчеләрен сатира һәм памфлетның[1] көйдергеч уты белән камчылый.

Бу мәсьәләдә ул үз-үзенә дә бик таләпчән була.

«Җырлап торам, торган җирем тар булса да»,— дип яза ул, үз җилкәсендә тормышның тигезсезлеген сизеп.

«Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә»,— дип яза ул шигырьләрендә һәм давыллы, әмма артык кыска иҗат эшчәнлеге дәверендә үзен халык мәнфәгатьләрен сизгер һәм уяу саклаучы көрәшче дип хис итеп.

Менә шуңа да иҗат эшчәнлеген «Ник йоклыйсың, мужик?» дигән чакыру белән башлап җибәргән шагыйрь, иҗатының ахырында, рәхимсез авыру аның соңгы көчен суыра башлагач, кинәт шөбһәләнеп үз-үзеннән: «Әллә (мин) Обломов тамы?» — дип сорый («Хәстә хәле» шигыре).

Тукай рус әдәбиятының бөек тарихи ролен чын мәгънәсендә бәяли. «Пушкинә» шигырендә сурәтләгәнчә, ул моның өчен аңа кайнар мәхәббәте белән тулы:

**Нәзыйрсыз шагыйрь улдың (афәрин), Пушкин Александр!**
**Бәнем дә дәрде шәукым һәм синең дәрдеңлә якъсандыр.**
**Сәнең эшгареңа, бәнчә, агач даш билә рәкъсандыр,**
**Агач рәкъс итмәмек шагыйрь улан инсанә ноксандыр.**
**Нәчен рәкъс итмәсен, шигърең мисале шәмсе рәхшандыр**
**Нә шагыйрьдер у кем әшгар аңа мәүлядан ихсандыр.**

Бөек рус язучысы Лев Толстойның вафаты белән язылган «Мөбарәк тәсбих өзелде» исемле ак шигыре аның рус әдәбиятын нихәтле көчле яратуы хакында бик ачык сөйли.

Социаль сиземләвенә тугрылыклы буларак, шагыйрь искелекне фашлаучы Толстойга иярми һәм аның белән бертавыштан болай дип җырламый кала алмый иде:

**Тәмле булганга гаҗәпләнмә бу байлар ашлары,**
**Күп вакыт борычы, тозы — мескен гидайлар яшьләре.**

Толстойның үлеме Тукайны тетрәтә. Югарыда искә алынган ак шигырендә Тукай аны барлык җаннарның җаны, кешелекнең намусы дип атый. Мөбарәк тәсбихне тәшкил итүче рус язучыларын санаганда, ул бөек язучы үлемен авыр кичергән А. М. Горькийны аерым билгеләп үтә.

Милли татар культурасының формалашуына зур йогынты ясаган алдынгы рус әдәбиятына мәхәббәт бигрәк тә 1905 елдан соң татарның алдынгы кешеләренең матур традициясенә әйләнә, моның өчен без төбендә Тукайга бурычлы.

[1] Фаш итү характерында язылган әсәр. *Ред.*

Флорид Әгъзәмов

# СОЦИАЛИСТИК РЕАЛИЗМ ӘДӘБИЯТЫНЫҢ НИГЕЗ ТАШЫ

Нибары алты битлек текст. Аның язылуына җитмеш ел вакыт узды. Ләкин бу әсәрнең кыйммәте арта гына бара. Ул ике дөнья, ике идеология көрәшендә хак як өчен юл күрсәтүче маяк булып балкый, ялган як тарафдарлары өчен коталгыч кылыч булып ялтырый.

Иҗтимагый яшәеш һәм иҗтимагый аңның, аларның төрле өлкәләренең объектив үсеш закончалыкларын ачып биргән һәр даһи хезмәтнең язмышы шундый. В. И. Ленинның 1905 ел, 13 ноябрьда дөнья күргән «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле әсәрендә күтәрелгән проблемалар яңадан-яңа буыннарны дулкынландыра, кайнар бәхәсләр уята. Әмма шунысы көн кебек ачык: андагы һәр фикернең раслыгы, тормышчанлыгы чынбарлык тарафыннан кире кагылмаслык булып исбатлана килә. Һәр теоретик тәгълиматның, концепциянең кыйммәте һәм көче аның нәкъ менә практикада раслануында, практикага дөрес юнәлеш күрсәтүендә.

«Партия оешмасы һәм партияле әдәбият»ның иҗат ителүе, беренчедән, шул чорның конкрет-тарихи шартлары белән бәйле, икенчедән, идеология тормышының үсеш закончалыкларын тирәнтен фәнни өйрәнүнең бер йомгагы, өченчедән, партиялелек кебек универсаль закончалыкның махсус бер өлкәдә — әдәби эштә ничек чагылуын тикшеренү нәтиҗәсе булып тора.

Мәкаләдә В. И. Ленин бик күп мәсьәләләр күтәрә. Менә аларның кайберләре: әдәбият-сәнгатьнең чынбарлыкны революцион үзгәртеп корудагы роле; аның тормыш, пролетариат эше белән элемтәсе, партиялелеге һәм халыкчанлыгы; художникның иреклелеге һәм җаваплылыгы; иҗат процессына партия җитәкчелеге; буржуаз-индивидуалистик карашларны фәнни нигездә фаш итү һ. б. Сәнгатькә нисбәтән тагын да конкретлаштырып әйткәндә, социологик, гносеологик, эстетик планда ул социалистик реализм методының теоретик нигезләрен һәм принципларын бәян итте.

Бу мәкаләдә партиялелек принцибының кайбер якларына кагылышлы фикерләр әйтелер.

Буржуаз идеологларның һәм эстетларның «иҗат иреге», «иҗат стихиясе», «сыйныфлар мәнфәгатеннән өстен тору», «партиясезлек» дип лаф оруларына кискен каршы чыгып, В. И. Ленин пролетариатны партияле әдәбият принцибын алга сөрергә, бу принципны үстерергә, әдәби эшне гомуми пролетар эшенең бер өлешенә әверелдерергә чакырды[1]. Әлеге лозунгның нигезендә объектив закончалык ята иде. Ул закончалыкның асылы шунда: иҗтимагый аң иҗтимагый яшәешнең төрле якларын билгеле бер сыйныф яки социаль төркем мәнфәгатьләре карашыннан торып танып-белә, бәяли, хөкем чыгара. «Бер генә тере кеше дә, — дип язды В. И. Ленин, — теге яки бу сыйныф

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 нче басмадан тәрҗемә, 10 том, 30 бит.

ягына басмый кала алмый, шушы сыйныфның уңышына шатланмый кала алмый, аның уңышсызлыкларына кайгырмый кала алмый, шушы сыйныфка дошман булганнарга, артта калган карашлар таратучы һәм шулай итеп сыйныфның үсүенә комачаулык итүче кешеләргә һ. б. һ. б. ачуланмый кала алмый»[1]. Бу хәл иҗтимагый аңның бер формасы булган әдәбият-сәнгатькә дә кагыла.

Партиялелек принцибы үзенең структурасы белән бик катлаулы һәм күпьяклы. Аерым алганда, ул социаль-политик, гносеологик, эстетик якларны үз эченә ала. Бу яклар бер-берсе белән аерылгысыз диалектик элементдә торалар.

## ГОМУМИ ПРОЛЕТАР ЭШНЕҢ БЕР ӨЛЕШЕ

Партиялелек принцибының нигезендә сыйнфыйлык, тормыш күренешләрен, фактларын, кешеләрнең эш-хәрәкәтләрен һәм уйхисләрен гәүдәләндергәндә аларны билгеле бер сыйныф яки социаль төркем мәнфәгатьләре күзлегеннән чыгып анализлау, бәя бирү ята. Ләкин бу — сыйнфыйлык һәм партиялелек төшенчәләре арасына тигезлек билгесе куярга мөмкин дигән сүз түгел. Хикмәт шунда, төрле сыйныфларның мәнфәгатьләрен политик партияләр гәүдәләндерә. Андый партияләрнең үзара көрәшен В. И. Ленин сыйнфый политик көрәшнең югары формасы дип саный. Алар арасында иң эзлекле революцион партияләр — коммунистлар партияләре. Нәкъ менә алар иң алдынгы үзаңны — социалистик аңны чагылдыралар. Партиялелек — сыйнфыйлыкның югары формасы, аңлы формасы. Матбугат һәм әдәбиятның партиялелеге мәсьәләләрен махсус тикшергән галим Г. Куницын бу җәһәттән түбәндәгечә яза: «...Идеологиянең (аерым алганда публицистика, әдәбият, сәнгать һ. б.) партиялелеге — идеолог, теоретик, публицист, художникның (һәркайсы үзенә хас үзенчәлекле чаралар белән) теге яки бу иҗтимагый сыйныфның мәнфәгатьләрен раслау өчен аңлы көрәше» [2].

Коммунистик партиялелек исә иң алдынгы сыйныф — эшчеләр сыйныфының мәнфәгатьләрен аңлы рәвештә иҗатта чагылдыру, тормышның үсеш тенденцияләрен, конфликтларын, геройларның эш-хәрәкәтләрен шул мәнфәгатьләр позициясеннән сурәтләү дигән сүз.

В. И. Ленин хезмәтендә бу фикергә кабат-кабат әйләнеп кайтыла. Ул, буржуазиягә бәйле, сүздә генә ирекле әдәбиятка капмакаршы буларак, чын-чыннан ирекле, пролетариат белән ачыктан-ачык бәйле әдәбият тудыру зарурлыгын басым ясап әйтә. Икенче урында, әлеге фикерне конкретлаштыра төшеп, социал-демократик эшчеләр хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә торган әдәбият тудыруны бурыч итеп куя. Бу бурычның кыен һәм яңа, ләкин бөек һәм игелекле бурыч икәнлеген искәртә. Өченче бер җирдә В. И. Ленин яңа әдәбиятта социалистик пролетариатның тәҗрибәсе һәм җанлы эше чагылачагын ассызыклый. Дүртенче бер урында социалистик реализм әдәбиятының рәхәткә туйган героиняга түгел, эч пошудан һәм симезлектән җәфа чигүче «өстәге ун меңнәргә» түгел, бәлки илнең чәчәге, аның көче һәм киләчәге булган миллионнарча һәм ун миллионнарча хезмәт ияләренә хезмәт итәчәге әйтелә [1].

В. И. Ленин яңа әдәбиятның эшчеләр сыйныфының мәнфәгатьләрен чагылдырырга һәм якларга тиешлеген генә түгел, ә шул мәнфәгатьләрне гәүдәләндерүнең төп шартларын да күрсәтте. Шуларның берсе — ирекле әдәбиятны иҗат итүгә яңа көчләр тарту. Аның нигезендә исә социализм идеясе һәм хезмәт ияләренә теләктәшлек хисе ята. Нәкъ менә социализм идеяләре пролетариат әдәбиятына яңадан-яңа иҗади көчләрне тупларга мөмкинлек бирә.

Әдәбиятның эшчеләр сыйныфы мәнфәгатьләренә хезмәт итүе өчен янә шул кирәк: әдәби эш гомуми пролетар эшнең бер өлешенә, оешкан, планлы, берләшкән социал-демократик партия эшенең состав өлешенә, бөек социал-демократик механизмның «тәгәрмәччегенә һәм винтчегенә» әверелергә тиеш[2]. Әлеге механизм исә эшчеләр сыйныфының аңлы авангарды — коммунистлар партиясе тарафыннан хәрәкәткә китерелә. Бу җәһәттән В. И. Ленин мәкаләсенең исеме үк бик характерлы: партия оешмасы һәм партияле әдәбият янәшә куелган. Димәк, сүз бу ике төшенчә бәйдерә торган күренешләрнең үзара мөнәсәбәте, ягъни әдәби

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә. 2 том, 526 бит.

[2] Г. Куницын. В. И. Ленин матбугатның партиялелеге һәм иреклелеге турында (рус телендә). М., 1971, 55—56 битләр.

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә. 10 том, 34 бит.

[2] Шунда ук, 31 бит.

эшкә партия җитәкчелеге турында бара. Биредә В. И. Ленинның бик тә әһәмиятле тагын бер фикеренә игътибарны юнәлтү кирәк. Юлбашчы партия эшенең бүтән формалары белән чагыштырганда әдәби эшнең аермалы һәм үзенчәлекле булуын, аңа җитәкчелек иткәндә шуны исәпкә алырга кирәклекне искәртә: «...Пролетариатның партия эшенең әдәбият өлеше пролетариатның партия эшенең башка өлешләре белән шаблонлы рәвештә тиңләштерелә алмый»[1].

Тикшеренүчеләр хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, партиялелек төшенчәсе партиянең политик линиясен үткәрү зарурлыгы турындагы фикер белән тыгыз бәйләнгән. Бердәм партия линиясе, ныклы большевистик курс, практик тәҗрибәне туплаган партия акылы һәм ихтыяры, программ документлар һәм лозунглар кысаларында эш итү — политик эшчәнлектә ленинчыл партиялелекнең нигезендә менә шул ята. Сәнгатьтә коммунистик партиялелек принцибын үткәрү — фәнни социализм идеяләрен, эшчеләр сыйныфы идеяләрен, марксистик-ленинчыл партия идеяләрен үстерү һәм яклау, художество чаралары белән шул идеяләр өчен актив көрәшү дигән сүз ул[2].

Эш шунда ки, инде әйткәнебезчә, эшчеләр сыйныфының мәнфәгатьләрен һәм идеяләрен нәкъ менә аның иң аңлы, иң оешкан отряды — коммунистлар партиясе гәүдәләндерә. Эшчеләр сыйныфының төп мәнфәгатьләре исә хезмәт ияләренең башка катлауларының төп мәнфәгатьләре белән туры килә. Шул рәвешле, коммунистлар партиясе, эшчеләр сыйныфы партиясе булганы хәлдә, башка хезмәт ияләренең дә мәнфәгатьләрен гәүдәләндерә. Бу — безнең җәмгыятебезнең хәзерге үсеш этабында аеруча калку чагыла. Бездә хәзер Коммунистлар партиясе бөтен халык партиясенә әверелде. Партиянең хезмәт ияләре мәнфәгатьләреннән башка бүтән мәнфәгатьләре юк һәм була да алмый.

Художник коммунистик партиялелек принцибын эзлекле төстә тормышка ашырыйм ди икән, ул үз иҗатында коммунистик төзелешнең мөһим проблемаларын күтәрергә, коммунистик идеалларны ялкынланып якларга, сыйныфсыз җәмгыять төзү процессында туган яңаны пропагандаларга, шул яңалыкны иҗат итүче көчләрне калку итеп күрсәтергә, коммунистик төзелеш эшенә комачаулый торган күренешләрне, искелекне һәм шуларны гәүдәләндерүче көчләрне фаш итәргә тиеш.

Партиянең әдәбият-сәнгать өлкәсенә караган программ документлары һәм карарлары нәкъ менә шушы идея белән сугарылган. КПССның XXIV съезды материаллары, КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» дигән карары — моңа ачык мисал. Үзәк Комитетның съездга Отчет докладында төп бурыч сыйфатында художество иҗатының барлык төрләрен коммунизм төзүдә актив катнашуга юнәлдерү торганлыгы әйтелә. Әдәбият-сәнгатькә «партия җитәкчелегенең көче,— диелә анда,— художникны халыкка хезмәт итүнең изге бурычы белән мавыктыра белүдә, аны җәмгыятьне коммунистик нигездә үзгәртеп коруда инанган һәм актив катнашучыга әверелдерүдә»[1].

Совет әдәбиятының аерылмас состав өлеше булган татар әдәбияты да үзенең барлыкка килүеннән башлап хәзерге яшәешенә һәм үсешенә кадәр төп рухы белән шушы магистраль юлдан атлый, яңадан-яңа үрләр яулый. Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, М. Җәлил, К. Нәҗми, И. Гази, Т. Гыйззәт, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Х. Туфан, С. Хәким һәм башка күренекле сүз осталарының иҗатлары — әлеге магистраль юлда һәркайсы бер маяк.

Әлбәттә, совет әдәбиятына, шул җөмләдән татар әдәбиятына, аларның эшлекләләренә коммунистик партиялелек принцибын үзләштерү, аны практикада үткәрү һәм үстерү җиңел генә бирелмәде. Кешелекнең художество иҗаты күрмәгән һәм белмәгән яңа юл һәм сукмакларны беренче булып салу вазифасы нәкъ менә алар өлешенә төште. Шуңа күрә аларга гаять катлаулы иҗат проблемаларын хәл итәргә, вакыты белән абынып-сөртенеп алырга, ялгышу газаплары кичерергә дә туры килде. Әмма социалистик чынбарлык һәм Коммунистлар партиясенең максатка юнәлгән киң колачлы тәрбия эше тәэсирендә совет художество интеллигенциясе бу каршылыкларны уңышлы төстә җиңә барды, коммунистик идеология аның эчке инануына әверелде, партия һәм халык язмышы аның шәхси язмышына әйләнде.

Нәтиҗәдә, күп милләтле совет әдәбияты — иң прогрессив әдәбият — дөньядагы барча намуслы иҗат интеллигенциясенең кыйб-

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә, 10 том, 31 бит.

[2] А. Дубровин. Сәнгатьнең коммунистик партиялелеге турында. «Коммунист» журналы, 1975. № 6, 87—88 битләр.

[1] КПССның XXIV съезды материаллары. Казан, 1971, 88 бит.

ласы булып балкый, планетабыздагы хезмәт кешеләре өчен исә революцион көрәшкә һәм яңа тормыш төзүгә рухландыручы зур мораль көч булып яши.

Совет әдәбияты — социалистик тормыш рәвешенең аерылмас өлеше. Ул рухи яшәешебездә, яңа кеше тәрбияләүдә һаман зуррак урын ала бара. «Җәмгыятебезнең коммунизм төзү юлыннан алга баруы белән, — дип билгеләп үтелде партиянең XXIV съездында, — совет кешесенең дөньяга карашын, аның әхлакый карашларын, рухи культурасын формалаштыруда **әдәбият һәм сәнгатьнең** роле һаман арта»[1].

Бу хәл әдәбият эшлеклеләренең халык һәм партия алдындагы җаваплылыгын янә дә күтәрә, алар алдына тагын да катлаулырак бурычлар куя. Халыкка һәм партиягә аңлы рәвештә хезмәт итү **художник** өчен коммунизм идеалларының эчке иманута әверелүен, аңарда дөньяга коммунистик караш тәрбияләүне күздә тота. Моннан совет художнигын, бигрәк тә яшь көчләрне, марксистик-ленинчыл тәгълимат белән коралландыруның әһәмияте алгы планга чыга. Партия, аның комитетлары, иҗат союзлары һәм аларның партия оешмалары бу бурычны төрле чаралар ярдәмендә тормышка ашыралар.

## ӘДӘБИЯТ — ТОРМЫШ КӨЗГЕСЕ

Мәгълүм булганча, әдәбият — чынбарлыкны танып-белү чарасы. Әлбәттә, табигатьне, җәмгыятьне һәм кешенең фикерләвен танып-белүнең формалары күп төрле. Шулар арасында дөньяны эстетик танып-белү үзенчәлекле бер урын тота. Әдәбият, сәнгатьнең бер төре буларак, кешелек үсешенең эстетик тарихын да гәүдәләндерә.

Чынбарлыкны дөрес, объектив чагылдыруы белән генә әдәбият хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен фәнни нигездә һәм дәлилле итеп яклый ала. Бу — кешелек җәмгыяте үсешенең эстетик тарихын иҗат итү процессына да, кешелекнең эстетик фикер үсеше процессына да карый.

Шуңа күрә дә В. И. Ленин әдәбиятның, иҗат интеллигенциясенең тормыш белән, халык язмышы белән элемтәсен ныгытуны, тормыш хакыйкатен, халыкның чын ихтыяҗларын чагылдыруны таләп итә. Партия нәкъ шушы таләпне күздә тотып эш итә. Аерым алганда, КПССның XXIV съездында халкыбызның үткәнен һәм хәзергесен реалистик планда, партия позицияләреннән торып, ялтыратмыйча, шул ук вакытта кимчелекләрне күпертмичә яктырткан, коммунистик тәрбия һәм төзелешнең чыннан да мөһим проблемаларына игътибарны туплаган әсәрләр һәм постановкаларның барлыкка килүе хуплап билгеләп үтелде. Мондый әсәрләр тагын бер кат шуны раслый: совет халкының күпкырлы тормышы белән художникның элемтәсе никадәр тыгызрак булса, иҗат казанышларына һәм уңышлары на юл шул кадәр турырак була.

Тормыш хакыйкатен дөрес чагылдыру, иң элек, аның төп үсеш закончалыкларын һәм тенденцияләрен, җәмгыятьнең әйдәп баручы көчләрен, алар яулаган казанышларны, алар җиңгән каршылыкларны «тотып алу» һәм иҗатта калку итеп гәүдәләндерү дигән сүз ул. Тарихның, бүгенге тормышның үсеш закончалыкларын һәм тенденцияләрен дөрес аңлау өчен язучыга чынбарлыкны гади күзәтү генә җитми, аңа дөньяны фәнни танып-белүнең бердәнбер методологик ачкычы — марксистик-ленинчыл теория белән коралланган булу кирәк.

Хәзерге чорны өйрәнгәндә, заман темаларын хәл иткәндә партия документларының әһәмияте аеруча зур. Чөнки аларда җәмгыятьнең нәкъ менә бүгенге үсеш процессы, киләчәк перспективасы анализлана.

Әдәбият өчен заман темасының нинди зур урын тотуын сөйләп тору артык. Бүгенге укучыны иң элек бүгенге чорның тенденцияләре һәм проблемалары, замандашлары һәм аларның уй-карашлары, фикер-хисләре кызыксындыра. Ул бүгенге тормыш мисалында, бүгенге геройлар язмышы мисалында шәхес булып формалаша, тормыш кагыйдәләрен үзләштерә.

Заман темасының конъюнктура белән бернинди алыш-биреше юк. Заман темасы — әдәбиятның төп кыйбласы, төп үсеш юлы ул. Димәк, әдәби хәрәкәттә зур, авыр, катлаулы һәм почетлы темаларны — җәмгыятьнең бүгенге төп үсеш тенденцияләрен күтәргән темаларның коммунистик партиялелек принцибы белән турыдан-туры бәйләнеше бар.

Әдәби җыелышларда булмасын, матбугатта булмасын, эшчеләр сыйныфы һәм аның вәкилләре тормышын алгы планга куеп яктырту зарурлыгы турында сүз күп бара. Шуларны гәүдәләндергән җитди әсәрләр аеруча игътибарга лаек була. Бу — татар әдәбиятында да шулай. Соңгы елларда бу

---

[1] КПССның XXIV съезды материаллары, 86 бит.

теманың әдәбиятыбызда чагылышы турында сөйләгәндә, без Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар»ы, Г. Ахуновның «Хәзинә»се һәм «Хуҗалар»ы, Ш. Бикчуринның «Каты токым»ы кебек китапларга мөрәҗәгать итәбез. КамАЗ төзелешен бөтен киңлеге, бөтен каршылыклары белән гәүдәләндергән иң яхшы әсәрләр дә шуңа күрә көтеп алынды, аларга оператив төстә тиешле бәя бирелде.

Юк, болар язучылар иҗатында конъюнктур темалар түгел. Бу — чор таләбе, бу — җитлеккән социализм җәмгыятенең алга таба үсеш тенденциясеннән чыга торган таләп. Эшчеләр сыйныфының бүгенге тормышыбызда тоткан урынының әһәмияте белән аңлатыла ул. Аның революционлыгы, дисциплиналылыгы, оешканлыгы һәм коллективизмы социалистик иҗтимагый мөнәсәбәтләр системасында аны әйдәп баручы итә.

Яки икенче бер теманы алыйк. Сүз әдәбиятта коммунист образының лаеклы урын алырга тиешлеге турында бара. Урынлы таләп, законлы таләп. «Эпохабызның акылы, намусы һәм вөҗданы» булган партия, кешелекнең иң яхшы сыйфатларын үзләрендә туплаган коммунистлар заманның иң алдынгы көченә әверелгән икән, аларның иҗтимагый тормышта тоткан урыны һаман әһәмиятлерәк була бара икән, әдәбиятның да әлеге хәлне игътибардан читтә калдырырга хакы юк.

Әлбәттә, әйтелгәннәрдән әдәбиятта гел эшчеләр һәм коммунистлар тормышы гына чагылырга тиеш дигән нәтиҗә ясарга кирәкми. Болар фикер раслау өчен мисаллар рәвешендә генә китерелде. Әдәбият кешелек җәмгыяте кебек гаять катлаулы системаның барлык якларын, барлык сыйныфларын һәм социаль төркемнәрен сурәтләргә тиеш. Әмма шунысы ачык, тормыш дөреслеген чагылдыру — ни бар шуны стихияле төстә кәгазьгә күчерү түгел. Партиялелек принцибы аңлы иҗат процессының нигезендә ята дибез икән, димәк, художник тормышның үзәнендә ята торган процессларның асылына төшенергә, халыкның олы язмышына бәйле зур проблемаларны күтәрергә, җәмгыятьне әйдәп баручы социаль көчләрне алгы планга чыгарырга бурычлы. Бу җәһәттән М. Әмирнең образлы сүзләре хәтергә килә: «Бераү, әйтик, чабата ясый яки кәрзин үрә,— дигән иде ул.— Ә икенче бераү яңа тәр автомашина ясый. Икесе дә кирәк әйбер, әмма бәяләре бер дип булмый»[1].

Әдәбият заман темасы белән генә яшәп, халыкның үткәненә бармак аша караса да ярый, дигән икенче бер ялгыш фикер дә тумаска тиеш. В. И. Ленин бүгенге иҗтимагый күренешләрнең асылын дөрес аңлау өчен аларның килеп чыгышын, үсештә нинди чорлар үтүен, хәзер нинди рәвешкә керүен өйрәнүнең зур әһәмияткә ия икәнлеген кат-кат искәртә килде. Бу — бик табигый хәл. Узган белән хәзерге, хәзерге белән киләчәк арасында дәвамчанлык бар, диалектик бәйләнеш бар. Бүген бара торган процессларны аларның узганыннан башка аңлавы кыен. Әлеге сөземтә әдәбиятка да бердәй кагыла. Без совет халыкларының, шул исәптән татар халкының, героик үткәнен, аның атаклы улларын һәм кызларын гәүдәләндергән әсәрләрне зур кызыксыну белән укыйбыз, шулардан гыйбрәт алабыз, бик күп яңа вакыйгаларны таныш-беләбез, эстетик ләззәт табабыз. Күп милләтле совет халыклары әдипләренең эпопеялары, роман-повестьлары, җыр-поэмалары һ. б.— моңа ачык мисал. Татар әдәбияты вәкилләре Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Усманов, К. Нәҗми, И. Гази, Ә. Фәйзи, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, А. Расих, Ш. Маннур, Н. Фәттах һ. б. әсәрләре дә югарыда әйтелгән фикерне раслап тора. Аларда «халык массасының тарихтагы роле, үткәндәге тарихның иң мөһим, хәлиткеч, борылыш моментларының җанлы процессы һәм халык көрәшен, идеалларын үз көрәше, үз идеалы итеп санаган һәм алгы сафта торган атаклы тарихи шәхесләр бөтен киңлеге, катлаулы һәм каршылыклы күренешләре белән сурәтләнә»[1]. Тарихи вакыйгаларга һәм шәхесләргә мөрәҗәгать иткәндә коммунистик партиялелек принцибына турылыклы булу — аларга сыйнфый күзлектән чыгып бәя бирү, иҗтимагый үсешнең төп тенденцияләрен объектив гәүдәләндерү, субъективизмга, берьяклылыкка юл куймау дигән сүз.

Әдәбиятта тормыш дөреслеге чагылсын дибез. Әмма тормыш дөреслеге белән сәнгать дөреслеге арасына тигезлек билгесе куярга ярамый. Әдәбият чынбарлыкка таянса да, ул аны факт дөреслеге буларак кына гәүдәләндерми. Чөнки тормыштагы кайбер фактларның чынбарлыкны дөрес чагылдырмавы, очраклы характерда булуы ихтимал. Сәнгать дөреслеге — катлаулы күренеш. Ул фактлар дөреслеген генә түгел, хәтта чынбарлыктагы вакыйгалар һәм харак-

[1] Мирсәй Әмир. Үзебез турында. Казан, 1971, 67 бит.

[1] Хәсән Хәйри. Иҗат чишмәләре. Казан, 1975, 106 бит.

терлар асылының дәрәслеген генә түгел, күренешләрнең фәлсәфи мәгънәсен ачуны, аларны идея-эстетик бәяләүне дә үз эченә ала[1].

## СӘНГАТЬ КАНУННАРЫНА ТАЯНЫП

Коммунистик партиялелек социаль-политик һәм гносеологик категория генә түгел, эстетик категория дә ул. Бу аспектлар иҗат процессында аерым-аерым түгел, ә диалектик бердәмлектә чагылалар. В. И. Ленин «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» һәм башка хезмәтләрендә әдәбият-сәнгатьнең махсус кануннар буенча үсүенә, әдәбият-сәнгать әсәрләренең үзенчәлекле закончалыклар буенча иҗат ителүенә дә зур игътибар бирде. Ул болай дип язды: «Әдәбият эше механик тигезләүгә, нивелировкага, күпчелекнең азчылык өстеннән хөкем сөрүенә иң аз бирелә... Бу эштә шәхси инициативага, индивидуаль һәвәсләкләргә күбрәк иркенлек, фикергә һәм фантазиягә, формага һәм эчтәлеккә иркенлек тәэмин итү һичшиксез кирәк»[2].

Мәгълүм ки, әдәбият чынбарлыкны образлар ярдәмендә танып-белә һәм образлар системасы белән укучыга тәэсир итә, аңарда эстетик хисләр уята. Коммунистик партиялелек нәкъ менә әсәрнең, политик эчтәлек белән беррәттән, сәнгать законнары нигезендә иҗат ителүен дә күздә тота.

Яңа культураны, шул җөмләдән яңа әдәбиятның бурычларын билгеләгәндә, В. И. Ленин аның моңарчы бөтен дөнья художество культурасы һәм әдәбияты ирешкән дәрәҗә белән генә чикләнмичә, аны узып китү, үткән заманда хыялланырга гына мөмкин булганны уздырырдай гүзәллек иҗат итү зарурлыгын искәртте, бөек коммунистик сәнгатьнең үз эчтәлегенә ярашлы форма табачагын әйтте.

Коммунистик партиялелек принцибына нигезләнгән социалистик реализм әдәбияты иң алдынгы идеяләрне иң камил формаларда гәүдәләндерүне үзенә бурыч итеп куя. Һәр әсәр һәм эчтәлек, һәм форма җәһәтеннән яңалык, мәгълүм бер эстетик ачыш алып килергә тиеш, кешелек туплаган эстетик хәзинәгә тәҗрибә өстәргә тиеш. Совет әдәбияты кыска гына вакыт эчендә бөтен дөнья әдәбиятын мәңге җуелмас җәүһәрләр белән баетты.

Сәнгатьтә уртачалыкка урын юк. Һәр художник һәр яңа әсәре белән, үзенең сәләтенә карап, үзенчәлекле юллар белән яңадан-яңа эстетик үрләр яуларга бурычлы. Әгәр язучы теге яки бу идеяне, сәнгать таләпләре белән исәпләшмичә, декларатив төстә әйтеп бирә икән, «андый әсәрнең әдәбият өчен дә, халык өчен дә, партия өчен дә кирәге шул кадәр»[1].

Практикада шундый хәлләр дә була: вакыйгаларның кайнар эзеннән язылган, әмма эстетик яңалык дәрәҗәсенә күтәрелмәгән әсәр дөньяга килсә, без авторга конъюнктурщик дигән гаеп ташлыйбыз, кайчак аны мәгълүм карарга иллюстрация бу дип үк җибәрәбез. Әйтерсең лә тема гаепле, әйтерсең лә художник сугар өчен тимернең суынганын көтеп торырга тиеш. Гаеп темада түгел, билгеле. Баксаң, бәла нәкъ менә вакыйгаларны, аларда катнашучы кешеләрнең эш-хәрәкәтләрен, шуларның мотивларын тирәнтен ачып җиткермәүдә, сәнгать кануннары таләпләрен санга сугып бетермәүдә булып чыга. Сүз бирелә, әлбәттә, сәләтле каләм осталарының аерым хәлләрдә уңышсызлыкка очравы турында бара.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Әгәр художник идея мәсьәләләренә, политик проблемаларга игътибарны кимету исәбенә эстетик як белән генә мавыкса, эчтәлеккә зыян килә, әсәрнең идея «нагрузкасы» кечерәя. Әгәр дә инде бу үзмаксат төсен алса, аннан «сәнгать сәнгать өчен» концепциясенә дә ерак калмый. Ләкин әдәби тәнкыйть һәм укучыларның алдынгы өлеше андый әсәрләрне, иртәме-соңмы, барыбер кире кага.

Социалистик реализм методы —«үзенең төп идея-эстетик принципларына хезмәт иткән сәнгать чараларыннан, стильләрдән түлысынча файдалану көченә ия булган иҗат методы»[2]. Моның шулай булуы бик табигый. Чөнки чынбарлык никадәр күпьяклы икән, аны чагылдыручы иҗат методының мөмкинлекләре дә күп төрле; хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүче политика тормышның күпьяклылыгыннан читкә алып китми, ә кешеләргә бетмәс-төкәнмәс кыйммәтләрне ачарга һәм үзләштерергә юл ача; чынбарлыкны чагылдыручы

[1] Г. Ермаш. Дөньяга марксистик-ленинчыл караш һәм чынбарлыкны сәнгатьчә танып-белү. «Коммунист» журналы, 1973, № 6, 106 бит.
[2] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә, 10 том, 31 бит.

[1] Мирсәй Әмир. Үзебез турында, 14 бит.
[2] Гали Халит. Иҗат методы һәм стиль мәсьәләләре. «Казан утлары», 1975, № 4, 161 бит.

художниклар да төрледән-төрле. Социалистик реализм аларның һәркайсына үзенең индивидуаль иҗат йөзен, иҗат стилен тулысынча ачарга бөтен мөмкинлекләрне тәэмин итә. «Без...— диде Л. И. Брежнев партиянең XXIV съездында,— сәләтләрнең һәм талантларның индивидуальлекләрен тулы ачу ягында»[1].

Кызганычка каршы, бездә социалистик реализм методының мөмкинлекләрен кечерәйтеп аңлатырга маташучылар да булды һәм әле дә бар. Моннан берничә ел элек бу метод турында булып узган бәхәсләргә тукталып тормыйбыз. Дискуссия барышында каршылыклы фикерләр байтак әйтелде. Әмма төп, принципиаль мәсьәләләрдә уртак фикерләргә дә киленде. Шулай да социалистик реализм методының хасиятен дөрес аңлатмый торган фикерләр һаман күренә әле. Мәсәлән, П. И. Плукш «Социалистик реализмның формалашуы һәм үсүе» исемле китабында социалистик реализм белән беррәттән романтизм һәм критик реализм методларының яшәп килүен исбат итәргә тырыша[2].

Тәнкыйтьче Р. Мостафин әлеге теория шаукымының күпмедер дәрәҗәдә безгә дә килеп җиткәнлеген әйткән иде. «Матбугат битләрендә үк булмаса да, Язучылар союзында уздырылган кайсыдыр җыелышта танылган тәнкыйтьчеләребезнең берсе, хәзерге татар әдәбиятында критик реализм әсәрләре дә яшәргә хаклы, дип белдерде. Н. Фәттахның «Артта калган юллар» һәм А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повестьларын шундый әсәрләр рәтенә кертте. Татар совет әдәбиятында романтизм методы белән иҗат ителгән әсәрләрнең яшәргә тиешлеге турындагы фикер исә тагын да активрак һәм эзлеклерәк төстә үткәрелде. Аерым алганда, мондый караш В. Воздвиженскийның «Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» турында» исемле китабында ачык чагылды»[3].

Шунысы бар, болар бөтенесе социалистик реализмны «нормативлыктан» һәм «догматизмнан» коткару өчен эшләнә. Әмма бу карашлар үзләре үк социалистик реализмны норматив һәм догматик аңлауның ачык чагылышы булып тора.

Күп милләтле совет әдәбиятының үсеш тәҗрибәсе шуны раслый: тормыштан аерылмаган романтик күтәренкелек тә, чынбарлыкны революцион үсештә сурәтләгәндә, яңалыкны, алдынгыны раслау яктылыгында, искене, гомерен кичергәнне, яңага аяк чалучы көчләрне тәнкыйтьләү дә социалистик реализм методына ят нәрсә түгел. Бөтен хикмәт әдипнең дөньяга карашында, аның позициясендә, тормыш процессларының асылын объектив гәүдәләндерүендә.

В. И. Ленин мирасына таянып эш итүче партиябезнең бу мәсьәләдә тоткан юлы бик ачык. «Без...— диелә КПСС Үзәк Комитетының XXIV съездга Отчет докладында,— социалистик реализм методы нигезендә эшләнгән күп төрле һәм бай формалар һәм стильләр ягында торабыз»[1].

В. И. Ленин тарафыннан ачылган, партия һаман үстерә килгән коммунистик партиялелек принцибы — чынбарлыкны эстетик танып-белү һәм сурәтләүнең бердәнбер объектив юлы ул. Бу принцип тормышта бара торган катлаулы процессларны һәм анда хәрәкәт итүче характерларны, аларның үзара мөнәсәбәтләрен, марксистик-ленинчыл тәгълимат җирлегендә сәнгать законнары таләпләренә ярашлы рәвештә гәүдәләндерүне күздә тота. Ул иҗат кешеләрен коммунизм идеалларын эзлекле якларга, халык мәнфәгатьләрен бөтен нәрсәдән өстен куярга чакыра. Шул ук вакытта бу принцип социалистик реализм методын тәшкил итә торган башка принципларның (халыкчанлык, гуманизм, интернационализм һ. б.) нигезендә ята, буржуаз идеологлар һәм эстетлар арсеналында булган һәртөрле концепцияләрнең ялганын фаш итәргә, идеология көрәшендә совет художникларына алгы сызыкта булырга ярдәм итә.

[1] КПССның XXIV съезды материаллары. 88 бит.
[2] П. И. Плукш. Социалистик реализмның формалашуы һәм үсүе (рус телендә). М., 1973, 311—324 битләр.
[3] «Казан утлары», 1974, 8 сан, 160 бит.

[1] КПССның XXIV съезды материаллары, 88 бит.

**Флүн Мусин**

# ӘДӘБИЯТ ФӘНЕНДӘ ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬТӘ СТИЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Соңгы ун-унбиш ел вакыт эчендә совет әдәбият фәне һәм тәнкыйть үзенең җитлегү чорын кичерә. Бу, барыннан да элек, әдәби хәрәкәтне бөтен катлаулылыгында һәм тулылыгында күзалларга омтылуда күренә. Нәтиҗәдә хәзерге әдәбиятның реаль байлыгы, андагы күп төрле эзләнүләр һәм табышлар торган саен тулырак ачыла бара.

Ахыр чиктә болар барысы да социалистик реализм турында тирәнрәк фикер йөртергә, буржуаз пропаганданың совет әдәбиятына, аның иҗат методына каршы һөҗүмен тагын да уңышлырак төстә кире кагарга мөмкинлек бирә. Аннан соң социалистик реализм мәсьәләләре буенча соңгы елларда барган дискуссияләр иҗат методыбызның чикләнмәгән мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итте, бу турыдагы элекке карашларыбызның киңәя һәм тирәнәя төшүенә китерде.

Ленинчыл партиялелек һәм халыкчанлык, тарихилык һәм гуманизм принципларына нигезләнгән бу методның новаторлык асылы нидән гыйбарәт? Аның чиксез мөмкинлекләре нәрсәдә чагыла соң? Әлеге сорауларга җавап эзләгәндә, галимнәр стиль мәсьәләләренә аеруча зур игътибар бирә башладылар. Һәм бу табигый хәл. Чөнки хәзерге әдәбиятның эстетик байлыгы, андагы кызыклы тәҗрибәләр һәм күркәм табышлар нәкъ менә әдипләрнең шул өлкәдәге эзләнүләрендә аерата ачык гәүдәләнә. Менә шуның өчен стиль мәсьәләсе хәзер совет әдәбият фәненең һәм тәнкыйтьнең иң мөһим мәсьәләләреннән берсенә әверелде.

Стиль турында сөйләшүләр, рус әдәбият белемендәге кебек үк, бездә дә 20 нче елларда кочәеп китә. Егерменче еллар — яңа әдәбият белеменә нигез салынган чор. Революция иске идеалистик методология урынына сәнгатьне марксизмча аңлауга нигезләнгән яңа методология тудыру бурычын куя. Бу бурычны тормышка ашыру илдә кискен сыйнфый һәм идеологик көрәш барган шартларга туры килә. Һәм шушы хәл 20 нче еллардагы әдәби-теоретик фикерләүгә дә нык йогынты ясый. Революция тудырган яңа әдәбиятның идея-эстетик асылы һәм аның әдәби мираска мөнәсәбәте мәсьәләләре аеруча актуаль төс ала. Бу мәсьәләләр тирәсендә матбугат битләрендә һәм әдәби даирәләрдә кискен бәхәсләр бара.

Безнең әдәбият фәнендә яңа әдәбиятның үзенчәлеген һәм асыл сыйфатларын ачыклау эшенә башлап Г. Ибраһимов алына. Аның «Пролетариат әдәбияты турында» исемле хезмәтен (1924) әнә шул юнәлештәге беренче карлыгач дип санарга була.

Яңа әдәбиятның асыл сыйфатлары турында сөйләгәндә, Г. Ибраһимов иң элек аның сәнгатьчә көченә, чынбарлыкны тирән һәм тулы итеп гәүдәләндерергә тиешлегенә басым ясый. Талантлы язучы, ди ул, көрәш дип, сыйныф дип, коллективизм, материализм, интернационализм дип һичбер сүз әйтмәстән, үзенең әсәрен шул рух белән сугарачак, сүз, фәлсәфә белән түгел, укучының күз алдына китереп куйган картиналары белән шул мәгънәләрне бирәчәк. Шул ук вакытта әдип татар әдәбияты әсәрләрендә чынбарлыкны берьяклы сурәтләүне тәнкыйть итә. Ул пролетариат язучысы революцион сыйныфларның һаман башыннан гына сыйпарга, тормыш күренешләрен һаман ал, матур төсләрдә генә бирергә тиеш дигән фикергә, тагын да конкретрак итеп әйткәндә, әдәбиятны «мәдхияләр мәҗмугасына» әверелдерүгә каршы чыга. Көрәшүче массаларның героик эшләрен тасвирлау белән бергә, пролетариат язучысы алар тормышындагы кулагәле якларга да күз йома алмый. Әмма кимчелекләрне күрсәтү, ак эмигрантларча, совет властена яла ягу, аны инкарь итү тәсен алырга тиеш түгел. Пролетариат язучысы, «авыру тәндәге черекне алып ташлау өчен операция ясаган» доктор кебек, кимчелекләрне тор-

мышны яңарту, сәламәтләндерү өчен тәнкыйтьләргә тиеш.

Нигездә дөрес, фәнни позицияләрдә торып язылган бу хезмәттә кайбер ялгыш тезислар да очрый. Әмма аларны һич тә әдипнең шәхси хаталары дип кенә карарга ярамый. Дөресрәге, алар 20 нче еллардагы әдәбият фәне үсешендәге кыенлыкларның бер чагылышы булып торалар.

20 нче елларның икенче яртысында һәм 30 нчы еллар башында әдәбият фәне мәйданына социология мәктәбе вәкилләре килә. Профессор В. Фриче җитәкчелегендәге бу мәктәп пролетариат әдәбиятының үз теориясен тудыруны дәгъва итеп чыга.

В. Фриче һәм аның шәкертләре стиль мәсьәләләрен өйрәнүгә аеруча нык игътибар итәләр. Стиль әдәбият фәненең һәм тәнкыйтьнең иң үзәк проблемаларыннан берсе итеп карала башлый. В. Фриче, әлеге мәсьәләгә тукталып, болай яза: «Әгәр соңгы елларда әдәбият белеме өлкәсендәге хәлләргә күз ташласак, без анда, тикшеренү эшенең нигез һәм үзәк проблемасы рәвешендә, стиль проблемасының зур тырышлык һәм бердәмлек белән алгы планга куелганын күрербез. Тарихи поэтиканың, әдәбият тарихының һәм социологиясенең ахыргы максаты итеп бер үк бурыч — әдәби (поэтик) стильләрнең тарихын һәм социологиясен булдыру бурычы карала»[1].

Татар әдәбият фәнендә дә бу мәсьәлә үзәк урынны ала. Г. Сәгъди һәм Г. Нигъмәти кебек күренекле галимнәребезнең хезмәтләрендә әдәби стильләрне өйрәнүгә киң урын бирелә.

Бу чорда стильгә ни өчен шундый игътибар бирелә, ни өчен ул әдәбият фәненең һәм тәнкыйтьнең үзәк мәсьәләсенә әверелә соң? Төп сәбәп үсеп килгән яңа әдәбиятның идея-эстетик асылын, аның нигез принципларын һәм критерийларын ачыклау, үсеш юлын билгеләү белән бәйләнгән иде. Хәзерге тел белән әйтсәк, бирeдә сүз, һичшиксез, туып килгән әдәбиятның методы турында бара. Әмма ул вакытта «метод» төшенчәсенең әле гамәлдә булмавы сәбәпле, фәнгә традицион «стиль» сүзе кереп китә. Чынлыкта алар еш кына бер үк мәгънәне аңлаткан төшенчәләр рәвешендә кулланылалар. Әдәбият фәне алдында торган мөһим бурычларны билгеләп, Г. Нигъмәти, мәсәлән, болай яза: «Хәзер безнең алда пролетариат әдәбиятының иҗат методларын билгеләү мәсьәләсе тора. Бу — пролетариат матур әдәбиятының стиле нинди булырга тиешлеген тикшерү диган сүз»[2]. Г. Сәгъди дә үткәндәге әдәбият фәнендә «әдәби агымнар» дип йөртелгән төшенчәләрнең (классицизм, романтизм, реализм һ. б.) хәзер бездә стиль мәгънәсендә алынуларын әйтә һәм түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Нәфис әдәбиятта иң элек игътибар ителә торган иң әһәмиятле нәрсә — өслүп. Тарихи поэтикада һәм әдәбият тарихында да төп әһәмиятле нәрсә — шул. Әдәбият тарихы ул төбендә югарыда алынган киң мәгънәсе белән өслүпләр тарихыннан гыйбарәт»[3]. Күрәсез, Г. Сәгъди стильне тарайтып аңлатуга, ягъни аны «сүз һәм җөмләләрне ничек төзү, нинди тәгъбирләр һәм аларны ничек куллану, кыскасы, сүз өслүбе мәгънәсендә генә» куллануга каршы чыга. Ул бу төшенчәне «дөньяга, тормышка мәгълүм бер караш нигезендә һәм шул карашка муафыйк рәвештә фикер-тойгыларны, баштан кичерүләрне нинди васиталар, нинди материаллар аркылы ничек формалаштыру мәгънәсендә»[4] аңлавын белдерә.

Бу чорда стиль төшенчәсе төрле мәгънәдә кулланыла. «Эпоха» стиле дигәндә, ул гаять киң мәгънәне белдерә. Бу төшенчәне фәнгә В. Фриче кертә. Аны ул иҗтимагый-экономик формациягә хас булган «бердәм» стильнең аерылгысыз бер өлеше итеп карый. Һәм социологик поэтиканың төп бурычын поэтик эпоха стиленең экономик стильгә туры килү закончалыгын ачуда күрә. Бу — фәннилектән ерак торган уйдырма концепция, билгеле. Чөнки ул әдәбиятны турыдан-туры экономика белән, иҗтимагый җитештерү ысулы белән бәйли, аның үзенчәлеген, идеологиянең специфик өлкәсе икәнлеген һәм үзенә генә хас эчке үсеш закончалыклары булуын искә алмый.

В. Фричега иярeп, Г. Сәгъди дә «иҗтимагый-сәяси төзелеш формасы, хуҗалык төзелешенең өслүбе шул дәвернең уртак әдәби өслүбен билгели»[5], дип яза. Г. Сәгъдинең әдәбият тарихын өйрәнүгә багышланган «Символизм турында» дигән хезмәте (1932) бар. Биредә дә ул В. Фричега ияра. «Көнбатыш әдәбиятларының үсеше турында очерк» исемле хезмәтендә (1931) В. Фриче Европа әдәбиятларының стильләр тарихын өйрәнә. Аныңча, бу әдәбиятларның Шекспирдан алып Маринеттига

[1] «Литература и марксизм» журналы, 1928, 1 сан, 5 бит.

[2] Г. Нигъмәти. Әдәбият һәм тормыш. Казан, 1931 ел, 11 бит.

[3] Г. Сәгъди. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан, 1930, 37 бит.

[4] Шунда ук, 37 бит.

[5] Шунда ук.

кадәргә озын юлы буржуаз характерда була. Чөнки бу зур эпоха дәвамында Көнбатыш Европада буржуаз җитештеру ысулының төрле-төрле стадияләре — сәүдә (меркантиль), промышленность һәм финанс капитализмы бер-берсен алыштырып килә-ләр. Бу стадияләрнең һәркайсының үз әдәби стиле була. Ачыграк әйтсәк, классицизм — сәүдә капитализмы стиле, романтизм — промышленность капитализмына күчү чоры стиле, ә реализм финанс капитализмы стиле булып чыга.

Г. Сәгъди аны Көнчыгыш әдәбиятлары җирлегенә күчерә. Ул төрки әдәбиятларындагы стильләр тарихын түбәндәгечә күз алдына бастыра. XI гасырда анда аристократик әдәбият стиле — классицизм яки рационализм туа. Бу стильнең үрнәкләре итеп Г. Сәгъди «Котадгу-белек» белән «Һибәтел-хакаикъ»ны һәм Мәхмүт Кашгари сүзлегендәге шигъри ядкарьләрне ала. Салкын акыл һәм гомумилек алдында баш игән, төрек аристократиясенең мәнфәгатьләрен чагылдырган бу әдәбиятта, ди галим, «тик акыл эшчәнлегеннән туган назари идеяләрне һәм бөтен җәмгатькә яки бөтен сыйныфка «уртак» булган фикерләрне, бөтен кешелек принципларын» биру өстенлек алды, ә «хисләрне, шәхси баштан кичерүләрне тәгъбир итүче ялкынлы сүзләргә, хыялый тасвирларга урын бирелмәде... шигъри шәхсиятләр кабартыла яки өскә калкып чыга алмадылар; шуның өчен шәхси кәефләрне һәм өметсезлек, төшенкелек кәефләрен тасвир яки тәгъбир итүче васиталарны бу әдәбият өслүбендә күрмибез. Аеруча шагыйрьнең «мин»легенә караган тасвир һәм тәгъбирләр бу әдәбият өслүбендә юк иде дияргә мөмкин»[1].

XII йөздә классицизм яки рационализм үзе әдәби стиль — дини романтизм белән алмашына. Бу стильне тудыручылар «гарәп империализмы, солтан һәм ханнар сугышыннан икътисади бөлгенлеккә төшкән, феодал-буржуа аристократиясенең монархия сәясәте кысынкылыгы астында имгәнгән хезмәт массасы арасында яшәүче яки шушы иҗтимагый катлауга якын торучы дәрвиш укымышлылар иде»[2]. Классицизмны инкарь итү төсендә мәйданга чыккан бу яңа әдәбият үзенең «артык гавами ачык һәм тәкәллефсез булуы белән аерыла». Хәзер шагыйрьнең «мин»е бик нык кабартыла, ул соң дәрәҗәдә индивидуализмга бирелә. Шагыйрь «һәрнәрсәдән элек үз хәлен, үзенең эчке тойгыларын, үз моңнарын, үз зарын тәгъбир белән шөгыльләнә, хәтта үзен «алла»лык баскычына күтәрә»[3]. Бу әдәбиятның күренекле вәкилләре итеп галим Ясәви белән Бакырганины саный.

XV йөзгә кергәч, Г. Сәгъдичә, Көнчыгыш әдәбиятларында тагын ике төрле стиль барлыкка килә. Бер яктан, дворян-буржуа аристократиясе укымышлылары тарафыннан символизм мәйданга чыгарыла. Бу стиль әдәбиятының беренче күренекле вәкилләре Сәккаки белән Лотфи булсалар, үзенең иң югары ноктасына ул Нәвои, Бабир һәм Байкара иҗатларында күтәрелә. Икенче яктан, реализм формалаша башлый. Реализм әдәбиятының беренче үрнәге итеп галим Мөхәммәт Салихның «Шәйбани намә» поэмасын ала. Реалистик стильнең төрки әдәбиятларда ныклап җитлегүе исә, аныңча, «буржуазия ныгып утырып алган, үз хакимиятен тамырландыра башлаган» заманнарга, ягъни XIX йөз ахырына һәм XX йөз башына туры килә.

Гәрчә Г. Сәгъди тегә яки бу әдәби стильнең туу сәбәпләрен (стильне ул метод мәгънәсендә куллана) артык гадиләштереп аңлатса да, аның күп кенә кызыклы теоретик күзәтүләре дә бар. Аннан соң, ул дәвер стилен бер дә үзгәрми торган, катып калган нәрсә итеп карамый, аерым әдәбиятларда аның «милли хосусиятләр» белән баетылуын искәртеп үтә. Ул «милли әдәби стиль» дигән төшенчәне дә куллана. Дөрес, аны турыдан-туры иҗтимагый-сыйнфый мохит белән бәйләп карый. Шул ук вакытта Г. Сәгъди: «бер дәвернең үз эчендә төрле иҗтимагый төркемнәргә карап, төбендә бер үк уртак өслүпнең үз төрлелекләре, яки икенче төрле әйткәндә, өслүп вариантлары булырга мөмкин»[4], ди. Биредә инде сүз аерым сыйныфларның әдәби стильләре турында бара.

Революциядән соңгы әдәбиятны тикшергәндә, Г. Нигъмәти белән Г. Сәгъди стильне метод мәгънәсендә дә һәм туры мәгънәсендә дә кулланалар. Кутәрелеп килгән яшь совет әдәбиятының идея-эстетик асылы турында сөйләгәндә, Г. Сәгъди нигез фикер итеп В. И. Ленинның түбәндәге сүзләрен ала: «Сәнгать — халыкныкы. Ул үзенең иң тирән тамырлары белән киң катлау хезмәт иясе массаларының иң эченә

[1] Г. Сәгъди. Символизм турында. Казан, 1932, 6 бит.
[2] Шунда ук, 7 бит.
[3] Шунда ук, 8 бит.
[4] Г. Сәгъди. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты, 37 бит.

үтеп керергә тиеш. Ул бу массаларга аңлаешлы булырга, алар тарафыннан яратылырга тиеш. Ул шушы массаларның хисен, фикерен һәм ихтыярын берләштерергә, аларны күтәрергә тиеш»[1]. Шушы фикердән чыгып, ул пролетариат әдәбиятының төп стиле реализм булырга тиеш дигән нәтиҗә ясый. Күрәсез, биредә сүз иҗат методы турында бара.

Инде революциядән соңгы әдәбият үрнәкләрен конкрет рәвештә тикшергәндә, Г. Сәгъди башлыча стильнең үзен күз алдында тота. Бу яктан аның «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» исемле хезмәте игътибарга лаек. Хезмәттә шул чор татар әдәбияты стиль ягыннан ике чорга бүлеп карала. Беренче чор гражданнар сугышы елларын (1918—1921) үз эченә ала. Илдә киеренке һәм авыр сыйнфый көрәш барган бу заманда пролетариатның уртак психологиясе туа. Бу психология үз чиратында шул чор әдәбиятында һәм сәнгатендә «үзенә махсус уртак бер стиль» тудыра. Аны Г. Сәгъди «кызыл романтизм» яки «хәрби коммунизм» стиле дип атый. Бу стиль әдәбиятының төп «иҗтимагый-психологик хосусиятләрен» хәрби энтузиазмда, чиксез каһарманлыкта һәм фронтта җиңү настроениесендә күрenә. Болар, үз чиратында, әдәбиятның «гыйсъянчылык, плакатчылык, абстрактчылык, космизм, схематик рәвештә язучылык, символчылык, мөбалагәчелек, нидачылык, агитация, ораторлык»[2] кебек сыйфатларын тудыралар. Шул ук вакытта галим аларны гражданнар сугышы чорындагы бөтен совет әдәбиятына хас сыйфатлар итеп тә карый. Татар әдәбиятындагы «хәрби коммунизм» стиленең беренче вәкилләре итеп ул Ш. Усманов белән К. Нәҗмине, М. Максуд белән Һ. Такташны саный.

Икенче чор (1921—1928) — тыныч тормышка, социализмның нигезләрен төзи башлауга күчү дәвере. Г. Сәгъди фикеренчә, ул дәвернең уртак иҗтимагый психологиясенә дә җитди эз сала. Бу психологиянең характерлы сыйфатлары рәтенә тормышка «тагын да ныграк реаль күз белән караучылык, революция тәҗрибәләрен һәр ягы белән ныклап өйрәнүчелек, социализмны төзү эшләрендә тагын да нык оешу, оештыручылык һ. б.»[3] керә. Болар барысы чорның уртак әдәби стиленә дә йогынты ясыйлар. Яңа әдәби стиль — пролетариат реализмы барлыкка килә һәм аның төп сыйфатларын «без»челек, коллективизм, конкретлык, ачыклык, гаммәчелек, матди һәм тормышлы булучылык[4] тәшкил итә.

Әдипләрнең нинди темага язуларына бәйле рәвештә, Г. Сәгъди гомуми әдәби стильнең ике вариантын билгели. Аларның беренчесен ул «авыл» варианты дип атый һәм аның вәкилләре итеп Г. Толымбай, Г. Гали, С. Кудаш, Д. Фәтхи һәм И. Хәйруллиннарны саный. Ә икенче, «шәһәр» вариантына М. Крыймов, Х. Туфан, Г. Ильяс, С. Батталларны кертә.

Метод мәгънәсендәрәк кулланылган гомум стильнең мондый вариантларын (аларны стиль агымнары дип тә атарга булыр иде) күрә башлауны әдәбиятның идея-эстетик үсешен һәм үзенчәлекләрен сиземләү дип бәяләргә мөмкин. Аннан соң хезмәтенең аерым әдипләргә багышланган бүлекләрендә ул язучы иҗатының үзенчәлекле сыйфатларын да күрсәтеп үтә. Әгәр Ш. Усманов геройлары дошманны «батырлык, осталык, акыллылык һәм хәйлә белән» җиңсәләр, К. Нәҗми хикәяләрендә исә кызыл гаскәр бу җиңүгә «көч белән, каракаршы килеп каты сугышу аркылы»[5] ирешә. Икенче бер очракта Г. Сәгъди әдипнең үзенчәлекләрен аның әдәби фикерләвеннән эзли. Бу уңайдан Х. Туфан иҗатына бирелгән анализ игътибарга лаеклы. Бер яктан, Г. Сәгъди аның иҗатында бөтен татар әдәбиятының стиль үсеше чагылуын, аның «романтиклык һәм космизмнан реаль вакыйгалылыкка, ягъни реализмга күчә» башлавын әйтә, ул Х. Туфанның «хис шагыйре түгел, уй шагыйре» булуын билгеләп үтә. Әгәр Дәрдмәндтә «фикер дулкыны белән хис дулкыны тигезрәк өлешле» булса, Х. Туфанда исә «авыр кузгалышлы уй, фикер хәрәкәте көчле»[6]. Әгәр Дәрдмәнд буржуаз тормыш тудырган фәлсәфи фикерләрне, «символизм, идеалистик монизм, тамырыннан чыккан символлар, шундый кинаячелекләр белән» бирсә, Туфан яңа социалистик чынбарлык тудырган фикерләрне «реаль тормышлы сурәтләр аркылы» бирә. Галимнең яңа әдәбиятны менә шулай традицияләр һәм новаторлык планында да карарга омтылуы тагын М. Максуд иҗатын тикшергәндә күренә. Бу әдипне ул революциягә кадәр формалашкан «чәчмә лирик өслүпне»

[1] В. И. Ленин о литературе. Рус телендә. Мәскәү, 1971 ел, 242 бит.
[2] Г. Сәгъди. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. 41 бит.
[3] Шунда ук. 45 бит.
[4] Шунда ук. 46 бит.
[5] Шунда ук. 61 бит.
[6] Шунда ук. 173 бит.

дәвам итүче дип карый. Сүз монда нәсерчелек традициясе турында бара. Ул М. Максудның бу традицион формадан яңа эчтәлекне бирүдә оста файдалануын күрсәтә. Әгәр революциягә кадәрге кайбер романтик шагыйрьләр әлеге форманы «йөрәкләрне пессимизм чаткылары белән көйдерү» теләгеннән чыгып файдалансалар, М. Максуд нәсергә «яңа матди хәят дәртен һәм җиңү тонын» бирү максатында мөрәҗәгать итә.

Революция тудырган яңа әдәбиятны үсеш... карап, аның үзенчәлекләрен ачарга омтылу Г. Нигъмәтигә дә хас. Бу омтылыш, аерым алганда, аның «Матур әдәбият фронтында ун ел» исемле күләмле мәкаләсендә ачык чагыла. Яңа пролетариат әдәбияты турында сөйләгәндә, игътибар үзәгенә революциядән соң формалашкан яшь әдип... иҗатын куеп, Г. Нигъмәти, аларда беренче елларда «заман тормышы күренешләрен киңләп тикшерүгә, вакыйгаларның үзләре турында хикәя язарга вакыт булмаса да, шул вакыйгалар турындагы тәэсирләрне язып, шуларны бүлешү теләге көчле иде»[1], ди. Бу елларда авторларның сәнгатьчә эзләнүләре пассиврак булу сәбәпле, аларның әсәрләренең әдәби эшләнеше дә «әле зәгыйфь, яңа идеяләргә карата тиешле художество формалары табылмаганлык күренеп ята»[2]. Шушылардан чыгып, ул бу чор татар әдәбиятында «корычтай коелган, яңгырап торган саф пролетариат әдәби стиле турында сүз дә булу мөмкин түгел иде»[3] дигән нәтиҗәгә килә.

Гражданнар сугышы тәмамланып, тыныч тормышка кайту белән, дип дәвам итә Г. Нигъмәти, әдипләр иҗат эшенә ныклабрак биреләләр. Әдәбият актив эзләнүләр юлына баса. Бу юлда әдипләр, романтизм, символизм, футуризм һәм имажинизм кебек агымнарны үтеп, реализмга киләләр, һәм реализм пролетариат әдәбиятының үз стиле булып таныла.

Әдәбиятның шушы гомум үсеш юлы турында сөйләү белән бергә, Г. Нигъмәти аерым әдипләрнең иҗат үзенчәлекләренә дә игътибар итә. К. Нәҗми хикәяләрендә, ди ул, «гражданнар сугышының конкрет типларын аерым кешеләр психологиясе белән бәйләп җентекләп бирелгән күренешләрен күрсәтүдән бигрәк, масса-күпчелек катнашкан күренешләрен бирә. Шуңа күрә дә аның аерым кешеләр исеме кертелеп, әсәрдә сурәтләр бирелешен шуларга бәйләп язган хикәяләрендә дә конкрет булмаган масса күренешләре күбрәк урын ала»[4]. Моның өстенә тагын К. Нәҗми әсәрләрендә «көрәшнең аерым моментларын бирүгә караганда, көрәш картиналарыннан алынган әсәрләнүләр, тойгыларны бирү (лирик момент) күп урын ала». Нәтиҗәдә әдип хикәяләрендә лиризм көчәя.

Шуннан соң Ш. Усманов иҗатына күчеп, Г. Нигъмәти аның әсәрләрендә гражданнар сугышының башкачарак яктыртылуын күрсәтә. Бу әдип инде «конкрет шәхесләрнең эш-хәрәкәтен күрсәтә, әсәрләрендә катнашучылар саны да чикләнүле... Хикәяләр вакыйгага бай, фабула төзелешенә әһәмият аларда нык бирелгән. Ләкин Шамил хикәяләре тел ягыннан эшләнү, кавидагыча сурәтләүче чаралар куллану ягыннан ярлылар. Ул хикәяләрен бизәкләп, матурлап, яңа сүзләр, катлаулы охшатулар сайлап тормыйча, турыдан-туры вакыйганың үзен язып, шуңа укучы игътибарын юнәлдерүгә күбрәк урын бирә»[5].

Шулай итеп, 20 нче еллар әдәбият фәнендә стиль мәсьәләсен аңлау шактый каршылыклы һәм буталчык төс ала. Бу төшенчә әле метод мәгънәсендә, әле үзенең туры мәгънәсендә кулланыла. Шуңа да карамастан, әдәбият фәненең бу мәсьәләгә дикъкать итүе кирәкле һәм законлы күренеш була. Чөнки моның белән революциядән соңгы әдәбиятның үсеш тенденцияләрен, әдипләрнең сәнгатьчә эзләнүләрен һәм табышларын гыйльми теоретик планда өйрәнүгә нигез салына.

Утызынчы еллар башыннан әдәбият белемендә һәм тәнкыйтьтә стиль мәсьәләсенә игътибар кими төшә. Беренче планга иҗат методы мәсьәләсе чыга. Баштарак ул рапчыларның «диалектик-материалистик иҗат методы» рухындарак аңлатылып килә. Мәгълүм булганча, рапчыларның бу төшенчәсе философия методын механик рәвештә әдәби иҗатка күчерү нәтиҗәсендә туа.

Республика матбугатында, бигрәк тә ТАПП органы булган «Атака» журналы битләрендә, иҗат методы мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр чыга башлый. Әмма ул мәкаләләрдә бу мәсьәләләр бик гадиләштереп аңлатыла. Ә кайчак авторларның метод төшенчәсен вульгарлаштырып һәм утилитар мәгънәдә аңлаулары күренә. Журналда басылган мәкаләләрнең берсендә,

---

[1] Ун ел эчендә татар матур әдәбияты. 16 бит.
[2] Шунда ук. 17 бит.
[3] Шунда ук.

[4] Шунда ук. 39 бит.
[5] Шунда ук. 41 бит.

мәсьәлән, болай диелә: «Хәзерге вакытта иҗат методының төп мәсьәләләреннән берсе булып демьянлашу проблемасы тора. Демьянлашу—үзеңнең иҗатыңны көндәлек сәяси һәм икътисади бурычлар белән нык бәйләп алып бару дигән сүз»[1]. Шундый бурычлар рәтеннән мәкалә авторы промфинпланны вакытында тутыру, язгы чәчүгә хәзерләнү, төрле җыемнарны вакытында җыеп бетерү һ. б. саный. Әмма берничә айдан, раппчыларның башка «иҗади» лозунглары кебек үк, «демьянлашу»ның да ялгыш булуы танылa. Безнең матбугатта РАПП җитәкчеләренең ялгышларын беренче булып К. Нәҗми тәнкыйтьләп чыга[2].

Татар тәнкыйтендә һәм әдәбият белемендә иҗат методы мәсьәләсе 1934 елдан, ягъни совет язучыларының беренче бөтенсоюз съездыннан соң тирәнрәк һәм дөресрәк яктыртыла башлый. Бу, аерым алганда, Г. Ибраһимовның «Кайбер әдәби мәсьәләләр» һәм Г. Нигъмәтинең «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» дигән мәкаләләрендә ачык чагыла. Әлеге мәкаләләрдә сүз социалистик реализм методы турында бара һәм аны марксистик-ленинчыл эстетика позицияләреннән торып яктыртырга омтылыш сизелә. Г. Ибраһимов белән Г. Нигъмәти совет әдәбияты методын татар әдәбият фәнендә беренче мәртәбә Ленинның чагылыш теориясенә һәм Энгельсның реализм концепциясенә таянып аңлаталар. Әйтик, Г. Нигъмәти социалистик реализмны «социалистик идея җитәкчелегендәге типик характерларны типик хәлләр эчендә бирү аша тормышны дөрес һәм җанлы итеп сурәтләрдә гәүдәләндерү[3]» дип бәяли. Һәр ике мәкаләдә дөреслек һәм типиклык мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Г. Ибраһимов иң элек сәнгать дөреслеген натурализм белән бутауга каршы чыга: «Мин натурализмга каршы. Тормыш кисәкләрен шул көенчә, фотографияләп, дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк»[4], ди. Аныңча: «әдәби әсәрләр тормышның каты көрәшле, күп катлаулы, бай каршылыклы тирән процессларын иҗат механизмы аркылы, җанлы сурәтләрдә гәүдәләндерү, чагылдыру юлы белән язылганда гына социалистик реализмга ирешеп булачак». Шул ук вакытта әдипкә бу төшенчәне таратып яки берьяклы итеп аңлатучылар белән дә очрашырга туры килә. Аерым тәнкыйтьчеләр аны үз әсәрләрендә большевик образларын әледән-әле һәлак иттергән өчен гаепләүләр. Мондый гаепләүләргә әдип В. И. Ленинның чагылыш теориясенә нигезләнеп җавап бирә. Бу теория белән коралланган әдәбият, ди Г. Ибраһимов, безнең үсешебезне бөтен барлыгында һәм төрле яклап күрсәтергә тиеш. Үзенә гаеп ташлаучыларга әдип мондый сорау бирә: «Гражданнар сугышында большевиклар үлде... Эшчеләр корбаны булдымы? Әллә бу үлетик акларны гына кырып, кызылларга тимәдемe?» Юк, ди әдип, «партия бик зур бирде, безнең һәммә фронтларыбыз, һәммә җиңүләребез күп кыйммәтле корбаннар аркылы алынды»[5]. Һәм әдәбият үзенең иң яхшы әсәрләрендә шушы олы хакыйкатьне күрсәтә. Моңа мисал итеп Г. Ибраһимов А. Фадеевның «Тар-мар» романын китерә. Аныңча, сугыштагы югалтуларны тасвирлау язучы өчен һич тә үзмаксат була алмый. Аларны «яшь буынны тәрбияләрлек, көрәшкә... чакырырлык итеп кискен тасвирларда язарга кирәк. Шулай иткәндә генә әдәбият безгә көрәш коралы була алачак, шулай иткәндә генә безнең әдәбият Ленинның теория отражения действительности принцибы нигезендә үсә алачак»[6].

Г. Нигъмәти үз мәкаләсендә, социалистик реализм методының «нигез мәсьәләсе дөреслек, җанлылык нигезендә типик хәлләр эчендә типик характерлар бирү»[7], ди. Алга таба галим типиклыкка түбәндәге бәяләмәне бирә: «Каһарманның типик характер булуы аның сыйныф яки сыйнфый катлауның табигатенә тапкыр килүе дигән сүз. Характер бөтен индивидуаль төрлелеге белән бирелергә, бөтен эчке каршылыгы белән күрсәтелгән булырга тиеш, ләкин шул вакыт анда билгеле бер сыйныф үзен сиздереп торырга, шул сыйныфның сыйнфый табигате өчен типик булган черталар өстенлеге анда табылырга тиеш»[8]. «Типик хәлләр» төшенчәсе дә шушы рухта аңлатыла.

Әйтергә кирәк, иҗат методы мәсьәләләрен яктыртканда Г. Нигъмәтинең сыйнфыйлыкка болай басым ясавы бер дә очраклы хәл түгел. Чөнки бу елларда кайбер әдәбият белгечләре, бигрәк тә раппчылар, яшь

---

[1] «Атака» журналы, 1931, 2 сан, 11 бит.
[2] Шунда ук, 11—12 саннар.
[3] Г. Нигъмәти. Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре. «Совет әдәбияты» журналы, 1933 ел, 11—12 саннар, 84 бит.
[4] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан 1960, 219 бит.
[5] Шунда ук, 222 бит.
[6] Шунда ук, 223 бит.
[7] Г. Нигъмәти. Татар әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре. 83 бит.
[8] Шунда ук, 84 бит.

совет әдәбиятын сыйнфыйлык һәм партиялелек позицияләреннән читкә алып китәргә тырышалар. Әмма аларның бу омтылышы партиянең һәм әдәби җәмәгатьчелекнең кискен тәнкыйтенә очрый. Шушы тәнкыйтькә кушылып, Г. Нигъмәти совет әдәбиятын теоретик планда өйрәнгәндә сыйнфыйлыкны, төп методологик принцип итеп, үзәккә куя. Әмма Г. Нигъмәти кайчак бу эш белән артыграк мавыгып китә. Менә бер мисал. Галим герой характерының аның эше белән бәйләнгән булуын әйтә дә, бу мәсьәләне марксистик рухта аңлату үрнәге итеп В. И. Ленинның түбәндәге фикерен китерә: «Эшләрен аңламаганда, кешеләрен дә... тышкы яктан гына аңларга була. Ягъни көрәштә катнашучы тегe яки бу кешенең психологиясен аңларга мөмкин, ләкин көрәшнең мәгънәсен түгел, аның партия өчен һәм политик әһәмиятен түгел»[1]. Бу цитатадан соң Г. Нигъмәти мондый нәтиҗә ясый: «Димәк, В. И. Ленин кешене бирүне сыйныфтан тыш торган бер тере кеше» бирү итеп алмый, сыйнфый кеше бирү дип ала»[2].

Әйтергә кирәк, бу очракта Г. Нигъмәти бөек юлбашчы фикерен үзенчәрәк аңлата. Моны ачыклау өчен тарихка күз ташлыйк. Әлеге фикерне В. И. Ленин М. Горькийга язган бер хатында әйтә. Бу вакытта (1909 елда) М. Горький Капри утравында яши һәм Ленинны күп кенә мөһим мәсьәләләрдә Богданов һәм Луначарский белән килештерергә тырыша. Шул ук вакытта М. Горький Владимир Ильичка алар арасындагы бәхәсне аңлый алмавын белдерә һәм болай ди: «Кешеләрен аңлыйм, ә эшләрен аңламыйм». Язучының бу сүзләре В. И. Ленинны ышандыра алмый һәм ул Горькийга югарыда китерелгән сүзләрне әйтеп хат яза. Анда В. И. Ленин кеше эшенең, бу очракта кеше көрәшенең партиячел һәм политик мәгънәсе турында сүз алып бара. Г. Нигъмәти исә бу өземтәгә каяндыр алып «сыйнфый кеше» төшенчәсен китереп кертә.

Тулаем алганда, Г. Ибраһимов һәм Г. Нигъмәти мәкаләләрендә яңа иҗат методының күп кенә мөһим мәсьәләләре күтәрелә. Шул ук вакытта алар бу методка хас булган барлык сыйфатларны ачып та бетерә алмыйлар. Алар күбрәк сыйнфыйлык принцибы белән эш итәләр, партиялелек һәм халыкчанлык, тарихилык һәм гуманизм принциплары турында, төпле мәгълүмат бирмиләр.

Утызынчы елларның уртасыннан әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтьтә теория мәсьәләләрендә игътибар кими. Бер яктан, Г. Халит әйткәнчә, алгы планга «татар классик әдәбияты вәкилләрен, аерым әдәби әсәрләрне масса алдында популярлаштыру һәм татар әдәбияты тарихын халыкка җиткерү»[3] бурычы куела һәм бу өлкәдә байтак эш башкарыла. Икенче яктан, фольклорны өйрәнүгә игътибар бермә-бер көчәя. Ә шагыйрьләр һәм драматурглар халык иҗаты әсәрләрен җыеп һәм өйрәнеп кенә калмыйлар, бәлки аларның мотивларына таянып әдәби әсәрләр дә язалар.

Шулай да тәнкыйтьнең төп игътибары агымдагы әдәби хәрәкәткә юнәлдерелә. Әмма бу хәрәкәтне анализлауда һәм бәяләүдә, бер яктан, үткән еллардан килгән вульгар социологизм үзен шактый сиздерсә һәм комачаулык тудырса, икенче яктан, тәнкыйтьнең эстетик базасы сай, критерийлары чикләнгән булуы күренә. Ул күбрәк әсәрләрнең идея-политик яңгырашы белән кызыксына, аларның шушы сыйфатын күтәрү өчен көрәшә. Әдәбиятның сәнгатьчәлегенә, бу өлкәдәге эзләнүләргә һәм ачышларга исә тиешле игътибар булмый яки алар кайчак шактый берьяклы аңлатылалар. Моңа мисал итеп К. Нәҗминең 1936 елда басылган «Татар совет әдәбияты яңа күтәрелеш алдында»[4] дигән мәкаләсен һәм Ә. Ерикәйнең 1947 елда язучылар җыелышында сөйләгән докладын[5] китерергә мөмкин. Гәрчә төрле вакытларга карасалар да, бу чыгышлар үзләренең рухлары буенча бер-берсенә бик якыннар. Аларда безнең тәнкыйтьнең шул чордагы җитди һәм типик кимчелекләре аеруча тулы чагыла. Теоретик фикерләүнең йомшак булуыннан туган бу кимчелекләрне һәм ялгышларны безнеңчә, «Бер тәнкыйть уңае белән» дигән мәкаләсендә Ә. Фәйзи бик дөрес ача. Аларны шагыйрь «әсәргә аның гомум тенденциясенә игътибар итмичә, аерым кимчелеге буенча гомуми хөкем чыгару»да, әсәрне «күзгә бик якын тотып, «күрә карап» укуда, мәгънәләре ягыннан бер-берсеннән бик ерак торган төшенчәләрне, мисал өчен «символ» белән «символизм»ны

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 34 том. Казан. 1963, 389 бит.
[2] Г. Нигъмәти. Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре. 83 бит.
[3] Г. Халит. Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйть мәсьәләләре. «Совет әдәбияты» журналы, 1941 ел, 1—2 сан, 127 бит.
[4] «Совет әдәбияты» журналы, 1936 ел, 3 сан.
[5] Ә. Ерикәй. Совет әдәбиятының яңа күтәрелеше өчен. «Совет әдәбияты», 1947 ел, 8 сан.

«форма» белән «формализм»ны, «тормыш дөреслеге» белән «натурализм»ны һ. б. үзара бутауда күрә [1].

Шул рәвешле фикер йөртеп, К. Нәҗми, мәсәлән, әлеге мәкаләсендә Х. Туфан, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Файзи һәм Ф. Бурнаш кебек шагыйрьләрне формализм чире белән авыруда, К. Тинчурин, Ш. Усманов, Х. Садри, Ф. Сәйфи-Казанлыларны натурализмга бирелүдә гаепли. М. Җәлилнең түбәндәге юлларын ул формализм үрнәге итеп китерә:

Кояш җирнең көмеш йонын тарый,
Кыр куяны төсле тере кыр.
Мамык кардан булган йонын коеп,
Ак-кола төскә төренде.

Шикәр төсле ак кар челтәрләнеп
Сүтелә бара.
Күбекләнеп аккан кар дулкынын
Җилләр тиздән сүтеп бетерер.

Күренә ки, биредә бернинди дә формализмга бирелү юк, бәлки шагыйрьнең образлы тасвирга омтылуы турында гына сүз булырга мөмкин.

Әдәбиятның идея сафлыгы мәсьәләсендә үтә уяулык күрсәткән, әмма эстетик критерийлары анык булмаган мондый тәнкыйть әдипләрнең сәнгатьчә эзләнүләрен шик астына ала. Еш кына шулай була: тәнкыйть сүздә әдәбиятның сәнгатьчә сыйфатын күтәрүне дүрт куллап яклый, шуның өчен көрәшкә чакыра, ә практикада аерым язучыларның шул юнәлештәге эзләнүләрен формализм күренешләре дип кире кага. Бу хәл ахыр чиктә сәнгатьчә эзләнүләрне, формалар һәм стильләр төрлелеген инкарь итә, әдипләрне стандарт фикерләүгә һәм натурализмга этәрә иде.

Гәрчә мондый тәнкыйть аерым тәҗрибәсезрәк язучыларга мәгълүм бер йогынты ясаса да, әдәбиятның гомум үсеш юлын үзгәртә алмый. Иҗади эзләнүләр, стильләр төрлелеге елдан-ел үсә һәм көчәя бара. Бер яктан, әдәбиятның милли үзенчәлеген, икенче яктан, аерым язучыларның индивидуаль стильләрен өйрәнү көн тәртибенә куела килә. 1940 елның 7 декабрендә республика язучыларының гомуми җыелышында ясаган отчет докладында М. Җәлил болай ди: «Безнең әдәбиятыбызның милли формасы нидән гыйбарәт? Бит бу безнең әдәбиятның яшәү формасы, ул булмаса, ул үзенең индивидуальлеген, конкретлыгын югалта. Бу проблеманы ныклап өйрәнергә кирәк. Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камал һ. б. үзенчәлеге нәрсәдә? Аларның иҗатында милли форма ничек чагыла?» [2]. Күренә ки, М. Җәлил биредә милли стиль һәм индивидуаль стильләр турында сүз алып бара. Шушы ук мәсьәләләрне 10 елдан соң, Татарстан язучыларының II съездында ясаган отчет докладында Г. Кашшаф кабат күтәрә. Ул тәнкыйтьнең мондый мәсьәләләргә «бөтенләй диярлек кагылмавын», М. Максуд, А. Шамов, Ш. Маннур, Ә. Исхак, Ф. Хөсни кебек танылган әдипләрнең «иҗат йөзләре өйрәнелмәвен» [3] әйтә.

Гомумән алганда, 50 нче еллар башында безнең тәнкыйтьтә әдипнең иҗат үзенчәлеге мәсьәләсенә игътибар арта төшә. Беренче чыгышларда әле сүз гомуми төстәрәк, иҗат үзенчәлекләре мәсьәләсе белән кызыксынуның кирәклеген тану рәвешендәрәк бара. «Әдәби осталык турында» исемле мәкаләсендә Г. Бәширов, мәсәлән, болай яза: «Тәнкыйть мәкаләләрендә булсын, җыелышларда булсын, әдәби әсәр турында сүз барганда, аны чын мәгънәсендә әдәби әсәр иткән «нечкәлекләргә» тукталмастан, гомуми төстә сүз йөртү гадәте бар. Хәлбуки, ел саен берничә роман, дистәгә якын поэма, хикәя һәм әдәби очерклар язылып торган, шуның өстенә бай гына әдәби мирасы һәм традицияләре булган бер әдәбиятта сюжет, композиция, тел, стиль һәм аларның һәркайсының үзенең нечкәлекләрен өйрәнүгә багышланган җитди фәнни хезмәтләр, тирән тикшеренүләр булмау ул тәнкыйть өлкәсенең артталыгын, аның әдәбиятка юнәлеш бирергә сәләте җитмәвен күрсәтә» [4].

Шушы кимчелекләрдән арынырга теләгәндәй, тәнкыйтьтә аерым әсәрләрнең әдәби «нечкәлекләр»енә үтеп керергә омтылышлар ясала башлый. 1953 елда «Совет әдәбияты» журналында бер-бер артлы Г. Ахуновның «Намус» романының сурәтләү чаралары» (8 сан), Ф. Хатиповның «Онытылмас еллар» повестеның художество эшләнеше» (9 сан) һәм Я. Халитовның «Язгы җилләр» романының тел һәм стиль үзенчәлекләренә карата» (10 сан) дигән мәкаләләре басылып чыга. Аларда әлеге әсәрләрдәге тел һәм сурәтләү чаралары турында кызыклы гына күзәтүләр ясала.

Әгәр әлеге мәкаләләрдә язучының индивидуаль стиленә караган аерым детальләр турында сүз барса, бара-тора стиль мәсьәләсе киңрәк планда куела башлый. Бу

[1] Ә. Файзи. Бер тәнкыйть уңае белән. «Совет әдәбияты», 1948, 6 сан.

[2] «Совет әдәбияты», 1941, 1—2 сан, 119 бит.
[3] «Совет әдәбияты», 1950, 8 сан, 82 бит.
[4] Шунда ук, 1952, 1 сан, 99 бит.

яктан М. Әмир белән Ф. Хөснинең республика язучыларының III съездында (1954) ясаган чыгышлары игътибарга лаеклы. Алар шул елларда рус тәнкыйтендә дә актуаль төс алган уңай герой мәсьәләсенә ике төрле карашны чагылдыралар. Гади генә итеп әйткәндә, М. Әмир «идеаль» герой концепциясен яклап чыга. Ф. Хөсни исә уңай геройларны сурәтләгәндә «аларны һәртөрле мәшәкатьләрдән, булуы мөмкин һәм табигый булган кыенлыклардан ничек булса да ышыклап калырга»[1] кирәкми ди. М. Әмир һәм Ф. Хөсни чыгышлары безнең әдәбияттагы ике стиль агымын күзаллау ягыннан кызыклылар. Дөрестән дә, М. Әмир белән Ф. Хөсни геройларны сурәтләүдә аеруча ачык чагыла торган ике стиль агымына безнең тәнкыйтьтә беренчеләрдән булып һәм бәлки әле үзләре дә сизеп бетермичә дикъкать иттеләр. Аларның берсе геройларны сурәтләгәндә ап-ачык төсләр белән эш итүгә, тормыш пафосын калку итеп гәүдәләндерергә чакыра. Ә икенчесе исә геройның көндәлек гадәти яшәешенә йөз тотуны, аны бөтен барлыгы белән гәүдәләндерүне яклый.

Илленче еллар башында аерым әдипләрнең иҗат үзенчәлекләре тирәсендә башланган сүз тора-бара әдәбиятта стильләр төрлелеге турында сөйләшүгә әверелә.

Индивидуаль стиль һәм стиль агымыннан тыш, тәнкыйтьтә милли стильгә караган мәсьәләләр дә кузгатыла башлый. «Хәзерге татар прозасы турында» дигән мәкаләсендә Х. Хәйри әдәбиятта милли форма һәм милли үзенчәлек мәсьәләсенә кагыла. Ул милли форманы бары тик тел һәм сурәтләү чараларына гына кайтарып калдыруга каршы чыга һәм бу төшенчә халыкның милли характер сыйфатларын да чагылдыруны кертә[2]. РСФСР язучыларының беренче съездында ясаган чыгышында исә Ф. Хөсни, әдәбиятта милли үзенчәлекләрне күрсәтүне өнәмәүчеләр белән бәхәскә кереп, икенче чиккәрәк ташлана, ягъни, соңрак И. Нуруллин хаклы әйткәнчә, әдәбиятның милли үзенчәлеген «милли колорит мәсьәләсенә генә кайтарып калдыра»[3].

Гомумән алганда, 20—50 нче елларда татар әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтендә әдәби стильгә караш бу мәсьәләне абстрактсыйнфый планда аңлатудан аны конкрет эстетик нигездә өйрәнүгә күчү юнәлешендә үсә килә. Нәтиҗәдә, әдәбиятның эстетик байлыгы, андагы сәнгатьчә эзләнүләр һәм табышлар да торган саен тулырак һәм тирәнрәк ачыла баралар. 60—70 нче елларда бу тенденция тагын да көчәя төшә.

---

[1] «Совет әдәбияты», 1954, 8 сан, 87 бит.

[2] «Совет әдәбияты», 1958, 8 сан, 107 бит.

[3] Шунда ук, 1961, 8 сан, 151 бит.

# ӘДӘБИЯТ ХӘЗИНӘСЕ

„Хәзинә» дилогиясе өстендә Гариф Ахунов алтмышынчы елларның башында ук эшли башлаган иде. Билгеле булганча, шул чорда ул, Әлмәткә китеп, үзенең булачак геройлары арасында яшәде, Татарстанда нефть эзләүнең тарихын җентекләп өйрәнде. Нефтьчеләр тормышына багышланган очерклар, мәкаләләр язды. Болар барысы да роман язу өчен хәзерлек чоры иде. 1963 елда «Хәзинә» романы дөнья күрде, тагын биш елдан китап сөючеләр әсәрнең дәвамы булган «Хуҗалар» романы белән таныштылар.

«Хәзинә» укучылар тарафыннан җылы каршыланды. Роман Г. Ахуновны чын язучы итеп танытты. Габдулла Тукай исемендәге премия аңа «Хәзинә» романы өчен дә бирелде.

Дилогиянең икенче кисәге булган «Хуҗалар» романы исә бераз башкарак язмышка очрады. Ул төрле бәхәсләр кузгатты. Аңа карата күп кенә тәнкыйть сүзләре әйтелде. Язучы Арслан Гобәйдуллин образын үсештә бирә алмаган, аңарда хәзерге заман җитәкчеләренә хас интеллектуальлек җитеп бетми, диделәр. Әсәрнең сюжет-композиция төзелешендәге аерым кимчелекләр күрсәтелде. Фатих ага Хөсни хатта: «Роман кадәр романда роман юк», дигән фикер әйтте.

Татарстан язучыларының соңгы съездында ясаган докладыннан күренгәнчә, Г. Ахунов бу әсәренең өлгереп җитмәгән булуын үзе дә аңлаган һәм, җиң сызганып, аны әдәби яктан камилләштерү өстендә эшләргә керешкән. Нәтиҗәдә «Хәзинә» романы белән уртаклыгы, һава берлеге сизелеп торган әсәр барлыкка килгән[1]. Болар «... Гариф Ахуновның, иҗат кешесе буларак, үз эшенә җитди каравын, тәнкыйть сүзенә колак сала белүен, туктаусыз эзләнүен, тынгысызлыгын раслыйлар»[2].

Дилогиянең беренче кисәгенә автор сизелерлек кул тидермәгән, ә «Хуҗалар»га, югарыда әйтелгәнчә, җитди үзгәрешләр кертелгән. Ләкин бу әле Г. Ахунов әсәр уңае белән әйтелгән тәнкыйть фикерләренең барысын да кабул иткән дигән сүз түгел. Ул килешердәйләрен, үзе дөрес дип тапканнарын гына кабул иткән. Әйтик, «Хуҗалар»ның төп герое Арслан нигездә беренче варианттагыча калган. Автор бу образның характерын билгели торган төп сыйфатларны үзгәртүне кирәк тапмаган. Арслан, элеккечә үк, җәмәгать мәнфәгатьләрен шәхси мәнфәгатеннән өстен куя, өенә келәм күтәреп килгән ялагайны куып чыгара, сабан туенда көрәшеп батыр кала, эчми-тартмый, сүгенә белми... Язучы үзенең бу героен башкаларга карагандакалкурак итеп сурәтли, аның уңай сыйфатларын ачык итеп, күпертеп бирә. Әмма, моңа карап кына, Арслан җир кешесе түгел дигән катгый нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. Тирә-юньгә игътибар беләнрәк карасак, мондый Арсланнарны күп очратырбыз.

Яңа вариантта автор үзенең бу героен тагын да күтәрә төшкән. Моңа ул образның бөтенлегенә зыян китерә, аны кечерәйтә һәм ваклый торган аерым эпизодларны кыскарту хисабына ирешкән. Беренче басмада, мәсәлән, мондый бер күренеш бар иде: яңа завод салу проекты белән дәртләнеп йөргән Арслан тота да, алдынартын уйлап тормыйча, Мәскәүгә китеп бара. Ләкин анда да эшләре барып чыкмый. Менә ул төшенке күңел белән башкаладан кайтып килә. «Чөйдә портфель эленеп кайта. Вагон чайкалган саен шап-шап стенага бәрелгән әнә шул калын сары порт-

[1] Г. Ахунов. Хәзинә. Татарстан китап нәшрияты, 1974 ел.

[2] А. Гыйләҗев. «Хәзинә»гә кереш мәкалә.

фельдә Арсланның чәлпәрәмә килгән өметләре кайта». Арслан башында авыр уйлар. Партиянең шәһәр комитеты секретаре Камил Мөстәкыймо̄в та башкалада булган икән, кайтырга бергә чыкканнар, юлдашы Арсланны ресторанга барырга чакырмаган, иптәшләрен эзләп киткәнгә салынып, үзе генә киткән. «Арслан үзе дә, начальник икәнен онытып, «тузан коеп» алырга каршы килмәс иде, ләкин аңардан читләшәләр, аның шешә белән дус булмавын белгән көннән бирле, аны компаниягә алмыйлар». Арслан эченнән әнә шулай уйлый. Ресторанга чакырмаган өчен, Мөстәкыймовка үпкәләп тә куя.

Яңа басмада исә бу юллар кыскартылган. һәм моннан образ бары тик откан гына. Арслан кебек җитәкче кешенең урындагы совет-партия органнары белән киңәшми торып, Мәскәүгә чыгып чабуы да, юк кына нәрсәләр өчен Мөстәкыймовка үпкәләп йөрүе дә аны бизәми, билгеле.

Камил Мөстәкыймов турында сүз чыккан икән, шул кад ресен дә билгеләп үтәргә кирәк. Төптәнрәк уйлап караганда, алда китерелгән эпизод секретарьны да уңай яктан ачмый бит. Партиянең Кәлимәт шәһәр комитеты секретаре Мөстәкыймов та Мәскәүдә булган. Ләкин нәрсә эшләгән ул анда? Газ эшкәртү заводы салу проекты белән Дәүләт комитетына Арслан үзе генә керә. Поездда да алар очраклы төстә генә бер вагонга туры киләләр. Мөстәкыймов белән Арсланны юлда бу рәвешле очраштыру авторга алар арасындагы конфликтны бераз куертып алу өчен кирәк булган. Арслан Дәүләт комитетында юлы уңмаганга борчылып утырганда вагонга «...авыз эченнән көңелле бер көй көйләп, Камил Мөстәкыймов кайтты. Өстәл буенда бөкрәеп утырган юлдашына:

— Моңаябызмы, Арслан Шәвәлиевич? — диде.

Арслан дәшмәгәч, тавышсыз гына чишенеп, салкын одеял эченә кереп ятты».

Әгәр дә Мө экыймов гомуми эш өчен янып йөрүче секретарь булса, сүз белән генә булса да, Арсланның көнелен юатыр, мәсьәләне тиешле органнар алдында куярга киңәш итәр иде.

Кыскасы, әлеге эпизодны төшереп калдырып, автор берьюлы ике образны — Арсланны да, Мөстәкыймовны да ваклanудан саклап калган.

Хәтерлисездер, беренче басмада яңа завод салу уе белән янып йөргән Арсланга «Татнефть» берләшмәсе җитәкчеләре: «Сабыр итик, иптәш Гобәйдуллин, партия бездән әлегә завод сорамый, нефть сорый», — дип җавап бирәләр. Димәк, югары хуҗалык җитәкчеләре шушындый җитди мәсьәләгә бәя биреп җиткермиләр, скважиналардан ургылып чыккан газның әрәмгә янып утыруына битараф карыйлар булып чыга. Алай гына да түгел, кушканны гына үтәп утыручы ваемсыз бәндәләр булып чыгалар. Партия бүген нефть сорый икән, нефть бирик, ә иртәгә газ сораса, ул турыда да уйларбыз, янәсе.

Ләкин «Татнефть» берләшмәсе кебек тулы бер югары хуҗалык оешмасының мондый политик-экономик сукырлык күрсәтүе тормыш чынбарлыгына туры килми. Автор бу турыда да уйланган. Яңа басмада: «Партия әлегә бездән завод сорамый, нефть сорый», дигән сүзләрне промыселның баш технологы Шәйхразиев кына әйтә. Әйе, аерым кешенең болай әйтүе бик мөмкин. Яңа вариантта Арслан Гобәйдуллин проекты, «Татнефть» берләшмәсендә каралып, Совнархозга җибәрелә, аннан Дәүләт комитетына керә. Димәк, югары оешмалар завод салуга каршы килмиләр. Тик төзелешне финанслау мәсьәләсендә генә кыенлыклар килеп чыга. Чөнки бишьеллык план инде расланган, нинди дә булса статьядан акча кыеп алу җиңел түгел. Бу эшкә партия органнары килеп кушылгач, боз урыныннан кузгалып китә. Завод төзүнең генә түгел, ә аның янында шәһәр салуның да проекты раслана.

Язучы психологик тирәнлекне дә көчәйтә төшкән. Беренче басмада газ эшкәртү заводын төзеп булмаячагын Кожанов Арсланга кистереп әйтә. Соңгы басмада инде ул ордым-бәрдем генә эш итми. Күңелсез хәбәрне әйтер алдыннан Арсланны психологик яктан әзерли, сүзе белән шатландыра алмаса да, аңа булган җылы мөнәсәбәте белән хәлне бераз җиңеләйтергә тели. Сөйләшү алдыннан чәй, коньяк белән сыйлый. Аннан соң да әле әйтәсе сүзен капылт кына аударып ташламый.

Шул рәвешчә, автор биттән-биткә, бүлектән-бүлеккә әсәрне камилләштерә, шомарта бара. Сюжет үсешендә артыклыгы күренеп торган урыннар төшереп үк калдырыла. Элекк: басмада буровой эшчесе Буяновның колак әтисе һәм алтын белән бәйләнгән маҗаралары бик киң итеп бирелгән иде. Яңасында бу урыннар бөтенләй юк.

1968 елгы басмада без Булат Дияровны да, ничектер, каршылыклы, үз кыйбласын

табып җиткермәгән герой итеп күргән идек. Ул яхшы нефтьче, бораулау мастеры, урау юллар белән булса да, семья да корып җибәрә. Әтисе эстафетасын уңышлы дәвам иттерүче яшь буын вәкиле. Көннәрдән бер көнне, курортларда йөреп, ил күреп, сәламәтлеген ныгытып кайткач, аны «корт» чага, нефтьче әшен мәгънәсезлек дип атауга кадәр барып җитә. Кешеләр өнә ничек ял итәләр. Ә без җилле-давыллы далада боларның бөтенесеннән читтә яшәргә мәҗбүрбез, имеш. Булатның өлеге фикер капма-каршылыклары яңа вариантта төшерелгән. Аларны алып ташлап, Г. Ахунов әсәрне кирәкмәгән йөктән җиңеләйтә төшкән.

Билгеле булганча, 1963 елда чыккан «Хәзинә» романының эпилогы да бар иде. Соңгы басмада бу эпилог өлеше «Хуҗалар» кисәгеннән соң бирелгән. Шулай итеп, ике кисәкнең бөтенлеге тагын да арта төшкән. Эпилогның эчтәлеге дә нык үзгәреш кичергән. Элек, демонстрациячеләр колоннасы белән үзәк мәйданны узгач, Арслан мотоциклы белән халыктан аерылып чыга да зиратка юнәлә. Кәрим Тимбиков каберенә килә. «Кәримне татар нефте тарихыннан сыза алмыйсың», — ди ул. Дилогиянең соңгы басмасындагы эпилогта Арслан шулай ук демонстрация колоннасында күрсәтелә. «... Мотоциклын аудармас өчен, үзенә бирелгән ал байракны тәз тотып алып барыр өчен, ул мотоцикл рулендә ныграк ябышты. Бәйрәмне Арслан балалары янында, Сәгыйдәнең каберенә зират кылып, гаиләсе белән генә үткәрергә теләгән иде. Менә аның бәйрәм колоннасын кырт кисеп, зиратка таба китеп барасы килде. Ләкин бу мөмкин түгел, ул колоннаны боза алмый, шушы зур һәм күмәк ташкын аны үзе белән алып бара иде».

Күргәнебезчә, халык ташкыны Арсланны үзенә ияртә, үз эчендә эретә. Бу очраклы түгел, ул инде күбрәк үз көченә ышанучы ялгыз герой түгел, ә халык массалары белән тыгыз бәйләнештә булган җитәкче.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: Гариф Ахунов соңгы басмада «Хәзинә» дилогиясен тагын да уңышлырак итеп язган. Әсәрнең ышандыру көче үскән, сюжет тыгызлыгы арткан, әсәрнең тукымасына бик үк ябышып тормаган урыннар төшереп калдырылган. Язучы яңа вариантта образларның тормышчанлыгын, рухи дөньяларын баетуга, психологизмны үстерүгә аеруча игътибар иткән. «Хәзинә» романы, хаклы рәвештә, татар әдәбиятының уңышлы әсәрләре киштәсендә үзенең лаеклы урынын алды. Аны, үз чиратында, әдәбиятыбыз хәзинәсе дип атарга мөмкин.

**ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН.**

# ЗАМАН ТЕМАСЫН ЗАМАНЧА ЧИШИК

Эдуард Касыймовның «Һаваларда тургай» романына язылган аннотациядә: «Моңысында сез яңа геройлар белән танышырсыз һәм үзегез яратып өлгергән персонажлар белән янә очрашырсыз. Ләкин алар инде яңа шартларда хәрәкәт итәләр, чөнки тормыш хәлләре үзгәргән, куера һәм кискенләшә төшкән, ә алда торган проблемалар җитди дә, катлаулы да, роман, шул сәбәпле, мөстәкыйль әсәр төсен алган», — дигән сүзләр бар.

Дөрестән дә, «Һаваларда тургай»ның «Томан аша» романы белән бәйләнеше артык зур түгел. Персонажлар, нигездә, шул ук булсалар да, икенче китапта геройларның башкалары алгы планга чыккан һәм аларның үзара мөнәсәбәтләре «Томан аша»ны укымаганда да аңлашылып тора. Вакыйгалар шул ук Бондюг заводында, аның тирәсендә бара. Ләкин игътибар үзәгенә куелган мәсьәләләр — башка. Әмма ни генә булмасын, бу ике романны, һичшиксез, уртак тема, бер үк диярлек персонажлар берләштерә. Һәм алар бер-берсен күпмедер дәрәҗәдә дәвам итә, тулыландыралар.

Соңгы елларда аерым заводларның һәм фабрикаларның тарихын өйрәнү эше нык җанланып китте. Моның нихәтле әһәмиятле, кирәкле булуы бәхәссез. Мәскәү, Ленинград заводларының тарихын

махсус өйрәнү нәтиҗәсендә язылган документаль һәм әдәби әсәрләр шул хакта сөйли.

Э. Касыймов чыннан да мактаулы эшкә алынган. Татарстанда химия промышленносте көннән-көн үсә, аның халык хуҗалыгындагы башка тармаклар һәм өлкәләр белән бәйләнеше ныгый бара. Язучы тасвирлый торган Бондюг заводы үзенең зур тарихы, данлы традицияләре белән аерылып тора. Дөрес, язучы заводның тулы тарихын язуны максат итеп куймаган, ул аның бүгенге көнен сурәтли. Әмма аның югарыда телгә алынган әсәрләрен укыганда, заводның ерак үткәне, Менделеев эшчәнлеге белән бәйле чорлары да шактый ачык булып күз алдына килә.

«Томан аша» һәм «Һаваларда тургай» романнарында тарих белән бүгенге көннең бәйләнеше өлкән буын белән яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә, әсәр геройларының гыйбрәтле язмышында бирелә. Нәселдән-нәселгә күчә килгән эшче горурлыгы, беренче чиратта, завод язмышын кайгырту, аның мәнфәгатьләре белән яшәү, кеше тормышының зурлыгын, әһәмиятен эшкә мөнәсәбәт белән үлчәп карау — өлкән буынга хас төп сыйфатлар енә шулар. Закир карт, Тиунов, Григорий Афанасьич, Мирыч кебек геройларның тамырлары, гомерләре, язмышлары шушы завод белән бәйләнгән.

Госман, Рива, Рәшит, Марс, Фуат, Зөлфә, Асияләр — яшь буын вәкилләре. Алар — аң-белемле, фән һәм техника белән коралланган кешеләр. Аларның характерлары, тормышка мөнәсәбәтләре дә катлаулырак, омтылышлары һәм максатлары да зуррак.

Картлар үз тәҗрибәләре, акыллары белән яшьләргә һәр вакыт ярдәмгә киләләр. Закир карт Фуатның эшчеләр династиясенә лаеклы алмаш булуын кайгырта. Үткән тарихны кадерләп саклау, заводның үз музеен төзү, Революция тавышындагы туганнар каберлегенә койма тоту кебек эшләрне дә башлап ветераннар күтәреп чыга. Романның төп герое Госман аерым цехларның технологиясен үзгәртеп кору эшенә тотынгач, пенсионер карт Муралев аңа зур ярдәм күрсәтә.

Гомумән, яшьләр өлкәннәрнең, этиәниләренең тормышын, хезмәтен үзләренә үрнәк итеп алалар. Читтән килеп, заводта яңарак эшли башлаган Госман белән Зөлфә дә үз язмышларын бай һәм данлы традицияләре булган эшчеләр коллективы белән бәйлиләр. Шул рәвешчә, завод һәм аңа мөнәсәбәт әсәрнең үзәгенә салынган төп идея төсен ала.

Язучының нияте, һичшиксез, изге. Алдына куйган максаты да бары тик мактауга гына лаек. Ләкин шул ниятнең тормышка ашуына, максатның әдәби әсәр булып гәүдәләнүенә килгәндә, безнә борчый торган берничә мәсьәлә бар.

Борчыган мәсьәләләрнең иң зуры шул: Э. Касыймов романнарын укыганда, завод тормышы җанлы, бөтен бер дөнья булып күз алдына килми. Дөрес, беренче китапта без завод тормышының аерым эпизодлары белән танышабыз. Яңа гына эшкә урнашкан Зөлфә әнисенә үзләренең цехларын күрсәтеп йөри; шулай бер вакыт министр килеп завод белән танышып йөри һ. б. Ләкин бу эпизодлар гына укучыны һич тә канәгатьләндерә алмый.

Икенче китапта вакыйгалар үзәк лаборатория тирәсенәрәк туплана башлый. Биредә барлык геройларны бер урынга җыярлык үзәк тә табыла кебек. Госман үз тирәсенә талантлы яшьләрне туплый, аларны эшкә өйрәтә, зур фәнни максатларга рухландырырга тырыша. Лабораториягә кыйммәтле приборлар кайтаралар. Тәҗрибә туплау өчен, Госман, Рива, Зөлфә төрле җирләргә командировкаларга баралар, нефтьчеләр белән бәйләнешкә керәләр. Заводка эстоннар килеп китә. Госман хлорлы барий җитештерүнең кыскартылган схемасын эшли.

Ул да түгел, заводның гипосульфит цехын ябарга уйлыйлар. Алда әле чишелмәгән, хәл ителмәгән бик зур проблемалар тора. Кыскасы, тормыш бер урында тормый, завод коллективы күп төрле борчу-мәшәкатьләр, киеренке хезмәт дәрте белән яши. Ләкин боларның һәммәсе хакында Э. Касыймов романнарында гади информация төсендә генә әйтеп узыла.

Язучы әйтерсең завод тормышын койманың тышкы ягыннан гына торып, шуннан күренгән хәтлесен генә яза. Әсәрдәге вакыйгаларның күп өлеше заводтан читтә барган һәм аңа һич мөнәсәбәте булмаган хәлләрдән тора. Язучы, берничә еллар буе завод тормышын өйрәнеп, әлбәттә, кызыклы һәм әһәмиятле материал туплаган. Ләкин ул материал, каләм иясенең хыялы, талант көче белән эшкәртелеп, бөтен бер дөнья булу дәрәҗәсенә җитмәгән. «Һаваларда тургай» романында язучының үзе ачкан дөньясы, үз тавышы җитәрлек

күренми. Эшчеләр тормышы — катлаулы характерлар, көчле шәхесләрне күрсәтү һәм иске белән яңаның көрәшен калку итеп сурәтләү өчен гаять уңайлы материал. Чөнки ул тормыш үсешенең, көрәшнең алгы сызыгы. Ләкин Э. Касыймов әсәрендә үзәктә торырдай, бөтен эшчеләр коллективын үз тирәсенә туплап, шул коллективның иҗат һәм ихтыяр көчен күрсәтердәй вакыйгалар ахырдан өйтеп кенә үтелә (эстоннарның заводка килүе, хлорлы барий җитештерүнең кыскартылган схемасы, гипосульфит цехын ябу мәсьәләләре һ. б.). Тагын иң гаҗәбе шунда, ул эшләрнең һәммәсе дә бер Госманга, аның тырышлыгына гына бәйле булып калган. Геройларны үзара бәйләрлек, аларны уртак максат һәм омтылышка буйсындырырлык җирлек тә Госманны борчыган өлеге мәсьәләләр тирәсендә бит инде. Олы максатлары булмаганга күрә, геройлар да күбрәк мәхәббәт маҗаралары, шәхси тормышларындагы борчу-мәшәкатьләр белән генә мавыгалар. Зур мәсьәләләр кузгатылса, характерлар да эреләнер, конфликт та табылыр, геройлар да сөзешеп кенә калмаслар, очкын чыгарып көрәшерләр иде.

Заводның үз эчендә вакыйгаларны хәрәкәткә китерә торган пружина табылмаган. Ул пружина Госман җитәкчелек иткән лаборатория булыр дип тә көтәсең. Талантлы инженер җитәкчелек итә торган, өметле кадрлар тупланган бу үзәк завод фәннең иртәгесенә карап эш итә, диелә әсәрдә. Ләкин нәкъ шул процесс үзе күрсәтелми. Өстәвенә, алга зур проблемалар килеп басканда, ул лаборатория бушап ук кала әле. Рива кияүгә чыга, Марс, Зөфәр зур тезелешкә китәләр. Болай да эше һәм Госманнан башка кешеләре бик чамалы күренгән лаборатория томан эчендә ук кала.

Әсәрне тормышчан, табигый төстә кабул итәргә комачаулый торган тагын бер сәбәп — андагы ясалмалыкта. «Томан аша» Фуатның читтән кайтуын сурәтләү белән башлана. Ул ике-өч ел өйгә бер хәбәр дә бирмәгән. Әллә туганнарына бик ачуланып, рәнҗеп чыгып киткәнме?.. Алай дисәң, үзе «берүк сәламәт булсаларчы» дип, борчылып кайтып килә. Инде әнисе нигә хат язмадың дип үпкәли башлагач, «Шулай кирәк булгандыр», дип кырт кисә. Мондый җавап та, Фуатның, читкә китеп, анда ни өчендер берничә ел утырып чыгуы да серле томанга төрелә. Бу исә укучыда аптырау гына уята, ясалма аңлашылмаучылык тудыра.

Мирычның табак битле бульдозерист белән сугышуы да ясалма. Беренчедән, сугыш чукмары булу Мирычның юаш холкына ук туры килми. Андый дуамаллыкны, чыгырдан чыгуны күбрәк Закир карттан көтәргә булыр иде. Икенчедән, аякларны сындыра язып шул хикмәт сугышу ни белән бетә соң? «Бәлеш бит» Мирыч белән килешергә дип аның өенә килә, карт аны куып чыгара. Соңыннан: «Юк, суынырга ярамас безгә» дип, сугыштан герой булып кайткан кешегә китә һәм... бу маҗара шуның белән бетә дә. Алай гына да түгел, гәүдәсе белән амбразура каплагандай, ватык кирпечләр өемен бульдозердан сакларга тырышкан Мирыч «өч көннән соң, «больничныен» да аптырмастан, ерак Кавказ тарафына сәфәр тота».

Григорий картның төпчек улы Марсны, армиядән кайтуга, Госман тиз генә үз лабораториясенә эшкә ала. Аныңниләр эшләгәнен, гомумән, ул егетнең ничек яшәгәнен, ниндирәк кеше икәнен без әсәрдә күрмибез. Әмма бер эпизод китерелә. Марс Казан университетына лабораториягә килә һәм аларның җыйнаулашып ике көн буе төзәтә алмый интеккән полярографларын ике сәгатьтә төзәтеп тә бирә. Моны белеп, профессор шакката. Шунда ук аны укырга керергә кодалый, «һич икеләнмә, үзем булышырмын», ди. «Әкияткә тартым, әмма чынга да якын», дип куя автор үзе дә.

Әсәрнең әдәби кыйммәтен төшерә торган тагын бер кимчелек — тупаслык. Бу нәрсә аерым бер геройга гына хас булса, характеры шундыйдыр моның дияр идең. Ләкин геройларның (аеруча яшьләрнең) күбесе сайлап алгандай тупаслар. Берничә генә мисал. Фуат озак югалып йөргәннән соң өйгә кайта һәм әнисенең йортка ир керткәнен, сеңелесенең кияүгә чыкканын белгәч, хәл-әхвәл дә сорашмаган килеш: «Сезгә бик мач килгән, икәүләп кияү эзләп яткансыз», — дип кычкыра. Беренче күрүдә үк исе-акылы китеп ошаткан Зөлфәне дә ул: «Ә сез ник катып калдыгыз? Дөньягызга ут төртмәгәннәрдер лә?» дип каршылый.

Ярый, егет кеше төрпәрәк сөйләшсен дә ди. Менә интеллигент семьяда үскән, чибәр, акыллы Зөлфә. Комсомол секретаре Нина белән сөйләшүе талашуга якын, иң якын дусты Сәриягә дә ул «әй, лыгырдамасана», «аптыратма, йөдәтмәсәнә»,

дип кенә җибәрә. Хәер, Зөлфәнең үзенә дә бик рәт юк: апасы аның белән сөйләшми, ә «бәйләнә, төпчеңә, бәгырь кисәгенә энәләр кадый». Зөлфә турында чын күңелдән кайгыртып, ул: «Нидер булган ул **мәнсезгә**, әнине чакыртам әле, андый гына **көлтә еланның** койрыгына баса белер ул», — дип сөйләнә.

Яки менә кызларның икенчесе — фәрештәдәй чибәр Асия. Өмә вакытында ул Фуатны эзләп йөри, юл уңаенда Зөлфәне дә каргап бара: «Аны каядыр көньякка олаккан диганнәр иде. Эх, шул сары ябалак аның Фуатының баш өстендә бөтерелмәгән булса, дуамалрак холыклы егет кисәккәе Асиянең йомшак, нәфис канатларында сырпаланмас идемени соң?» Асиянең үзләрен ташлап киткән әтисенә, бик үк тәүфыйклы булмаган әнисенә тупас җикеренүләре күпмедер күләмдә аңлашылсын да ди. Ләкин бу тупаслык, беренче чиратта, Асиянең үзен характерлый, аның усаллыгы, зәһәрлеге күңел кайтаргыч. Әсәр буена ул Фуатны үзенә каратырга тырышып йөри (без аның башка сыйфатын, максатын күрмибез дә) һәм менә ул киләчәген болайрак күз алдына китерә: «Теге егетнең әнисе Рабига апа соңыннан ниләр китереп чыгарыр да, ниләр аударып өсләренә. Хәер, Фуат череп ямьшәйгән бәрәңге түгел, ул белер...». Автор аны саф күңелле, нәфис тойгылы кыз итеп күрсәтергә теләсә дә, Асиядә нәкъ шул сафлык, нәфислек юк.

Тупаслык авторның үз телендә дә еш очрый. Язучы үз геройлары белән шактый саксыз эш итә, әйбәт итеп күрсәтергә теләгән геройлары да бик ямьсез тойгы калдыралар. Мәсәлән, Госман авылга кайта һәм әнисенең ахирәте булган Нурдидә түтиләргә керә. Карчык өйдә булмый, Госманны аның килене Миңнурый каршы ала. «Үзе сыңар кулы белән **тулып ашкан күкрәкләре** өстендәге ачык изүен каплагандай итә, үзе, **чамасыз ымсынып**, үткер күзләре белән кителмәгән кунакны **кармалый»**. Мондый сүзләрдән соң Миңнурыйны әйбәт күңелле, эчкерсез, гади авыл килене дип никадәр мактасалар да, бу ямьсез сурәттән туган тәэсир үзгәрми.

Кызларның хис-кичерешләре, мәхәббәт тойгылары да нәфис сурәтләнә дип әйтеп булмый. Зөлфә үзен аңгыралыкта, җебегәнлектә гаепләп йөри, Зәбирен башта ук тәвәккәлләп кулга алырга, җизнәсе әйткәнчә, «суярга да тунарга иде». Кыю, әрсез була белмәде, янәсе. Хәзер әнә Зәбирен ничек сагына: «Ул бит яратуын белгерткәндә дә кайберәүләр шикелле тартынып тормый. Кысарга тотынса, күкрәкләрең сытылып, билең өзелеп чыгардай итә, үбәргә керешсә, тыннарың куыла...». Бу кадәресе, белмим, нинди әдәби нормаларга сыядыр?..

Әсәрнең стиленә хас тагын бер сыйфат — кабатлау. Мәсәлән, бик күп фигыльләрне «ябышты» сүзе алыштыра: «Ура» кычкырырга ябышты; балык тотарга иләп кенә ябышты; үпкә-йөрәк дигәнен савыктырырга ябышты; экономикага төптәнрәк ябышты; ут уйнатырга ябышты; стена газетасының яңа редакциясен сайларга ябыштылар; көләргә ябышты; еларга ябышты; эшләргә ябышты һәм башка бик күп «ябыштылар». «Тәмләп карау» шулай ук бик популяр фигыль: ризыкны тәмләп карау; концертны тәмләп карау; тормыш рәхәтен тәмләп карау; тал-чыбыкны тәмләп карау һ. б. Хәтта заводның микроклиматын да тәмләп карап була икән. Геройлар бик еш кына чиныйлар, чәрелдиләр, кеткелдиләр, шаркылдыйлар, хахылдыйлар, хихылдыйлар... Шуңа күрә аларның кыяфәтләре дә әллә ничегрәк булып күз алдына килә башлый. Кайбер җөмләләрне исә аңлап ук булмый: «Рива, япаялгызы гына булса да, кай кичләрдә лабораториядә калгалый һәм инде **сеңеренә сеңә башлаган шөгылен дәвам итә иде»**; «Соң кала җиренә кучтем, инде үзләренә ярыйм дип, гомер буе **канында эреп, сеңерләрендә каткан гадәтне капыл гына суырып яки сыгып атарга ябышсынмыни!»** (Сүз Госманның әнисе турында бара.) Гомумән, әсәр әдәби телне үстерүгә, нәфисләндерүгә хезмәт итә дип әйтеп булмый.

Әсәрнең геройлары хакында берничә сүз. Беренче китапта төп урынны Фуат алып тора һәм күпмедер дәрәҗәдә аның характеры үсештә, үзгәрештә бирелгән иде. Аның ныклыгы, үз тормышы турында җитди уйлануы, кешеләрнең ышанычын акларга тырышуы, борчылулары, Зөлфәгә булган мөнәсәбәте ачык һәм аңлаешлы, егетнең холкы-фигыленә туры килә торган логика белән бирелгән иде. Икенче китапта бу образ төссезләнгән, активлыгын, ачыклыгын югалткан. Зөлфә белән мөнәсәбәтләренең ачыкланмыйча, ясалма рәвештә сузылуы да, Асиягә булган мәхәббәтенең ышандырырлык булмавы да бу образны тоныкландырган гына.

Зөлфә дә беренче китапта тормышчан,

шат күңелле, яшьләргә хас хыял-омтылышлар белән яши иде. Икенче китапта автор бу образны да шактый «катлауландырган», баштагы ачыклык югалган. Зөлфә әсәргә ни эшләргә белмичә миңгерәүләнгән хәлдә килеп керә һәм ни уйлап, ни баш ватып та бер карарга килә алмыйча торып кала. Ул ниндидер фән яки завод тормышына бәйле мәсьәләләр белән баш ватса, бер хәер иде әле. Юк шул, аның башын егетләр әйләндергән. Ичмасам, күңелен ялаган егете аңа торырлык булса икән. «Зөлфәнең, чынлап та башын ташка орырдай хәлгә җитеп, үтә кәефсезләнгән көннәре иде. Барысы да шул Зәбире аркасында... Коры куык булып чыкты, ахры». Зәбиреннән өмет тә өзеп бетерәсе килми, егете дә ышанычлы түгел. Аның белән араны өзгәч тә, кыз ахырга кадәр шул күңел ярасы белән генә мәшгуль. Җитмәсә, Фуат белән булган мөнәсәбәтләрен дә хәл итеп бетерә алмый. Гади эшче дип, теге вакытта аны читкә каккан булган икән, хәзер менә Асия белән икесен бергә күргән саен үләрдәй булып көнләшә: «Фуатны күргән саен зиһене чатнап, йөрәге жу итеп, бөтен тәненнән кымырҗу үтеп китә...»

Ул арада Рәшит Сәлмәнов та Зөлфәне ярата икән әле. Өч егет арасында башы әйләнгән Зөлфә, ниһаять, Рәшиткә тукталырга була. Ләкин биредә дә әле мәсьәлә хәл ителмәгән килеш кала: «Баскычтан атлады. Тукталды. Уйга калды. Янә менде. Янә тукталды...»

Әсәрдә шактый урын биләгән Асия дә эше белән түгел, мәхәббәт маҗаралары белән генә күренә. Гомумән, кызлар икесе дә тыйнаклык, нәфислек, ягымлылык кебек сыйфатлар белән «вакланмыйлар». Хәлбуки, бүгенге көн турындагы әсәрдә без гармоник үскән, рухи бай булган, зур интереслар белән яши торган, сәнгать һәм культура белән таныш булган яшьләрне күрергә телибез. Бу сыйфатлар бәлки «Һаваларда тургай»ның төп герое булган Госман образына җыелгандыр. Ул — заводта үзәк лаборатория җитәкчесе, химикларның башлангыч оешмасында иң актив эшләүче фән кандидаты, уйлап табучы, рационализаторларның да иң алдынгы сафында, унлап авторлык таныклыгы бар, дистәдән артык мәкалә бастырган, аннан килеп, ничәмә-ничә студентның дипломына җитәкчелек итеп килә, аспирантурага үз белгечләрен хәзерли, үз шәкертләре бар, фәннең чын кешесе. Кызганычка каршы, Госманның бу сыйфатлары әсәрдәге вакыйгалар барышында ачылмый, ә, аңа характеристика язгандай, санап кына чыгыла. Шулай да ул романдагы иң уңай һәм укучы күңелендә симпатия уятырга тиешле геройларның берсе булып гәүдәләнә. Ул бөтен барлыгы белән фәнгә, иҗат эшенә бирелгән кеше. Госман зур мәсьәләләр кузгата, аның шул мәсьәләләрне хәл итәрлек һәм авырлыкларны җиңәрлек ныклыгы, түземлеге дә бар. Нәкъ менә шундый яшь, эш дип янып яши торган белгечләр заводның киләчәген билгели, шул киләчәкне якынайта да инде. Характер буларак та Госман — ярыйсы ук әйбәт эшләнгән образ. Семьяга, иптәшләренә, авылдашларына мөнәсәбәттә ул олы җанлы, кешелекле, кайгыртучан булып күз алдына килә. Ләкин образның бөтенлегенә зыян китерә торган сыйфат та бар. Бу — аның шактый җебегән булуы, икеләнеп, аптырап кала торган гадәте. Әлбәттә, кешегә каушау, икеләнү, курку кебек сыйфатлар да хас. Ләкин алар шундый җаваплы урында эшләгән, киләчәктә фән үзәге заводларда булырга тиеш дип, шундый зур эзләнүләрне башлап йөргән кеше образына шактый зыян китерәләр. Өстәвенә, автор бу героен ясалма хәлләргә куеп та түбәнәйтеп җибәрә. Мәсәлән, Әлмәт гостиницасында Рива белән булган вакыйга аларның характерлары, мораль сыйфатлары, үзара мөнәсәбәтләре белән хәзерләнми, акланмый. Шундый тотнаксызлыгы, Рива бүлмәсенә керә алмаган өчен «пүчтәк кенә киртәне дә атлап үтә алмадым» дип, үзен җебегәнлектә гаепләве Госман образының логикасын боза.

Госманның партком секретаре Вероника Борисовнаны көзге салкын кичне автобус тукталышында очратып, моны иң җайлы урын, иң кулай вакыт дип санап, бик җитди, әһәмиятле сүзләр сөйләшүләре дә гаҗәп тоела. Аларны, кешедән качырачачыра, завод язмышына кагылган мәсьәләләрне шул рәвешчә хәл иттерү бик ясалма, әлбәттә.

Гомумән, автор вакыйгаларга яшерен төс бирүне ярата. Мәсәлән, технологиянең кыскартылган схемасын төзү, ни өчендер, конспирациягә корыла. Аны Муралев белән икәү генә Госманнарның квартирасында, өйдә кеше юк чагында гына эшлиләр. Бу турыда нигәдер шыпырт кына сөйлиләр. Бәлки ачыш ясау чынлап та шулай яшерен эшләнәдер?.. Шулай да,

дәүләт интересы күздә тотылган, үзеннән «миллионнар исе килеп торган» шундый зур ачышны, заводта бик зур үзгәрешләр тудырачак мәсьәләне ничек Госман берүзе генә диярлек хәл итә — монысы бөтенләй аңлашылмый. Дөрес, бу мәсьәлә соңыннан парткомда да, химиклар конференциясендә дә карала, ләкин анда инде җиңү быргылары гына уйный. Шулай итеп, бер Госман, бернинди каршылыксыз-нисез, заводны үзгәртә дә куя. Мондый ясалмалылык тормыш чынлыгына да, әдәби дөреслеккә дә туры килми.

Әсәрдәге ясалмалык, аңлашылмаучылыклар авторның үзе сурәтләгән материалга ачык позициясе булмаудан килә шикелле. Язучының осталыгы, талант көче тормыш материалын конкрет максаттан чыгып сайлавында, аңа үзенең фикерен, мөнәсәбәтен салуда, ниндидер ачыш ясавында чагыла бит. Нәкъ шушы як материалның үзе кебек үк әһәмиятле һәм ул авторның индивидуаль йөзен билгели. Укучы да әсәрдән вакыйга һәм күренешләрне генә түгел, әнә шул ачышны эзли, язучының үз фикерен, карашын аңларга тели.

Тормыш материалы үзе генә әле заманча да, актуаль дә була алмый. Актуальлек тә, яңалык та шушы материалга салынган мәгънәдә, авторның шушы материалда тормыш хәрәкәтен, аның закончалыгын ача алуында. Югыйсә, бик сәер каршылык килеп чыга: язучы бүгенге көн тормышына мөрәҗәгать итә, ләкин әсәр заман рухын чагылдырмый; әйбәт геройны күрсәтергә тели, тик герое гына, ни өчендер, бик үк әйбәт булып чыкмый; язучының нияте изге, тик әсәр генә укучыны дулкынландырмый. Авторның әйтергә теләгән фикере, максаты ачык булса, гадәттә, геройлары да аны кыен хәлдә калдырмыйлар, укучылар да авторга теләктәш булалар. Язучы аларны кыйбласыз әсәргә кертеп җибәрсә инде, геройлары да аптырап йөри, укучының да башын әйләндерә һәм, ахыры килеп, язучыдан да «үч алалар».

Әдәби әсәрне укып чыкканнан соң, аның әһәмияте, кыйммәте турында уйланасың. Тормыш турында нинди белем бирә, укучыда нинди хис уята, нинди зәвык тәрбияли, укучыны уйландырырлык, дулкынландырырлык нинди проблема күтәрә? «Һаваларда тургай» романында бу сорауларга җавап табуы кыен. Күп мәсьәләләр, күрәсең, авторның үзе өчен дә ачык ук түгел әле. Шуңа күрәдер, әсәр заманча яңгырамый, атмосферасы, геройларының фикерләү дәрәҗәсе, эш-хәрәкәтләре белән ул үткән көнгә карый.

**ФЛЕРА ГАНИЕВА.**

**Галия Кайбицкая**

# ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ БЕЛӘН ЯНӘШӘ

*Салих Сәйдәшевның тууына 75 ел*

*Күренекле опера җырчысы, Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая үзенең сәхнәдәге иҗат юлы, мәшһүр әдипләребез һәм сәнгать эшлеклеләре, композиторлар һәм җырчылар белән иҗади хезмәттәшлек еллары, кызыклы очрашулары хакында истәлекләр яза.*

*Журналыбызның бу санында әлеге истәлекләрдән татар профессиональ музыкасына нигез салучы атаклы композиторыбыз Салих Сәйдәшевка багышланган берничә бүлекчә тәкъдим ителә.*

**...1923** ел, Казан театр техникумының ачылган елы иде. Техникумга кабул ителгән көнемнән миңа бәхет капкасы ачылган кебек булды. Тулай торакка күчеп, бергә торган укучы кызларым белән танышып, дуслашып та өлгермәгән идем әле. Өч-дүрт көн үткә, «Галия Кайбицкаяны кемдер сорый», дип, мине чакырып алдылар. Сынауларны фамилиям буенча Төхфәтуллина булып үтсәм дә, Кайбицкая фамилиясен ишеткәч, йөгереп чыктым. Әдһәм абыем килгәндер, дип уйладым. Аның сәхнә фамилиясе туган авылыбыз исеме белән Кайбицкий дип йөртелә иде. Коридорга чыксам, каршымда бөтенләй башка кеше — урта буйлы, зәңгәр күзле, кара бөдрә чәчле бер егет басып тора. «Исәнмесез! Сез Галия Кайбицкая буласызмы? Мин Салих Сәйдәшев булам, — дип, ул кыяр-кыймас кына кулымны алып кысты. — Безнең спектакль көнендә сәхнә артында җырларга бер кыз кирәк иде. Сез җырламассызмы дип килгән идем». Мин ни әйтергә белмичә, уңайсызланып, аптырап калдым, кызардым-бүртендем. Мөгаен, бу эшне Әдһәм абыем кузгаткандыр дип уйладым. Ниһаять, телгә килеп: «Уйламый сөйләнгән сүз бу, мин җырлый белмим», — дип җавап кайтардым. Ләкин Салих Сәйдәшев бу сүзләремә әһәмият бирмичә, җырларга үгетли башлады. «Сезне үзем өйрәтәм, аннары үзем белән бергә, минем янда җырларсыз», диде. Иртәгә тагы килерен әйтеп, саубуллашып чыгып китте. Шул көннән соң ук Салих Сәйдәшев белән тагын берничә тапкыр очраштык. Мин аңа үземнең җырлый алмавым турында күпме генә аңлатып карасам да, булмады. Көннәрдән бер көнне ул мине үзе белән театрга алып китте. Анда пианино янына утырып уйный башлады. Мин бөтен күңелемне биреп тыңлап торганда янә: «Үз көйләрем болар», дип яңа көйләр белән дә таныштыра башлагач, минем күңел, нечектер, тиз үзгәрде. Аның матур уены, үзенә генә хас нечкә моңы музыкага булган мәхәббәтемне яңартып, кузгатып җибәрде. Шул беренче ишеткән көнемнән Сәйдәш моңнарына гашыйк



*Салих Сәйдәшев тормыш иптәше Асия ханым белән.*

булдым. Тыңлаган саен тыңлыйсым, ул уйнаганда шул минуты белән кушылып җырлап җибәрәсем килә иде. Шул ук елның сентябрь аенда театр спектакльләренең берсендә Салих Сәйдәшев белән сәхнә артында Габдулла Тукай сүзләренә язылган «Зиләйлүк» көен башкардык. Ул пианинода уйнады, мин җырладым. Бу безнең беренче чыгышыбыз иде. Оялу-каушаудан булдымы, тавышым халыкка барып җитәрлек матур чыкмады, күңелсезрәк үтте. Шулай да Салих абый кәефен төшермәде, икенче җырлаганда тавыш биребрәк җырларсың, дип куйды.

Икенче атнада янә шул ук сәхнә артына килеп җырладык. Бу юлы мин, Сәйдәшнең көчле аккордларына карап, тавышка нык басым ясап җырладым. Хәтта залдан халыкның кул чабып җибәрүләре дә ишетелде. Әмма Салих Сәйдәшев бүгенге җырлавыбыздан да канәгать түгел иде: «Күп тавыш бирелде, урта сызыкны табарга кирәк булыр», диде ул. Шул көннән соң без репетицияләрне еш ясый башладык. Бер кадәр вакыттан соң зуррак әсәрләрне дә өйрәнә башладык. Беренче зур эшебез Мирхәйдәр Фәйзинең «Асылъяр» пьесасындагы җырлар булды. Салих абый пьесадагы җырларны тавышыма җайлап, нотага салып, үзенчә эшкәртеп җырлата иде. Спектакльнең баш роле Лаләнең бөтен җырларын шулай зур ихлас белән миңа үзе өйрәтте. Мин Лаләнең сүз һәм җырларын бергә бәйләп башкарганда Салих абый: «Син Лаләнең нәкъ үзенә охшыйсың» дия иде.

...Салих Сәйдәшевның иҗаты халкыбызның героик эшендә һәм көрәшендә юлдаш булып килде. Аның йөрәктән чыккан көйләре халык тарафынннан тиз үзләштерелә иде. Беренче татар профессиональ композиторының әсәрләрен сөймәгән, белмәгән һәм танымаган кеше булмады. Аның музыкасы Татарстанның иң ерак төбәкләрендә, казакъ далаларында, Башкортстан төзелешләрендә — һәркайда көчле яңгырады. Сәйдәшев чиксез зур таланты белән баштан ук музыкада үзенең иҗади телен тапты, осталыгы үсә барган саен шул стилен туктаусыз баета килеп, халык белән аның йөрәгенә якын, моңлы һәм шул хасиятләре белән серле булган музыка телендә сөйләшә белде. Аның стиле — музыкаль теле хезмәт ияләренә якын булганлыктан, аны теләсә кайда беренче аккордларыннан ук таныйлар һәм рәхәтләнеп тыңлыйлар. Шунысы характерлы, Сәйдәш музыкасы чын-чыннан татар музыкасы булып, бүтән милләт кешеләре тарафыннан да яратып тыңлана һәм кабул ителә. Бу үзе генә дә Салих

Сәйдәшев музыкасының интернациональ характерда булуын раслый. Монда, әлбәттә, Сәйдәшевның үзендә, аның музыкасында булган интернациональ омтылыш ярдәм итә булырга кирәк. Татар музыкасына хас булган пентатониканы баету юлында Сәйдәшев гаять уңышлы иҗат итте, татар музыкасында моңа кадәр кулланылмаган хроматизмны кертеп, әсәрләрен гармонияләштерүдә гомум кешелек музыкаль культурасы казанышларыннан иркен файдаланды. Сәйдәш язган һәрбер әсәрне, шушы яңалыклары булуга да карамастан, халык үзенеке дип кабул итте. Бигрәк тә без, җырчылар, Сәйдәш музыкасының интернациональ рухы көчәюенә һәм, шуның аркасында, үзебезгә дә классик музыканың аңлаешлырак, якынрак була баруына куана идек.

Салих музыкасын язганда җиңел иҗат итә иде. Мин аның шунысына кызыга идем — кайберәүләр кебек, пианино янында, бармаклары белән инструмент клавишларына суга-суга көй эзләнеп утырмады. «Көйләрем үзләреннән-үзләре килеп торалар», дип әйтә иде дә, пианинода яңа бер нәрсәне бик иркен генә уйный да башлый иде. Көй язарга аның илһамы килгән чак була иде бу. «Менә синең белән сөйләшәм, ә үзем күңел белән сиңа көй язам», дия иде. Чыннан да, Сәйдәшнең күңелендә көйләр әйтерсең үзләреннән-үзләре яңгырап тора иде.

Татар драма театрында Кәрим Тинчуринның «Кандыр буе» әсәрен куярга хәзерләнгән чак. Кәрим ага үзе режиссер. Салих Сәйдәшев — композиторы. Баш рольләрне Ситдыйк Айдаров, мин, Фәридә ролен Сара Садыйкова әзерлибез. Менә спектакльне чыгарыр көн дә якынлашты. Бер көнне Салих минем янга килде дә, елмаеп кына: «Галия, син җырлый торган Гөләндәм ариясенең ахыры юк бит, язылып бетмәгән, язып бетерәсе бар», — диде. Мин аның сүзенә каршы килеп: «Ярар, ярар, ярты икәнен аның кем дә белмәс, менә дигән итеп җырлармын, өйрәнергә вакыт калмады», — дип көлеп җавап бирдем. Ул һаман елмайган көе миңа бераз текәлеп карап торды да: «Әйдә әле, Галия, хәзер арияңне тәмамлап бирәм, ахырын таптым», — диде һәм йөгерә-атлый үз бүлмәсенә кереп китте. Артыннан керсәм, ул инде пианино янында, аккордлар биреп, ариянең ахырын уйнап утыра. Һәм иң гаҗәбе шул: җырның ахырында кычкырып көлгән тавыш — минем тавыш! — ишетелә иде. Янына килү белән: «Мә, җырлап кара инде хәзер, тулыландымы?» — дип, арияне баштан ук җырларга кушты. Мин әле генә язылган музыкада, үз көлүемне дә тойган хәлдә, Гөләндәм ариясен көлә-көлә җырлап бирдем. Ул шундый җиңел башкарылып, бөтен булып килеп чыкты. Сәйдәшнең үзе яктырып китте. «Рәхмәт, Галия! Җыр бу, ахыры да, башы да булды хәзер. Бар, Тинчуринга җырлап күрсәт инде», — диде. Шул минутны белән репетициягә кереп киттек. Җырны режиссер Кәрим абый Тинчурин да хуплап каршы алды.

Салих Сәйдәшевның көйләрне шулай кинәт кенә тотып алып, гади генә күренешләрне дә музыкага җиңел сала белү осталыгын тагын бер кат күрергә туры килде миңа.

1928 нче ел. Атаклы драматургыбыз Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» музыкаль драмасындагы Гөлйөзем образын икенче вариантта хәзерләп ятабыз. Бер көн шулай эш кинәт тукталып калды. Шаулап репетиция барган чагында режиссер Вәлиев-Сульва миңа карап: «Кая музыка?» — диде. Гөлйөзем үзенең ариясен җырлап бетергәч, биеп китәр өчен режиссерлар композиторга музыка язарга кушкан булганнар. Кинәт килеп чыккан паузаны композитор үзе дә күрми калмады, әлбәттә. Шул арада Салихка күзем төшеп, аның аптыраган кыяфәтеннән көлеп җибәрдем. Ул уйчан, үзен гаять уңайсыз сизә сыман. Шуннан мин аның күңелен күтәрим әле дип, шаян тавыш белән: «И матур син, егеткәй, егеткәй, бу көеңнең ахыры юк бит, егеткәй!» дип, үземчә такмаклап куйдым. Янә: «Дәвамын да тизрәк тапчы, егеткәй!» дип биеп тә алдым.

Салих миңа карап елмайды, шул чак аның күзләре очкынланып китте. Таҗи Гыйззәт белән карашып алды да урыныннан сикереп торып: «Хафаланмагыз, хәзер ариянең ахырын язам. Әйдә әле, Галия, шул сүзләреңне кабатлый төш», диде. Үзе рояль каршына утырып нидер уйный башлады. Мин, «и матур син» дип, төрле сүзләр әйтә-әйтә тагын биеп киттем. Режиссер Вәлиев-Сульва да, артистлар да көлешеп карап тордылар. Шул арада композитор Сәйдәш һәм драматург Таҗи Гыйззәт, миңа караган килеш, минем әйткән сүзләремнең дә кайберләрен файдаланып, Гөлйөземнең ариясен тәмамлап та бирделәр. Шулай итеп, ария төгәл бер рәвеш алды, режиссерның да күңеле булып, репетицияне дәвам иттерде.

Таҗи Гыйззәтнең бу үлмәс «Наемщик» әсәрендәге Гөлйөзем ролен меңә еллар буе берүземә уйнап барырга туры килде. Гөлйөзем — урам җырчысы. Кулымда хәерче капчыгы, өстемдә ямаулы күлмәк, аягыма кигән нәрсәм — авыл чабатасы. Спектакльне бик күп уйный торгач, ул чабатам да тузып бетте, ялан аякка калдым.

Режиссерым Вәлиев-Сульва: «Әгәр сиңа биергә уңайсыз булса, салып ташла иске чабаталарыңны», дигәч, мин сәхнәгә ялан аяк чыга башладым. Автор — драматург Таҗи Гыйззәт, Гөлйөземне аеруча якын иткәнгәме: «Мин Гөлйөземнең ялан аяк сәхнәгә чыкканын күрсәм, балам күк кызганам, аягына шырпы керер күк», дия иде.

30 нчы елларның башында, җәй көне, Таҗи Гыйззәт белән Салих Сәйдәшев авылларда булган чакларында, шуннан ике пар чабата алып кайттылар. Бер пары Батыржанга, икенчесе Гөлйөземгә. «Авылдан менә нинди чабаталар алып кайттык, театрның чабаталарын көтеп торырга туры килмәс», дип көлеп-шаярып, Ситдыйк Айдаров белән миңа чабата бүләк иттеләр. Без, Батырҗан белән Гөлйөзем, шул яңа чабаталарны киеп тагы күп еллар бергә уйнадык.

Сәйдәшевның иҗади җитезлек-хәрәкәтчәнлеге бәлки аның тиз тәэсирләнүчән булуыннан, тирә-юньдәге хәлләрне йөрәгә аша тирән кичерүеннән дә килгәндер. Татар академия театрында күп хезмәт иткән күренекле сәхнә остазыбыз Нури Сакаевның йөрәк авыруыннан кинәт үлеп китүе бөтен татар артистларын тирән кайгыга салды. Бу хәбәрне Салих тагы да авыррак кичерде. Күрәсең, алар бик якын дуслар булганнар. Ул көннәрдә Салих кеше күзеннән югалып, бер ялгызы утырды. Чырае бик тә кайгылы иде. Ул театр бинасының өске катына күтәрелә торган баскыч астындагы рояль алдында утырган да (театр — Островский урамында, хәзерге ТЮЗ бинасында иде), башын бер якка авыштырып, акрын гына клавишларга баса. Ничектер, мин килеп чыктым. Күрәм, йөзе агарып киткән, күзләре ярым йомылган, нидер яза. Мин, комачауламыйм дип, үтеп киттем. Ярты сәгать тә үтмәде, кулына нотасын тоткан килеш, Салих театр музыкантлары янына килде. «Шуны уйнап карыйк әле»,— дип, кәгазьләрен сузды.

Бу — бүген инде һәркайсыбызга мәгълүм «Матәм маршы» ноталары иде. Артистларыбызның күңеленә ул шул кадәр тирән үтеп керде ки, музыканы ишеткәч, барыбыз да дулкынланып елаштык. Композиторның бу әсәрендә дә халык музыкасындагы моң көчле һәм үткен хис-фикерләр белән үрелеп бирелгән иде. Артистларның тирән кичерешләрен күреп Сәйдәш: «Бу минем Нурига соңгы бүләгем — «Сакай маршы» булсын», — диде.

Соңгы елларда Салих Сәйдәшев әсәрләре симфоник музыка концертларында да мәхәббәт яулап алды. Чөнки композитор үзенең музыкаль пьесаларга язган әсәрләрен киңрәк рәвештә эшкәртеп һәм төрле буяулар белән баетып, симфония традицияләренә һәм формасына якынлаштырып бирүгә иреште. 1937 елның июнь аенда Казанда барган симфоник музыка концертларында композитор Салих Сәйдәшевның беренче мәртәбә яңгыраган «Сүнгән йолдызлар» увертюрасы, мәсәлән, әнә шундый әсәрләреннән берсе иде.

Театрыбызда Кәрим Тинчурин һәм Таҗи Гыйззәт әсәрләре аеруча еш куелды. «Наемщик» һәм «Зәңгәр шәл» спектакльләренең уңышында Сәйдәш музыкасы, һичшиксез, гаять зур урын тота иде.

Аның үзенә генә хас моң һәм нечкәлек белән язылган увертюра, хор, балет, ария, дуэтлары, беренче яңгыраулары белән үк, меңләгән тамашачыларның күңелен биләп алдылар. Бу бер триумфаль казаныш иде. «Наемщик», мәсәлән, Сәйдәш музыкасы ярдәме белән дә чиксез дәрәҗәдә уңышка ирешеп, киләчәктә хәтта шул нигездә опера язу фикерен уятты.

# ИДЕЛ БУЕ ХАЛЫКЛАРЫ ҺӘМ ДЕКАБРИСТЛАР ХӘРӘКӘТЕ

Илебез халыкларының революцион көрәш этаплары марксистик тарих фәнендә хаклы рәвештә үзәк урынны тота. XIX гасырның 80 нче елларында Маркс һәм Энгельс тәгълиматының бәрәкәтле орлыклары Россия җирендә үзенә уңдырышлы туфрак тапты һәм тиздән пролетар азатлык хәрәкәтенең җиңүчән көченә әверелде. КПСС Үзәк Комитетының В. И. Ленинга 100 ел тулу уңае белән игълан ителгән тезисларында бу турыда түбәндәге сүзләр әйтелә: «Марксизмны кабул итү һәм көрәштә файдалану өчен кирәкле җирлек Россиянең социаль-экономик үсеше, андагы киеренке сыйнфый каршылыклар һәм революцион традицияләр нәтиҗәсендә хәзерләнде. Һәм бу традицияләр крестьян күтәрелешләрендә, А. Н. Радищев иҗатында, декабристлар хәрәкәтендә, А. И. Герцен, Н. Г. Чернышевский кебек социал-демократлар эшчәнлегендә, XIX гасырның 70 нче еллар народниклары көрәшендә чагылыш тапты».

Азатлык хәрәкәтенең барлык этапларында, руслар белән берлектә, илебезнең башка халыклары, шул исәптән татар халкы вәкилләре дә катнашты. Рус булмаган милләтләрнең бу көрәшен тирәнтен өйрәнү зур фәнни, политик, тәрбияви әһәмияткә ия.

Бүгенге көндә, С. Алишев һәм башка тарихчыларның күпьеллык фәнни хезмәтләренә нигезләнеп, татар халкының Е. Пугачев хәрәкәтенә кергкән өлеше турында зур сүз алып барырга була. Совет тарих фәнендә татарларның 1812 елгы Ватан сугышында катнашуы турында да шактый киң мәгълүматлар бар. Бу сугыш чын мәгънәсендә бөтен халык патриотик күтәрелешенә әйләнгәч булды һәм Россия халыкларының рухи көчен бергә туплады.

Татарларның 1812 елгы Ватан сугышына катнашуын С. Глинка[1] һәм партизан полководецы Д. Давыдов[2] билгеләп үттеләр. Бу мәсьәлә рус тарихчылары фәнни хезмәтендә, Р. Таһиров мәкаләсендә һәм «Татарстан АССР тарихы»нда шактый киң яктыртылды. «Казанские известия» газетасында 1812 елгы көрәш сәхифәләренә багышланган зур фактик материал басылган. Шулай итеп, татар халкының Наполеон баскыннарына каршы руслар белән бер сафта торып көрәшүе турында шактый фәнни мәгълүматлар тупланган.

Рус булмаган халыкларның азатлык көрәшенә катнашуын, ул көрәшнең формаларын, колачы ни дәрәҗәдә киңлеген өйрәнү мәсьәләсендә күп милләтле гаскәр проблемасы аерым бер урын алып тора. Күп милләтле гаскәр проблемасы теоретик яктан да, тарихи планда да әлегә тиешле куәтле күләмдә исбатлы өйрәнелмәгән. Чөнки тарихчылар бу мәсьәләдә күп кыенлыкларга очрыйлар. Әйтик, беренчедән, гаскәрнең азатлык хәрәкәтендә тоткан урынын, политик юнәлешен ачыклау шактый авыр. Икенчедән, гаскәрдәге ризасызлыклар, чуалышлар турында сөйли торган фактик материаллар бик аз сакланган. Өченчедән, азатлык хәрәкәтендә катнашкан гаскәриләрнең кайсы милләт вәкиле икәнлеген ачык билгеләү җиңел эш түгел.

Хәзергә кадәр бу мәсьәләгә багышланган бернинди хезмәт тә басылып чыкканы юк. Бары тик армиянең иҗтимагый-политик хәрәкәттә тоткан урыны турында сөйли торган берничә әсәрне генә телгә алырга мөмкин[3].

[1] Глинка С. Н. Подвиги добродетели и славы русских в Отечественную и заграничную войну. М., 1816, 92 бит.

[2] Давыдов Д. Опыт теории партизанского действия. М., 1822, Икенче басма, 43 бит. Шул ук авторның сугыш язмалары. М., 1940, 226—227 битләр.

[3] Васин И. Армия и революция. М., 1973; П. Голуб. Партия, армия и революция. М., 1967; Найда С. Ф. Революционное движение в царском флоте. 1825—1917. М.— Л., 1948.

Мәгълүм булганча, В. И. Ленин армиянең иҗтимагый тормышта тоткан роленә зур игътибар иткән. Аның күрсәтмәләре зур теоретик һәм методологик әһәмияткә ия.

Патша хөкүмәте һәрчак армияне халыктан аерырга омтылды, революцион карашлар гына түгел, хәтта кечкенә генә оппозицион фикер чагылышыннан да курыкты. Армия дәүләтне илбасарлардан сакларга, шул ук вакытта ул, феодаль тәртипләрне яклап, революцион хәрәкәтне буарга да мәҗбүр булды.

Армиядә иҗтимагый-политик хәрәкәт яралгыларын юк итү өчен хөкүмәт барлык чаралардан файдаланды. Гаскәр — алдынгы фикерле кешеләр өчен үзенчәлекле бер сөрген урыны, алпавытларга исә тынгысызрак крестьяннардан тизрәк котылу чарасы булып саналды. Армиягә рекрут бирү мәсьәләсен һәр алпавыт үзе ничек теләсә, шулай хәл итте. Чөнки аларга елның теләсә кайсы аенда, теләсә кайсы көнендә үз крестьяннарыннан теләсә кемне солдатка озату хокукы бирелгән иде. Тынгысыз җаннардан котылу өчен шуннан да шәбрәк чара булырга мөмкинме соң?!

Үзара шымчылык, әләкчелек, таяк-камчы тәртибе — болар барысы да патша армиясе өчен хас нәрсәләр иде.

Рус булмаган халыклар өчен солдат хезмәте аеруча авырга килә иде. Социаль тигезсезлек, милли кимсетүләр, офицерларның ерткычлыгы һәм шуның өстенә тел белмәү рус булмаган солдатларның хәлен чын-чыннан газапка әверелдерде. Боларның барысын исәпкә алганда, төрле милләт гаскәриләренең азатлык хәрәкәтендә катнашуына аеруча зур әһәмият бирергә туры килә.

Хәрби суд архивлары, хөкүмәткә каршы чыккан солдатларны һәм офицерларны хөкем иткән төрле комиссияләрнең карарлары бу мәсьәләне ачыклау өчен төп чыганак булып тора. Тик күп кенә очракта андый документлар да чын вакыйганы тиешенчә яктыртмый, яки андый кәгазьләр архивлардан күптән юкка чыккан була. Әйтик, Чернигов полкы солдатлары һәм кече офицерларының «җинаять» эшен тикшерү кәгазьләре шулай югалган.

«Россиядә революцион хәрәкәт җитәкчеләренең био-библиографик сүзлеге» исемле фәнни китапны төзүчеләр бу турыда түбәндәгеләрне язып калдырганнар: «Бу хәрәкәтнең зур җитәкчеләре, юлбашчылары, әлбәттә, бармак белән санарлык һәм аларның тәрҗемәи хәлләре алдан төзелгән исемлектән тыш та язылырга мөмкин. Әмма декабристлар сафында булган гади кешеләрнең, народникларның, социал-демократларның исемнәрен ачыклау өчен зур, авыр һәм тынгысыз фәнни хезмәт башкарырга туры киләчәк. Чөнки 1825 елгы декабристлар хәрәкәтендә катнашкан солдатлар, гади матрослар турында кайбер материаллар әле яңа гына табыла башлады һәм аларны тиешенчә тикшерү өчен тузанлы архивларда күп заманнар казынасы булыр»[1].

Матбугатта басылып чыккан архив материаллары буенча декабристлар хәрәкәтендә татарлардан да шактый хәрбиләр катнашканы ачыкланды. Әйтик, подпоручик А. Борнашев А. Рылеев йортында киңәшмәдә булган, ул киңәшмәдә 1825 ел, 14 декабрь восстаниесенең планы тикшерелгән.

Декабрист А. Арбузов капитан-лейтенант Җанбулатовны үзенең остазы дип исәпли. Император канцеляриясе архивларындагы декабристлар исемлегенә барлыгы 547 исем теркәлгән. Шулар арасында 78 нче, 119 нчы, 136 нчы, 141 нче, 312 нче саннар белән Булатов, Борнашев, Галәмин, Кудашев, Назимов һ. б. исемнәр язылган.

В. Е. Галәминның квартирмейстер частенда подполковник булуы билгеле. Ул ярлы семьядан чыккан, бай балаларына дәресләр биреп, шуннан килгән акчага яшәгән. Башта князь Волконскийга, соңра князь Новосельцевка хезмәт иткән. Акыллы һәм сәләтле бу егет яхшы математик, яхшы рәссам булган. Шул сәләтләре өстенә зур дәрәҗәле кешеләр белән танышлыгы аңа югары хәрби чинга күтәрелергә мөмкинлек тудырган. Декабристлар хәрәкәтенә катнашканы өчен Галәминны хәрби дәрәҗәсеннән мәхрүм иткәннәр һәм Петропавловский пехота полкына озатканнар[2]. Мәскәү лейб-гвардия полкы подпоручигы Кудашев исә җыелма гвардия полкына күчерелгән.

Борнашевның соңгы язмышы тагын да гыйбрәтлерәк. Декабристлар хәрәкәтендә катнашканы өчен аны, 12 нче классны чиновник итеп, эчке эшләр департаментына эшкә җибәргәннәр.

[1] Био-библиографический словарь. М., 1927, I том, 19—20 битләр.
[2] Восстание декабристов, II том, М.— Л., 1926.

Патша хөкемдарлары төзегән материалларга караганда, имештер, Борнашев үзенең «яшьлек мавыгулары»ннан бөтенләй ваз кичкән. Әмма император канцеляриясе архивларын өйрәнгәндә, Борнашев фамилиясе хөкемдарлар ышанычын акламаган кеше буларак тагын телгә алына. Димәк, ул үзенең карашларына, азатлык идеалларына тугры булып калган. Бу нәрсә император канцеляриясенең III бүлек управляющие Дубельт боерыгыннан яхшы аңлашыла: «Борнашевны кулга алырга һәм барлык кәгазьләрен пичәтләп, үзе белән бергә үк император җәнабләре канцеляриясенә озатырга»,— дип яза Дубельт 1849 елда. Һәм шунда ук катгый кисәтеп куя: «Борнашев йортындагы бер генә кәгазьне дә югалтмый пичәтләргә, әгәр ул бер-бер кәгазьне кешенеке дип расларга тырышса, андыйларын да алырга».

Һәм тагын шунысы игътибарга лаек: Дубельт боерыгында Петрашевский һәм аның иптәшләре хакында телгә алына. Димәк, император канцеляриясенең III нче бүлеге Борнашевны Петрашевский иптәшләренең берсе дип саный. Ә бу нәрсә Петрашевский түгәрәге, аның рухи чыганаклары турында элекке карашларны тагын да киңәйтә, түгәрәкнең милли төрлелеге турында төшенчә бирә.

Ләкин, архив документларыннан күренгәнчә, жандармнар Борнашевны шул көнендә үк кулга төшерә алмыйлар. Чөнки ул, 25 көнлек отпуск алып, бөтен әйберләрен һәм кәгазьләрен җыйнап, Мәскәү һәм Курск якларына сәфәр чыккан була. Ул сәфәреннән Борнашев 1849 елның 31 октябрендә генә әйләнеп кайта.

Декабристлар хәрәкәтендә катнашкан татар офицерларын телгә алдык. Ә соң бу көрәшчеләр арасында зур булмаган милләтләрдән гади солдатлар булганмы?

«Био-библиографик сүзлек»тә Мәскәү лейб-гвардия полкы барабанчысы Рамазан Семенов турында да әйтелә. 1825 елның 14 декабрендә ул Сенат мәйданында восстаниега катнашкан, яраланып госпитальгә кергән, 1826 елның 15 февралендә шуннан Петропавловский крепостена озатылган, аннары Кавказ корпусына сөрелгән.

Мәгълүм булганча, 14 декабрьда Сенат мәйданына Мәскәү лейб-гвардия полкыннан 800 ләп солдат чыккан. Алар сафында, әлбәттә, рустан башка милләт вәкилләре дә күп булган [1].

Сенат мәйданыннан соң восстание Украинада дәвам итә. Васильково шәһәрендә һәм шул тирәдәге авылларда урнашкан Чернигов полкы Украина восстаниесендә төп көч була. Шымчылар доносы буенча, 13 декабрьда Пестель кулга алына, восстаниенең төп җитәкчесе булып С. Муравьев-Апостол кала.

Чернигов полкы 1825 елның 29 декабрендә баш күтәрә. Бу вакытта инде Муравьев-Апостол белән аның энесе Матвей да кулга алынган була. «Көньяк җәмгыяте» членнары Соловьев, Шепилло, Кузьмин, Сухинов һәм башкалар солдатларны көрәшкә өндиләр, Муравьевны коткарырга чакыралар.

Муравьев-Апостол эше буенча төзелгән тикшерү-эзәрлекләү кәгазьләрендә прапорщик Һадиев та телгә алына. Ул документларны игътибар белән тикшергәндә, тагын Николаев фамилиясе күзгә ташлана. Николаев Муравьев-Апостолның якыннарыннан берсе булып исәпләнгән. Чынлыкта ул хыянәтче булган. Тикшерү комиссиясе алдында ул Муравьев-Апостолның көрәштәшләре турында күп нәрсәләр сөйли, башкалар белән беррәттән фельдфебель Федор фамилиясе һәм татар прапорщигы Һадиев фамилияләрен телгә ала. Эзәрлекләү комиссиясе аларны Муравьев-Апостол фикерләрен яхшы белеп тә, жандармериягә хәбәр итмәүләре өчен гаепле саный. Ләкин соңра, кирәкле дәлилләр таба алмау сәбәпле, Һадиевны азат итәргә мәҗбүр була.

Тикшерү документларында тагын подпоручик Казанлы исеме очрый. Дөрес, подпоручик Казанлы турында бик аз билгеле. Әмма аның белән бергә хезмәт иткән декабрист майор Спиридонов турында шактый күп нәрсәләрне ачыкларга мөмкин. 1 нче армия штабы капитаны В. С. Сотниковның дежур генералга тапшырган яшерен рапортында түбәндәгеләр әйтелгән: «Спиридонов... Пенза пехота полкында азатлык рухы урнаштырды; чөнки ул солдатларны артык үз иркенә куйды, алар белән әшнәләрчә мөнәсәбәттә булды».

Солдатлар һәм кече офицерлар белән якын мөнәсәбәттә булуын Спиридонов үзе дә яшерми. Эзәрлекләүләр комиссиясенә биргән язма күрсәтмәләреннән аның Кры-

---

[1] М. В. Нечкина. Восстание 14 декабря 1825 года. СССР Фәннәр академиясе басмасы, М., 1951.

жановский, Аскирка, Казанлы һ. б. офицерлар белән элемтәдә булуы ачыклана. Спиридонов үзе ахыргача азатлык идеалларына тугры булып кала.

Әзәрлекләү комиссиясенең башка документлары да декабристлар хәрәкәтендә төрле милләт вәкилләре катнашуын раслый. 3 нче пехота полкы командиры генерал-лейтенант Рот башкомандующий генерал Саkenга рапорт яза. «Подполковник Муравьев-Апостол шайкасындагы фетнәчеләр» исемлегенә ул шактый гына төрки фамилияләрне кертә. Әйтик, Мостай Баязитов, Бертуль Якуб, Бакселей Мәгъдәлиев, Сәлим Гиряков, Шәнгәрәй Алмакаев, Михаил Камаев, Әбдрәхим Истаев, Якуб Тимергалиев, Хәким Әхмәров, Фәткул Зәетов, Хәмит Сәгыйтов, Ишмехәммәт Биктимеров [1] һ. б.

Ләкин бу фамилияләрнең язылышы төрле документларда төрлечә — Мәгъдәлиев фамилиясе кәгазьләрдә Магделеев яки Магдилеев дип языла. Сәгъдиев исә кайчак Сайчитов, кайчак Сайгитов булып китә. Аның каравы, бу исемнәр «законга каршы җинаять» эшләгән Муравьев-Апостол, Бестужев-Рюминнар белән рәттән куела. Бакселей Мәгъдәлиев һәм Сәлим Тряков — Чернигов полкының 1 нче мушкет ротасы солдатлары. Мостай Баязитов — шул ук полкның 2 нче ротасыннан, Шәнгәрәй Алмакаев — 3 нче ротадан, Фәтхул Зәетов — 4 нче ротада, Хәмәт Сәгыйдов — 6 нчы мушкет ротасында хезмәт иткән. Ишмехәммәт Биктимеров — барабанчы, Әбдрәхим Истаев — Чернигов полкының 2 нче гренадер ротасыннан, Хәким Әхмәров — Матвей Муравьев командалыгындагы гренадер ротасы солдаты. Баязил Баязитов Чернигов полкының 5 нче мушкет ротасы командиры А. Д. Кузьминның денщигы булган. Кузьмин исә декабристлар хәрәкәтендә шактый күренекле шәхес. Ул бертуган Борисовлар оештырган «Берләшкән славян җәмгыяте» эшендә актив катнашкан. Бу җәмгыять членнары солдатлар арасында үз карашларын, үз идеяләрен таратырга тырышканнар. Кузьмин һәм аның денщигы Б. Баязитов үзара һәрчак яхшы мөнәсәбәттә булалар. Димәк, Баязитов та декабристлар рухы белән сугарылган булган.

Генерал-адъютант К. Ф. Тольның яшерен рапортында гади солдатларның да декабристлар восстаниесенә катнашуы ачыктан-ачык әйтелә. Офицерларның күпчелеге кулга алынганнан соң да генерал Толь солдатлар арасында азатлык идеяләре саклануыдан курка. «...солдатлар һәм офицерлар С.-Петербургта кулга алынган командирларының фикерен яклыйлар, ул фикерләрне җәмгыять өчен файдалы саныйлар һәм хөкүмәткә карата дорфа мөнәсәбәттә торалар», — дип яза Толь.

Хәрби суд карары буенча, декабристлар хәрәкәтенә катнашкан солдатларны шпицрутеннар белән суктыралар. Җәзага түзә алмыйча, аларның күбесе һәлак була. Исән калганнарын сөргенгә озаталар яки чик буендагы полкларга күчерәләр.

Рус халкының азатлыкка омтылышын декабристлар бөтен кешелек җәмгыяте омтылышы белән бәйләгәннәр, руслар язмышын Россиядәге башка халыклар язмышыннан аерым карарга теләмәгәннәр, уртак дошманга — патша хөкүмәтенә каршы көрәштә барлык халыкларны берләштерергә мөмкин дип санаганнар.

«Көньяк җәмгыяте»нең поляк революционерлары, Литвадагы «Хәрби дуслар» оешмасы белән элемтәгә керүе, декабристлар хәрәкәтенә башка милләт вәкилләренең дә тартылуы нәкъ әнә шуны раслый.

Башка халыкларның культурасына, гореф-гадәтенә һәм теленә декабристлар һәрчак зур ихтирам белән караганнар. Кайбер декабристлар башка милләт хатын-кызлары белән гаилә корганнар. Декабрист Бестужев-Марлинский, мәсәлән, татарча яхшы белгән, гарәп телен өйрәнгән.

Декабристларның азатлык идеяләре Казан якларында да теләктәшләр тапкан. Н. И. Лобачевский, И. М. Симонов, П. С. Кондырев, И. И. Хәлфин кебек алдынгы фикерле галимнәр үзләренең яшерен оешмаларга катнашмавы турында аңлатма язарга мәҗбүр булганнар [2]. Казан университетының укытучы-профессорлары һәм студентлары өстеннән даими күзәтү, шымчылык урнаштыру турында генерал Желтухинга махсус күрсәтмә бирелгән.

Шулай итеп, әле аз гына тарихи материалларны өйрәнгәндә дә декабристлар хәрәкәтенең күп милләтле булуы һәм анда башка халыклар белән беррәттән татарларның да киң катнашуы ачык аңлашыла.

Сәвия ЛАТЫЙПОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

[1] Декабристлар восстаниесе. Материаллар, VI том. М.—Л., 1929, 86—94 битләр.
[2] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, I тасвирлама, 1511 саклау берәмлеге, 1 бит.

## Сырбай Мәуленов

# ҖЫРЛЫ КАЗАН

*Казакъ шагыйре Сырбай Мәуленовның исеме татар укучысына электән үк таныш. Аның күп кенә шигырьләре Нури Арсланов, Зәки Нури, Мәхмүт Хөсәен тарафыннан тәрҗемә ителеп, республикабыз матбугатында басылып чыктылар.*

*1970 елда С. Мәуленов Казанда да булып китте. Аның 1972 елны «Казахстан» китап нәшриятында басылган «Шыңдагы шугыла» исемле очерк-юлъязмалар җыентыгында «Җырлы Казан» дип аталган бүлек тә бар. Түбәндә без укучыларыбызга шул әсәрне тәкъдим итәбез.*

Уфадан очкан самолет бер сәгать үтәр-үтмәстән түбән төшә башлады. Стюардесса кыз самолетның Казанга килеп җитүен белдерде.

Казанда яңгыр ява иде. Аның энҗедәй эре-эре тамчылары асфальтка шыбыр-шыбыр килеп төшә дә як-якка чәчрәп китә. Инде июнь башлануга да карамастан, соры, төксе күк куеныннан әле булса кыш салкыны китмәгән кебек. Әйтерсең әле анда кар бураннары дулый, ә шушы суык яңгыр аның илчесе булып җиргә ява иде.

— Өфедә көн аяз, кояшлы иде. Казан сезне боз-яңгыры белән каршылады,— дип көлемсерәде безнең белән бергә кайткан татар язучысы Гариф Гобәй.

Бу кеше инде алтмыштан узган. Шулай да аңа карап һич алай димәссең. Гомумән, ул бар хәрәкәт-торышы белән дә бик сылу, бик ыспай абзый. Өстәвенә, әле бик оста җырчы да икән. Бергә-бергә башкорт язучыларының мәҗлесләрендә булганда аның әнә шул күркәм сыйфаты да ачылды. Гариф абзыйның болытсыз аяз көндәй саф тавыш белән җырлавы мине сокландырган һәм татарның ул мактаган «Нурия», «Гөлмәрфуга», «Галиябану»дай сылу кызлары хыялымда күз алларына килеп баскан иде.

Хәзер мин ул олы язучының кисәтү сүзләрен яхшыга юрап:

— Жаңгыр жауса — җиргә куәт. Укабыз коелмас,— дидем.

Шул арада сүзгә татарның иң өлкән шагыйрьләреннән берсе Хәсән Туфан кушылды.

— Сез хәзер Тукай, Такташлар җиренә аяк бастыгыз, — диде ул.

Күреп-белгән татар язучыларыннан безгә аеруча танышы шушы Хәсән абый иде. Чөнки ул безнең Кустанайга да, Алма-Атабызга да килгәләгән кеше. Әйткәнемчә, ул хәзерге татар шигъриятенең иң олыларыннан берсе, аксакалы.

Ә аңарчы Тукай, Такташлар яшәгән биредә. Бу исемнәр бала чагыбыздан ук безнең дә күңелләребезгә сеңгән, якын исемнәр. Алар әйтерсең һәрчак минем янәшәмдә, янымда гына йөргәннәр. Бергә-бергә безнең инештә су коенышкан, япан далада

безнең белән атта чабышып үскән, кыр-далада бергә төн кунган, мәҗлесләребездә янымда утырган, бергә безнең моңнарны моңлашкан кебек якын иде алар миңа. Һәрчак күңелем түрендә иде ул исемнәр.

— Шуларны хөрмәтләп баш иярге дип бирегә килүем,— дидем мин Хәсән Туфанга. Һәм ул минем бу сүзләремә ризалык белгерткән сымак итеп:

— Әйе, Тукай безнең шигърияттебезнең премьер-министры булса, Такташ — президенты! — дип куйды. Олы шагыйрьнең бу сүзләре Тукай, Такташ гомеренә эпиграф шикелле тоелды миңа.

Әйе, алда безне Тукай, Такташлар җырлаган серле Казан, нурлы Казан көтә иде.

Казан каласы казакъ кешесенә элек-электән якын, мәгълүм кала. Казан татары белән кыр-дала казагы борын-борыннан кан-кардәшләр алар. Казан-шәһәре нәшриятларында минем халкымның беренче китаплары дөнья күргән. Димәк, ул халкымның аң-үсешенә булышлык иткән кала. Хәер, татарның элгәрерәк чыккан үз әдәбияты да казакъ даласында күпләп таралган, укылган. Бу хәл исә бик борынгы чорда ук инде татарлар арасында аек фикерле һәм укымышлы кешеләрнең ишле булганлыгы белән аңлатылса кирәк. Элек-электән үк бит Казанның үзендә генә дә ике обсерватория һәм гомумхалык мәдәният үзәкләре — клуб, китапханәләрнең эшләп килгәне мәгълүм. Унтугызынчы гасыр азагында инде Казан каласында татарның беренче романнары басылган, газета-журналлар чыга башлаган.

Бүген без менә шул атаклы Казан туфрагына аяк басабыз.

Мине тагын да рухландырганы — биредә бөек Ленинның үзе йөргән булуы! Ленинның аяк эзләре сакланган җир бит бу! Һичшиксез, шушы изге җиргә аяк басу, ул даһи кеше сулаган һаваны сулау һәркем өчен изге теләк, асыл максаттыр.

Менә без Казан университетында. Университет бинасы алдында унҗиде яшәр Владимир Ульяновның һәйкәл-сыны басып тора. Әйтерсең аның үз ишләре арасында атлый-йөгерә университетка килеше. Бинаның икенче катында Ленинның класс-музее. Бу аудитория нәкъ Володя Ульянов укыган вакыттагыча итеп сакланган. Ул утырган парта... Яшь Ленинның куллары тигән китаплар... Болар һәркем өчен иң кадерле әйбердер.

Шушы университетта уку чорында инде Ленин, моңарчы яшәп килгән иҗтимагый мохитны үзгәртеп корырга ниятләгән революцион яшьләр белән якынлашып, тәгаен марксист булып җитлегә дә. Шушында ул революцион көрәш юлына баса. Соңрак шушында сөйләгән ялкынлы революцион чыгышы өчен ул укудан чыгарыла һәм, кулга алынып, беренче мәртәбә сөргенгә җибәрелә.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, заманында Казан университетында атаклы язучы Лев Толстой, исем-аты күпләргә мәгълүм композитор М. А. Балакирев, олы галим, үзенчәлекле математик Н. И. Лобачевский һәм башка бик күп талант ияләре укыган.

Университеттан ерак та түгел — Ирек мәйданы. Мәйдан уртасында — Владимир Ильичның янә бер һәйкәле. Казанлылар өчен ул да бик кадерле. Бу һәйкәл янынан көннең-көне буе халык өзелми. Әледән-әле аңа үсмер балалар төркеме килеп баш ия. Мәктәп балаларын шунда — Ленин бабалары каршында зур тантана белән пионерга кабул итү уздырыла...

Биредән инде без пролетариат әдәбиятына нигез салучы Горькийның яшь чагында хезмәт иткән пекарнясына юнәләбез. Бу музей-йортның подвал өлешендә он тутырылган дәү-дәү капчыклар өеме. Яшүсмер Горький шул авыр капчыкларны иңнәрендә ташып көн күргән. Адәм ышанмаслык газапларны, авырлыкларны башыннан кичергән. Шул ук вакытта аны Казан пристанендә көнлекче грузчик итеп тә еш күрергә мөмкин булган. Әйе, Казан аны, корыч эшкәрткән мартен мичедәй сугыпсугарып, киләчәк өчен, алдагы олы көрәш өчен чыныктырган кала. Шуңа күрә Алексей Максимович үзе дә, физик яктан Нижний Новгородта туган булсам, рухи яктан Казанда туганмын. Тормыш университетларым арасында Казан минем өчен иң кадерлесе, дип тикмәгә генә әйтмәгәндер...

Узган гасырда Горький күреп белгән ярлы Татарстан бүген илдә алгы сафларда атлый. Татарстан үзенең бүгенге нефть эзләү һәм нефть чыгару осталыгы белән шактый күп ил-төбәктән өстен тора, теләсә кемне үзенә ярышка чакыра ала. Безнең ил күләмендә җитештерелгән кыйммәтле җир маеның шактый күп өлешен

хәзер Татарстан бирә. Кайчандыр фәкыйрь саналган татар иленең «кара алтын» хәзинәсе бүген илебездән чит дәүләтләргә чыгарыла, аларның хаҗәт-ихтыяҗларын канәгатьләндереп килә. Нефть кудыручы корыч манаралар инде киң Кама үзәнен дә чолгап алган. Ә җир маен чыгару үзәге саналган Әлмәт каласын ишетеп белмәгән кеше, мөгаен, дөньяда юктыр. Бу республикада һәркем, һәр һөнәр остасы үз эшендә җырчы — шагыйрьгә тиң бүген. Аларның һәркайсы чын ихласлык, изге теләк белән яңа чор Татарстанының тарихи дастанын яза. Тирән җир куеныннан ургылып аккан «кара алтын» ташкыннары да, кыр-басуларны тутырып дулкынланган иген сабаклары, яңа туган шәһәр урамындагы яшь тирәк яфрагының шавы да әнә шул җыр-дастанның аерым көй-юлларын хәтерләтә сыман.

Горькийның 1886—1887 елларда хезмәт иткән пекарнясы да артта калды. Алдыбызда — ак таштан салынган Казан Кремле. Кремльнең бирге чатында шагыйрь Муса Җәлилгә куелган зур һәйкәл тора. Бу сын-пәһлеванның кул-аяклары богаулы, шулай да ул ярсу юлбарыстай алга, көрәшкә омтылган сыман. Әйтерсең лә ул кыю һәм мактаулы көрәш юлын узган Мусаның нәкъ үзе. Бирегә Муса Җәлил ярым ялангач, ялан аяк килеш ташка басып, бар торышы белән алга, киләчәккә омтылган. Аның үткен карашында өмет, җиңәчәгенә ышаныч нурлары чагыла төсле.

Муса Җәлил! Аның исеме хәзер ирек сөюче барлык илләрнең халыклары теленнән төшми. Хыялга тиң шәхес ул хәзер. Богаулы Мусаны күрү белән минем күз алдыма Волховның баткак урманнары, ничәмә айлар буена канлы бәрелеш кырына әверелгән Синявино калкулыклары, өсләренә тоташ ут-ядрә явып торудан хәрабә хәленә килгән шыксыз бистә-авыллар килеп басты. Шушы Волхов сазлыкларында бит инде, 1942 елның җәй башында, якында шартлаган снарядның һава дулкыны бәреп егып исәңгерәткән һәм каты яраланган мизгелдә көчсез-хәлсез шагыйрьне фашистлар камап алган, әсир иткән. Муса Җәлилнең соңгы пулясын үзенә атарга ниятләвен, әмма пистолетының атмый калуын тасвирлаган үкенечле шигырен мин күптән казакъ теленә тәрҗемә иткән идем инде. Шунлыктан аның сугышып үткән җире Волхов тирәсе икәнлеге дә, ничек әсирлеккә төшүе дә миңа күптән билгеле иде. Ә инде Волхов фронтының, Волхов сазламыкларының ул көннәрдәге хәлен мин үз күзем белән күрдем. Кабат оештырылган Икенче Удар армия сафларында шул төбәктә сугышкан идем. Шул сәбәпле Муса Җәлил миңа аеруча якын тоела.

Ир йөрәкле шагыйрьне ил онытмады. Аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Шул ук көннәрдә аның кайнар каны белән язылган каһарманлык җыр-дастаны— «Моабит дәфтәре» җыентыгы илебездә иң яхшы әдәбият-сәнгать әсәрләренә бирелә торган иң югары бүләккә — Ленин премиясенә лаек булды. Ул китаптагы шигырьләр бүген дөньядагы барлык телләргә күчерелгән.

Муса Җәлил хакында Әзербәйҗанның танылган шагыйре, совет поэзиясенең иң күренекле вәкилләренең берсе саналган Сәмәд Вургун элегрәк болай дип язып чыккан иде: «Бөтен дөнья һәм шул дөнья йөзендәге әдәбият исемнәре иҗатларының мәңгелек данына әверелгән күп кенә шагыйрьләрне беләм. Ләкин шагыйрь һәм герой Муса Җәлил кебек шигырь белән генә түгел, бәлки үлеме белән дә исемен мәңгеләштергән шагыйрьләр бик аз. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең данлыклы халык шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил».

Муса Җәлилнең үзенә атап язылган шигырь-җырлар, дастаннар хәзер бик күп. Шулар арасында казакъ шагыйре Жубан Молдагалиев, татар шагыйре Нәби Дәүли поэмалары да герой шагыйрьнең батырлык, фидакарьлегенә бер хатирә булып тора. Муса Җәлилнең үз шигырьләрен телдән-телгә тәрҗемә итүче һәм аны төрле телдә укучылар саны да елдан-елга арта бара.

...Без Кремльне, аның үзәгендә иркен җиһан киңлегенә үрелеп утырган мәһабәт Сөембикә манарасын карап, йөреп чыгабыз да Казан каласының кыл уртасында урнашкан Кабан күленә таба юл алабыз. Кабан күле янәшәсендәге бакча-аланда, биек бер урында Тукай басып тора. Бер заман шушындагы Печән базарында сатылып, кулдан-кулга күчеп йөргән ятим бала бүген бөтен бер милләт хөрмәтенә лаек дан иясе. Шул халыкның сөеклесе, киңәшче-әүлиясе. Бүген ул үз югарылыгыннан җитди генә алга карап, уйланып тора... Кичә мин шагыйрьнең җирләнмеш урынында булдым... Кабер ташына шагыйрьнең шигъри юллары сырланган.

Жырлый-жырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә.

Егерме җиде яшьлек шагыйрьнең никадәр рухи көчкә ия булуын күрсәнче [1]!

Кабан күле — каланың әйтерсең якты, зәңгәр күзе. «Казан вә Кабан арты» шигырендә Тукай менә ни ди бит аның хакында:

Кай заманда, кайсы телдә искә алынса да Казан,
Искә керми калмый һич тә шундагы бер күл — Кабан.
Бу шәһәрне һәм бу күлне җырлыйдыр милләт теле
Бик яратып, әллә инде иске шөһрәт аркылы! [2]

Бу күл янәшәсендә моң-җырларын уйланып Тукай күпме йөрегәндер?! Һәм ничәмә-ничә яшь йөрәк шул күл буенда бер-берләрен табышып, йолдызлы күк гөмбәзе чатырына сыенып серләшкән, алтын айны моңа шаһит иткәндер... Шулай да Кабан күле, бер карасаң, тынып калган күз яшедәй шул син...

Идел... зур бер тамыр кебек ул, ничәмә-ничә порт-шәһәрне берләштергән олы су юлы. Ул үзенең аксыл пароходлары, пароходларында җилфердәгән ялау-флаглары белән күңелне үзенә әйдәп тора. Казан порты вокзалы... Аның зур тәрәзәләре аша киң Идел тагын да матураеп, алланып күренә. Аргы як ярдагы Ослан таулары шул ил иркәсе Иделне саклап, каравыллап торадыр шикелле. Яр-кыяга тын гына бәрелгәләп, тын гына агып яткан Иделне һәрберебез җир шарына бөек Ленинны биргәне өчен генә дә олыларга, күңелләребездә аңа карата йолдыздай якты хис сакларга тиешбез бит...

Казан порты — ул чын хезмәт мәйданы. Пассажирлар янсә йөкләр төяүле бихисап пароходлар бирегә килә тора, икенче берләре моннан ерак юлга китә торалар. Советлар иленең олы су юлы боларның барын да үз күкрәгендә күтәрә, кирәк җиренә илтеп җиткерә. Кайчандыр Некрасов җырларында телгә алынган бурлак оныклары бүген шул ук Идел киңлегендә зур-зур корабларны йөртә. Диңгез кебек Идел дулкыннары аларны җай гына чайкалдыра. Ул дулкыннар бүген Стенька Разин бәетен генә түгел, зур Иделнең үзенә, аның хезмәтенә багышланган тантаналы гимннарны да тыңлыйлар.

Казан елга портыннан Ленинградка, Мәскәүгә, Куйбышев һәм Горький шәһәрләренә, тагын бик күп башка шәһәрләргә барырга мөмкин. Идел Совет Татарстанының башкаласын ерак-ерак җир-төбәкләр белән тоташтыра.

Иркен Идел өстендә җил уйный, тирә-юньгә көмеш-тәңкә күбекләр чәчә. Аларга алданган акчарлаклар шаулап, канат җәеп биектән түбән үргылә да, өметләрен өзеп, янә югары күтәреләләр. Су өстендә дәү-дәү кораблар, каек-көймәләр... Пароходлар туктаусыз үзара хәбәрләшеп, кычкырып үтеп китә тора. Ә суга мул Идел ярларында — яшел постау кебек тоташ чирәм, яшеллек. Шәһәр халкы үзенең ял көннәрен шул Идел ярында уздыра: ял итә, сәяхәткә йөри, янсә каек көймәләре белән чоңгыллы киң елга кочагында йөзеп күңел күтәрә.

Катер белән Идел өстен гизеп йөрүе нинди рәхәт! Дулкын сине бер күтәрә, шул чак уй-хыялларың да биеккә-биеккә ашкан төсле була. Икенче мизгелдә син як-ягыңда дулкын-дулкын кайнап торган суга чүгәсең. Яр буйлары — монарланып яткан болын, тугайлар... Катерда без — Казагыстан Язучылар союзының Целиноград оешмасы җаваплы секретаре Нургоҗа Уразов, мин һәм татар дуслар барыбыз бергә йөрибез. Безнең Нургоҗа чәчмә әсәрләр дә яза, шигырь дә... Арадан кемдер тальян гармун уйный. Аның көенә дулкыннар тагын да җәһәтрәк тибрәнәләр шикелле.

Туган яктан ерак китеп
Диңгезләр кичтем.
Сагыш дигән тирән күлнең
Суларын эчтем.

---

[1] Шигырь 1908 елны язылган (тәрҗ.).
[2] С. Мәуленов китабында бу шигырь казакъ акыны Җакан Сыздыков тәрҗемәсендә бирелгән (тәрҗ.).

**И, гүзәл туган ягым,**
**И, ямьле туган ягым,**
**Тальян гармун моңы булып**
**Җырыма кучтең.**

Нургожаны да җырга кушылырга өндәсәк тә, ул дәшмәде. Ә мин үзем татар җырларын бик якын күрәм. Үзебезнең Тургай шәһәрендә без Габдулла, Гыймади атлы татарлар белән күрше яшәдек. Яшь чакта бергәләп якындагы үр-тауларга кыр суганы җыярга йөри идек. Анда күпчелеге татар кызлары белән татар егетләре була торган иде. Билгеле, егетләрнең берәрсе кулында гармун була. Берара без аны чеңләтеп көйләп тә җибәрәбез. Егет-кызлар аңа кушылып җыр башлый. Билгеле инде, башлыча, моң-сагышлы татар көйләре уйналып, татар җырлары җырлана иде... Шул чактагы күңел җилкенүләре, яшь йөрәкнең ашкынып тибүләре онытыламы соң?!

Безнең җыр катер белән Идел өстеннән күтәрелеп, җилпү канатлы акчарлактай ераклардан урап килә дә кабат баш очында яңгырый башлый:

**Таныш түгел юллар буйлап**
**Мин озак йөрдем.**
**Туган ягым күренерме дип,**
**Тауларга мендем.**

— Әйт шуны! — дим мин җырны куәтләп, күңелем булып. Җыр тагын үз-үзенә көч-дәрт өстәгәндәй яңгырый төшә.

**Туган яктан еракта да**
**Мин дуслар таптым.**
**Ләкин яшьлек дустым калган**
**Илемә кайттым.**

— Бу җырның авторы шагыйрә Гөлшат ханым Зәйнашева була инде, — диделәр татар юлдашлар.

Күрәмсез, татар сүзләре безгә никадәр якын [1]. Казакъ халкының: «Татарга тылмач кирәкми»,— дип әйткән бик борынгы мәкале бар. Бу мәкаль безнең ике кардәш халыкның бик күптәннән килгән дуслыгы, якынлыгына ишарәдер.

Төштән соң без, катерны елга ярында калдырып, җыйнаулашып, урманга кереп киттек. Каен белән карагай катнаш куе урман безне үз кочагына алды: тар гына үзән сукмагы буйлап ярдан аргы почмакка юнәлдек. Урман һавасы сөзеп тондырылгандай саф, җиңел, рәхәт иде. Агачлардан искитмәле тәмле ис аңкып тора иде. Ул ак каеннар, карагай-наратлар арасында кечкә кадәр йөрдек. Әңгәмәбез исә гел әдәбият тирәсендә, Тукай, Такташ, Җәлилләр хакында булды. Кайбер татар юлдашлар белән ул шагыйрьләрнең истә калган аерым шигырьләрен ярыша-ярыша хәтерләштек. Мин дә белгәннәремне әйтә килдем. Шулай итеп йөргән арада көн узып та китте, кич җитте. Бер мәлне мин:

**Җиктереп пар ат Казанга туп-туры киттем карап;**
**Чаптыра атларны кучер суккалап та тарткалап,**

— дип, Тукай абыебыз әйткәндәй, әйдәгез, Казанга карап юл тартаек,— дидем.

Катерга утырып кайтырга чыккач та Дәрдмәнд, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимовларның язмыш-гомерләренә кагылышлы сөйләшүләр дәвам итте.

— Галиәсгар Камал белән Такташ икәве шәһәрнең Горький исемендәге ял паркында җирләнмеш икән. Анда барып зиярат кылдым. Такташ баш очындагы кабер ташына кемдер язып киткән бер куплет шигырьне күчереп алдым,— дип, мин татар дусларыма блокнотымны күрсәттем.

---

[1] Бу җыр китапта да шулай һич үзгәрешсез бирелгән (тәрҗ.).

**Үлем турында уйлама,**
**Илең турында уйла.**
**Илең турында уйласаң,**
**Гомерең озын була.**

Янә Казанның елга портына кайтып төштек. Тамак ялгап алу өчен Идел-елга уртасында, дулкында чайкалып утырган «Җилкән» ресторанына керергә ниятләдек. Эчкерсез сөйләшү биредә дә өзелмәде. Әүвәл бер көлешеп алдык. Татар шагыйре Мәхмүт Хөсәен Нургоҗаның балыкны чәнечкегә чәнчеп алырга азапланганын күреп:

— Тавык, балык, каз ишеләрне кул белән устауга кирәк,— дип көлдерде.

Шуннан соң гына Нургоҗа балык башына ике куллап ябышты. Аннан соң Ренат Еникеев сүз алып, казакъ шагыйре Таһир Жароковның «Каргиго» исемле шигырен татарча сөйләп бирде. Сүзгә татар шагыйре, безнең якташыбыз Нури Арсланов та кушылды. Ул казакъ шагыйре Җакан Сыздыковның хәл-әхвәлен сорашты да:

— Тукайны бик яратып, бик күп тәрҗемә иткән мөхтәрәм акын бит ул,— дип өстәде.

Әйтергә кирәк, Нури Арсланов үзе дә бик мөхтәрәм шагыйрь. Өстәвенә, исеме дә җисеменә туры килеп тора: Нури — нурлы йөзле, мөлаем кеше. Ә чал кергән чәчләре чын арыслан ялларыдай кабарып, җилкәсенә үк төшеп тора. Ул чәчнең үзендә бер кодрәти-илаһи көч яшеренгән сыман. Һәм шундый чәчнең әйткәнгә күнеп, сыпырганга сыпырылып, чын ял булып ятуына мин хәйран калып утырдым.

Алда әйткәнемчә, Тукайның язмыш-гомере белән дә, шигырьләре белән дә яхшы ук танышмын. Шагыйрьнең үз истәлекләрен дә, икенче бер шагыйрь Әхмәт Фәйзинең Тукайга багышланган әсәрен дә укыганмын. Чөнки минем өчен Тукай — иң олы шагыйрь, остаз. Казанга килү белән дә иң элек Тукай зиратын барып күрдем. Нури Арслановка шул хакта сөйләдем. Ул миңа җавап итеп:

— Без дә казакъ әдәбияты белән яхшы танышбыз,— диде.

— Шулай булмый ни, татар әдипләренең күбесе өчен Казагыстан уртак ватан ич,— дидем мин, Нури Арсланов сүзләрен куәтләп.— Тукай безнең Уральскида басмаханәдә эшләгән, беренче шигырьләрен шунда яза башлап, шунда шагыйрь булып җитлеккән. Соңра, авырып киткәч, янә безнең Кустанай өлкәсенең Карабалык районына килгән. Казакъ казанынннан тәгам итеп, дәвага казакъ кымызын эчкән. Безнең нәселле атларда дала буйлап йөргән гой. Татарның икенче бер танылган язучысы Кави Нәҗми, шулай ук безнең Кустанайда булып, Сәрвәрхан атлы сылу кызыбызны алып киткән.

— Анысы хак,— дип көлде Нури Арсланов.— Сәрвәр ханым бүгенге көнгә кадәр Кустанай казакълары җырын онытмый җырлый әле.

Ябырылып, Идел суыдай кара-соры төстәге төн килде. Идел җиле салмак-сабыр гына төнгә эшенә кереште. Ресторан түбәсе аша күк йөзе үзе күренмәсә дә, тирәяктагы мөлдерәмә су өстенә ул һәр йолдызының нурын чәчә иде. Бөрчек-бөрчек йолдыз сибелгән төнге Иделгә карап сокланып утыру үзе бер рәхәт тамаша икән! Биредән Казан каласы үзе дә, хәйран энҗе муенсаларын таккан татарның бер сылуыдай, матур булып күренә иде. Шәһәр өстендә, күктән асып куелганнар диярсең, биек-биек төзелеш краннары... Каланың төрле төбәкләреннән, яңа чор Алып батырларының сулышы кебек, хезмәт гөрелтесе ишетелеп тора иде.

Без «Җилкән»не калдырып калага юнәлдек. Кая карама төзелеш, өем-өем актарылган җир-туфрак иде.

— Казаныбыз Алып батыр адымы белән алга баручы баһадирларның берсе шул,— диде Нури Арсланов горурланып.— Бер ара күрми торсаң, шәһәрдәге үзгәрешкә хәйран каласың. Кайчан гына эшкә яраксыз саналып буш яткан урыннарда бүген өр-яңа кварталлар калкып чыкты. Шәһәр картасы да, елдан-ел чыга торган төрле «Сәяхәтнамә»ләр дә әлеге үзгәрешләр артыннан өлгерә алмыйлар.

— Бөтен илебез шулай, барлык кала-шәһәрләребез шундый үзгәреш чоры кичерә гой,— дип, мин ирексездән татар шагыйренең сүзләрен бүлдердем.

Нури Арсланов безнең як үзгәрешләрен дә белә икән.

— Хак әйтәсең, — диде. — Элегрәк мин белгән Иртыш яклары да нык үзгәргән икән. Бер-ике ел элек барып чыккан идем, Павлодарны танымадым. Биек-биек йортлар калкып чыккан. Куәтле заводлар очкын чәчеп, гөрләп утыралар.

Казан-Мәскәү вакыты белән сәгать кичке унга якынлашкан иде. Мин, Нури Арсланов белән саубуллашып, «Таң» кунакханәсе янында төшеп калдым. Өч сәгатьтән, Ленинград — Алма-Ата самолетын каршылап, кайтып китәсе идем. Казанда ул бик аз гына вакытка туктала. Кунак йорты хезмәткәрләре белән исәп-хисапны өздем дә Гариф Гобәй абзыйларга юнәлдем. Казанда миңа юлдашчылык һәм житәкчелек кылып, бик күп нәрсә белән таныштырган, аралаштырган ул яхшы кешегә рәхмәт әйтеп саубуллашмый китүем егетлеккә саналмас дидем.

— Ничек соң, ошадымы Казан? Безгә рәнжеми генә Алма-Атаңа китеп баруыңмы? — дип сорашты әүвәл Гариф абзый.

— Рәхмәт инде барысы өчен дә, барыгызга да,— дидем мин.— Аеруча җиңгәй белән сез күп хөрмәт күрсәттегез, рәхмәт!

— Ул кадәр рәхмәтләр әйтерлек без ни эшләдек?! — диде җиңгәй аптыраган сымак бер гадилек белән, үз күреп, якын итеп.

— Ачык йөзегез, җаксы сүзегез бик житкән,— дидем.

Озата чыккан Гариф абзый машинага ук утырды. Төнге Казанның үзәк урамнарыннан чабып үтеп, без аэропортка юл алдык. Инде Казан өстендәге коңгырт күктә таң билгеләре шәйләнә иде.

Озакламый мин көткән самолет та килеп житте. Аның биек баскычына күтәрелгәч, мин төн юрганына төренеп яткан Казанны тагын бер кат күздән кичердем дә:

— Киләчәктә күрешкәнгәчә хуш, Казан! — дип кул болгадым.

**Казакъчадан**
**ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИН** тәрҗемәсе.

## Фатих Хөсни

# ИКЕСЕ ДӘ ГАЕПЛЕ

хикәя



Язучы хикәя язып бастырды. Тормыш геройлары белән танышлыгы шәп түгел иде, ә чамалаган кадәресендә тырышты, фантазиясен җәлләмәде, хәтта бер уйлаганда хикәя тик фантазиядән генә тора иде. Героеның күңелдә кала торган төп күрсәткечләре түбәндәгеләр: колхозчы малае, соңыннан шәһәргә килеп төпләнгән һәм нык төпләнгән, югары уку йортын бетергән, ләкин диплом якламаган, анкета тутырганда ул графасына «Тулы булмаган югары белемле» дип яза, әмма бик тә тулы бер ягы бар: хатын-кызлар тирәсендә уңыш казана. Хәер, уңыш казанырлыгы да бар— буе-сыны килгән, кара тутлы чибәр егет, сүзгә-өнгә оста, артык мактанмас, әмма кирәкле кадәресен төшереп тә калдырмас. Ихтимал, шушы кирәк кадәресен төшереп калдырмауның бер галәмәтедер: әлегә кырыкка да җитмәс борын өч хатын аерган. Ләкин ул моны бервакытта да селкеп йөрмәс, кыска гына итеп «Өйләнгәнме? Өйләнгән» белән бетерер.

Ах алла, безнең кайсыбыз гына сөттән коенган, бәлки язучыбыз үзе гомер буе бер хатын белән генә торганлыктан, өч хатын белән торып караган кешеләргә эченнән генә кызыгып йөргәндер, хикәясендә героеның нәкъ менә шушы ягын калкыта төшеп сурәтләде. Теге бичараның үзе күләгәдәрәк саклый торган ягын.

Ә, әйе, әйтергә оныткандыз: язучы героеның исем-фамилиясен Рәүф Рахманов дип куйган иде, әлбәттә, бер дә уйламыйча. Ә менә уйлаган булса, ярыйсы икән! Нәкъ менә шушы ике тутык, ягъни героеның үзе күләгәдәрәк саклый торган ягын артык төчеләнеп күпертү — бердән, исем-фамилиясен уйламыйчарак кую — икенчедән, аның бу хикәядән соң килгән данын берьюлы җимереп ташлады да инде. Югыйсә, гомер буе бер хатын белән генә торып үтли башлаган кешеләр, бигрәк тә язучының каләмдәш иптәшләре, хикәя белән үтә дә нык кызыксынып, моның өчен аның авторына «даһи» дигән ти-

тулны тагарга әзер торалар һәм, белмәмешкә салынган атлы күренергә тырышып, әлеге хатын алыштыру һөнәренең нечкәлекләрен сораштыра башлаганнар иде.

Билләһи, иң югары титулны эләктерәм дигәндә генә... язучыны судка чакырып повестка килеп төшмәсенме! Суд булгач — суд инде, кызыл япмалы өстәле, судьясы, халык утырышчылары, секретаре, графин тулы суы һәм кызыксынып кереп утырган ачык авызлары белән. Әлбәттә, эшне судка биргән кеше дә шунда утыра — Рәүф Хәбибрахманов дигән кеше булып чыкты анысы. Бөтен төсе-кыяфәте, буе-сыны, сөйләве, хәтта сөйләгәндә бер якта ялтырап-ялтырап китә торган бердәнбер алтын теше белән дә хикәядә сурәтләнгән геройга төп-төгәл туры килә. Оста сөйли, үзен яклый белүе ягыннан бусы хәтта хикәядәге геройдан күп өстен күренә иде.

— Хөрмәтле судья, хөрмәтле суд утырышчылары, иптәшләр!— дип, судка бик тә тирән илтифат-такт белән башлап китте бу, үзенә сүз бирелгәч,— «өч хатын аерган» дигәне нигездә дөрес тә булсын, ди. Узган эшкә салават, анысын сузып тормыйк, кайберәүләр өчтән дә уздырып җибәрәләр, кайберәүләр, вообще, чутын да алып тормый, чут төймәсенә салып тора торган эшмени ул, үзегез уйлап карагыз,— бераз артыграк кызып китмәдемме, дип уйлап, чак кына пауза ясады. Аннары сабыррак тон белән янә ялгап китте,— дөрес, аның язганында Хәбибрахманов дип түгел, Рахманов дип кенә йөртелә. Ләкин уйламагыз, мин писатель түгел дә, ул яктан берни дә белмим дип. Беләбез: эшнең зурга китүеннән шүрләп фамилияне бераз үзгәртү нәрсә алар өчен. Чүп тә түгел. Әйтик, Хәбибрахманов дигән фамилиядән «Хәбиб»не атып бәреп, Рахманов итеп кенә калдырды, ди. Аннан эш үзгәрәме? Пычагым да үзгәрми. Фактически минем турыда язылган статья бу и баштанаяк клевета, панимаеш. Әйтик, өч хатын, ди, фактически бусы дөрес тә булсын, ди. Әйткәнемчә, өчтән уздырып җибәрүчеләр дә бар, шушы без йөргән юлдан ук йөриләр. Мәсьәлә анда түгел, мәсьәлә детальләрендә. Әйтик, «беренче хатынын куып җибәрде» дигән статьяда, Әсманы әйтә ул. Әнә күршеләр утыра, беләләр Әсманың характерын. Куарсың Әсманы. Ул сине куар, даром гына да түгел, артыңа иң элек бик шәпләп тибеп калыр и, ул гына җитмәсә, артыңнан чабып килеп, өстеңә бер чиләк лакан суы кояр. Характерыбыз килешмәде Әсма белән и, фактически алып әйткәндә, тагы бер сәбәбе бар: баланы күп китерде. Өч ел тордыкмы икән, өч елга өч бала тупырдатты да куйды, панимаеш. Әгәр утыз ел бергә тора калсаң, утыз бала дигән сүз. Кем түзсен моңа. Үзең бул шоп-шома сиксән сумга бөкреңне чыгарып утыручы служащий. Куып җибәрмәдем Әсманы, үзем чыгып киттем Әсмадан. Фактически перспективасыз эш икәнлеген алдан күреп.

Аннан кире, килеп җиттек, ди, Мөсфирәгә. Яшь, матур, җырлый белә, иң шәп җырчыларныкы язылган ике йөз пластинка гына җыйды. Ташып торган культурный. Кибеттә эшли, дус-ишләре белән сөйләшеп, мине дә кибеткә урнаштырдылар. Ашаганыбыз бал да май, йөргәнебез такси. Шулай гөрләтеп торганда, әллә тагы дус-ишләренең күп булуы да эшне бозды, бер дә бер көнне, көнне түгел, кичне, фактически турыдан-туры ярып салмасынмы:

— Картая башладың син, Рәүф. Туры әйткәнгә хәтерең калмасын, көндез ярый да барасың, кеше арасында күрсәтерлек фигураң, буең-сының бар, әмма кичлегең юк, җаным, бигайбә,— ди.

— Хөрмәтле судья, хөрмәтле суд утырышчылары, иптәшләр, үзегез уйлап карагыз, бихисап авыр сүз бу ир өчен. Кайсы гына ир моңа түзеп торыр икән. Һич ялгансыз әйтәм, яшен суксын әгәр ялганласам, түзә алмадым бу хурлыкка, ормадым-сукмадым, ридикюлен

и башка чүп-чарын кулына тоттырдым да, барып, ишекне ачтым һәм гомердә сызгыра белми торган кеше, панимаеш, дәррәү сызгырып җибәрдем: «Выжт! — мин әйтәм,— кашың-күзең исән чакта». Каршы килмәде, китте. И шуны фактически миңа гаеп итеп такмакчы язучы. Бүрәнә аркылы бүре күрә бу язучы халкы да...

Аннан кире, килдек, ди, Таифәгә. Дөрес, мактана алмыйм, кашыкүзе әллә нәрсә түгел, илла тотар җире юк иде дип әйтмәс идем. Олыгаеп барган мәлгә ярый иде бусы, аш-суга да оста иде, торып калырга бик тә исәп бар иде, но бит бер килмәсә килми кешегә: бала китерми торган хатын булып чыкты Таифә. Хәер, үз гаебен үзе танмады, шито-крыто, аерылыштык. Хәтта җылады да түгелме әле киткәндә?

— Минем әйтердәй сүзләрем менә шул, иптәш судьялар. Кешенең кайгысын-борчуын аңлап, аның хәленә керер бервакытта, панимаеш, Хәбибрахманов дигән фамилиядән «Хәбиб»не йолкып ат та, аның өстенә дөньяга фаш булырлык бөһтан бәла як. Мин әле аны, то есть язучыны, минем Хәбибрахманов дигән фамилиядән «Хәбиб»ен кырып аткан өчен дә судка бирә алам. Әле әйткән булалар үзләрен, «кеше рухының инженерлары» дигән булалар. Какой инженер син, кешенең авырткан җирен түбәләгәч.

Язучыга сүз бирелде, ул, мескен, нәрсә дисен! «Кеше рухының инженеры» булса да, әллә ни җәелеп китә алмады:

— Валлаһи-билләһи, мин Сезнең турыда язам дип язмадым, Рәүф абый. Просто бер туры килү генәдер. Хәтта бу очраклы туры килү өчен дә менә иптәш судьялар алдында гафу итүегезне үтенәм.

Суд икән — суд, бөтен ваклыкларын китереп суздылар-суздылар да, «гаепләү составы җитмәү сәбәпле», «Эш»не шуның белән туктаттылар. Ә тамаша итеп «болай гына карап утырырга» килгән кешеләр, суд утырышыннан таралышлый үзара сөйләшә-сөйләшә, яклларның икесен дә гаепләделәр:

Рәүф Хәбибрахмановны, «Каракның бүреге яна» дигән хакыйкатькә туры китереп, үзенең бөтен чүп-чарларын халык алдына чыгарып селкегәне өчен.

Ә язучыны, тормыштагы хәл-әхвәлләрне шулай якынтын белеп, бер дә майламыйча-җайламыйча, дөрес итеп язып чыгарганы өчен.

1975.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КИТАП НӘШРИЯТЫ — 1976 ЕЛДА

Татарстан китап нәшрияты 1976 елда китаплар бастыру планын чыгарды. План КПСС Үзәк Комитеты съездлары, пленумнары карарлары яктылыгында китап нәшриятларына куелган бурычларны күз алдында тотып төзелгән. Аның тематикасы бай һәм төрле.

Масса-политика, производство-техника, авыл хуҗалыгы редакцияләрендә чыгачак китапларда Татарстан хезмәт ияләренең һәм партия оешмаларының тугызынчы бишьеллык планны үтәү, арттырып үтәү өчен фидакарь хезмәтләре беренче планга куела. КПССның XXV съезды материалларын бастыру, аларны пропагандалау өчен 70 табактан артык китап чыгарырлык резерв калдырылган.

Матур әдәбият әсәрләренә дә зур урын бирелгән. Проза, поэзия, әдәби тәнкыйть әсәрләре, кечкенәләр өчен матур итеп бизәлгән китаплар барлыгы 120 дән артык исемдә чыгачак. Шулай ук җыр китаплары, ноталар, альбомнар, төрле темага багышланган плакатлар да шактый.

Габдулла Тукайның тууына 90, Тажи Гыйззәтнең 80, Муса Җәлилнең 70 ел тулу даталары уңае белән һәрберсенең дүртәр томлык сайланма әсәрләре чыгачак.

Планга кергән һәр китапның эчтәлеген, темасын әйтеп, аннотацияләр бирелгән.

Татарстан китап нәшрияты планы илебездәге барлык республика, край, өлкә китап сәүдәсе оешмаларына, потребсоюзларга җибәрелде. Китапханәләр, мәктәпләр китапларга шулар аша заказ бирә алалар. Казанда аерым укучылар соравы буенча китаплар җибәрә торган махсус кибет бар. Адресы: г. Казань, ул. Октябрьская, 18, магазин № 14, «Книга-почтой».

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУ

Язучыларның чираттагы гомуми җыелышы «Казан утлары» журналының 1—6 саннарын тикшерүгә багышланды.

Язучы Әдип Маликов журналда басылып чыккан очерклар, Хәсән Сарьян проза әсәрләре, Зиннур Насыйбуллин поэзия, әдәбият белгече, филология фәннәре кандидаты Фатих Урманчеев тәнкыйть мәсьәләләре турында доклад ясады.

Фикер алышуларга СССР Язучылар союзы секретарьлары Олег Шестинский белән Зәки Нури (журналның баш редакторы), Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Габдрахман Минский, Нәби Дәүли, Мәдинә Маликова һәм Флүн Мусин катнашты. Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов сөйләшүләргә йомгак ясады.

*

* *

Шул ук җыелышта РСФСР язучыларының IV съездына делегатлар сайланды. Делегация составына: Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Зәки Нури, Хәй Вахит, Аяз Гыйләҗев, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Әдип Маликов, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Шәүкәт Галиев, Михаил Скороходов, Шамил Бикчурин, Марс Шабаев, Әхсән Баянов, Марсель Зарипов, Вакыйф Нуруллин, Мәдинә Маликова, Хәкимҗан Халиков, Яхъя Халитов, Фарваз Миңнуллиннар керде.

## КИТАП СӨЮЧЕЛӘР КИҢӘШӘ

Күптән түгел китап сөючеләр җәмгыятенең район, шәһәр бүлекчәләре председательләре һәм җаваплы секретарьлары үзләренең беренче киңәшмәләренә җыелды. Китап дуслары алдында торган бурычлар турында доклад белән җәмгыятьнең республика идарәсе председателе, ТАССР культура министры урынбасары М. Низамиев чыкты.

Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов залдагыларга котлау сүзләре белән мөрәҗәгать итте, әдипләребезнең иҗат планнары белән таныштырды. Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов киңәшмәгә катнашучыларга киләсе елда чыгачак әсәрләр турында сөйләде.

Китап пропагандасының нәтиҗәлелегенә ирешү, китап сәүдәсен тагын да җанландыру, халык арасында аң-белем таратуның яңа формаларын куллану, матур әдәбият дуслары оештырган махсус клубларның эше — чыгышларда сүз әнә шулар турында барды. В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсе директоры М. Делешева, Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә хезмәткәрләре В. Аристов һәм А. Фәтхиев, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре З. Бухараев, Максим Горький музее каршындагы китап дуслары клубы председателе В. Шатунова, Таткниготорг директоры урынбасары Н. Нуретдинова, Татпотребсоюзның китап сәүдәсе бүлеге начальнигы Р. Балдина, республика балалар китапханәсе методисты С. Юльметова һәм башкалар китап сөючеләрнең мактауга лаек эшләре турында сөйләделәр.

Китап сөючеләр Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә, беренче номерлы китап кибетендә булдылар.

Аннары китап дуслары язучылар һәм шагыйрьләр белән очраштылар. Алар алдында Рәдиф Гатауллин, Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова, Әхмәт Рәшитов, Госман Садә чыгыш ясады.

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Үзбәкстанның Карши шәһәрендәге Максим Горький исемендәге китапханәдә Муса Җәлилнең тормышына, иҗатына, аның якты истәлегенә багышланган әдәби кичә булды. Кичәгә катнашучы мамык үстерүчеләр фашист тоткынлыгында Мусаның көрәштәше булган, хәзер укытучы булып эшләүче Фәрит Солтанбековның чыгышын зур дулкынлану белән тыңладылар.

Ф. Солтанбеков китапханәгә татар язучысы Р. Мостафинның «Герой-шагыйрь эзләреннән» дигән китабын бүләк итте.

## ҮЗБӘК ТЕЛЕНДӘ МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ЯҢА КИТАБЫ

Муса Җәлилнең «Билгесез сукмаклар» исемле шигырьләр җыентыгы Ташкентта, «Яшь гвардия» нәшриятында үзбәк телендә 10 мең тираж белән басылып чыкты.

## ФЕРМА — МУСА ҖӘЛИЛ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

Халык җырларына кергән Зөя суы буенда «Ватан» колхозының җәйләве җәелеп киткән. Монда — товарлыклы-сөтчелек фермасы маллары.

Җәйләүгә электр кертелгән. Сыер савучы кызлар, операторлар — барысы да урта белемле. 1974 елда алар һәр сыердан 3318 килограмм сөт саудылар һәм район хуҗалыклары арасында беренче урынны яуладылар.

Елның-елында югары күрсәткечләргә ирешә барганнары өчен, Буа районындагы «Ватан» колхозының комсомол-яшьләр фермасы коллективына Татарстан комсомолының герой-шагыйрь Муса Җәлил исемендәге премиясе бирелде.

Тугызынчы бишьеллыкны тәмамлау елында яшь терлекчеләр яңа уныш казандылар.

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Республикабыз җәмәгатьчелеге атаклы драматург, артист һәм җәмәгать эшлеклесе Таҗи Гыйззәтнең тууына 80 ел тулу көнен киң билгеләп үтте. Югары уку йортларында, мәктәпләрдә, культура йортларында, китапханәләрдә аның тормыш юлына һәм иҗади эшчәнлегенә багышланган әдәби кичәләр булды, китап күргәзмәләре оештырылды.

Казанда, Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры бинасында шушы мөһим дата уңае белән тантаналы кичә үткәрелде.

Кичәне өлкән драматург Риза Ишморат ачты. Филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт Таҗи Гыйззәтнең иҗади эшчәнлеге, аның әсәрләрендәге төп социаль юнәлеш һәм уңай герой проблемасы турында доклад ясады. Кичәнең икенче бүлегендә Академия театры артистлары «Ташкыннар», «Чаткылар», «Кыю кызлар» спектакльләреннән өзекләр күрсәттеләр, ә М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры артистлары Таҗи Гыйззәт пьесаларыннан, музыкаль драма һәм комедияләреннән арияләр, ариозалар, җырлар башкардылар.

## ОЧРАШУЛАР

Язучы Самат Шакир, Братск ГЭСы төзелешендә берничә тапкыр булып, дөньядагы иң зур гидроэлектростанция төзүчеләр турында очерклар, шигырьләр циклы һәм мәкаләләр язган иде. Шулай ук ул төзүчеләр белән әдәби очрашулар үткәрде, яшь каләмнәрнең әсәрләрен укып, консультацияләр бирде.

Күптән түгел С. Шакир яңадан Братскида булды. Братск ГЭСы төзелешендәге эшчеләрнең һәм инженер-техник работникларның хезмәтләрен матур әдәбиятта яктыртуы өчен, төзелешнең егерме еллыгы уңае белән, С. Шакирга «Братск — ГЭСстрой, 20 ел» дигән знак-медаль, истәлек папкасы һәм сувенирлар бирелде.

* * *

Самат Шакир Төркмәнстан ССРның Кушка шәһәрендә булып кайтты. Ул анда басмачыларга каршы көрәштә катнашкан Татар полклары сугышчыларының эзләре буйлап, китап язу өчен материаллар туплаларга барган иде. Язучы Кушка гарнизонында хезмәт итүче пограничниклар белән очрашты, аларга үзенең шигырьләрен укыды.

## ТЕАТРНЫҢ ЯҢА УҢЫШЫ

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрының Мәскәүдәге гастрольләре уңышлы тәмамланды. Шул уңай белән СССР Культура министрлыгы һәм РСФСР Культура министрлыгы приказы белән халыкны, аеруча яшь буынны Ватанга бирелгәнлек рухында тәрбияләүдә зур әһәмияте булган «Бер төн» (Б. Горбатов) спектакле өчен театр коллективына һәм театрның баш режиссеры РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Сәлимҗановка премия бирелде.

## ЛАЕКЛЫ БҮЛӘК

Совет театр сәнгате өлкәсендә озак еллар дәвамында һәм нәтиҗәле эшләве өчен, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры директоры **Рәшидә Габдуллаҗан кызы Җиһаншина КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

# 1975 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

## ПРОЗА

Р. Батулла. **Җитмеш җиде пәһлеван.** Әкият. № 2.
Ә. Гаффар. **Теге гозер...** Повесть. № 12.
А. Гыйләҗев. **Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят.** Повесть. № 8.
Ә. Еники. **Гөләндәм туташ хатирәсе.** Кечкенә роман. № 9, 10.
Б. Камалов. **Җир хакы — ир хакы.** Хикәя. № 2.
Э. Касыймов. **«Зинһар, рәнҗемә!»** Этюдлар. № 4.
Г. Мөхәммәдова. **Яшьлек көннәре.** Повесть. № 1, 2.
В. Нуруллин. **Яшьнәп үткән яшьлек.** Повесть. № 11, 12.
Ү. Саттаров. **Кызым хикәяләре.** № 1.
С. Сөләйманова. **Сагы барның сагы ятар.** Хикәя. № 7.
М. Хәсәнов. **Хәдичә.** Романнан өзекләр. № 1.
Хәниф Хәйруллин. **Картлык... кемгә шатлык!** Повесть. № 3.
М. Хәбибуллин. **Чоңгыллар.** Роман. № 5, 6, 7.
Ф. Хөсни. **Мичче Гыйният.** Хикәя. № 6.
Ф. Шәфигуллин. **Әкълимәгә — ислемай.** Хикәя. № 10.
Г. Шәрәфи. **Аккошлар кайтыр әле.** Хикәя. № 11.

## ПОЭЗИЯ

Г. Афзал. **Уйланулар дәфтәреннән.** Шигырьләр. № 6.
Н. Арсланов. **Батырлык турында.** Шигырьләр. № 1.
Ә. Баянов. **Кышкы чәчәкләр.** Поэма. № 2.
Ә. Баянов. **Йолдызлар җитә...** Шигырьләр. № 11.
К. Булатова. **Борынгыдан урман-суларга бай.** Шигырьләр. № 3.
М. Газизов. **Авырлык үзәге.** Шигырьләр. № 4.
Р. Гатауллин. **Нигез сагындырса.** Шигырьләр. № 11.
Э. Гыйрфанова. **Кояшлы яңгыр кебек.** Шигырьләр. № 3.
Р. Гәрәй. **Шигырь укыттылар.** Шигырь. № 8.
Г. Зәйнашева. **Мәңгелек сакчы.** Җыр. № 6.
Г. Латыйп. **Күкләрем шундый биек.** Шигырьләр. № 6.
З. Мансуров. **Ипи.** Шигырьләр. № 7.
Н. Мадьяров. **Күзем текәп күксел офыкларга...** Шигырь. № 8.
Ш. Маннур. **Олы чишмә.** Шигырьләр. № 7.
Х. Мөдәрисова. **Тәрәзәмне каерып давыл керде.** Шигырьләр. № 3.
М. Ногман. **Айбулат.** Шигырь. № 7.
Н. Нәҗми. **Кайда булдым!..** Шигырьләр. № 9.
Г. Рәхим. **Тамыр.** Шигырьләр. № 4.
Г. Рәхим. **Авыл дәфтәреннән.** Шигырьләр. № 10.
Г. Садә. **Иген кыры...** Шигырьләр. № 8.
Ф. Сафин. Шигырьләр. № 12.
С. Сөләйманова. **Соңгы патрон.** Шигырьләр. № 1.

Х. Туфан. Шигырьләр. № 12.
В. Туктарова. **Ни диеп шаулыйсыз.** Шигырьләр. № 3.
Е. Уткин. **Әнкәй дә гел җыеп ала иде...** Шигырь. № 8.
Р. Фәйзуллин. **Төрле дәфтәрләрдән.** Шигырьләр. № 3.
Р. Хисамиев. **Уҗым булып калка.** Шигырьләр. № 4.
Р. Харис. **Сагындырган.** Шигырьләр. № 10.
Х. Хөснуллин. **Сабан туе туган якларымда.** Шигырь. № 8.
А. Хәлим. **Кышкы фантазия.** Шигырьләр. № 11.
С. Шәрипова. **Акчарлактай ак самолет.** Шигырьләр. № 4.
Ф. Шәфигуллин. **Диңгез төне.** Шигырьләр. № 9.
Ф. Яруллин. **Ничек булыр!** Шигырь. № 8.
Н. Әминова. Шигырьләр. № 12.
Н. Әхмәдиев. **Бодайларның керфек каккан чагы...** Шигырь. №
Роберт Әхмәтҗанов. **Чал платан төбендә.** Шигырьләр. № 8

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕННӘН

А. Исаакян. Шигырьләр. № 10.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. Каюмов. **Тукайга барам.** Шигырьләр. № 10.

## ДУСЛАР ИҖАТЫ

С. Вагуни. **Солдат итеге турында җыр.** Шигырь. № 3.
А. Граши. **Төнге баллада.** Шигырь. № 3.
С. Капутикян. **Син мине озата барганда.** Шигырьләр. № 3.
Й. Мөхлисев. **Кашгар дәфтәре хатирәләреннән новеллалар.** № 12.
А. Погосян. **Реквием.** Шигырь. № 3.
Р. Патканян. **Тургай.** Шигырь. № 3.
Г. Эмин. **Алар күпләр.** Шигырь. № 3.
Т. Әйди. **Моң һәм нәфрәт парчалары.** № 12.

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Ш. Хөсәенов. **Әнием нең ак күлмәге.** Пьеса. № 6.

## БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

З. Гомәрова. **Бабай тарта шалканны.** Шигырьләр. № 3.
Ш. Галиев. **Жираф белән Зариф.** Шигырьләр. № 6.
Җ. Дәрзаманов. **Солдат булдым.** Шигырьләр. № 3.
М. Мәһдиев. **Котелмәгән сораулар.** Парчалар. № 7.
Р. Мингалимов. **Малайлар.** Шигырьләр. № 9.
Х. Халиков. **Зиләнең курчагы.** Шигырьләр. № 1.

## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Г. Афзал. **Очкыннар.** Шигырьләр. № 3.
А. Буланов. **Электр баганасы.** Шигырьләр. № 4.
В. Багряшевский. **Чуклы тал.** Хикәя. № 10.
**Бервакыт шулай була.** № 4.
Х. Гатин. **Шәп машина.** Шигырьләр. № 6.

А. Дубин. **Мәзәк хәлләр. № 2.**
Ж. Дәрзаманов. **Өйләнеп бер ел торгач.** Шигырь. **№ 4.**
Ә. Исхак. **Үтенеч хаты.** Шигырьләр. **№ 1.**
Г. Латыйп. Шигырьләр. **№ 11.**
З. Мансур. **Дуслар хөкеме.** Шигырьләр. **№ 11.**
З. Нури. **Төн трагедиясе.** Шигырьләр. **№ 2.**
З. Нури. **«Чәнечкеле китап»тан.** Шигырьләр. **№ 11.**
**Осетин мәзәкләре. № 1.**
**Сугыш еллары юморыннан. № 5.**
И. Туктар. **Җөмләләр. № 11.**
Фәнияр. **Эпиграммалар. № 11.**
Ф. Хөсни. **Икесе дә гаепле.** Хикәя. **№ 12.**
Ф. Яруллин. **Сөбханалла!** Шигырьләр. **№ 3.**
М. Әмир. **«Чаян» фронтта. № 6.**

## БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

А. Айнетдинов. **Юллар батырлыкка чакырды. № 4, 5.**
Н. Арсланов. **Узганнарны хәтерләгәндә. № 5.**
И. Ахунжанов. **Мәхәббәт һәм нәфрәт җырчысы. № 5.**
Г. Бакиров. **Ул елларда. № 3.**
Б. Боотур. **Пушкин таулары итәгендә. № 4.**
Х. Вахит. **Мин — солдат. № 5.**
И. Вергасов. **Кырым партизаннары.** Хикәяләр. **№ 8, 9.**
И. Гази. **Көен дәфтәреннән. № 5.**
М. Гаяз. **Оясыз калган сыерчык.** Шигырь. **№ 9.**
Гиз-эль Габид. **«Окоп дәфтәре»ннән.** Шигырьләр. **№ 9.**
Ян Грант. **Кечкенә инешнең башы. № 1.**
Җ. Гыйльманов. **Якташларыбыз дошман тылында. № 6.**
М. Дибаева. **Хатлары килә, үзләре кайта. № 6.**
**Заман дәшә сезгә, җырлар дәшә. № 5.**
Ш. Зәйни. **Фронтта очрашулар.** Истәлек. **№ 4.**
Х. Камалов. **Безне намус утка кертте. № 4.**
Н. Кравцова. **Багеровога таба. № 2.**
М. Кәримов. **Бездән алда яшәдегез.** Шигырьләр. **№ 3.**
М. Кәрим. **Минем Җиңү көнем. № 5.**
П. Лукницкий. **Нева «уч төбе». № 3.**
Ә. Маликов. **Солдат шигырьләре. № 5.**
А. Маркелов. **Утларда чыныккан. № 7.**
М. Мильштейн. **Фәрит. «Җен карчыгы». № 3.**
Т. Насыйров. **Ватан сугышы һәм китап. № 5.**
З. Нури. **22 июнь.** Шигырьләр. **№ 5.**
Г. Паушкин. **Кургаш ява.** Шигырьләр. **№ 5.**
П. Павленко. **Якташым Юсупов. № 1.**
Ш. Рәкыйпов. **«Мәңге сакларга!». № 3.**
М. Садри. **Мәскәү — Берлин.** Шигырьләр. **№ 5.**
С. Хәким. **Сугышның бер көне. № 5.**
М. Хөсәен. **Туган ил өчен!** Шигырьләр. **№ 5.**
Х. Хәйри. **Язучы һәм фронт. № 6.**
С. Шакир. **Империя канцеляриясен штурмлаганда. № 1.**
С. Шакир. **Полк комиссары. № 2.**
С. Шакир. **Утлы еллар дәфтәреннән. № 4.**
С. Шәкүров. **Истәлек. № 5.**
М. Әмир. **Сугышчан сәлам белән.** Хатлар. **№ 5.**
Г. Әпсәләмов. **Фронт газеталары редакциясендә. № 4.**
М. Җәлил. **Сугыштан соң.** Шигырь. **№ 5.**

### Абдулла Әхмәткә 70 яшь

А. Әхмәт. **Зәңгәр конверт.** Хикәя. № 3.

### М. Рафиковка 50 яшь

М. Рафиков. **Су буенда бер урам.** Авыл язмалары. № 4.

### Ә. Исхакка 70 яшь

Р. Мостафин. **Кызыл кошлар җырчысы.** № 5.
Ә. Исхак. **Ышану.** Шигырьләр. № 5.

### М. А. Шолоховка 70 яшь

М. Шолохов. **Алар Ватан өчен сугыштылар.** Романнан өзек. № 5.

### Гали Халитка 60 яшь

Г. Кашшаф. **Үзенчәлекле талант.** № 6.

### Салих Батталга 70 яшь

С. Баттал. **Яшәү мәгънәсе.** Шигырьләр. № 8.

### Сафа Сабировка 60 яшь

С. Сабиров. **Кар астында калган эзләр.** Хикәя. № 8.

### Сергей Есенинның тууына 80 ел

С. Есенин. **Аерым тамга белән тамгалана...** Шигырьләр. № 8.

### Г. Ахуновка 50 яшь

А. Гыйләҗев. **Күпне күрәбез!** № 9.
Г. Ахунов. **Утлар яна учакта.** Драма. № 9.

### Таҗи Гыйззәтнең тууына 80 ел

Р. Кәримов. **Драматургиябез горурлыгы.** № 9.
Т. Гыйззәт. **Идел буйлары.** Юлъязмалар. № 9.

### Заһидә Бурнашевага 80 яшь

М. Гайнуллин. **Азатлык яулап.** № 10.
З. Бурнашева. **Бала шигыре.** Шигырьләр. № 10.

### Каюм Насыйриның тууына 150 ел

Я. Абдуллин. **Каюм Насыйри иҗатында мораль-этик мәсьәләләр.** № 2.
С. Акбиев. **Каюм Насыйри һәм Әбүсуфьян Акаев.** № 2.
Ә. Кәримуллин. **Каюм Насыйриның «Таң йолдызы» проекты.** № 2.

## Хәй Хисмәтуллинга 80 яшь

Н. Юзиев. **Озын гомер, бай тормыш. № 11.**
Х. Хисмәтуллин. **Үткән юллар. № 11.**

## Г. Иделлегә 70 яшь

**Хезмәт шатлыгы. № 12.**
Г. Иделле. **Беренче остазым. № 12.**

## Г. Тукайның 90 еллыгына

В. Исхаков. **Тукай белән очрашу. № 4.**
Әхмәт Фәйзи. **Тукай һәм рус әдәбияты. № 12.**
Х. Хөснуллин. **Халкы җиккән атта.** Шигырь. **№ 4.**
**Шагыйрьнең бөеклеге. № 4.**

## М. Җәлилнең 70 еллыгына

Җ. Дәрзаманов. **Пистолет монологы.** Шигырь. **№ 9.**
И. Зәбиров. **Җәлил дусты. № 9.**
И. Ильенко. **Үлемсез дуслык. № 2.**
М. Мохтарова. **Шагыйрь тормышыннан бер сәхифә. № 2.**
Р. Мостафин. **Аны комсомол үстерде. № 11.**
Л. Небенцаль. **Муса Җәлил эзләреннән. № 9.**
Л. Попов. **Муса Җәлил Якутиядә.** Шигырь. **№ 11.**
М. Рәхимкулова. **Җәлилнең «Хөсәения» чоры. № 2.**
С. Сөләйманова. **Җәлил.** Шигырь. **№ 9.**
А. Шпирт. **Ул легенда булып кайтты. № 11.**
**Яңа документ раслый. № 11.**
Ч. Җәлилова. **Август көннәрендә Берлинда. № 9.**

### ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Г. Агишева. **Мәңгелек дуслык. № 1.**
Ф. Ильская. **Һаман истә. № 10.**
Г. Кайбицкая. **Ситдыйк Айдаров. № 10.**
Г. Кайбицкая. **Якты йолдыз белән янәшә. № 12.**

### ОЧЕРКЛАР

Р. Вәлиев. **Таяну ноктасы. № 4.**
Н. Габдуллин. **БАМ тайга аша үтә. № 10.**
М. Зарипов. **Киңлекләр. № 8.**
**КамАЗ елъязмасы. №№ 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12.**
К. Латыйпов. **Бүгенге батыр. № 1.**
М. Миншин. **Ак ефәк. № 9.**
М. Маликова. **Мең дә бер сынау. № 12.**
М. Мәхмутов. **Геленҗик янында булган хәл. № 10.**
Ф. Насыйров. **Рәхмәт сезгә, кешеләр! № 7.**
Г. Паушкин. **Чаллы сәхифәләре. № 4.**
И. Салахов. **Сиреньнәр чәчәк атканда. № 11.**

К. Тимбикова. Әминә киләмнәре. № 3.
К. Фәсәхов. Туган авыл, туган җир. № 6.
Х. Хәсәнов. Революционерның соңгы хатлары. № 11.
М. Хөснимәрдәнов. Солдат хатлары. № 2.
З. Шәфигуллин. Бөреләр ачылганда. № 3.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Г. Коновалов. Тарихи язмышлары ягыннан бертуганнар. № 1.
Ф. Табеев. Бишьеллыкның алгы сызыгында. № 4.
Ф. Әгъзәмов. Социалистик реализм әдәбиятының нигез ташы. № 12.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ә. Баянов. Үсеш гармониясе. № 1.
М. Зарипов. Киңрәк колач белән. № 11.
Ш. Максудова. Бер сорауны ачыклау кирәк. № 10.
Ф. Миңнуллин. Беренче нәтиҗәләр. № 8.
Ф. Мусин. Заман героена йөз тотып. № 6.
М. Мәһдиев. Югарыга карап фикер ит. № 9.
Т. Нурмөхәммәтов. Үз галәме, үз киңлекләре. № 11.
Г. Рәхим. Киләчәккә узып барышлый. № 9.
Ф. Урманчеев. Тәнкыйтьченең осталыгы. № 8.
Югары сыйфат, иҗади активлык. № 8.
Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында. № 8.
Ю. Әминов. Бүгенге драматургиябез хакында кайбер фикерләр. № 10.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Я. Абдуллин, Ч. Бәхтиярова. Сәнгатьтә милли һәм интернациональ якларның диалектикасы. № 8.
Ш. Асылгәрәев. Реализм турында. № 9.
М. Галиев. Ачыктан-ачык. № 1.
Р. Галявин. Көлке көлә кипә. № 11.
Ф. Ганиева. Заман темасын заманча чишик. № 12.
Ф. Галимуллин. Әдәбият хәзинәсе. № 12.
Ф. Миңнуллин. КамАЗ китаплары. № 4.
Г. Куклис. Әмирхан Еникинең күп төрле геройлары. № 7.
Ә. Камал. Тәүбә итү — төзәлү түгел әле. № 6.
Р. Мостафин. Эшче коллектив ничек туа. № 1.
Р. Мостафин. Күп бизәкле, бердәм әдәбият. № 7.
Ф. Мусин. Фәндә яңа агым. № 10.
Ә. Мәхмудов. Шагыйрәнең «Фал китабы». № 2.
Ф. Урманчеев. Уйланулар, борчылулар. № 5.
Ф. Урманчеев. Әдәби осталык мәсьәләләре. № 11.
Р. Фәйзулла. Таң шәһәре. № 2.
Ф. Хатипов. Тугрылык һәм батырлык. № 8.
М. Юныс. «Муса Җәлил» океаннар гизә. № 6.
Ф. Әгъзәмов. Иҗат чишмәләре. № 10.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Т. Галиуллин. **Җырдан — җырга. № 7.**
Н. Хисамов. **Заман һәм шагыйрь. № 2.**

## ӘДӘБИ МИРАС

**Әнвәр Давыдов. № 3.**

## ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Ф. Ганиев. **Кушма фигыльләр — хәрәкәт тасвирының куәтле чарасы. № 10.**
В. Хаков. **Гасырлар сулышы. № 11.**

## ТӘРҖЕМӘ ТЕОРИЯСЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Р. Ахунов. **Әдәби тәрҗемәдә компенсация методы. № 8.**

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Р. Кукушкин. **Шагыйрь һәм образ. № 5.**
З. Мәҗитов. **Һәр шагыйрьнең үз тавышы. № 4.**
Ф. Мусин. **Әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтьтә стиль мәсьәләләре. № 12.**
Г. Халит. **Иҗат методы һәм стиль мәсьәләләре.** Беренче мәкалә. **№ 3.**
Г. Халит. **Иҗат методы һәм стиль мәсьәләләре.** Икенче мәкалә. **№ 4.**
Ф. Әгъзәмов. **Социалистик реализм әдәбиятының нигез ташы. № 12.**

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Г. Таһирҗанов. **Татар әдәбиятының катлаулы мәсьәләләре.** Беренче мәкалә. **№ 7.**
Г. Таһирҗанов. **Әдәбият тарихында иҗтимагый-мәдәни мөнәсәбәтләренең роле. № 8.**
Г. Таһирҗанов. **Әдәби бәйләнешләр һәм аларның нәтиҗәләре. № 10.**

## БЕРЕНЧЕ РУС РЕВОЛЮЦИЯСЕНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

М. Абдуллин. **Беренче рус революциясендә татарлар һәм хәзерге буржуаз историография. № 1.**
Ш. Хамматов. **Татарстанда революция көннәре. № 10.**

## СӘНГАТЬ

Я. Абдуллин. **Татар мәгърифәтчеләре сәнгать һәм аның социаль роле турында. № 11.**
Ч. Бәхтиярова. **Казан консерваториясенә 30 ел. № 12.**
Й. Вәлитова. **Ул йолдыздай балкыды. № 10.**
И. Илялова. **Актер осталыгы. № 12.**
Ф. Кадыйрова. **Татар театрында романтизм. № 6.**
М. Мәһдиев. **XX йөз башы татар публицистикасында рәсем сәнгате мәсьәләләре. № 10.**

М. Нигъмәтҗанов. Олы максатка йөз тотып. № 3.
А. Файнберг. Яхшы да булсын, төрле дә. № 6.
Р. Хәйретдинов. Музыка профессоры Мансур Солтанов. № 1.
С. Червонная. Без Казаннан, Иделдән. № 6.

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

В. Галиев. Тылмачлар, сәяхәтчеләр, дипломатлар. № 1.
К. Фасеев, Ә. Булатов. Мәгърифәтче галим Шәмсетдин Кұлтәси. № 7.
Р. Фәхретдинов. Казан арты. № 11.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

С. Акбиев. Мулланур Вахитов һәм Сәид Габиев. № 1.
С. Латыйпова. Идел буе халыклары һәм декабристлар хәрәкәте. № 12.
С. Мәүленов. Җырлы Казан. № 12.
М. Ногман. Казан йодызлары. № 6.
М. Садри. Соңгы очрашу. № 6.
В. Семенова. Гадел Кутуй турында. № 6.
Б. Сәмигуллин. Әдипнең яңа табылган бер рәсеме. № 1.

Укучылар сүзе. № 3.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

«Без — җиңәргә өйрәнгән халык». № 11.
И. Рәми. Шакир Мөхәммәтов. № 5.
С. Шакир. Нур Баянның тууына 70 ел. № 5.
З. Шәрәфетдинов. Казан лингвистика мәктәбенә 100 ел. № 10.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1 — № 12.


# КАМАЗ-БАТЫР

БАТУ МУЛЮКОВ музыкасы

ЗӘКИ НУРИ шигыре

Tempo di marcia






Үсә ярда яңа кала — Чаллы,
Яңа гигант сала Чаллы, Чаллы.
Төрле яктан, ерак юллар үтеп,
Килдек сине якын итеп.

Днепро, Кузбасс, Магнитка —
Үткән юлыбыз.
Бүген — КамАЗ, бүген аны
Җырда зурлыйбыз.

Үсә ярда яңа кала — Чаллы,
КамАЗ-батыр сала Чаллы, Чаллы.
Матур җырлар җырлап мактана ил:
Туа яңа автомобиль!

Җирдә иркен юллар буйлап
Ул батыр үтәр —
Бездән ерак-еракларга
Сәламнәр илтәр.

Үсә ярда яңа кала — Чаллы,
Яңа гигант сала Чаллы, Чаллы.
Синдә сүнмәс яшьлек эзе кала,
Синдә яшьлек үзе кала.

КамАЗ — бөек чор даны,
Ил төзи аны.
КамАЗ — батыр, КамАЗ — матур!
Ул — яшьлек даны.

## Журнал укучылар игътибарына

Редакциягә килгән хатлардан күренгәнчә, журналыбызны укучыларның кайберләре, төрле сәбәпләр аркасында, 1976 ел өчен журналга языла алмый калганнар. Алар: «Инде без ни эшлик? Журналга ничек язылыйк? Бу эштә безгә ярдәм итсәгез иде», дип үтенеп язалар. Ул иптәшләргә редакция үзе берничек тә ярдәм итә алмый. Чөнки газета-журналларга яздыру һәм аларны укучыларга тарату эшен махсус органнар — «Союзпечать» агентлыклары һәм элемтә бүлекләре башкара. Безнең журналга вакытында языла алмый калган иптәшләргә аны 1976 елның март яки апрель аеннан алдыра башларга мөмкин. Моның өчен подписканы январь аенда ук гамәлгә ашырып куярга кирәк. Журналга подписка илебезнең теләсә кайсы элемтә бүлегендә кабул ителә. Ул бөтен союз газета-журналлар каталогына 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210